

# КАЗАН УТЛАРЫ

10

ОКТЯБРЬ

1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

10
ОКТЯБРЬ
1981

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

## *Бу санда*

ТАТАРСТАН ИЛЕБЕЗГӘ ИКЕ МИЛЛИАРД
ТОННА НЕФТЬ БИРДЕ

**Ф. САФИН.** Шигырь . . . 3
**А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Татарстан могҗизасы.** Хатирәләр, очрашулар, уйланулар . . . 4

**М. МӘҺДИЕВ. Торналар төшкән җирдә.** Лирик-документаль повесть . . . 36
**И. ЮЗЕЕВ.** Очты дөнья читлегеннән. Шигъри трагедия . . . 62
**Ә. ЕНИКИ. Соңгы китап.** Истәлекләр . . . 98

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

**М. ЗАРИПОВ. Ап-ак карабодай кырлары** . . . 133
**Э. МӨЭМИНОВА. Ул — остазым минем** . . . 141

КПССның XXVI СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

**Проблемаларның үзәгендә — кеше.** Түгәрәк өстәл янында . . . 145

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ф. МИҢНУЛЛИН. Хикәя һәм хикәячеләр** . . . 161

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Н. ХИСАМОВ. Шагыйрьнең күңел яктысы** . . . 169
**Ф. ӘГЪЗӘМОВ. Рухи туганлык нигезендә** . . . 172

МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

**М. МӨЛЕКОВ. Халык күңелендә калган моң** . . . 176
**И. ФӘЙЗУЛЛИН. Шодадагы көннәремнең таҗы.** Истәлек . . . 181

**Безнең сафка** . . . 184

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ф. Әсгатьнең тууына 80 ел . . . 186
Х. КУМЫСНИКОВ. Г. Болгарскаяның тууына 90 ел 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары 189

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия:** **ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** (баш редактор урынбасары), **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 24/VI-1981 ел. Басарга кул куелды 11/IX-1981 ел. ПФ 13302. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 102944 экз. Заказ Д-214
Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

# ТАТАРСТАН ИЛЕБЕЗГӘ ИКЕ МИЛЛИАРД ТОННА НЕФТЬ БИРДЕ



## Фәннур Сафин

* * *

Җир шарының «Дуслык» тамырында
Ярсып тибә туган җир каны —
Татарстан нефте —
Сокландыра
Европаны, бөтен дөньяны.

Бөек Идел-Чулман буйларының
Алтын куллы ул һәм кызлары
Инде
Ике миллиард тонна «кара алтын»
Күтәрәләр шулай югары:

Ургый байлык девон төпләреннән!
Заманага лаек дастан бу!
Ул янәшә куя батырлык һәм
Данлы җирем — Татарстанны!


Кешелекле дөнья, якты дөнья
Тынычлык дип янган илләрдә
Бөек Хезмәт — бүләк булсын, Илем,
Киләчәккә илтер юлларга!

## Аяз Гыйләҗев

# ТАТАРСТАН МОГҖИЗАСЫ

ХАТИРӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР, УЙЛАНУЛАР

## I. Сораулар



Язучы-галим Игорь Можейконың «7 һәм 37 могҗиза» дигән китабы бар. Ул моннан берничә еллар элек кенә «27 могҗиза» исеме белән укучылар арасында таралган иде. Язучы эзләнүләрен дәвам иттергән, моңарчы кешелек дөньясына мәгълүм булган атаклы 7 могҗизага — Мисыр пирамидаларына, Семирамиданың асылма бакчаларына, Галикарнас мавзолеена, Родос Колоссына, Александрия маягына, Эфесс Дианасы храмына, Олимпия Зевсы статуясына башта егермене өстәгән, хәзер исә дөнья могҗизалары санын 37 гә җиткергән. Галим могҗизаларны җирнең бөтен почмагыннан — Урта Азиядән, Якын һәм Ерак көнчыгыштан, Африка илләреннән, Һиндстан белән Шри Ланкадан эзләп тапкан, табышларының чын могҗиза икәнлеген фән һәм тарих белән дәлилләгән.

Шушы китапны уртага салып, якын дусларымның берсе белән дөнья хәлләрен сөйләшеп утырганда, һич көтмәгәндә, ул миңа мондыйрак сорау бирде:

— Ә бездә — Татарстанда?.. Могҗиза диярлек берәр нәрсә бармы? Мин уйга калдым.

Бездә могҗиза дәрәҗәсенә күтәреп, менә бу китапта саналганнарга тиң куярлык нинди фактны табып була икән? Бармы ул?..

Татарстаныбызга алтмыш ел тулган көннәр иде. Ул көнне без халкыбызның якты үткәне һәм матур бүгенгесе турында байтак сөенечле фактларны тезеп-тезеп сөйләшсәк тә, өзеп кенә «могҗиза» табып бирә алмадым. Дөрес, татар халкының яшәү перспективасы моннан күпме вакытлар элек кенә кап-караңгы һәм өметсез булган. Үткән йөзнең ахырында Казан шәһәрендә халык артык күп кырылганлыктан, рәсми статистика: «1960 елга Казан халкы үлеп бетәчәк», дип белдергән. Ә шушы гасыр башында халкыбызның күңел җырчысы бөек Тукай: «Татар халкы! Син үләргә мәхкүм инде!» дип сыкраган...

Шул халыкның республикасы, теле, музыкасы, театрлары, гореф-гадәтләре гөрләп чәчәк ату үзе олы бер могҗиза дип саналырга хаклы. Әмма мондый күренешне байтак халыкларда, Совет иленең барлык республикаларында күзәтергә мөмкин... Ни генә булса да, чынлап уйласаң, татар халкының бүгенге казанышларын могҗиза дип рәхәтләнеп атарга була.

Моннан ары, кая гына барсам да, кемнәр белән генә очрашсам да, күңелемнән шушы сорау китмәде: бармы ул безнең җирдә дә шул могҗиза дигәннәре?

Сентябрь урталарында КПССның Зәй горкомы секретаре сабыр акыллы һәм ифрат кешелекле Мәгъсум Гарипов белән Чаллы — Зәй юлыннан машинада барганда мин аңа да шушы сорауны бирдем. Ул, гадәтенчә, бераз уйланып барды да:

— Нигә булмасын? Мин үзебезнең Зәй районы күләмендә генә байтак гаҗәеп эшләрне саный алам. Уникаль ГРЭС! Зәй диңгезе! Һәммәсен бер итеп күз алдына китерсәң, чын могҗиза ич алар! — диде.

Бара-бара без кинәт сулга борылдык, юлсыз җиргә килеп кердек, вак-төяк чокырларны сыек ут көлтәсе белән капшап, үр менә башладык. Кич җитеп, бөтен җирдә моңсу эңгер куера башлаган чак иде. Ниһаять, кечкенә генә тауга менеп җиттек, машина кипкән үләннәрне шыштырдатып туктап калды. Төштек, кайсы тирәдә тукталуыбызны тиз чамаладым: аста, зәңгәрсу рәшәдә эреп аккан Зәй елгасы аръягында, сирәк елтыраган утлары белән Аксар авылы шәйләнә иде.

— Күрәсеңме? — дип сорады юлдашым, Чаллы — Зәй юлындагы тоташ ут чылбырына ишарәләп.

Кичке юл чыннан да искиткеч матур һәм мәгънәле иде: утлар олы бәйрәмдә кабынган факеллар төсле тоташтан агалар, тау өстенә, безнең янга машиналар гөрелтесе чак-чак кына менеп ирешсә дә, шушы тоташ хәрәкәт, дәвамлылык, җанлылык күңелдә әллә нинди шигъри, кайнар хисләр уята, уйландыра, чак кына моңсуландыра да иде.

— КамАЗлар китә,— дип аңлатты Мәгъсум Гарипович.

Зәй елгасы үзәнен яктыртып, кинәт мең яшен кабынгандай булды, мин: «Менә ич ул Татарстанның могҗизасы!» — дип чак кына кычкырып җибәрмәдем. Шушы бәләкәй тау өстеннән без тиңдәшсез тарихи вакыйганы күзәтеп торабыз икән ләбаса!

КамАЗлар китә! Тоташ, җанлы ут чылбыры булып, гөрли-гөрли Чаллы — Зәй юлыннан КамАЗлар уза! Мин мең мәртәбә җаяу, мең мәртәбә җигүле атның йөгәненә ябышып узган юлдан көчле-дәһшәтле машиналар уза! Илебезнең бөтен республикаларына, бөтен юлларына, төзелеш мәйданнарына, рудникларга, карьерларга, хуҗалыкларга, колхоз-совхоз кырларына, плантацияләргә шушы гайрәтле-егәрле сылулар — Алып батыр КамАЗлар тарала! Илебез кырларында, юлларында сезне очратып: «Саумысез, кардәшләрем!» дип сөенеп сәлам биреп уза торган идем, сезнең төп таралу юлыгыз монда икән, миңа бик таныш юлда. Зәй елгасы белән янәшә сузылып барган бу юл Көньяк белән Төньякны тоташтырган истәлекле юл, хатирәләр юлы, минем яшьлегемнең юлы... Менә нинди кодрәткә ия булган икән бүген ул юл!

Мин юлдашымнан:

— Бу тау ничек атала? — дип сорадым.

— Алтынтау,— диде Мәгъсум Гарипович.

Чынлап әйттеме ул, уйнап кына шулай дидеме, тауның исеме дә миңа искиткеч ошады, ул исем минем ул кичтәге халәтемә тулысынча туры килә, бу тауның исеме башкача булу һич мөмкин түгел иде! Алтынтау!.. Кич гаҗәеп җылы, рәхәт, юл сихерле иде, җанлы ут ташкыны, Татарстанның мактанычы КамАЗлар чын могҗиза иде! Ә могҗизаны тулысынча бәяләр өчен табигать Алтынтауны калкытып куйган...

— Бар ул, бар могҗиза! Безнең Татарстанда да бар! — дидем мин дустыма Казанга кайткач. Кичергәннәремне сөйләп бирдем.

Дустымның кашлары югары күтәрелде, ул минем белән нигездә килешсә дә, аның сораулы карашыннан «Автогигантлар бер Татарстанда гына түгел бит!» дигән сүзләрне дә аңладым.

Аңа кайбер ул белмәгән тормыш фактларын сөйләп бирергә кирәк иде. Минем «Могҗиза, чын могҗиза!» дип, чын күңелемнән әйтелгән сүзләрнең буш түгеллегенә аны ышандыру кирәк иде...

# 2. Сүз ачыклагычы өчен аз-маз хатирәләр

Җырга-моңга бай зәңгәр таулы Сарман районының Чукмарлы авылында тусам да, әтиемнәр утызынчы елда Зәй районының Югары Баграж авылына күчеп килгәннәр, кырык дүртнең көзенә хәтле мин шунда яшәдем. Өч яктан куе карурманнар белән уратып алынган, районның иң читендәге шушы керәшен авылы минем бала чагымның бишеге, яшьлегемнең нигезе булды. Тимер юлдан 110, су юлыннан 60 чакрым ераклыкта качып утырган бу авыл, үзе бер мөстәкыйль дәүләт кебек, күрше-тирә белән, киң дөнья белән артык аралашмыйча гына яши иде кебек. Авылның көнчыгышыннан тибеп чыккан нәни генә инешне дә багражлылар зурлап Олы су дип йөртәләр, безнең, чыннан да, шул инештән дә олырак суны күргәнебез юк иде! Инеш аръягында болын, болынның теге ягында саз-баткаклар башлана, куе яшькелт мүк тирбәлгән дәү келәмгә йомыры-йомыры түмгәкләр сибелгән, түмгәк саен тәкърарлек оясы... Сазлык безнең иң яраткан уен урыныбыз. Селкенеп торган түмгәк араларында качышлы уйныйбыз, мүктә пәкеле уйнау да рәхәт, шунда ук чәкәлешеп тә алабыз. Сазлык тирәсендә эш тә җитәрлек — мүк йолкабыз, анда-санда ялтырап яткан күлләрдән киндер көлтәсе чыгарабыз, мунчала каезлыйбыз. Беркатлы авыл уйлары тулган баш очыбыздан чыелдый-чыелдый тәкърарлекләр оча! Инеш аръягында җәен-көзен кеше өзелми! Бөтен йорт кирәк-яракларын, тормыш, хуҗалык нәрсәләрен Баграж кешеләре үзләре җитештерә, колхозның ныгыган чагы, тормыш бөтен, табын ашлы-сулы, хәлләр көйле иде. Мал-туар асрыйлар, кием-салымны авыл тегүчеләре тегә, һәркемнең өстендә кайры тун, искитәрлек! Киндер станында сугып, күлмәк-ыштанны да алачадан тегәләр, шәлне дә үзләре бәйли, тоз белән «кырачин» кайтып торса, багражлылар үз хуҗалыклары белән рәхәтләнеп яшиләр. (Көмешкәне кайнатсалар да, сугышка кадәр безнең авылда аракы эчү бик чикләнгән иде!) Клуб (элек чиркәү булган!) гөрләп тора, спектакльләрне авыл яшьләре куя, безнең атаклы гармунчыларыбыз, җырчыларыбыз, биючеләребез бар...

Шунда, инеш аръягында, кызыклы гына бер күзәтүебез бар иде безнең. Сазлыкның тирбәлеп торган урынына бассаң, аяк тубыктан тыгыз мүк арасына кереп күмелә, әллә ничә җирдән быкырдап авырсы исле су күтәрелә башлый, күбекләр мыгыр-мыгыр килеп сүнәләр һәм җыелган пычрак су өстен ал-кызылга, куе шәмәхә төсенә манып, астан май таплары калка. Бер-беребезгә күрсәтеп:

— Чыкты, әнә чыкты! Нефть чыкты! — дип сөенешеп кул чабабыз.

— Бар ди анда нефть! — дип куя өлкәнрәк малайлар.

— Бар инде, чыкты! Әнә ич! Югыйсә, гомергә дегет таммаган, арба кермәгән сазлыкка май таплары каян килер иде? — дип карулаша акыллыраклар.

Болай ук ышанып әйтә алдыкмы икән, анысы тәгаен хәтердә калмаган, мәгәр Баграж сазлыгындагы шәмәхә тапларны без сәерсенеп, хәйран калып күзәтә идек. Авылда безнең акыл ирешмәслек бердәнбер күренеш иде бу! Ул чакта әле аның Казанында да искитәрлек заводлар юк, гомер-гомергә сабын кайнатканнар, шәм койганнар, тире-яры иләгәннәр. Патша самодержавиесе татарлар арасында промышленностьның үсүен бер дә теләмәгән!.. Ә нефть... әнә кайларда чыга ул! (Мәктәптә география карталарында кап-кара скважиналар, фонтаннары белән чекерәеп күзгә бәрелеп торалар). Бакуда, Грозныйда, Төрекмәнстанда, тагын әллә кайларда. Ә бездә юк. Бездә, гомумән, мактанырлык бер нәрсә дә юк: шахталар да юк, нефть тә юк, алтын-көмеш тә юк, тимер юл-

лар да аз... Котып та әллә кайларда!.. Бездә һаман бер төсле тормыш: арыш чәчәләр, бодай, киндер сугалар, бәләк-бәләк кыяр үстерәләр. Урманнарда чүнникләр күп, кура җиләге үсә, җир җиләге. Кая карама, анда гөмбәләр табарга була... Ә болар белән мактанып ерак китә алмассың! Үзгәреш тә юк, кызык та, нефть тә юк!

Ихлас әйтәм, миңа малай чакта бездә тормыш бер дә үзгәрмәс, шул ук кыр-елгалар бездән соңгы буыннарга да нәкъ безнең көннәрдәгечә барып җитәр, менә бу бормалы урам-тыкрыклар, агач өйләр, салам түбәләр, хәтта киртә-корталар да мәңгелекләр булып тоела иде. Хәзер генә аңлыйм: Югары Багражның тышкы дөнья белән артык алыш-бирешсез яшәве мине шундый беркатлы нәтиҗәләргә китергәндер, ахрысы! Без тып-тын, үтә гади, үзенчә кызык, кабатланусыз беркатлы дөньяда яши идек! Сазламыктан чыккан ефәк таплар да безнең өчен әллә ни иде!

Күз күрмәсә дә, уебыз йөгерә башлаган еллар, колак ишетә, газеталар гөрли! Донбасслар, Ураллар, Магниткалар төзелә, ерак Амурда яңа шәһәрләр салалар, кеше стратосферага омтыла, Осипенко, Гризадубова, Росковалар туктаусыз очып, ил күген бизиләр, папанинчылар котыпка барып җитте, Чкаловны ишетеп беләбез, Испания, Хәбәшстан сугышлары булып узды...

Бер бездә генә күзгә күренерлек үзгәрешләр юк та юк иде!

Дөрес, тирә-якны, мохитны бәяләгәндә без беркатлырак булганбыз, күренешләрнең төбенә тоз сала белмәгәнбез әле... Мисал...

Сугыш елларында без үсмер егетләр идек. Баграж — Зәй — Чаллы юлларының һәр бормасы безгә таныш. Фронтка әтиләрне шушы юлдан озаттык. Абыйлар да шуннан китте. Яралылар култык таяклары белән ерак чакрымнарны үлчи-үлчи шушы юлдан кайтты. Әни, апаларыбыз шушы юллардан Чаллы базарына йөрделәр, өшәнчеккә килгән күлмәккүнчекләрен тоз, керосинга алыштырып, безнең гомерләрне саклап калдылар. Пристань тирәсендә акмаса да тамса, бер бүктәр әйбер күтәреп китәләр дә, кысыр сыер җилене хәтле янчыкка тутырып, тоз алып кайталар. Юк, кәнфит-прәннек түгел, тоз! Сельпога товар, МТСка бензин-керосин, солидолы-башкасы, кыскасы, районның бөтен кирәк-ярагы шушы юлдан кайта иде.

Зәй — Чаллы арасы... Күпме ачы тир, канлы күз яшьләре тамган юл ул. Күпме шатлык-өмет авазлары яңгыраган юл ул. Зәй — Чаллы юлы безнең гомернең бик күп вакыйгаларына шаһит! Үкчәләре ашалып беткән кирза итекләр, солдат ботинкалары, мыеклы чабаталар киеп, без бу юлның һәр квадратында үзебезнең эзләрне калдырдык. Фронтка без икмәкне шушы юлдан ташыдык. Язын чәчүлекнең байтак өлешен шушы юллардан алып кайттык. Баграждан Чаллыга турырак юл да бар, Кабан Бастырык, Шыкмай, Борды авыллары аша, әмма явым-төшемнәрдә урын юлларга керерлек түгел, шуңа күрә әйләнечтән — Зәй аша йөрибез. Атлар арык, арбалар иске, күчәрләр майланмаган, чыбылдыклар кырык ямаулы. Ә йөзебез барыбер якты, күңелләр күтәренке, без зарлана да, зарланганны тыңлый да белми идек. Арба чәкүшкәсеннән чак кына калкурак малайлар «эһ» тә итмичә кара төннәрдә, үзәк өзгеч көзге җилләрдә шушы юлга чыгып китә идек. Мин юлдашларымның якты хатирәләрен, эшчән яшьлегебезне байтак әсәрләремдә ачарга тырыштым. «Дүртәү», «Берәү», «Язгы кәрваннар» повестьларының күпчелек геройлары чын, тормышта булган кешеләр. Мин дә шулар арасында. Чын кешеләр дим, алар Баграж малайлары, Баграж толлары, Баграж җиңгиләре...

Юлның Аксар авылы турыннан без кырыкмаса-кырык тапкыр узганбыздыр. Элегрәк монда Тәкмәк авылы бар иде, хәзер ул юк. Тау итәгендә, Зәй болынына төшеп, ат ашатып төн кунганыбызны да ап-ачык хәтерлим, әмма бу таучыкның Алтынтау булуын менә хәзер генә — 1980 елның көзендә Мәгъсум Гарипович авызыннан беренче тапкыр ишет-

тем. Бер дә алтынлы булып күренми иде заманында бу теңкәгә тигән җәфалы урләр! Әллә биеккә, күз күтәреп карарга мөмкинлегебез булмадымы икән? Гел үр дә үр, гел борма да борма! Чокырга чокыр тоташкан, чокыр төбендә тиздән су, лай, күз гел эштә — әле атның ак күбеккә баткан арык ботларына сызланып карыйсың, әле аның ябык сыртына; йомшак тавыш белән чөмгереп аңа көч-куәт биргән буласың. Түшлекне ныгытасың, аркалыкны тикшерәсең, мунчаладан гына ишелгән камыт баулары чыдармы дип хафаланасың. Арада көчлерәк бер ат була, арба ныгытып ук батып калганда, үз атыңны тугарып, егәрле атны җигәсең, тиздән бата-бата иңне арт үрәчәгә терәп, арбаны этәсең... Муеннар тегәрҗеп юанлыгы гына, күз чокырлары чынаяк чокыры кебек тирән, тутлы яңаклар җәя бавы кебек киерелгән. Кая ул, тауга күтәрелеп карарга да, аның Алтынтау булуын уйларга безнең вакыт юк. Тизрәктизрәк өстән коеп ява башлаганчы барып җитәргә дә, авыл белән берәмтекләп җыйган күз карасыдай икмәкне тапшырырга кирәк. Бу җәһәттән безнең уйлар бер, теләкләр бер, фронтка икмәк кирәген бөтен күзәнәкләребез белән беләбез!

Бериш хәсрәт тәнкыйтьчеләр безне «бер төрлелек»тә гаепләп, байтак кына тукмап килделәр. Юкка булган! Без әсәрләребездә чагылдырган авыл үсмерләре дөнья таң калырлык эш күрсәткәннәр икән ул чагында!.. Тәнкыйтьчеләр әнә шуларны ачып саласы урынга, «шәкерт җиләненнән борча чүпләгәннәр», урман артынданиләр барын күрмәгәннәр. Кызганычка каршы, мин үзем дә үзебезнең яшьлеккә икенче күз белән бераз соңгарак калып карадым. Ул көннәр турында кат-кат борчылып уйлансам да, фактларның барын да белеп җиткермәгәнмен. Инде байтак еллар узгач, заманында без танышырга мөмкин булмаган документлар басылгач кына мин үз чордашларымның, юлдашларымның нинди олы һәм кирәкле эш башкаруларына тагын бер кат инандым. Менә ул кыйммәтле документларның берсе:

«Красная Армия помогает Будапештскому населению продовольствием. Из справки политотдела 46-й армии о занятых Красной Армией районах в западной части Будапешта.

11 января 1945 года.

Командование частей и подразделений Красной Армии оказывает помощь жителям города, снабжая их, по мере возможности, продуктами питания. Так, например, командование 305-го стрелкового полка 108-й стрелковой дивизии передало в распоряжение населения свыше 5 тонн хлеба, более 100 кг. крупы и пр.

В районе расположения этого полка находится приют, устроенный шведским представительством Красного Креста для 200 детей евреев и коммунистов, расстрелянных салашистами. Приют находится недалеко от нашего переднего края и подвергается систематическим обстрелам немецкой артиллерии. Дети сидели без пищи и воды. Командованием полка отпущено для приюта 5 тонн картошки и свыше 400 кг. мяса.

Начальник 7-го отделения политотдела
46-й армии подполковник Грекул.»

Менә икенче документтан өзек.

«Выполнение решения советского правительства об оказании помощи г. Будапешту.

26 июня, 1945 года.

СНК СССР товарищу Микояну А. И.
НКО СССР товарищу Хрулеву А. В.

Докладываю:

Ваше задание о введении новых норм снабжения в г. Будапеште, согласно решению ГОКО от 19 июня 1945 года, выполнено.

Бургомистру города передано зерна — 3000 тонн, сахара — 1000

тонн, соли — 960 тонн и 250 грузовых автомашин. Остальное зерно и мясо (скот) будут переданы городу до 10 июля в сроки по согласованию с бургомистром города...»[1]

Ит, май, тоз, он, ярма, шикәр...

Журналда Варшава, Вена, Прага, Белград, Берлин гражданнарын, фашист коллыгыннан кичә генә азат ителгән венгр, поляк, немец, австрия, югославия халыкларын азык-төлек белән тәэмин итү турында искиткеч гыйбрәтле, мәңге онытылмаслык тарихи документлар теркәлгән. Документларга 1944, 1945 еллар датасы куелган.

1944—45 еллар...

Хәтердә: без кара көзгә кадәр Чаллыга икмәк ташыдык... Без фронтка икмәк, сөт, ит озатып, үз ватандашларыбызның тамагын туйдырып кына калмаганбыз икән. Европа илләрен, Европа халыкларын ач үлемнән коткарып калганбыз икән! Совет солдаты Европа халыкларын фашист коллыгыннан коткарып кына калмаган, ул аларга бөек интернационализм рухының нәрсә икәнен чынлыкта күрсәткән. Ярты илебез җимерек яткан хәлдә, тылда азык-төлек ягы ифрат кыен чакта, немец снарядлары явып торганда безнең әти-әниләребез бүленеп калган еврей балаларына, коммунист балаларына үз авызларыннан өзеп ит, икмәк илтә торган булганнар.

Кырык дүртенче ел...

Хәтердә! Истә! Онытылмас та. Көз. Ил табынына куелган икмәктә безнең газиз өлешебез бар бит!

Мин хәзер ул чакларны хәтерләп горурланам. Бөек Ватан сугышында җиңүнең 30 еллыгына багышланып игълан ителгән документлар горурлык хисемне тагы да ныгыталар, үстерәләр. Үзебезнең тамак ягы кысан булса да, без көрәшә белгәнбез, җиңелмәгәнбез, батыр булганбыз!

Баграж — Зәй — Чаллы юллары...

Казан дигән каланың
Санап чыктым урамын.
«Сау бул, бәгырем!» дигән идем
Елап бирде кулларын,

— дип җырлыйлар иде безнең кызлар шушы юлларда.

Бүген менә Алтынтауның түгәрәк маңгаенда уйга чумып басып торам.

Аста — тигез асфальт җәелгән магистраль. Юл читендә аклы-каралы чуар бетон баганалар. Күрмәсәм дә, беләм: офыкта Зәй ГРЭСының торбалары шәйләнә. Хәзер без шушы юлдан, шушы үзәннән барлык республикаларга, тугандаш илләргә гаҗәеп сылу, гаҗәеп эшлекле КамАЗларны озатабыз. Кем моны могҗиза түгел дип әйтә ала?

Машиналар, фикеремнең дәреслеген раслагандай, һаман агылалар.

Бу юллардан элек йөрмәгән кешеләр өчен бу күренешнең бөеклеге дә юктыр бәлки? Мөгаен, минем күңелгә дулкын-дулкын булып иңгән уйлар башкалар күңеленә кереп тә карамас?! Әмма без, күрүчеләр, үз кичергәннәребезне башкалар да әсәрләнерлек итеп сөйләп бирергә бурычлыбыз. Шулай түгел мени? Минем котыпта булганым юк, әмма папанинчыларга кабатланмас хөрмәт саклыйм. Испания көрәш кырлары да һаман истә, Хәбәшстан батырларының итальян илбасарларына каршы көрәшләре дә онытылмый. Котыпны яулау да, Испания дә, Хәбәшстан да безнең яшьлегебез. Ә яшьлек хатирәләре бер чакта да кешене ташлап китми, хатирәләр һаман матурлана гына бара, кеше күңелен гомере буе җылытып, дәртләндереп яши. Яшьлеге хатирәсез һәм ямьсез булган кеше гомере буе бәхетле була алмый. Йөзәрләгән нурлы машиналарга карыйм да Алтынтау белән мин дә биегәям, офыкларым тагын да киңәя, мин үземнең кеше булуым белән, Татарстан кешесе бу-

[1] «Коммунист» журналы, 4 сан, 1975 ел.

луым белән горурланам. Ил белән, халкың белән горурлана алу хисе кешеләр өчен бик кирәк, ифрат дәрәҗәдә кирәк! Бар ул могҗизалар, бездә дә бар! Тик кайчагында могҗизаларны ап-ачык күрү өчен нәкъ менә Алтынтау башына менү һәм уйлану кирәк икән.

Рәхмәт, Мәгъсум Гарипович!

Казанга кайткач, мин дустымның күзенә туп-туры карап:

— Бар бит, могҗизаларның чыны бар! — дидем.

Дустым тулысынча килеште, әмма минем сүзгә бер өстәмә кертеп куйды...

## 3. Акыллы сүзгә колак салмыйча ярамый

— Хак! — дип килешеп башлады сүзен дустым.— КамАЗ безнең республиканың данын еракларга алып китте. Автомобиль гиганты Татарстанны илнең иң эре индустриаль төбәкләре белән янәшә куйды. Һәммәсе дөрес. Әмма КамАЗ турында сөйли башладым исә, мин үзе безнең нефтьчеләребезне күз алдына китерәм. Татарстан нефтенең егәрен, аның илгә биргән файдасын исәплим. Нефть! Безне ил күләменә менә нәрсә чыгарды! Европа илләренә дә без нефть аша кул суздык. Нефть аркасында безнең көнкүрешебез, тормышыбыз, географиябез үзгәрде: яңа калалар, юллар салынды. Зәй ГРЭСы да, Түбән Каманың дөньякүләм атаклы комбинатлары да, Әлмәт, Лениногорск, Җәлил калалары да нефтькә рәхмәт әйтсеннәр. Инде килеп, Татарстан эшче сыйныфы абруе да турыдан-туры нефтькә бәйләнгән. Күпме белгечләр, инженер-техник хезмәткәрләр, эшчеләр тәрбияләде нефть! Күпме кешеләрнең язмышына кискен борылыш кертте, аларның яшәү мәгънәсенә әйләнде. Дөрес, автомобиль комплексын планлаштырганда һәммәсе исәпкә алынгандыр — географик, социаль-экономик шартлар күздә тотылгандыр, эшче ресурсларның чыганагы уйланылгандыр, транспорт, ягулык, энергетик ресурслар исәпләнгәндер. ЭВМнар төрле регионнарның уңай һәм кире якларын санап-исәпләп Министрлар Советына, Госпланга бик этрафлы мәгълүматлар биргәндер. Әмма автогигантны «кайда төзергә?» дигәндә, тагын бер мөһим фактор күз алдында торгандыр, ул мөһим фактор — Татарстан! Илгә ничаклы нефть биргән атаклы республика. Автогигант төзелешен Ватан Татарстанга, Татарстан партия оешмасына, Татарстан эшчеләренә-белгечләренә ышанып тапшырды. Нефтьчеләр безнең республикабызның данын югары күтәреп, икенче бер могҗизага — КамАЗ төзелешенә юл ачтылар. КамАЗ безнең героик эшләребезнең логик дәвамы ул, ә ул юлның башында, һичшиксез, нефтьчеләр торды. Онытмаган булсаң, 1981 елның көзендә Татарстан җире илгә 2 миллиард тонна нефть бирү тантанасын билгеләп үтәчәк...

Дустым, сүзен:

— Татарстан нефте могҗиза түгел мени? Ике миллиард тонна нефтьне күз алдыңа китерә аласыңмы соң син? — дип тәмамлады.

Ике миллиард нефтьне күз алдына төгәл генә китереп булмаса да, аның авырлыгын, күләмен саннар белән исәпләп чыгарып була. Ике миллиард тонна нефтьне чыгару өчен түгелгән көчне күз алдына якынча гына булса да китереп уйлый алсак та, саннар белән төгәл генә исәпләп чыгару мөмкин түгел.

Һәр скважинаның беренче ноктасын билгеләгән кеше булган.

Һәр йортның, һәр урамның, һәр шәһәрнең беренче казыгын кагучы булган. Татарстан җиренең аскы, девон катламнарын уз уч төбен белгән кебек белүче кодрәтле геологлар килеп чыккан.

Татарстан нефте менә ничә еллардан бирле илебезнең экономик үсешен, куәтен, егәрен, халыкның көнкүреш дәрәҗәсен билгеләүче фактор булып килә.

Могҗизамы ике миллиард тонна нефть?

Могҗизамы ике миллиард тонна нефтьне якты көнгә чыгару өчен түгелгән көч? Моңа җавап бирү өчен аз булса да тарихка күз салмыйча мөмкин түгел, чөнки чагыштырып карау ысулы хакыйкатькә илтә торган ышанычлы юлларның берсе. Безнең көннәрдә нефть энергетика һәм промышленностьның бик күп тармаклары нигезенә әверелде. Әмма аңа кадәр нефть шактый озын, шактый катлаулы юл үтте инде. Адәм уллары нефтьне кайчаннан бирле башлаганнар соң?

Белгәннәр, бик борынгы заманнарда ук нефть төрле урыннарда өскә саркып чыккан. Археологлар раславынча, безнең эрага кадәр VI гасырда ук нефтьне кулланганнар инде. Урта гасырларда исә ничек кулланууларына кадәр билгеле: табиблар «җир маен» дару итеп санаганнар, ярага, шешкә сөрткәннәр, эчәргә дә тәкъдим итә торган булганнар. Җир өстенә саркып чыккан нефтьнең куерып, асфальтка әйләнүен дә бик борынгыдан ук искәргәннәр. Борынгы Шумерда асфальттан савыт-сабалар, бизәнү әйберләре һәм скульптуралар ясаганнар. Вавилонда нефть крепостьлар, ныгытмалар төзегәндә алыштыргысыз материал булып саналган. Борынгы Мисырда мәетләрне дә әлеге дә баягы нефть ярдәмендә бәлзәмләгәннәр.

Шулар өстенә бик борынгыдан нефтьнең яктырту һәм җылыту чыганагы икәнен дә белгәннәр. Янган чакта нефть мул сөрем чыгарган, асфальт яндырганда өстән корым яуган. Һәм белгечләр нефтьне кудырып, таркату юлларын эзләргә керешкәннәр. Һәм тапканнар! Нефтьне кудырып, фракцияләргә аеру ысулын Рим врачы Кассий Феликс язып калдырган. Шул чорда нефтьтән бензин, керосин, мазут һәм гудрон аерып ала белгәннәр. Җир маеның кодрәтле көчкә ия икәнен еллар үтү белән ныграк аңлаганнар.

Россия нефтьне промышленность юлы белән эшкәртүне дөньяда беренчеләрдән булып башлый: 1745 елда Федор Прядунов дигән тынгысыз җан Ухта нефтенә нигезләнеп, нефть кудыру заводы сала һәм ел саен «мең потка якын саф, чиста ягулык» алуга ирешә. Бу сыеклыкны лампа мае итеп тә, медицинада да кулланалар. 1823 нче елда Моздокта нефть эшкәртү заводы салына. Баку нефтен керосин итеп эшкәртү 1860 елда башлана. 1873 елда андый заводларның саны 80 гә җитә һәм алар елына 16 мең тонна керосин эшләп чыгара башлыйлар. XIX гасырның икенче яртысында бу заводларның технологиясе бераз катлаулана, нефтьтән майлау материаллары, гудрон һәм башка нәрсәләр аерып алына. Галимнәр һәм инженерлар нефть калдыкларын таркатуның төрле юлларын эзлиләр һәм термик юл белән эшкәртеп, составтан яктыру газы җитештерә башлыйлар. Узган гасырның 70 нче елларында Казанда һәм Киевта газ заводлары салына. Казан заводыннан чыккан газ шәһәр урамнарындагы меңнән артык фонарьга «ризык» була.

80 нче елларда карбюраторлы двигательләр уйлап табылгач, нефтьнең, шул җөмләдән бензинның дәрәҗәсе бермә-бер арта...[1]

Дөньяның икенче почмагында — Америкада, 1859 нчы ел ахырында, Ойл-Крикта, Титусвил янында, Пенсильваниядән төньяк-көнбатышта беренче тәҗрибә скважинасы бораулана һәм 20 (!) метрдан нефть фонтаны бәреп чыга.

Нәкъ егерме ел элек кенә нефтьне тоз чыгару коеларында очрат-

[1] Мәгълүматларның байтагы «Наука и жизнь» журналыннан алынды. 8 сан, 1975 ел.

калаган булалар. Аны «ризык пычратучы, тозны бозучы!» дип каһәрләп, сүгеп килгәннәр. Ә кайбер эшкуарлар «тау мае»н шешәләргә тутырып, дәва чарасы итеп базарларда сатып йөргәннәр. Утыз ел үтүгә, ягъни 1889 елда, бөтен дөнья скважиналарыннан 4 миллион тонна нефть чыгарыла, шуның 80 проценты Пенсильваниягә туры килә[1].

Вавилонда нығытмаларга һәм Мисыр мәетләренә нинди микъдарда нефть кулланганнардыр, анысын әйтүе кыен, әмма мин мөмкин булган урыннарда нефтьнең күләмен бик төгәл әйтеп бардым, игътибар иттегезме? «Мең потка якын...» «16 мең тонна...» «Утыз ел... 4 миллион тонна...» Бу саннарны мин Татарстан күкрәгеннән чыккан 2 миллиард тонна белән янәшә куяр өчен теркәп киттем...

Ниһаять, Татарстан җиренә уяныр чак җитә.

ВКП(б)ның XVIII съезды резолюцияләрендә мондый юллар бар:

«Идел белән Урал арасында яңа нефть базасы — Икенче Баку булдырырга!»

Идел белән Урал арасы.

Тәҗрибәле рус геологлары бу төбәккә күптән күз тотканнар һәм «кыйммәтле чималның бай ятмалары нәкъ әнә шунда булырга тиеш!» дип раслаганнар. В. И. Ленин да Идел тирәсеннән нефть эзләү идеясен кайнар рәвештә яклаган булган. Бу төбәкнең гаять өметле булуын академик Иван Михайлович Губкин фәнни рәвештә нигезләгән. Әйе, аңа кадәр үк чит илнең әрсез алабайлары Идел нефтенә кулларын һәм борыннарын сузып караганнар. Атаклы «Нобель и К» фирмасы да Казан губернасыннан тырышып-тырмашып «кара алтын» эзләгән. Әмма нефть бик тирәнгә яшеренгән була, чит ил эшкуарларына бирелми. Заманның техник мөмкинлекләре дә чикләнгән чак бу.

1939 нчы елда, XVIII съездан соң нәкъ бер ел үткәч, академик И. М. Губкин тәкъдиме белән Татарстанда геологик разведка тресты төзелә. Трестка республикада җир катламнарын өйрәнеп, нефть ятмаларын табу бурычы йөкләтелә. Идел-Кама регионында интенсив эзләнүләр башлана һәм бу эш Бөек Ватан сугышы көннәрендә дә тукталып тормый.

Нефть безнең сөекле Олы су ярларыннан бәреп чыкмады, әмма аның беренче чыганагы бездән ерак та түгел Шөгер авылы янында булды.

Лениногорск шәһәрендә нефть музее бар. Шунда, беренче карашка әллә ни искитмәслек пыяла савытта кара-көрән сыеклык саклана. Дәһшәтле кырык өченче елның җәендә буровой мастерлары Гариф Хәмидуллин белән Яков Буянцев һәм аларның иптәшләре Шөгер авылы янында бораулаган скважинадан чыккан Беренче Нефть булыр бу! 617-648 метр тирәнлегендәге бу Беренче скважинаны бораулау 25 ай дәвам итә! Бу санны хәтергә сеңдереп куярга кирәк — беренче скважинаны 2 елдан артыграк бораулыйлар. Хәзер исә девон катламнарына байтак бригадалар 15—17 көндә төшеп җитә. Авыр сугыш елы шартлары, мөмкинлекләр бик аз, тәҗрибә бөтенләй юк диярлек, алай да беренче бораулаучылар кара алтын ятмаларына барып җитәләр. Бик зур җиңү була бу, чагыштыргысыз Олы җиңү!

Икмәкнең һәр бөртеге алтын белән бәяләнгән еллар, чималның, нефтьнең, руданың һәр мыскалы күз карасыдай кадерле чак. Әле дошманны үз өненә барып кырасы һәм Европа илләрен фашист чумасыннан азат итәсе бар. Завод-фабрикалары хәрабәләр хәленә калган йөзләгән шәһәрләргә җан өрәсе бар. Нәкъ шул чакта Татарстан күкрәге Шөгердән ургылып чыккан нефть — ул безнең мактанычыбыз да, сөенмәс горурлыгыбыз да! Һәм бу гомергә шулай булып саналыр. Татар-

[1] П. Хаггет. География, Мәскәү, «Прогресс» нәшрияты, 1979 ел. 231 бит.

стан нефтьчеләре беренче кыю адымнарыннан ук Ватаныбыз чакыруына эш белән җавап бирделәр: 1944 нче ел дәвамында республикабызның яшь промыселларыннан фронтка 42 мең тонна нефть озатылды!

Моны һичбер чакта да онытырга ярамый.

Беренче йөз мең тонна кара алтын чыгарылды. Татарстан елына 100 миллион тонна нефть бирә башлады. «Есть! Беренче миллиард үтәлде!» дип, Ватанга кайнар рапорт бирдек. Әмма миллиардларның беренче тонналары — әнә шул атаклы 42 мең! — искиткеч югары бәһагә ияләр! 1944 елда данлы Совет Армиясе фашист илбасарларын илебездән тулысынча куып чыгарды һәм үзенең югары интернациональ миссиясенә — кол ителгән Европа илләрен фашизмнан тазартуга кереште.

Татарстан нефтенең Бөек Ватан сугышында катнашуы үзе бер горурлык түгел мени?! Татарстан нефте, шулай итеп, үзенең данлы юлын Ватан сугышы фронтларында илнең азатлыгы өчен көрәштән башлады.

Татарстан нефте халыкларның туганлык, аралашу аренасына әйләнде. Төрле милләт уллары, иңне-иңгә куеп, Шөгер, Писмән, Тимәш якларын көрәш кырына, ярыш, хезмәт кырына әйләндерделәр. 1970 елда Татарстан нефтьчеләре елга 100 миллион тонна нефть алуга ирештеләр һәм байтак еллар шул югарылыкта тордылар. 1966 ел, 16 март Указы белән, ирешкән югары казанышлары өчен «Татнефть» берләшмәсе илебезнең иң югары бүләге — Ленин орденына лаек булды.

Ә 1971 елда татар шигъриятенең аксакалы Хәсән Туфан данлы нефтьчеләребезгә түбәндәге шигырен багышлады:

Яз, Заман,
Язып куй тарихка:
Бер миллиард тонналы табышны!
Безнең бу — титаник ярышта
Иң алгы сызыкта барышны.
Остардың, нефтянник туганым,
Җиңәргә, үсәргә остардың:
Хәерле сәгатьтә башлансын
Икенче миллиардка стартың!

Хәсән Туфан — бәрәкәтле хезмәтнең көчен аңлый торган гали зат. Ул Татарстан нефтьчеләренең хезмәтен «титаник ярыш» дип атый. Һәм беренче миллиард тонна белән котлап, икенче миллиардка үзенең изге хәер-фатыйхасын бирә. Әйе, ул елда республикабызның юмарт ятмалары беренче миллиард бирүне төгәлләделәр. Моның өчен 28 ел дәвамына сузылган Б Ө Е К хезмәт кирәк булды.

## 4. Очрашуларның тагын берсе, әһәмиятлесе

Сиксәненче елның октябренда театр йомышлары белән тагын Әлмәткә юлым төште. Бөтен дөнья юеш, пычрак. Әле узган килүемдә генә нефтьчеләр мәркәзенең яшеллегенә, гөлбакчага әйләнүенә куанып, сокланып киткән идем. Хәзер исә агачларга карарга имәнгеч, яфраклары саргаеп түгел, ботакларында ук череп, муртаеп, җиргә коелалар. Шундый шыксыз, чырайсыз көздә соңгарак калган кыр эшләрендә күпме кеше, машиналар җәфа күрә дип уйладым. Терлекләр бик иртә абзарга керсә, колхозлар өчен бәла! Ә мондый явымлы көздә мал көтүнең ни икәнен беләм, үзем үсмер чакта ике ел көтү көттем.

Әлмәткә нинди йомыш белән килсәм дә, «Татнефть»кә кермичә кит-

мим. Бу юлы да генераль директорның урынбасары Үзбәк Газизович Саттаров янына кагылдым.

Үзбәк Газизович белән очрашу бер вакытта да эзсез калмый, чөнки ул һәр вакытта да нефть чыгару эшенең иң алдынгы сызыгында, иң кайнаган үзәгендә була. Һәрвакыт пөхтә киенгән, искиткеч эшлекле, тирән белемле, дөньяның һәм вакытның хәрәкәте белән өзлексез кызыксынып яшәүче бу нефтьче җитәкченең бер чакта да зарланганын күрмәссең. Иң кыен чакларда да ул кул сырты белән һаваны «эһ» дип бер кисеп куя да өстәлендәге «Беломор» кабына тотына. Чыраендагы кырыс җитдилек шундук елмаю белән алышыныр... Минем аны бик күп урыннарда — эш өстендә,— объектларда, утырышларда, галимнәр, язучылар, кунаклар арасында очратканым бар. Саттаров берчакта да үзгәрмәс, һәрчак туры сүзле, вәгъдәчел булып калыр, шатлыкны уртаклаша белер, хәсрәтне бүлешер. Ул шундый кеше! Күңеле киң, бик күп гади эшчеләрнең, нефтьчеләрнең исем-фамилияләрен хәтерендә тота, үтә гади кешеләр белән дә тигез торып сөйләшә, һәркемгә җандай якын сүзе булыр... Ул нефтьчеләрне сәнгать-әдәбият белән аралаштырып, теркәп торучы иң актив эшлеклебез, үзе дә байтак еллардан хикәяләр яза. Аның хикәяләренә наянлык, юмор, күзәтүчәнлек хас. Казанда әдәби юбилейлар, премьералар булганда Үзбәк Газизович хәзер үк килеп җитә. Үзе белән күңелле, эшлекле атмосфера, кешелекле мөнәсәбәт алып килә. Әлмәттә ул иң актив әдәбият сөючеләрнең берсе, менә ничә еллар инде Әлмәт драма театрының худсовет члены, эше-киңәше белән иҗат оешмаларына, иҗат кешеләренә өзлексез ярдәм итеп килә.

Иң мөһиме — ул зур галим, укымаганы, белмәгәне юк, хәтере ачык, әллә нинди катлаулы мәсьәләләрне чишкәндә дә ярдәмче китапларга, белешмәләргә карап тормый, саннарның йөзләбен, меңләбен күңелдән белә. Моның өчен эшне ихлас ярату гына җитми, моның өчен күп еллык хезмәт, тәҗрибәң булуы да кирәк...

Бу юлы керүемдә Саттаров кабинетында тагын өч кеше бар иде. Өченең берсе сөйли, мин керүгә, ул, чак кына тыелып, Саттаровка карады. Үзбәк Газизович безне таныштырды.

— Антипов, Альберт Иванович, доцент, үзебезнең татар егете,— диде ул.

Доцент Антипов нефть һәм химия промышленносте институтының Әлмәттәге кичке факультетында укыта икән. Факультет — әлмәтлеләрнең горурлыгы! Соңгы елларда аның диварларыннан бик күп кадрлар югары белем алып, ныгып, колачлары киңәеп чыкты. «Татнефть» берләшмәсе институт белгечләренә фәнни-практик мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итеп кенә тора. Антиповка — «Ягулыкны сак тоту һәм югалтулар» дигән теманы берләшмә промыселлары җирлегендә өйрәнеп, тиешле нәтиҗәләр чыгару һәм фәнни нигезләмәләр эшкәртү тапшырылган икән. Саттаров монда мине тагын бер мәртәбә сөендерде: ул яшь доцентның дөрес юнәлеш алуын, аның хезмәтенең практик кыйммәте югары булуын бик тиз тотып алды, тәпле, төгәл сораулар биреп, фәнни хезмәтнең төрле якларына ачыклык, өстәмә кертте. Кеше хезмәтенә чын күңелдән сөенә алу һәм ул сөенечне уртак итә белү — кешеләрнең гүзәл сыйфаты түгел мени?!

Белгечләрне озаткач, хәл-әхвәл алыштык, мин соңгы еллардагы явымнардан зарланып алдым, җәй-көзнең җайсыз килүе авыл хуҗалыгына бик нык зыян сала дип, кайбер үзем белгән мисалларны китердем. Үзбәк Газизович беравык сүзсез утырды, тагын «Беломор»ына тотынды, папиросны өйрәнелгән гадәт белән оста гына чиртеп чыгарды да, торып, бүлмә буйлап йөренә башлады.

— Яңгыр-карлар безнең яклар өчен гаҗәеп нәрсә түгел! Соңгы елларда җәйләр буе койган чаклар булды. Менә 52 градус салкынны әйт син! Илле ике градус!

Саттаровның сүзен юкка гына башламавын белә идем, фикеренең дәвамын көтеп, күзләренә карадым.

— Нефтьче хезмәте башка бер хезмәткә дә охшамаган, син аны бик яхшы беләсең! — дип гадәттәгедән кайнарланыбрак башлады ул сүзен.— Нефтьче һәрвакыт ачык һавада. Аның эш урынын һава шартлары йогынтысыннан һич саклый торган түгел! Чөнки эш объектыбыз бөтен республика буенча таралган. Яңгырның-карның, давыллы җилләрнең байтак зыян салган чаклары булды, әмма мондый афәт башка беренче тапкыр төште. Безнең регионның салкынлык полюсы Җәлил поселогында, салкынлык 52 градуска җиткәндә, «Җәлилнефть» эшчеләренең нинди хәлдә калуын күз алдыңа китерәсеңме син? Операторлар, ремонтчылар — һәммәсе ачык һавада. Җитмәсә, поселок берничә сәгатькә утсыз-сусыз калды. Ун меңгә якын кешене эвакуацияләү турында сүз кузгатылды... Менә шул ситуацияләрдә нефтьчеләрнең холкы күренде дә инде! Бирешмәделәр! Поселокны, кешеләрне саклап калдылар, нефть объектларында да эш тукталмады... Нефтьнең һәр тоннасы кадерле. Ул тонналарны табу елдан-ел авырлаша, катлаулана бара. Үз мәшәкатьләре өстенә табигать та авырлыклар китерсә, монда инде чын сугышчан холык кирәк! Нефть чыгаруны «җәлилчеләр» өзмәделәр, сынатмадылар. Без олы Җиңү бәйрәменә барабыз. Сиксән беренче елның көзендә икенче миллиард тонна нефть чыгаруны төгәлләргә исәп тотабыз. Бу — бик зур бәйрәм!

Мин моны белә идем, ике миллиард тонна нефть турында газеталар яза башлаган иде. Әмма Үзбәк Газизович авызыннан бу сан бөтенләй башкача яңгырап чыкты. Минем уйланып калуымны Саттаров үзенчә аңлады.

— Ике миллиард тоннаны күз алдыңа китерергә тырышып утырасыңмы? Мин 52 нче елдан нефтьтә эшләп тә аны өлешчә генә күзаллый алам. Ә шушы кадәр кара алтын табуга куелган көч турында сөйләшергә була! Бөек хезмәт куелды! Мөмкин булса, мин моны халкыбызның күмәк батырлыгы дип атар идем. Горурланам да! Җир куеныннан шул кадәрле байлык чыгарып б е з н е ң б у ы н үз бурычын намус белән үтәде! Өченче миллиард та булыр! Әмма анысы — бездән соң киләчәк буыннар эше. Алар өлеше. Алар бурычы. Без эстафетаны ышанычлы, сыналган кулларга тапшырабыз. Мәгәр безнең буынның хезмәте дә бик зур хөрмәткә лаек...

Шушы очрашу, шушы сөйләшү миндә төрле уйлар кузгатты. Миңа Үзбәк Газизовичның «б е з н е ң б у ы н үз бурычын үтәде!» дигән сүзләре аерата ошады.

Гомумән, ир-егетләрнең үз күңелләрен, үз эшчәнлекләрен чор һәм буын белән кыю рәвештә бәйли алуларын ошатам. Дөрес, бөтен кешегә дә андый хокук насыйп түгел, әмма кайберәүләрнең күзгә карап шулай дип әйтергә хаклары барын беләм! Ялгыз кеше эштә-хезмәттә бик әһәмиятле урын тотса да, уртак җимеш әнә шул ялгызларның тырышлыгы аркасында туса да, бары тик чор, буынның гомуми хезмәте генә тарихны хәрәкәткә китерә ала, алга илтә. Бигрәк тә хәзерге фән-техника заманында коллектив хезмәтнең, коллективлар эше нәтиҗәсенең кыйммәте зур. Саттаровның гаять зур коллектив — Татарстан нефтьчеләре исеменнән тулы хокуклы вәкил булып сөйли алуы, үз хезмәтен буындашлары, чордашлары белән бәйли алуы мине тетрәндереп җибәрде.

Буындашлары исеменнән җитди сөйләүне үз өстенә теләп ала икән, бу кеше үз тормышы турында гына түгел, яшьтәшләре, чордашлары турында да бик күп уйланган дигән сүз. Күп уйланган икән, ул үз чордашларын бик яхшы белә, аңлый, аларның кайгы-шатлыкларын уртак

итә ала, ул үз чордашлары белән бер сулышта кайнап яшәгән, заманның иң әһәмиятле мәсьәләләрен хәл иткәндә алгы сызыкта булган дигән сүз. Илгә ифрат олы хезмәт күрсәтеп, ике миллиард тонна сыек ягулык биргән буын исеменнән сүз әйтә ала икән, Үзбәк Газизович Саттаров үз өстенә тагын бер бурыч йөкли булып чыга. Димәк, үзенең дә ил алдында йөзе ак. Без нефтьчеләребезнең шушы буыны турында әле бер генә уйланмабыз, «безнең буын үз бурычын үтәде» дигән җитди йомгак безне нык уйландырырга тиеш. Ватан сугышының күп нечкәлекләре, детальләре менә ничә еллар инде һаман ачыклана гына бара, ваклыклар ачылган саен, сугышның зурлыгы, бөеклеге кимеми, киресенчә, нечкәлекләр илебез халыкларының батырлыгын торган саен ачыграк яктырта гына баралар. Нефтьчеләр турында да без әле кайта-кайта уйланырбыз, үз вакытында күреп бетермәгән фактлар ачыкланыр, кечкенәрәк саналган вакыйгалар, детальләр заманның хәлиткеч төсмерләре урынын алыр. Нефтьчеләр турында әле олы әсәрләр язылмаган. Нефть турында байтак гүзәл әсәрләр язган каләмдәш дусларым миңа үпкәләмәсеннәр, нефтьчеләр темасы әле үзенең Толстойларын көтә.

Нефтьче галим Үзбәк Газизович Саттаров...

Нефть чыга башлауга ук, безнең Татарстанга илебезнең бөтен якларыннан белгечләр килде, осталар, инженер-техниклар тупланды. Татарстан җире үзе олы бер мәктәп булып, бик күп үңган егетләребезгә һөнәр, белем, тәҗрибә һәм гыйлем бирде. Бик күпләр Татарстан нефтендә ныгып канат ярдылар һәм илнең яңа, башка бәрәкәтле промыселларына таралдылар. Мангышлакта, Урайда, Нижневартовскида, Уренгойда, Төмәндә Татарстанның күпме егетләрен очратырга була! Дан һәм хөрмәт аларга. «Татарстан нефтьчесе булу илебездә иң ышанычлы пароль!» дип язган идем бер пьесамда. Китүчеләргә хәерле юл, әмма бүген, нефть инде кими барганда, аны табу һәм җир өстенә чыгару бермә-бер авырлашканда Татарстанны ташлап китмәгән, шунда калган белгечләргә хөрмәтем аерата зур минем. Моны гади сүзләр белән генә аңлатып та булмый, китүчеләргә чын күңелемнән ак юл теләсәм дә, монда калганнарга мөнәсәбәтем, бөтенләй үк булмаса да, башкача — җылырак, яктырак! Нефть ургылып чыкканда, мактау арты мактау явып торганда, эш тирәсендә очынып йөрүчеләр дә булды. Алар башка төбәкләргә, башка промыселларга «каймак ашарга» киттеләр...

Калучыларның берсе ул — Саттаров.

Үзбәк Газиз улы Саттаров шунда, Әлмәт авылында, 1922 елның 8 мартында туган.

Егерме икенче ел! Егерме икенче елгылар! Безнең язучылар арасында егерме икенче елгылар юк, тормышта хәзер алар бик сирәк очрый. Егерме икенче елгылар Ватан сугышының иң авыр айларында дошманны күкрәкләре белән каршылаган егетләр. Аларның иң зур күпчелеге ил өчен, ирек өчен батырларча үлеп калды. Димәк, «егерме икенче елгылар вәкиле» булып сөйли алу да үз гомереңнең «моңлы бер җыр» булуын таләп итә, шуны сорый.

Үзбәкнең атасы революциягә кадәр дә, революциядән соң да балалар укыта. Әнисе Мөшфика апа да яшьрәк чакта укытучы булып эшли. Үзбәк ак күңелле гаиләдә туа, яшьтән үк китап, белем, халыкка хезмәт итү дигән изге сүзләр арасында үсә. Үзбәк Әлмәттә М. Горький исемендәге урта мәктәпне тәмамлагач Казанга китә, Коммуналь төзелеш институтына керә. Институт та М. Горький исемен йөртә. Егет тырыш була, җәмәгать эшләренә катнаша, әдәби кичәләргә йөри, яңа спектакльләрне калдырмый. Озакламый институт ябыла һәм Саттаров Свердловск шәһәренә күчәргә мәҗбүр була, ул анда укуын С. М. Киров исемендәге Урал индустриаль институтының 3 курсында дәвам иттерә. 1941 ел була инде бу! Егерме икенче елгыларның һәммәсенең

тормыш юлына кискен үзгәреш кертkән дәһшәтле ел. Табигый булараk, Үзбәк Сәттаров та 1941 елның августында армия сафларына алына, аны Киев шәһәренә, танк-техник училищесына укырга җибәрәләр. 1942 елда ул бу училищены Көнгер шәһәрендә тәмамлап, техник-лейтенант званиесе ала. Аны хәрәкәттәге армиягә озаталар. Ул фронтта була, сугышларда катнаша. Сәттаровны яңадан училищега кайтаралар һәм Т-34 танкларына хезмәт күрсәтүче итеп әзерлиләр. 1943 елның башында Т-34 танклары эшелоны белән техник-лейтенант Сәттаров 1 Украина фронтына китә һәм Җиңү көненә кадәр Армия сафларында була.

1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Курск, Воронеж, Белгород сугышларында катнаша, Украина җирләрен азат итеп, СССРның дәүләт чигенә кадәр барып җитә.

Кырык өченче ел!

Авыр Т-34 танклары төялгән эшелонны күз алдыгызга китерегез. Егерме бер яшьлек, юка гына, пөхтә генә, елгыр лейтенант, гайрәтле броняга төрәлгән машиналар янына баскач, үзе дә ничек үзгәреп китә!

Үзбәк Сәттаров сугышны «Кызыл йолдыз» ордены һәм күп санлы медальләр алып тәмамлый. Сугыштан соң да аңа илгә тиз генә әйләнеп кайту насыйп булмый әле. Ул совет гаскәрләренең Үзәк группасы составында Польша, Германия, Чехословакиядә озак кына хезмәт итә. Тыныч тормыш аның өчен 1947 елда гына башлана. Бик күп елларга өзелгән укуны дәвам итәргә карар бирә. Илне торгызу, аякка бастыру өчен белемле егетләр кирәк булачагын бөтен барлыгы белән аңлый. Ул Казанга химия-технология институтының 3 нче курсына кайтып керә.

Күпме юллар, күпме еллар узгач, яңадан тыныч шәһәрдә... Нинди зур бәхет! Сау-сәламәт килеш илгә кайту, Казан-башкалада йөрү, китапханә залларында яраткан китапларың белән очрашу — боларның нинди олы бәхет икәнен канлы сугыш юлларын узган солдаттан яхшырак белүче бармы икән? Бу бәхетнең кадерен бик яхшы аңлаган Сәттаров үлгәннәрнең дә, терелләрнең дә йөзенә кызыллык китермәслек итеп тырышып укый. Киров исемендәге мактаулы стипендия ала. 1950 елны институтны тәмамлап, инженер-механик була. Сәттаровны Кемерово шәһәренә эшкә җибәрәләр, Ново-Кемеровск химкомбинатына. Комбинатта ул башта инженер-конструктор булып эшли, аннары проект бүлегендә өлкән инженер вазифасын башкара. 1952 елда Әлмәттә атасы Газиз вафат була һәм Үзбәк Сәттаров, әнкәсенең соравын үтәп, туган ягына кайта.

Әлмәт. 1952 ел.

Шәһәрнең ул чагын кемнәр хәтерли икән? Татарстан җиренә бөтен илдән техника, кешеләр агыла башлады. Буровойларны Уралдан китерделәр. Куйбышев, Волгоград, Пермьнән вышкалар, долотолар килде. Әзербайҗан торбалар җибәрде. Мәскәү, Ленинград, Уфа, Грозныйдан әллә никадәр катлаулы машиналар агылды. Илебез 1951 елдан 1955 елга кадәр Татарстан нефтен үстерүгә 500 миллион сумнан артыграк капитал салды.

Әлмәтне танымады Үзбәк Сәттаров. Таныйрлык түгел иде. Элек кәҗә чирәм кыркып йөргән урамнар юк. Элек каз бәбкәләре ваемсыз гына узып йөргән тыкрыклар беткән. Бөтен җирдә канаулар, чокырлар, төзелеш нигезләре, торбалар, электр баганалары. Бөтен якка яңа юллар узган. Яңа юллардан яңа тормыш вәгъдә итеп, торба, тимер конструкцияләр төягән машиналар чаба. Вахта автобуслары төрле телләрдә сөйләшә. Яшьләр, кызлар, өлкәннәр. Һәр йортта эшчеләр, эшчеләр. Әлмәт татарлары килгән кешеләр белән үз булып, туганлашып беткәннәр. Өйләргә сыймаганнар палаткаларда. Һәркем һәр көн мунча яга. Шәһәр мунчасына сыймаганнар хуҗалыкларга йөри. «Менә рәхмәт,

менә бәракәт, менә сәламәтлек!» Зәһирә апаларына кунакка барган иде, исе китте Үзбәк Саттаровның: иdәнне тутырып нефтьчеләр йоклап ята. Вахтадан кайтканнар. Кешеләрне берәм-берәм аралап басып узарга туры килде. Фронт юллары, окоплар, авыр һавалы блиндажлар, очраклы исән калган түбәсез каралты-куралар нигәдер хәтергә яңадан ургып килеп төште. Монда да чын фронт иде, аның да алгы сызыгы. Яшь инженерның йөрәге кысылып-кысылып куйды. Тик шушы кайнап торган яңа тормышның кайсы ноктасында урын алырга?!

Ул елларны хәтерләп, Үзбәк Газизович хәзер болайрак сөйли:

— Җанга якын һөнәр сайлап алу кебек үк, күңелгә ятышлы эш урыны табу — олы бәхет ул. Без менә һөнәр юнәлеше турында күп сөйлибез, яшьләргә туры юлны күрсәтергә тырышабыз. Һөнәр сайлау исә, кайчагында, бик очраклы була. Минем белән дә шулайрак булмадымы икән? Әлмәт белән өр-яңадан танышып йөргәндә буровойга барып кердем. Каранам, каранам, күз күнекмәгән хәрәкәтләрне шәйлим, ниләрдер бик таныш, җанга үтә якын кебек. Күрәм — буровойны хәрәкәткә китерү механизмнары танктан алынган икән! Двигатель танкныкы! Көч кучергечләр! Борт кучергечләре дә! Хәтта кулислар да. Әйе, сугыштан соң безнең заводлар байтак дизель двигательләрен тыныч тормышка, хезмәт кырларына — буровойга җибәргәннәр икән! Танк приводлары хәзер нефть чыгара! Нефть эзли! Буровойлар шунда ук үз булып китте, алар да мине үз итте, эшкә калдым. Тиздән «Татнефть» берләшмәсенең бораулаучылар әзерләү мәктәбендә укыта башладым. Тәҗрибә аз, дәреслекләр юк. «Юк»ны «бар» белән тулыландырабыз: дәрт бар, көч күп, теләкләр изге! Бораулаучылар мине өйрәтә, мин аларны, бергәләп җир катламнарына төшүнең серләрен ачабыз. Бораулаучылар өчен беренче дәреслекне дә мин яздым. Аны бастырып чыгару турында уйлаган юк, вакыт көтми, эшебез ашыгыч, тиз-тиз генә машинкада бастырдык та эшчеләр арасында тараттык. Бергәләп үсәбез!

Шул көннән Үзбәк Саттаров бөтен гомерен Татарстан нефте белән бәйли.

Нинди генә җаваплы, катлаулы хезмәтне башкармасын, һәрвакыт җитди, уңган, таләпчән һәм өлгер булып кала. Миңлебай газ эшкәртү заводында баш инженер булып эшләгәндә ничәмә-ничә рационализаторлык тәкъдиме кертә! Нефтьчеләр, төзүчеләр, газовиклар алдында зур абруй казана. Аны «Татнефтегаз» трестына баш инженер итеп күтәрәләр. «Татнефть» берләшмәсендә чыккан барлык нефтьне җыю, озату һәм куллану объектлары, шул исәптән Миңлебай газ эшкәртү заводы да,— һәммәсе Үзбәк Газизович карамагына тапшырыла. Олы эш була бу, катлаулы һәм җаваплы эш. Хәтәр эш! Ир-егет хезмәттә сынала. 1965 елда Үзбәк Газизович Саттаровны Ленин орденлы «Татнефть» производство берләшмәсенең генераль директоры урынбасары итеп билгелиләр. Ул бүген дә шушы җаваплы урында. Сугышчан орден, медальләре янына «Октябрь революциясе» ордены һәм тыныч хезмәт медальләре дә өстәлде.

Кешенең асыл сыйфатларын билгеләгәндә без телебезнең нинди олы сүзләренә мөрәҗәгать итәбез: эшлекле, уңган, таләпчән, белемле, киң карашлы, дәртле, яңалыкны тоя белә, үз эшен җаны-тәне белән ярата, ярдәмчел, вәгъдәчел, туры сүзле, саф күңелле дибез.

Коммунист, Татарстан нефть җитәкчеләренең берсе буларак, республикада гына түгел, илебездә зур абруй казанган Үзбәк Газизовичта бу саналган сыйфатларның һәммәсе дә бар.

# 5. Нефть уйландыра да...

Яшермим, моңарчы да без Үзбәк Саттаров белән, очрашкан саен, нефть турында бик күп сөйләшә идек. Ничек сөйләшмисең, кая гына карама — нефть, кая гына барып төртелмә — нефть продуктлары, нефть тормышыбызның бөтен тармакларына, дөнья хәлләренә, илләр арасындагы мөнәсәбәтләргә, җирнең бүгенгесенә һәм киләчәгенә меӊ төрле җепләр белән барып тоташа иде. 1964 елның 4 ноябрендә «Дуслык» нефть үткәргеченең беренче чираты файдалануга тапшырылды, һәм Татарстан нефте тугандаш республикаларга — Чехословакиягә, Венгриягә, Польшага һәм Германия Демократик Республикасына озатыла башлады. Көнделәге уй һаман өзелми, киресенчә, яңа төсмерләр белән байый гына бара: әйе, без бу ил халыкларына азатлык алып килдек, хәзер хуҗалык төзелешендә дә ярдәм итеп, бар булганын уртак итеп киләбез! «Дуслык» нефть үткәргече шуның иң матур чагылышы түгел мени?! Әлмәттән ерак та түгел аның беренче чакрымнарында: «Җирдә тынычлык һәм халыклар дуслыгы хакына шушы ноктадан татар нефте юл ала!» дигән язу кадакланган. Искиткеч тирән мәгънәле сүзләр! Совет халкының яшәү гамәле, туганлык, интернациональ идеяләр, безнең уртак хезмәтебезнең максаты шушы сүзләрдә ярылып ята.

Нефть! Әлмәттә, Техника йорты фойесында дөнья картасы эленеп тора. Зур карта-диаграмма. Картада җир шарындагы сыек ягулыкның якынча запаслары күрсәтелгән. Якын Көнчыгыш, Персия култыгында — бүгенге көндә җир шарының ут чорнаган ноктасында аның иң зур ятмалары. Саннары күп санлы миллиардлар белән күрсәтелгән. Америка империализмының туймас капшагычлары ни өчен шушы төбәккә сузылганын аңлау өчен әллә ни хикмәт кирәкми.

Әйе, Үзбәк Саттаров белән Әлмәттә очрашабызмы, Казандамы, республика, ил тормышы, дөнья хәлләре турында кызып-кызып сөйләшә башлауга, сүзебез, һичшиксез, нефтькә барып ялгана иде. Әмма соңгы очрашуда Үзбәк аганың аерата дулкынлануына, очынып-дәртләнеп сөйләвенә игътибар иттем. Җаваплы урында озак эшләгән, тормышның көтелгән һәм көтелмәгән бөтен алмашынуларын үз җилкәләрендә татыган кешеләр, гадәттә, хисләрен ашыгып тышка чыгармыйлар. Аларга еллар белән олы тәҗрибә һәм шуның нәтиҗәсе, дәвамы булып сабыр акыл килә. Үзбәк Саттаровны мин сабыр акыллы дип белә идем. Соңгы очрашуда исә ул яшәреп китте, чал мыегы астыннан рәхәт елмаю өзелмәде, фикере тыгыз, уйлары канатлы иде. (Гәрчә мин аның әлерәк кенә больницадан чыгуын, врачларның чыгармаска тырышуларын, РОЭсының югары булуын, кан басымының уйнап-шаярып сикергәләвен бик яхшы белә идем).

Гадәттә, ул сүз алганда, сорауларым кими торган иде, бүген, киресенчә, җаваплар алган саен, сорауларым өстәлә, туктаусыз арта торды.

«Нигә алай ашыгып чыктыгыз?» дигән сорауга ул көлемсерәп җавап бирде: «Хәзер авырырга ярамый! Елы, айлары шундый!» диде.

«Хәзер» дигәннең мәгънәсен аңлыйм, «Татнефть» берләшмәсе — Үзбәк Газизовичның туган йорты — икенче миллиард тонна нефтьне чыгару ярышында финиш сызыгына чыкты. Хәзер бөтен көч тупланган, акыл, дәрт тулаем дәрәҗәдә эшкә җигелгән булырга тиеш!

Ул бүгенге дәрте белән мине дә эшкә чакыра түгелме соң?! Шулай булып чыкты да: «Әдәбият-сәнгать әһелләре Татарстан нефтьчеләре алдында бик зур бурычлы!» — диде ул. Килештем. Әмма бер утыруда гына аны аңлап бетермәдем, күңелемдә бик күп сораулар тулып калды.

Ничәмә-ничә НГДУ арасыннан нигә «Җәлилнефть»кә баруымны теләде ул? Ничәмә-ничә җитәкчеләр арасыннан шул идарәнең начальнигы Шәфагать Фәхразович Тәхәветдиновның исемен нигә аерып атады?

Дөрес, 1978 ел азагында — 1979 ел башында Татарстан аша узган дәһшәтле салкын дулкыннарның иң аяусызы нәкъ менә «Җәлилнефть» промыселлары таралып утырган төбәктә булган икән. Тугызынчы вал! Аерым урыннарда салкынлык 50 градустан артып киткән! Сирәк була торган хәл, ифрат сирәк! Бөек Ватан сугышы башланган елның кышында да салкыннар Идел буе районнарын тетрәткән иде. Йөзәр яшьлек мәгърур имәннәр, өрәңгеләр өшеп корыды, чикләвек куаклары коры чыбыкка калды. Алма, чия бакчалары тоташтан кара көеп утырдылар...

Дөрес, «Җәлилнефть» идарәсенең горурланырлыгы бар, алар — кышкы зәмһәрирдән промышленность объектларын, су кудыру насосларын, скважиналарны һәм поселокны саклап алып калганнар, кыенлыкларны, өстәмә мәшәкатьләрне батырларча җиңеп чыкканнар.

Дөрес, идарәнең начальнигы иң яшь, өметле җитәкчеләрнең берсе. Шәфагать Фәхразовичка утыз ике яшендә республиканың иң эре нефть предприятиесенә җитәкчелекне ышанып тапшыралар.

Мәсьәлә ачыклансын өчен, тагын бер мөһим якны әйтеп-искәртеп узарга кирәк. Җәлил — үзенчәлекле поселок. Бирегә урнашкан НГДУ — «Җәлилнефть» идарәсе промышленность объектлары өчен генә түгел, поселок өчен дә тулаем җавап бирә. Торак йортлар да, мәктәп, больницалар да, клублар, кибетләр, ашханәләр, балалар бакчалары, санаторий-профилакторий да, хәтта картлар йорты да, аларныкы, нефтьчеләрнеке. Дөрес, халык сайлап куйган поссовет бар, председателе дә пыр тузып эшләп йөри, әмма халыкның күп тармаклы тормышы, көнкүреше өчен асылда нефть идарәсе җавап бирә. Менә шундый поселок икән ул Җәлил һәм Татарстанда башка андый торак пункты юк та икән.

Димәк, афәт булып салкын иңгәндә, нефтьчеләр, поссовет җитәкчеләре белән берлектә, поселокны салкыннан саклап калганнар. «Саклап калганнар» дип сүздә әйтү җиңел, ә тормышта бу хәлдә нинди көтелмәгән вакыйгалар булмагандыр дисең!? Нефть объектларын һәм поселокны саклау көн тәртибенә килеп баскач, нефтьче җитәкчеләр үзләрен ничек тотканнар? Ике якка да бердәй куркыныч янаганда алар кайсы якка булса да авышмаганнармы?..

Гомумән, ун меңгә якын кешесе булган поселок утсыз-сусыз калгач, нефтьчеләр гаиләсендә ниләр булды икән?! Куркыныч кемнәрнедер тәмам өркеткәндер, кемнәрдер Җәлилне ташлап ук киткәннәрдер? Китүчеләр белән калучылар арасында яңа мөнәсәбәтләр туып өлгергәндер...

Фантазия ерак вакыйгаларны хәтергә төшерде. Ташкентта зилзилә, җир тетрәү булып, шәһәрнең шактый өлеше җимерелгәннән соң, бөтен ил, бөтен республикалар бердәм булып тугандаш үзбәк халкына ярдәмгә ташланганда, кайберәүләрнең, абруйлы гына кешеләрнең, тәртәләрен читкә борулары мәгълүм бит!.. Монда ни хәлләр булды икән, Җәлилдә!?

Һәлакәт, куркыныч килгәндә характерлар ачыла. Куркак гомере буе куркак булып яшәми, аның канына сеңгән куркаклыгы, сыналу килгәч, авыр моментта гына ачылып китә. Батырлык та шулай. Юаш, сабыр холыклы, моңлы күңелле Газинур Гафиятуллин дошманның ут атып торган амбразурасын каплаганда гына батыр булмаган, ул гомере буе батыр булган. Батырлык та, куркаклык та тормышның кискен бәрелешләрендә ап-ачык чагыла. Җәлил төбәгенә килгән афәт нефтьчеләрне яңа яктылыкта күрсәтәчәк түгелме?.. Борылышлар, кыенлыклар, авырлыклар кешеләрнең күләгәләрен түгел, үзләрен күрсәтәләр, чын йөзләрен!

Әлмәт театры коллективы кайчаннан бирле нефтьчеләргә, аларның үтә мактаулы, үтә тынгысыз хезмәтләренә багышланган пьесага зарыгып яши. Шушы вакыйга пьеса өчен нигез була алмасмы?..

Бу сорауларга җавапны анда, поселокның үзендә, җәлилчеләр арасында гына табып була иде. Әйе, миңа Җәлилгә барырга кирәк...

Әлмәттән кайткач, мин газета-журналлардагы «нефть, нефтьчеләр» сүзенә аерата игътибар бирә башладым. «Җәлилнефть» дигән сүз чыгуга, күңелем чаптар ат кебек ярсый иде. «Нинди кешеләр яши анда, нинди хикмәтле эшләре бар аларның?» Күңелдә гел шул сорау иде. Җәлилгә барганчы ук мин алар арасында, нефтьчеләр уртасында идем. Моңарчы да үземне кызыксындырып килгән сорауларга җавапларны алар эшчәнлегенә аша табарга тырыштым.

Менә «Советская Татария» газетасының 14 ноябрь саны. 1980 ел. Кыска гына белешмә: «Җәлилнефть» идарәсе бер безнең республикада гына түгел, Идел — Урал регионында иң эре нефть чыгару предприятиесе. «Татнефть» берләшмәсендә чыгарыла торган нефтьнең 15 проценты шушы идарә өлешенә туры килә. Нефть чыгарыла башлаганнан бирле бу идарә ятмаларыннан барлыгы 155 миллион тоннадан артык «кара алтын» алынды, шуның 60 миллионнан артыгы унынчы бишьеллыкка туры килә. Бу — узган бишьеллыкка караганда 20 процентка артык дигән сүз.

Идарә хезмәтнең бик югары күрсәткечләренә ирешә, чыгарылган нефтьнең 80 проценты экспорт кондициясенә җиткерелеп тапшырыла, мөһим социаль проблемалар уңышлы хәл ителә.

Нәтиҗәләр куанычлы, әммә шуның белән бергә унынчы бишьеллыкның җәлилчеләр өчен шактый кыен булуын да искәртеп узарга кирәк. Хаталар, исәпләп бетермәүләр һәм план өзелү фактлары да булды. Аларның күпчелеге республика нефтьчеләре өчен уртак хаталар иде. Унынчы бишьеллык нәтиҗәләренә аек, объектив бәһа бирү — алдагы бишьеллыкларның уңышларына ныклы нигез булып торачак».

Шушы кереш соңында «Җәлилнефть» идарәсенең баш экономисты Мәсгуть Гиниятуллинның зур мәкаләсе урнашкан. Гиниятуллин?! Таныш фамилия ич бу! Күптән түгел генә Новосибирскида чыга торган «ЭКО» исемле фәнни журналда аның бик төпле, миндә бик күп яңа фикерләр кузгаткан мәкаләсе басылды түгелме? Журналның октябрь ае санын эзләп алам, чыннан да, «Татнефть» берләшмәсенең генераль директор урынбасары Н. Хәмидуллин белән Мәсгуть Гиниятуллинның «Нефть скважинасының эш сыйфаты» дигән фәнни мәкаләләре басылып чыккан. Элегрәк тә мәкаләгә күз йөгертеп чыккан идем, хәзер мин журнал битләренә бөтенләй башкача карадым. Үземне борчыган сорауларга конкрет җирлек, конкрет кешеләрнең эше аркылы җаваплар эзләдем.

Уйланып язылган, уйландыра торган мәкалә.

Скважина — нефтьчеләрнең эш үзәге. Скважина — катлаулы һәм шактый чыгымнар сорый торган нефть чыгару корылмасы. Нефть чыгару предприятиеләренең төп фондларының яртысы скважиналар коруга тотыла. Мин боларны элек тә белә идем. Партиябезнең XXV съезды скважиналар төзү циклын 25 процентка кыскарту бурычын куйган иде. Әлмәтлеләр, мәсәлән, тармакта беренче буларак, бу зур бурычны ике ел ярымда үтәп чыктылар. 1975 елда бу күрсәткеч 54 тәүлек булса, хәзер нибарысы 33,7 тәүлек тәшкил итә. Скважиналарны төзү циклы кыскара барса, скважиналарның эш гомерен озайту — нефть чыгару предприятиеләренең иң зур, иң катлаулы бурычы. Бераз алгарак китеп булса да, Шәфагать Фәхразовичның бик төпле бер фикерен әйтеп, бу фикернең никадәр катлаулы икәнен белдерәсем килә. Ул: «Һәр кешенең генә түгел, һәр скважинаның да үз холкы бар. Кешеләр белән эшләү дә җиңел түгел, скважиналарның серен аңлау да елдан-ел катлаулана бара», дигән иде.

Республика сыек ягулык күләмен ил таләп иткән югары дәрәҗәдә тоту өчен, яңа ятмалар ачу белән бергә, хәрәкәттәге скважиналарны н ә т и җ ә л е эшләтү һәм катламнарның нефть бирүчәнлеге бүгенге кон-

дә хәлиткеч роль уйный. Гади оператордан башлап иң югары җитәкчеләргә кадәр бу аксиоманы бик яхшы беләләр. Безнең республикада катламнардан җир асты байлыгын тулырак һәм аз көч түгеп алуга юнәлтелгән комплекслы чаралар программасы эшләнгән. Ул нефтьне катламнардан су кудырып чыгару ысулларын камилләштерүне, сыек ягулыкны юдырып алу сәләте югары булган химик сыекчалар, реагентлар куллануны һәм күп төрле оештыру чараларын үз эченә ала.

Скважиналарга капиталь ремонт ясау елдан-ел катлаулана һәм күләм ягыннан арта бара, моны истә тотып, «Татнефть» производство берләшмәсендә катламнарның нефть юмартлыгын арттыру һәм скважиналарга капиталь ремонт ясау белән шөгыльләнүче махсус идарәләр оештырылды.

Кем белән сөйләшсәң дә, кайсы оператор, мастер белән очрашсаң да, алар бер авыздан скважиналарга ремонт ясауның бүгенге көнгә иң кыен һәм иң мәшәкатьле эш икәнен әйтеп торалар. Эшнең авырлыгы шуннан гыйбарәт ки, әлегә ремонтчы бригадаларның техника белән кораллану дәрәҗәсе бик чикләнгән. Торба күтәрү өчен әлеге дә баягы иске конструкциядәге «ПТМТ-40» мачталары кулланыла. Аның йөк күтәрү мөмкинлеге бик чикле. Торбаларны сүткәндә һәм аларны яңадан ялгаганда барлык эш кулдан башкарыла. Скважинаның тирәнлегенә карап, торбалар санының 200—210 чамасында икәнен дә ачыклап үтәргә кирәк. Бер скважинаны ремонтлау өчен генә кул аша шушы кадәр торбаны үткәрү эшчеләрнең һәм мастерның теңкәсенә тия. Ачкычлар да бик иске. Бораулау торбаларын күперчеккә урнаштыру да әлегәчә механикалаштырылмаган. Бу эшнең никадәрле җитди игътибар үзәгендә торуын «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры Әкълим Касыймович Мөхәммәтҗанов съезд алды көннәрендә «Правда» газетасында да язып чыкты. «Алдынгы технологияне үзләштерү юнәлешендә иң мөһим тармак булып скважиналарны ремонтлау хезмәте тора. Кызганычка каршы, соңгы ун-унбиш ел эчендә, бу җәһәттә кулланыш тапкан механизмнарның техник дәрәҗәсе дә, аларның эш күрсәткечләре дә әллә ни алга китә алмады. Байтак эшләр кулдан яки искергән җайланмалар белән башкарыла. Эш урынының һәрвакыт ачык һавада булуы да эштә өстәмә кыенлыклар тудыра. Болар һәммәсе бергә ремонтчыларның гайрәтен чигерәләр һәм кадрларның эштән китүенә сәбәп булалар».

(«Правда», 19 январь, 1981 ел).

Хәзер берләшмәдә скважиналарга ремонт ясауда 100 дән артык ысул кулланыла. Яхшымы бу, яманмы? Әмма ремонт схемалары фәннитикшеренү институтлары тарафыннан тикшерелеп типлаштырылмаганнар, скважиналарда бер үк төрле ремонт таләп ителгәндә дә һәр идарә, цех, хәтта бригадалар да төрле-төрле технология кулланалар. Бу технологик алымнарның нинди очракта кайсы уңышлырак икәнлеге фәнни нигезләнмәгән. Ремонтчыларның бу зарларын үз колагым белән дә ишеткәләдем, газеталарда да бу турыда ачынып һәм борчылып язып чыктылар.

Скважина ремонтлаучылар ярдәм көтә.

Скважиналар тирәсендә эш кайный, скважиналар тирәсендә фән туа, хезмәтнең экономик законнары ачыла. Скважиналарның саны, аларның эшчәнлеге — бөтен идарәнең, нефть чыгару предприятиесенең хезмәт көзгесе дә икән. Моны М. Гиниятуллин бик гади исәпләү юлы белән аңлата. Чагыштырмача хезмәт чыгымнары дигән күрсәткеч нефтьчеләрнең эш нәтиҗәсен бик төгәл исәпләп бирә ала икән! Производствода хезмәт күрсәтүчеләрнең санын скважиналар санына бүлсәң, әнә шул күрсәткеч килеп чыга. Бу беренче карашка гади бүленешнең нигезендә төгәл мәгънә ятканын М. Гиниятуллин бик тапкыр рәвештә исбатлап бара. Шушы бер сан аша хезмәт җитештерүчәнлеге дә, производствоның тех-

ник коралланy дәрәҗәсе дә, эшләп чыгару күрсәткече дә, кыскасы, нефть чыгаруның ни чаклы эффектлы булуын раслаучы бөтен факторлар чагыла! Санарга өйрәтә, санарга мәҗбүр итә торган берәмлек икән ул «удельная численность!»

«Җәлилнефть» идарәсен алыйк. Бу мәгънәле күрсәткеч соңгы ун ел эчендә күзгә күренеп түбәнәйгән, якынча икеләтә кимегән, инде бик төгәл булыйк дисәк, 1,9 дан 1,05 булып калган. Әгәр бүгенге көндә «Җәлилнефть» промыселларында мең ярымнан артык скважина эшләп утырганын исәпкә алсак, бу сикерешнең экономик кыйммәтен бәяләп бетерерлек түгел! Гади тел белән әйткәндә, унынчы бишьеллык башыннан «Җәлилнефть»тә хезмәт чыгымнары өчтән бергә кимегән! Бу «Татнефть» берләшмәсе арасында иң яхшы күрсәткеч!

Нефтьнең моңарчы билгеле булган ятмалары күзгә күренеп саранланганда, скважиналарның егәре кимегән чакта, геологик-техник күрсәткечләр начарланганда, «Җәлилнефть»тә «кара алтын» чыгару унынчы бишьеллыкта узганы белән чагыштырганда, тулаем 5,4 процентка арткан икән!

Әле без бая өстәрәк телгә алган «хаталарны, исәпләп бетермәүләрне һәм план өзелү» фактларыннан тыш, әлегә рәсми отчетларда аерып телгә алынмаган табигый факторларны — җәйге давылларны (ул турыда алда сүз булачак!) һәм кышкы салкыннарны (салкыннар идарә эшчәнлеген шактый вакытта графиктан чыгаралар) да санасак, бу үсеш сокландыра, җәлилчеләрдә ярыш ялкынының чыннан да сүнмәс вә сүрелмәс икәнлеген раслый!

«Әһә!» дидем мин уйлый-уйлана торгач, «юкадә икән чикләвек!» Үзбәк Газизович юкка гына «Җәлилгә бар!» дип димләмәгән. Җәлилчеләрнең нефть бирергә теләмәгән «кирле-мырлы холыклы» катламнарга да актив һөҗүм башлавын, югары катламнардагы күкертле нефтьне чыгара башлавын да телгә алсак, аларның эшчәнлеге нәкъ менә коммунистик хезмәтнең үрнәге икән ләбаса! «Баштагы елларда нефть чыга торган иде, хәзер без аны чыгарабыз!» дип шаяртып куйган иде Үзбәк Газизович бер мәлне...

## 6. Димәк, мин Җәлилгә барам!

Уйландым, көен дәфтәремне актарындым, китаплар караштырдым, әзерләндем. Юлга чыгар алдыннан гына кылт итеп күңелгә тагын бер сорау кунды: «Ә суык? Нәрсә ул суык?!»

Беләм, Канадада, мәсәлән, салкыннар 17 градуска җитсә, нефтьчеләр эшкә чыкмыйлар, суыктан куркалар. «Ачык һавада көне бу эшләргә кирәк ич!» Бу — факт.

Ә илле градус? Күпме бу, азмы?

Җир шарының салкынлык полюсы Антарктидада урнашкан. Салкынлык рекорды 88,3 градус! Антарктиданың салкыннары турында «Восток» станциясендә кышлаган белгечләребез болай дип язып чыкканнар иде: «Термометрда төрекөмеш туңа. Туңа да подшипник шары сыман тәгәрәп йөри. Металл ялучанга әйләнә — кувалда белән бер сугуга, тимер, пыяла сыман, чәрдәкләнеп ваклана. Бензин дөге боткасы кебек ап-ак, куе һәм ямьмый торган массага әйләнә. Янып торган факелны шул бензинга тыксаң сүнә. Кар вак, очлы кырлы ком кебек тарала, чожтырдый һәм чаңгыны шудырмый. Температура 70 градус салкын булганда берниди приборсыз да белеп була — сулап чыгарган һава борын төбендә үк вак карга әйләнеп җиргә сибелә».

Әлмәт, Җәлил шартларында илле градус салкын ниләр күрсәтә ала! Моны анда баргач кына белеп булачак иде...

Бөек шагыйребез исеме белән аталган бу поселок туган ягым — Сарман районында урнашкан була да, моңарчы бу якларга килеп чыкканым юк иде. Кешенең чын яшәү формасы — көрәш. Тышкы яктан карaганда сабыр гына аккан тормышыбызда һәрчак көрәш өстенлек итә, ат озын үргә менгәндә бот мускулларын соң чиккә җиткереп кабартып тарткан кебек, көрәш кискенләшкәндә кешенең дә хәле киеренкеләнә, акылы тизрәк эшләргә тотына, көндәлек тормышында булып та, моңарчы сизелмәгән сыйфатлары — кыскасы, эче һәм тышы ап-ачык күренә башлый.

Икенче миллиард тонна күңелдән китми. Республикабыз шул уй белән яши. Моңарчы илебезнең бер генә төбәгеннән дә ил казнасына шул кадәрле «кара алтын» кергәне юк әле! Алдарак андый төбәкләр булыр, бу санга Көнбатыш Себер нефтьчеләре дә якынаеп килә. Әмма минем республикам Татарстан илдә беренче булачак!

Спортчы дөнья рекорды кую өчен халык алдында ничә минутлык чыгыш ясый? Биш минут? Ике? Бер!? Ә шушы минутлар өчен ничә еллык авыр юл узганын, күпме көч сарыф иткәнен, ничәмә-ничә чиләк тир түккәнен ул үзе һәм тренеры гына белә. Актер, сәхнәгә чыгып бер авыз сүз әйтүгә, залдагы йөзләгән тамашачының күңелен яулап алырга тиеш! Шундый сихри югарылыкка ирешер өчен ул айлар буе репетицияләр үткәрә, күпме йокысыз төннәрдә газаплана, тау-тау китап-журнал актара, тормышны өйрәнә.

Унынчы бишьеллыкта җәлилчеләр 60 миллион «кара алтын» биргәннәр. Аларның күпме тир түккәнен, никадәр йокысыз төннәр үткәргәнен, шушы саннар өчен ничаклы юллар узылганын кем белә? Уйларым шул тирәдә йөри, юл читләрендә, уйсулыкларда мыштым гына җир мае имеп яткан сиртмәле коелар баш иеп мине озатып калалар. Уйлар чиксез, уйлар якты. Менә күрсәткеч тактасы. Саумы, Җәлил!

Әлмәттән килешли шактый озын үр мендек. «Җәлилнең бөтен ягы да тау»,— дип ачыклады шоферым. Җиде юл чатына, җиде җил күзенә утырган бу шәһәрчә поселок Муса Җәлилнең үзенә һәйкәлдер кебек тоелды миңа. НГДУның өч катлы бинасы алдында Җәлилнең мәгърур сынын күреп башымны идем, Җәлилнең көрәштәшләре санынча утыртылган яшь куе чыршылар гөжләп мине сәламләде. Борылып як-ягыма карадым. Урамнар киң, тәрәзәләр якты, кешеләр көләч, һавасы саф.

Байтак көннәр җәлилче нефтьчеләр тормышы белән яшәдем. Промышленность объектларының эше белән якыннан таныштым, операторлар, мастерлар, цех начальниклары белән очраштым, җир асты ремонты бригадаларын вахтага озатып калдым, цехларда иртәләрне-кичләрне каршыладым. НГДУның төрле рангтагы җитәкчеләре белән күрешеп, аңлашып яшәдек. Ниһаять, промышленностьны гына түгел, сәнгатьне дә бик яхшы аңлаучы, Ленинград, Мәскәү театрлары хәлен биш бармагы кебек белүче искиткеч инсафлы, югары дәрәҗәдәге интеллигент холыклы экономист Мәсгуть Гиниятуллин белән дә очраштык. Бар эшен куеп торып, бу очрашуларга мине ягымлы, ачык йөзле, сүзгә тапкыр Альберт Шәйхуллович Ситдыйков — идарәнең партоешма секретаре озатып йөрде. Казан университеты шәкерте, төп һөнәре белән геолог, ул җир катламнарын гына түгел, кеше күңеле тирәнлеген дә бик яхшы белә.

Әлбәттә, мине беренче чиратта җәлилчеләрнең бүгенге тормышы, бүгенге хәлләре кызыксындырды. («Җәлилчеләр» дип аларны атау күңелгә үк рәхәт!) Әлбәттә, һәр очрашкан кеше белән без бүгенге көннең иң зарур проблемалары турында сүз алып бардык. Мин, сүз арасында гына дигәндәй: «Ә теге вакыйгаларны, салкынны, сусызлыкны онытмадыгызмы?» — дип сорап куйгаладым. Булып узганнарга бүгенге кешеләрнең мөнәсәбәтен белү дә кирәк иде миңа. Узганнарны онытырга ярамый, тарих сабак ул, узганнар киләчәккә юл ярырга ярдәм итә.

Әлбәттә, бары тик шул көннәргә бәйләнешле вакыйгаларны белергә теләп кенә очраткан иптәшләр дә байтак булды...

Ниләр булган соң ул кышта?..

Җәлил — яшь поселок. Нигезе 1964 елда гына салынган. Яшь шәһәрләрдә, кагыйдә буларак, бала-чага ишле була, яшь әниләр көнләшә-көнләшә, ярыша-ярыша, бәби ташыйлар. Бала-чага ишле җирдә Яңа ел бәйрәме иң хозур, иң матур бәйрәм! Техника йорты каршысында поселок бәйрәменә баш булып, күзләрнең явын алып, аллы-кызыллы утлары белән балкып купшы чыршы утыра. Әти-әниләр култык асларына нәнирәк чыршылар кыстырып, өйләренә ашыгалар. Мәктәпләр бизәлә, йортлар бизәлә, кибетләрдә ялтыравык табалары биеп тора, уенчыклар залында чират!.. Эш урыннарында да җанлылык. Һәркемне ел йомгаклары кызыксындыра. Һәркемнең телендә «план, үтәлеш, премия» сүзләре. Кич ләрен шәһәр өстендә бихисап йолдызлар кабына. Күге тыныч, тормышы мул, күңелләре көр җәлилчеләрнең. НГДУда саныйсы саналган, исәпкә алынган. План үтәлә! Көннәр ифрат салкын, төннәрен тагын да ныграк суыта, урамнарга куе-тыгыз томан җәелә, кар шыгырдаганы әллә каян яңгырап ишетелә. Вахта машиналарының тавышы үзгәрде, алар ниндидер, күренми торган, тоташ стенаны аударып алга кыймылдыйлыр төсле. Иртәләрен салкынлык куера, кояш тирәсендә «алка»лар җемелди. Термометрдагы кара-көрән сызык төшә-төшә дә бөтенләй күздән югала. Әйе, нефтьчеләрнең кышның төрлесен күргәннәре бар. Әйе, һәр кыш аларга әллә ни кадәр санап бетергесез өстәмә мәшәкатьләр тудыра, зыян сала. Нефтьчеләрнең исе китми, чөнки эштән соң аларны җылы өй, кайнар аш, хөрмәтле түр көтеп тора.

Бүген якшәмбе булса да, эш дәвам итә, җаваплы урыннарга ышанычлы кешеләр куелган, тәҗрибәле шоферлар теләсә кайсы юлга чыгып китәргә әзер. Катлам басымын саклау, транспорт һәм электроцехларда гына киеренкелек гадәттән тыш ныграк сизелә. Чөнки «Татнефть» берләшмәсеннән дә, ЦИТСтан да тәшвишле, хәвефле хәбәрләр килә башлады. «Сак булыгыз, чарасын күрегез: гадәттән тыш суыклар көтелә!» «Кайбер скважиналарның туктау фактлары бар». Әле куркырлык хәл юк, андый гына аварияләр еш булып тора. Авария бригадалары чыгып китә тора, кабельләрне ялгыйлар, насосларны кузгаталар, скважиналар тагын гөләп эшкә тотына.

Тик монысын, бу кадәресен беркем дә көтмәгән була. Бәла бөтенләй көтелмәгән яктан килеп чыга... Ул сыналулы көннәрнең шаһиты, ул чакта поссовет председателе булып эшләгән Азат Исхакович Исмәгыйлевне тыңлап карыйк.

— Хәзер мин башка эштә. «Тәҗрибәң кирәгеннән артык күп, утны-суны гына түгел, утсызлык белән сусызлыкны да кичергәнең бар», дип, мине НГДУның укыту комбинатына директор итеп күчерделәр. Лаеклы алмаш әзерләү өчен тырышабыз.

— Ә сез теге кышны онытмадыгызмы? — дип бүлдердем мин аны.

— Юк, онытмадым. Онытырга ярыймы соң? Поселокка Җәлил исемен бик белеп кушканнар дип уйладым мин ул көннәрне! Халык бик бер дәм бездә, эшчән. Күбесе шушы як кешеләре. Сарманнан, Әлмәттән. Читтән килгәннәр дә байтак. Руслар, украиннар, чувашлар — бер туганнар булып беттек. Халыкның тормыш дәрәҗәсе, көнкүреше поссоветта аермачык күренеп тора ул. Кыенлык килгән очракларда кешеләрнең гади көннәрдә күренеп бетмәгән сыйфатлары да ачыла. Кешенең генә түгел, эш-хезмәтнең дә моңарчы беленмәгән яклары килеп чыга. Мәсәлән, без ни өчен сусыз калдык? «Где тонко, там и рвется», ди рус халкы. Ни өчен котельня сафтан чыкты? Генплан буенча бездә ике резервуар төзү эше каралган икән. Аның берсен нигәдер салырга «оныткан нар». Бәла юк чакта без дә аңа игътибар итмәгәнбез. Иң әүвәл Зәй ГРЭСыннан электр килү тукталды. Акташтагы өченче су үткәргечтә на-

сослар туктады. «Җәлилнефть»нең промысел һәм хуҗалык объектларын, поселокны су белән тәэмин итүче Бикәсаз станциясе дә тынды... Резервуардагы су кимегәнне котыбыз чыгып күзәтеп торабыз. Башка бөтен расходларны туктатып, суны бары тик пар казаннарына гына җибәрә башладык. Инде иң соңгы авария запасларыбызны озатып бетердек. Электр энергиясе озакламый килә башласа да, насослар байтак вакытка хәрәкәтсез калды. Ниһаять, безнең резервуар бөтенләй бушады.

Нишләргә? Чараның иң алдан кайсысына керешергә? Җылы йөри торган магистраль торбаларны, стоякларны, меңләгән батареяларны ничек итеп туңудан саклап калырга? Су кайчан булыр? Бер сәгатьтәнме, әллә бер тәүлектәнме?.. Әлегә бик күпләр бәла килгәнне белмиләр. Йортларда бәйрәм шатлыгы! Йортларда бик күпләр кичке бәйрәм табынына утыралар. Һәркемдә кунаклар! Өйләр тулы бала-чага! Тиздән-тиздән бәла килгәнне һәркем үзе татып караячак, салкын-явыз акрынлап йортларга үтеп керәчәк! Инженер-техник хезмәткәрләр, коммунистлар, поссовет депутатлары, активистлар НГДУга җыелдык. Нефть объектларын салкыннан саклау өчен бер штаб, поселокны һәм көнкүреш объектларын коткару өчен икенче штаб төзелде. Беренче штабның башлыгы итеп НГДУ начальнигы Тәхәветдинов, икенчесенең җаваплы кешесе итеп аның урынбасары Шубин билгеләнде.

— Иң беренче эшләрегез ни булды? Каян башладыгыз?

— Халык массаларын паникадан, куркып-каушап калудан сакларга кирәк иде.

— Халыкка ничек мөрәҗәгать иттегез? Радио ашамы?

— Юк. Депутатлар, активистлар, партия членнары үзләренә билгеләнгән йортларның һәр квартирасына кереп, халыкны өмәгә чакырдылар. Әйе, өмәгә. Беренче катларны, подвалларны кар белән күмеп, аз булса да җылылыкны сакларга кирәк иде безгә. Кешеләр бәйрәм мәҗлесләрен ташлап, кырык градустан ашкан суыкта кар көрәргә чыктылар. Икенче эш — больница! Шул ук төнне авыруларны инде суынып өлгергән палаталардан аерым квартираларга күчердек. Бар булган электр приборларын исәпкә алып, аларның барысын тоташтырдык. Алар эшләп торганда, квартираларда җан сакларлык кына җылы бар иде әле. Операция чираты җиткәннәрне, бәби табарга тиешле аниләрне Әлмәткә, Сарманга озаттык. Кеше эштә танылa, ике ай элек кенә баш врач итеп билгеләнгән Әдип Ибраһимовны һәм аның коллегаларын күрсәгез иде сез! Бернинди каушау, зарлану юк. Зар дигәннән, чын, ул көннәрдә зар ишетмәдек. Поселоктагы ун меңгә якын кешенең язмышы, эше, саулыгы НГДУ кулында иде. Меңнән артык скважинаның һәммәсе сусыз хәлдә салкында калганнар иде... Йортларда, подвалларда дежурлык бер генә минутка да өзелмәде. Тәүлек буе вахтада булып, туңып-арып кайткан нефтьчеләргә кайнар аш пешерерлек су үткәрергә, җылы үткәрергә кирәк иде. Подвалларда паяльный лампалар эшләтәбез, аларны бөтен «Татнефть» берләшмәсеннән җыеп алып кайттык. Дизель ягулыгы белән эшләүче машиналар кабына алмый интегә, шоферлар ягулыкка бәйрәмгә алып кайткан аракыларын кушып җибәрәләр. Һәр стояк янында диярлек дежур слесарьлар тора, торбаларны иске-мосКы белән төреп, солярка сеңдереп яндырып җылытабыз. Котельняга су кичке тугызларда гына килеп җитте. Хәзер системага җылы бирердән элек, квартираларны йөреп чыгарга, һәр батареяны ныклап тикшерергә кирәк иде. Кемнәрдер кунакка киткән, ишекләр бикле, форточкалар ачык калган.

Батареялардан суны төшереп бетердек дип юкка тынычланганбыз. Генпланда каралган тагын бер мөһим чылбырның өзеклеге килеп чыкты. Суны химик юл белән эшкәртеп, кислородын киметеп торбаларга озата торган «диаэроционная җайланма» дигән нәрсәне проекттан нигәдер төшереп калдырганнар икән. Менә сиңа мә! Су йөреп торган батарея-

ларның аскы өлешенә калын булып ләм утырган иде! Яртылаш лай утырган батареяларның илле проценты шытырдап каткан булып чыкты...

Шартлаган батареяларны, торбаларны тизлек белән алыштырырга кирәк иде. Җәлилгә берләшмә җитәкчеләре килде. Торба, кирәкле материаллар төягән машиналар агылды. Сварка эшләре өчен карбид җитми башлады. Карбидны, беләсезме, җәһәннәмнән, Караганда шәһәреннән барып таптык!

Квартираларда туктаусыз газ яна, электр приборлары эшли. Газ җитми башлагач, өстәмә подстанцияне тоташтырдык. Янгын куркынычы да, газ белән агулану куркынычы да бар иде. Өйдән-өйгә, квартирадан-квартирага гел йөреп тордык. Салкыннарга күз ачкысыз кара бураннар ялганды! Җәлил — җил оясына урнашкан поселок. Елның 250 көнендә көньяк-көнбатыштан өзмәс җил өреп тора.

Хуҗалык йомышларына суны кар эретеп булдырсак та, ашарга-эчәргә су каян алдыгыз дисезме? Бензовозларны пар, кайнар су белән кат-кат юып, цистерналарда эчәр су ташыдык. Поселоктан ерак та түгел урман эчендә чишмә бар икән, кемдер шуны белеп алган, чиләк-чиләк аннан су ташый башладылар. Җил кешеләрне аяктан ега, өчәре-дүртәре тотынышып баралар...

Александр Кириллович Шубин — НГДУ тарафыннан билгеләнгән штаб начальнигы кайларда гына булмады ул көннәрдә! Машиналар кабынмаса, ул анда. Торбалар вакытында килеп җитмәсә, ул анда. Әле генә больницага кереп бара иде, икенче карасаң, кибеттән чыгып килә. Котельняларда, мәктәпләрдә, НГДУда... Миңа да йокы тигәне юк. Хатын белән өч-дүрт көннән соң гына очраштык. «Яңа ел котлы булсын!» дим. Ул, коты чыгып, миңа караган. «Сиңа сары төшкән бит, күзләреңне күр әнә!» ди. Юк, сары ук төшмәгән иде, сөрем-төтеннән, сварка утыннан, йокысызлыктан барыбызның да күзләренең төсе үзгәргән иде.

Пенсионер коммунистлар бик нык ярдәм итте. Менә Нәҗип агай Дәүләтшин, элек колхоз председателе булып та эшләде, соңрак Райфо мөдире булды. Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны. Ничәмә-ничә квартирага кереп, җылы сүз, тәмле теле белән ничаклы кешеләрнең сынык күңелен күтәрмәде ул! Ә йортларда төрле хәлләр, төрле язмышлар бар, имчәк балалары, хәлсез авырулар...

Халыкны күчерү турындагы уй күңелгә кереп тә карамады. Халыкның шул кадәр дәррәү, бердәм булып эшкә керешүе, дәрте, егәре ничектер ул турыда сүз кузгаттырмады. Андый сүз, андый тәкъдим кешеләрне җәберләү булыр кебек тоелды. Бик күпләр чын күңелләрен биреп, авырлыкны җиңеләйтергә тырыштылар. Алай да ике кеше турында аерып әйтәсе килә. Аларның берсе НГДУның партоешма секретаре Альберт Ситдыйков булса, икенчесе икмәк ташу машинасы шоферы Газизә Нуриева.

Альберт Шәйхулловичка бер төп сыйфат хас — ул нәкъ кирәгендә иң кыен урынга килеп чыга белде, нәкъ кирәгендә сүзен тапты. Эш туктал калган чакларда да, ул килеп чыккач, күңелләр үзеннән-үзе күтәрелә, дәрт өстәлә иде. Ә Газизә Нуриеваны бөтен поселок «туендыручыбыз!» дип атый. Хәзер дә аны шулай дип йөртәләр. Хаклы исем! Без икмәкне Азнакайдан яки Актүбәдән ташыйбыз. Газизә ханым көненә ике рейс ясый. Көндезгә 12 дә һәм кичке 5 тә алып кайта. Шушы режимнан чыкмас өчен ул салкын буранлы көннәрдә ничек тырыша иде. 1972 елдан бирле НГДУ Орсында эшләп хөрмәт казанган бу ханым ул көннәрнең героена әверелде! Пөхтәдер үзе, матур киенә, тырыш, уңган. Иң әшәке бураннарда да юлын табып, җаен табып, кайда урагын ишегалларыннан үтеп, кайда машинасын трактордан сөйрәтеп, икмәкне вакытында алып кайтып торды.

Насос станцияләре эшли башлады, котельнябыз җанланды. Без

әкренләп йортларга су, җылы бирә башладык. Куркыныч безнең өчен узып бара иде инде...

Исмәгыйлов белән очрашканнан соң минем Александр Кириллович Шубинны күрәсем килә башлады. Очрашкан һәрбер кеше аны «тылсымчы ул, чын тылсымчы!» дип яратып атады.

Александр Кириллович терекөмеш кебек җитез, ачык чырайлы, көләч кеше икән. Мин аны, кылган гамәлләренә карап, өлкәнрәк яшьтә дип күз алдына китергән идем, юк, яшь икән, яртә яшьләрдә генә. «Ничек булды? Ничек таптыгыз? Ничек кичереп өлгерттегез?» дигән сораулары аны гаҗәпләндерде. Александр Кириллович күзләрен зурайтып, беравык миңа карап торды.

— Башкача ничек булуы мөмкин соң? — дип, ул сорауга сорау белән җавап бирде.— Без бит нефтьчеләр. Табигать белән ел тәүлегенә көн саен очрашып, көрәшеп яши торган кешеләр. Башка һөнәр ияләре үпкәләмәсен, әмма нефтьчеләр үзгә камырдан әвәләнгән затлар!

Соңыннан да мин җәлилчеләрнең, гомумән, Әлмәт ягы кешеләренең «нефтьчеләр без» дип аерым басым ясап әйтүләренә игътибар иттем. «Без колхозларның хәлен аңлыйбыз, чөнки без — нефтьчеләр», диде юлда бер иптәш. Нефтьче дигән сүз һөнәр, профессия иясен белдерүче берәмлектән тыш, әчке, тирәнрәк һәм киңрәк бер мәгънә алган, бу исем нәселдән-нәселгә күчеп, горурлыкны да, җаваплылыкны да, мактанычны да, туганлык җепләрен дә аңлата икән! «Без нефтьчеләр һәм башкача булуы мөмкин дә түгел!» — диде Шубин беренче сүзеннән үк. Аңа ышанмыйча мөмкин түгел иде.

— Без поселокның үзендә генә тәүлеккә ун мең кубометрдан артык су кулланабыз... Ул көнне су кичкә кадәр бөтенләй булмады. Котельня иртәнге сәгать тугызда туктады. Катастрофаның күләме 2 январьда иртән генә тулаем мәгълүм булды. Һәм, ышанасызмы, шушы бер көн эчендә, без торак йортларның туксан процентын коткарып калдык. Без кереп карамаган бер генә квартира да калмаган иде. Газосварщиклардан ун звено төзедек, аларга ныклы график булдырдык. Алар һәр йортта, һәр подъездда иң элек бер рәт квартирларны җылытып чыктылар. Күршеләр шул квартирларда яшәп торды. «Нигә минем квартираны алдан җылытмыйсыз?» дип дәгъвалаучылар булды, ләкин алар телгә дә алмаслык аз иде. Сварщикларны бәйрәм сые белән кызыктырып, ярты куеп юлдан яздырырга маташучылар да булгалады, әмма гомуми тәртип бозылмады! Олылык хөкем сөргәндә, вак-төяк белән алданулар оят бит ул!.. Суыкны күрдек, әмма җылылыгы да җитәрлек булды! Кайнар иде безнең өчен көннәр!.. Ә Җәлилдә кышын гел салкын була. Әлмәткә шалтыратасың, «суык» дип зарланасың, ышанмыйлар.

— Бу юлы ышандылармы соң?

— Бу юлы ышандылар! — дип көлә Шубин...

Больницаның баш врачы озынча буйлы, ябык, какча кеше. Озын бармакларын тезе өстенә куеп ял иттерә. Хирург икән. Дөресрәге, универсаль врач, «балалар врачы да булырга туры килә, башкасы да!». Әдип Ибраһимовка кырык биш яшь.

— Салкыннар штурм башлаганда, бездә туксанга якын авыру бар иде. Күбесен өйләренә яки уңайлырак квартирларга урнаштырдык. Врачлар, бер көн калдырмыйча, алар янына барып дәвалап йөрделәр. Больницабыз салкыннан бик зур зыян күрде, торбаларның күпчелеге эштән чыкты, стояклар шартлады. Эш шул кадәр җитдигә әйләнде, белгечләр, «май урталарына ремонтны тәмамлый алсагыз — сөенегез!» диделәр. Ярты елга больницаны ябу куркынычы туды... Больница сафтан чыккач, миңа бәләкәй генә шок булды, гадәттән тыш салкыннарда, грипп башланса нишләрбез дип курыктым. Чәч агарды, бигрәк тә уң як чигә чалары... Халык арасында салкын тидерүчеләр булгалады, әмма чир таралмады, грипп ябырылмады. Мин моны халыкның югары рухы, киерен-

ке хезмәте белән аңлатам. Чирләргә беркемнең дә вакыты юк иде. Безнең медперсоналны гына алыйк. Арадан элек буяучы, штукатур, слесарь булып эшләгән кешеләр табылды. Яңа «һөнәр ияләре» барлыкка килде: врач-слесарь, сестра-штукатур һ. б. Үз көчебез белән кыска арада больницаны аякка бастырырга булдык. Партком секретаре Альберт Шәйхуллович торбалар табарга булышты. Көне-төне чабабыз, ә һәркемнең өендә үз проблемалары бар! Берәүнең дә өе ягылмаган! Мәсәлән, минем квартирда малайлар көне буе хоккей уйный. Телевизорны капка итеп, бер-ике шайба кертеп куймасалар ярар иде дип, хатын белән очрашканда сөйләшеп алабыз... Киеренкелек югары рух, коллективизм хисе тудыра. Безнең халыкка бердәмлек рухы бик нык сеңгән икән! Элегрәк иптәшләр арасында үзара тарткалашып алулар да була иде, ул көннәрдә хезмәт дисциплинасы ныгыды, бер-беребезгә хөрмәт артты! Чын күңелдән бер җан булып тырыштык һәм 25 январьга беренче авыруларыбызны больницага кабул иттек! Үзенә күрә олы бер җиңү, бәйрәм иде бу...

Шубин һәм Ибраһимовлар белән очрашканнан соң, мин шундыйрак фикергә килдем: әйе, авыр хәлләрдән дә тормыш мәгънәсе табып була икән. Коллективлар авырлыкта, кыенлык килгәндә тагын да ныгып, көчәеп калганнар. Совет кешеләренә хас бу гүзәл сыйфатның тормышыбызның мәгънәсе, яме һәм мактанычы булуына Җәлилдә тагын бер тапкыр инандым.

## 7. Ул да Әлмәт ягы егете...

«Җәлилнефть» идарәсенең начальнигы Шәфагать Фәхразович Тәхәветдинов белән без берничә көн дәвамында очрашып, аз-маз фикер алышып йөрсәк тә, тиз генә ныклап бер утыра алмадык. Ел ахыры җиткән көннәр. Идарә начальнигының һәр сәгате генә түгел, һәр минуты исәпләнгән булып чыкты. Берләшмәгә дә чакырып алалар, аңлыйм, ел азагында кичектермәс уртак мөһим мәсьәләләрне хәл итеп калырга кирәк. Идарә интереслары берчакта да берләшмә интересларыннан аерыла алмый. Ә республикабызда гына түгел, илебездәге иң эре производство берләшмәсенең ел азагына хәл итәсе мәсьәләләре байтак җыела. Идарәдә дә эшләр шома гына бармый. Мин барында, мәсәлән, Уфадан бензин төягән цистерна вагоннар килеп җитмәде. Җәлилдән Бөгелмәгә, Чаллыга киткән дәү-дәү машиналар ике көн рәттән буш әйләнеп кайттылар. Мәсьәлә бик җитди, үтә борчулы һәм тиз арада хәл итүне таләп итә иде. Идарәнең үзендә запас чикле... Бензин менә-менә бетәргә тиеш. Вахта машиналары, ашыгыч ярдәм, янгын, авария машиналары бар... Ул ике көндә мин Шәфагать Фәхразович янына керергә кыймадым. Урта буйлы, базык тәнле, кара тутлы йөзле, житез хәрәкәтле иптәш бу ике көндә сирәк елмайгандыр...

Кичләрнең берсендә мин аңа үзем алданрак әзерләгән «сораулыкны» тапшырдым, «мөмкин булса, уйлана торыгыз!» дидем.

Ниһаять, кичләрнең берсендә, тагын да мәшәкатьлесендә, без аның эш бүлмәсендә икәүдән-икәү генә калдык. Тәэминатчыларның «йоклап калуы» аркасында, бензин һаман килеп җитмәгән, бар булган запасны куллану хокукын НГДУ начальнигы үз кулына алган иде, шуңа күрә безнең әңгәмәнең өзелүе мөмкинлеге бар, «бензин мәсьәләсе» нефтьчеләр өчен бик нык кискенләшкән иде. Алай да Шәфагать Фәхразович тыныч күренде, кулында минем кәгазь. Сорауларга номер сукмаган идем, ул «буш вакытыгыз ничек уза?» дигән сорауга зур итеп «берле» саны куйган иде.

— Ни өчен «беренче»ме? — диде ул.— Буш вакыт безнең иң авырт-

кан җиребез. Алда бу мәсьәлә тагын да кискенләшәчәк әле! Сүз бер минем генә буш вакытым турында бармыйдыр дип ышанам. Әйе, хезмәт белән буш вакыт аерылгысыз бәйләнгән... Инде килеп әйтсәк, мин шушы төбәктә, Әлмәт районында тудым. Габдрахман авылында. Нефть безнең буын өчен бер чакта да ерак хыял булмады, ул безнең көндәлегебез, чынбарлыгыбыз иде. 1953 елда, беренче класста укыганда, беренче тапкыр буровойга бардык. Экскурсиягә. Буйга бик кечкенә малай идем әле. Зур-зур абыйларның дәү, мәһабәт манара тирәсендә бер дә каушамыйча, курыкмыйча эшләп йөрүләрен күреп хәйран калдым. Салам түбәле өйләр арасыннан кем нинди олы юлга чыга бит, бераүләр зур шәһәрләрне күреп, иң көчле тәэсир алып кайта, икенчеләр диңгез күреп шакката, ә безнең янга тәэсирләнерлек нәрсә — нефть үзе килде. Габдрахман мәйданын эшкәртә башлаган чак иде. Безнең авыл басулары гүләп-гөрләп торды. Кыскасы, без нефть белән бергә үстек. 1963 елда, диплом яклар алдынан, практиканы «Туймазынефть» трестында слесарь булып башладым да, бораулаучы ярдәмчесе булып тәмамладым. Ике елдан, Октябрьск нефть техникумын тәмамлап, Әлмәткә эшкә кайттым. «Әлмәтбурнефть» трестының өченче бораулау конторасында бораулаучы булып эшләдем, аннан производство бүлегендә өлкән инженер булдым. Шуның белән «бораулау эшләрен»дә минем миссиям тәмамланды. Нефть чыгара башладым. Башта оператор идем, аннан җир асты ремонты мастеры, скважиналарны ремонтлау цехы начальнигы урынбасары, катлам басымын саклау цехы начальнигы, кыскасы, тугыз ел гомеремне нефть чыгару эшенә багышладым. Байтак баскычларны уздым, һәр эшне үз кулларым белән башкардым, һәр процессны үз күзем белән карап үткәрдем. Җитмеш сигезенче елның апрелендә чакырып алдылар да... «Җәлилнефть» идарәсенә җитәкче итеп билгеләделәр. Эшкә хирыс идем! Сүз арасында әйтеп узыйм, алтмыш тугызынчы елны өйләндем. Өйләнгәнче «буш вакыт» турында уйлап та караганым булмагандыр! Өйләнгәч, belә башладым. Анда да, «бүген җиңеләя эш, иртәгә җиңеләя» дип, үзеңне һәм өйдәгеләрне ышандырып йөрисең. Ә табигать, нефть, скважиналар, кайсы гына тармакта эшләсәң дә, гел яңа, көтелмәгән хәлләр китереп чыгара. Буш вакытны уртак итәр өчен хатыным Венера белән читтән торып нефть институтын бетердек. Ул да хәзер дипломлы инженер, производство бүлегендә эшли. Улыбыз Рөстәмгә — унбер, кызыбыз — Светланага биш яшь...

Идарә начальнигы итеп билгеләнгәч, Венера «инде хәзер эшең беркайчан да бетмәс», дип куйды. Мәгәр зарланмады, «Көчеңә ышансаң, алын! Мин сиңа ярдәмче булырмын!» — диде. Моны нигә аерып әйтәм дигәндә, гаиләдәге дуслык, ышаныч, бер-береңә хөрмәт — әлеге дә баягы «буш вакыт»ка бик нык бәйләнгән! Хезмәт кешесенең гаилә ныклыгы дөрес яшәү өчен бик кирәкле! Әгәр кеше өендә дә җан тынычлыгы тапмаса, харап аның тормышы!

Коллектив һәм җитәкче. Мин моның әһәмиятлелеген яшьтән үк сизенеп килә идем, зур коллектив белән җитәкчелек итә башлагач, бу мәсьәләнең «девон ятмаларына» төшеп җитә яздым... Беренчедән, сиңа кадәр коллективта байтак җитәкчеләр эшләп киткән була. Кешеләрнең эш стиле һәрвакытта да бер төсле булмый. Була да алмый. Заман, технология үсеше һәм башка бик күп сәбәпләрдән тора ул эш стиле. Җитәкченең шәхси сыйфатлары да мөһим урын тота. Мин килгәнче, идарәнең эшендә еш кына өзеклекләр булып алгач, план үтәлмәгән. Әмма эшне кабул итеп алгач, мин үземә кадәр эшләгән иптәшләрне тәнкыйтьләүдән башламадым. Аларны телгә дә алмадым. Алар калдырган мирасны кабул итеп алгач, анализ ясагач, үткәндәге кыенлыклар белән үз хәлемне җиңеләйтергә, зарланырга тотынмадым. Эшкә тотындык. Нефтьче хезмәте тәүлек буе, айлар-еллар буе тукталып тормый. За-

вод-фабрикаларда эш никадәрле катлаулы булса да, бер урынга тупланган, ә нефть промыселлары кайдан-кая җәелгән, объектлар таралып утырган. Автоматлаштырылган идарә пунктлары әле төп бурычларын үтәүгә ирешмәгәннәр, кыяр-кыймасрак кына үсеп киләләр.

Ныклы ритм булдыруның җиңел түгеллеген белә идем. Иң элек шуны сиздем: идарәнең артта калуы һәм план өзелү белән кайбер звено җитәкчеләре килешеп яши башлаганнар. Байтак иптәшләр, отчет бирер вакыт җиткәч, җыйналганнар да, баш кашып, «каян, кемнән нефть алып торабыз инде?» дип аптырашып утырганнар. һәрбер җитәкче, һәрбер нефтьче, кайсы тармакта утырса да, үз көчен сизәргә, үз көченә ышанырга тиеш иде! Коры сүз белән генә ышандырып булмый, яңа технологик алымнар кертергә, кыю рәвештә ярыш утын кабызырга кирәк иде! Мин килгәнче, идарәдә «коры кеше, усал» дигән хәбәрләр таралган иде. Ишеттерделәр! Мин бу хәбәрне юкка чыгарырга ашыкмадым, усаллык белән дә алдырырга тырышмадым. Белгечләр, мастерлар белән һәр скважинаны диярлек күздән кичереп чыктык. «Нефть бар, ятмалар тере, ала белергә генә кирәк!» дигән уртак карарга килдек. Иң мөһиме: нефть бар! Алда торган бурычларны чишү — безнең эш! Андый-мондый юк сәбәпләр табып, авырлыкны башкаларга йөкләмәскә, артка чигенмәскә! Менә минем максат шул. Мин моны иптәшләрдән яшермәдем. Кешеләр үзләренә дә, миңа да ышанырга тиешләр иде. Әтием Фәхрази, аңа хәзер җитмеш яшь, «тормыш үзе университет ул, балам, үзе өйрәтә!» дип кабатларга ярата иде. Тормышны университет дәрәҗәсенә күтәрә белергә генә кирәк. Меңләгән нефтьчеләрне берләштергән коллектив белән яңачарак тәҗрибәләр үзләштерә башладык. Югары, күкертле горизонтларны эшкәртә башлаган идек. Көткән нәтиҗәләргә ирешә генә алмыйбыз бит! Скважинага насосны төшерәбез, бер көн эшли, ике — яна! Берне төшерәбез, икене. Яна! Бу ни хикмәт? Бүгенгедәй хәтеремдә номеры да: 15 848 нче скважинага киттек. Теңкәгә тигән скважина! Ачыкланды: насосларны нефть чыга торган катламнардан әскарак төшергәннәр! һәр скважинаның үз холкы бар, һәр скважинаның насос төшерү тирәнлеген, режимын табу өчен атналар буе промыселларда яттык. Атналар буе өйгә кайтмадык! Күкертле нефть чыгаруны бермә-бер көчәйттек. Май аенда тәүлеккә алты йөз тонна нефть ала башладык. Әлеге скважина 30 тонна урынына 120 тонна бирде.

Икенче проблема — җир асты ремонты мәсьәләләре. Җитди проблема! Яхшыртырга кирәк, яхшырту — кадрлар белән ныгыту дигән сүз дә иде. «Югары сыйфат бригадалары» оештыра башладык. Өметебез артты. План үтәлә башлаган атналарда, 16 нчы июнь көнне Җәлил өстеннән давыл узды. Кырыктан артык электр баганасы ауды, кабельләр өзелде. Эш тукталды. Якшәмбе көн иде. Июнь. Халык таралган Бөтен транспортны күтәреп, электрикларны аякка бастырдык: «Идарә эшенә куркыныч яный!» Белгечләрнең, эшчеләрнең намусын, ныклыгын, эшкә бирелгәнлеген сыный торган кискен моментлар була. Бу да шуларның берсе иде. Авария китергән зыяннан ике тәүлектә котылдык. Мондый бердәм коллектив белән зуррак максатлар да куярга мөмкин икәнлегенә көннән-көн ныграк ышана бардым.

Еллык планны үтәп килгәндә генә, ел азагында, көтелмәгән, күрелмәгән салкыннар килде. Суыкларга әче бураннар ялганып китте. Табигать кышның кыш буе безнең җанны алырга тырышты! Сез ул вакыйгаларны беләсез, бик күп кешеләр белән очраштыгыз. Мин җәлилчеләрнең ул кыштагы яшәешен батырлык дигән олы бер сүз белән генә атар идем. Кышкы суыклар, аварияләр безне тагын ритмнан чыгардылар. Тик без аптырап калмадык. Планны дүрт ай үти алмасак та, аннан ныклы графикка кердек, үтәлми калган әҗәтләребездән дә котылдык.

План үтәлү — коллективның көчен ныгыта. Авыр сынауларда мин

шуңа ышандым. Бер мин генә түгел, иң мөһиме, моңа коллектив ышанды. Моның беренче дәлиле — планны тотрыклы үтәп баруыбыз булса, икенче дәлил — кадрларның эштән киту-китмәү мәсьәләсе. 1977 елда эштән китүчеләр саны, идарә буенча, 17 процент булса, 1980 елда бу сан ун процентка төште.

План үтәлеше — коллективның мөмкинлеген дә арттыра. НГДУ каршында ярдәмче хуҗалык оештырдык, дуңгызлар симертәбез, хәзер фермабызны ныгытабыз, киңәйтәбез. Кибетләрдә сөт, май, ит өзелми диярлек. Озак еллар идарәдә эшләгән алдынгылар өчен уңайлы коттеджлар салабыз, торак фондын арттырабыз. Менә дигән санаторий-профилакториебыз бар...

Дөрес, яшәү уен түгел, тормыш итү беркемгә дә җиңел генә бирелми. Ә яшьләребез арасында бик тиз җиңеллеккә омтылырга теләүчеләр бар. Ул бер кулы белән эшкә керешергә гариза язса, икенчесе белән һәйбәт квартир таләп итеп кәгазь тотыра. Без сигез квадрат метрлы бүлмәдә бәби үстердек, хатын белән икебез дә кичке институт тәмамладык. Зарланмадык. Әйе, хак, хәзер нефтьчеләрнең белем дәрәҗәләре үсә, тормыш шартлары күзгә күренеп яхшыра. Үзгәрешләр бик нык сизелерлек булса да, кеше һәр очракта да кеше булып калырга тиеш. Җитешсезлекләр һәркемдә дә бар. Кеше башкаларныкын гына түгел, үз җитешсезлеген дә күрә алсын. Моның өчен көч кирәк. Үз җитешсезлегеңне күрә алу — үзең белән үзең көрәшү ич ул! Эш яраткан кешене олылыйм. Булсынга дип йөргән кешеләрне олылыйм. Ил төкерсә, күл була — массалар бер фикердә тырышканда, фикер көчкә әйләнә. Коллективны бер фикергә китереп җиткерү җитәкченең төп бурычларыннан берсе дип саныйм. Җитәкче кешенең эше, тормышы, гамәле, мөнәсәбәте һәммә кеше өчен үрнәк дәрәҗәдә булырга тиеш. Шуңа ышанам, шуңа омтылам. Шәхси мисал, ышандыра алу көче, кирәк чагында нык куллы да булу — болар безнең эштә бик зур әһәмияткә ияләр.

Эш — яңалык ул. Бүгенге көн кичәгегә охшамаган. Аның иртәгесе бүгенгегә охшамасын дисәң, уйларга, эзләнергә, табарга туры килә. Чыгарыла торган нефтьнең һаман сулана баруы өр-яңа проблемалар тудыра. Күкертле нефтьне тоздан һәм судан арындыру иң катлаулы эшләрнең берсе булып санала. Күкертле «кара алтын»ны чыгаруның күләме арткан саен хәл тагын да кискенләшәчәк. Элек без күкертле нефтьне турыдан-туры Әлмәткә озата торган идек. Күпме көч, энергия сарыф ителә иде. Хәзер үзебездә чистарту җайланмасы өлгерттек. Тәүлек саен дүрт мең ярым тонна «кара алтын»ны әзер килеш озатабыз. Әлмәттәге куәтләрнең киеренке эшен киметтек. Установканы, Үзбәк Газизович идеясен тормышка ашырып, үз көчебез белән башкардык. Баш инженерыбыз Нигъмәтуллин Ш. Ш., баш технолог Каюмов Р. К., автоматлаштыру цехыннан Кузьмин, Әфләтүнов, Шәрипов иптәшләр зур эш башкарды. Тормыш бары тик җиңү баскычларыннан гына тора.

Инде хәзер «буш вакыт»ка тагын әйләнеп кайтыйк... Буш вакытым калса, улым, кызым белән булырга тырышам. Кармак салып, җылы җирдә яр буенда утырырга яратам. Янган утка һәм аккан суга карап, әллә ниләр уйлап бетерергә була! Үз тормышымны нефтьтән башка күз алдына китермим. Атналар буе арып эшләгәндә төннәрен төш күрергә дә вакыт юк. Якшәмбе төшләреңдә дә гел нефтьне күрәм. Нефтьче булмасам, бу дөньяда ничек яшәр идем икән, дип сискәнеп уйлап куям. Нефтьче булуым белән горурланам. Менә икенче миллиард тоннага якынлашабыз. Илебез Татарстаннан ике миллиард кара алтын алачак! Мин моны үз тормышымдагы иң зур, мәңге онытылмаслык вакыйга дип саныйм. Татарстан нефте, нефтьчеләрнең хезмәте — олы бер могҗиза ул!..

Буш вакыт дигәннән, сүз бер минем турыда гына бармый дип киле-

шенгән идек. Технология процессы камилләшә барган саен, кул хезмәте азайган саен, коллективның буш вакыты гел арта торачак. Без коллективның буш вакыты белән идарә итәргә өйрәнергә бурычлы. Поселокта спорт, ял, күңел ачу урыннары бер-бер артлы ачыла, киңәя бара. Коллективның буш вакыты турында кайгырту — безнең иң төп бурычларыбызның берсе.



## 8. Йомгаклау сүзе

Ике миллиард тонна — буыннарның ил алдында йомгаклау сүзе дә ул. Җәлилчеләр арасында йөреп, мин иң әүвәл әнә шуңа инандым. Күз алдымнан «кара алтын» чыгаручыларның бик күп вәкилләре узды: татарлар, руслар, чувашлар. Якташлар, үз җиребез вәкилләре, читтән килүчеләр. Хәзер алар һәммәсе дә горур бер исем йөртә: җәлилчеләр. Мин аларның бүгенгесен күрдем, киләчәкләренә ышандым. Башта үзем очрашкан бик күп кешеләр турында бәйнә-бәйнә язып чыгармын дип ниятләгән идем, әмма җәлилчеләрнең эше, көнкүреше белән ныграк таныша барган саен, моның мөмкин түгеллеген күрдем. Нинди афәткә баш бирмәгән нефтьчеләрнең ул атналардагы яшәвен бер сүз белән атарга мөмкин — Батырлык! Җәлилчеләр минем күңелемне, уйларымны яңартып, тормышның кайнар сулышын өстәп озатып калдылар. Әлбәттә, алдагы тормышымда, әсәрләремдә ул батырлар, аларның газиз хезмәтләре чагылыш тапмый калмаслар. Алай да, менә бүген, зур тантаналар алдыннан, берничә кешенең исемен атамасам, күңелем почмакланмас кебек! Иң элек, үземнең чордашларым турында. Менә, ике дус — кордашлар, икесе дә коммунистик хезмәт ударнигы, нефть промышленносте отличниклары, икесе дә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры. Икесе дә 5 нче участоктан. Әмир Надыйров — беренче промыселда мастер, Муса Әхмәтгәраев — өлкән оператор. Беренчесе нефтьтә — 28 ел, икенчесе чак кына азрак — 26 ел эшләгән. Тоташ стаж. Күчмичә. Икеләнмичә. «Нефть өчен көчне җәлләмәдек»,— диләр алар бер авыздан. «Ничек иде? Хәзер ничек?! Аерма нәрсәдә?» дип белешәсем килә. Чөнки, менә алар, тарихны тудыручылар, хезмәт батырлары. Чирек гасыр гомерләрен һич икеләнмичә Татарстан нефтенә багышлаган кешеләр. Чәчләре чаларса да, яшь әле алар, кыяфәтләреннән көч-дәрт бөркелеп тора, сүзләре сайланып чыга, фикерләре төгәл, үткәннәре тәҗрибәгә бай.

— Без башлаганда һәр скважинага алты-җиде кеше хезмәт күрсәтә иде, — дип башладылар алар, берсенең сүзен икенчесе тотырып.— Хәзер алты-җиде кеше 100 скважина карыйбыз. 21-22 скважинага бер оператор. Элек парафин теңкәгә тия иде. Кыргычны сменага өч-дүрт мәртәбә төшермәсәң, бетте баш! Хәзер парафинны күргән дә юк. Торбаларга реагент җибәреп, юдыртып кына алабыз. Скважина тамагындагы бәйләвечне — манифуль сызыгы дибез без аны — парафин утыруга сүтеп ала идек. Шыплап тулган парафинны ваклап, тачкалар белән читкә ташып яндыра идек. Егерме бишәр тачка тәгәрәткән чаклар була иде. Һәр скважина янында күз көеге — факель янып утыра иде. Юллар начар, техника җайланмаган. Начальство да тракторга утырып йөри иде ул чакта! Шуннан китте үзгәрешләр, китте, өлгер генә! Юллар салынды, техника артты, төрләнәнде. Батырма электр насосларының өр-яңаларын уйлап чыгардылар. Хәзер алар икешәр, өчәр ел эшли. Безнең бишенче участок җитмеш тугызынчы ел планын арттырып үтәде. Берләшмә буенча беренче урынга чыкты. Ә авыр ел иде бит! Уңышның сере нәрсәдәме? Дөрес, техника белән коралллану үсә, үзгәрә, камилләшә тора. Юллар да әйбәт, эш шартлары да акрынлап алга

бара. Тәэминат әйбәтләнде! Менә дигән йортларда торабыз. Иң мөһиме — без алдынгы тәҗрибә белән коралландык. Тәҗрибә — узганнарга нәтиҗә генә түгел бит ул, алдан күрә белүчәнлек тә. Алдан күрә белүчәнлек эштә ышаныч, ныклык, төгәл график, ныклы планнар тудыра. Нефтьтә бик күп нәрсәләрне алдан чамаларга, тирәнтен күрә белергә кирәк... Киләчәккә ышанычыбыз зур. Шунысы да бар, без өч-дүрт елдан пенсиягә китәчәкбез. Участокта күбебез өлкәннәр. Яшьләр азрак, яшьләр җитми. Татарстанда нефть чыгаруның кимүе яшьләрне куркытмасын. Алдагы эшләребез дә бихисап! Мәсәлән, хәзер скважиналардан 50—60 процент су килә! Су өлеше алда тагын да артачак. Проблема-мы бу?! Нindие генә әле! Эзлә, ян, тырыш!..

Акыллы сүзләрегез өчен рәхмәт сезгә, кадерле чордашларым!

Эзләү һәм эзләнү. Табу һәм җиңү! Максатка ирешү. Ил тормышы белән янып яшәү. Бу — җәлилчеләрнең көндәлек тормышы. «Күкертле нефть чыгара башлау үзе генә дә күпме яңа мәшәкать өстәде,— дип башлады сүзен җир асты ремонты мастеры Наил Вәлиев.— Күкертле нефть клапаннарны ашый, торбаларны тизрәк туздыра, штангалар черек җеп кебек өзелә!.. Әллә никадәр яңа авырлык тудырды күкертле нефть. Инженерыбыз Ю. А. Закиров яңа насос эшләде. Алты скважинага аның ысулы белән әзерләнгән штангаларны төшердек, 6—7 ай өзелмичә эшләделәр. Тырышкан таба!» Наил Вәлиев КПСС члены, Остазлар советы члены, Татарстанның атказанган нефтьчесе, нефть промышленносте отличнигы.

Менә тагын бер ветеран. 1963 елдан — Җәлилдә. Гел нефтьтә. Кузьмин Геннадий Николаевич. «Поселоктагы беренче йорттан квартир алган кеше мин. Буйдак булганым өчен бирделәр. Шофер булганым өчен. Кибет юк, мәктәп юк, клуб юк. Гаиләсе булганнар килергә базмый иде. Квартирны ачып кердем, тәрәзә төбенә егерме сантиметр кар утырган. Төрле яктан дулаган җилне туктатыр шык юк иде ул чагында. Юлларда өчәр метр кар ята иде!»

Өлкәннәр янында яшьләр. Белемле, төпле фикерле инженерлар. Нефть әнә шундыйлардан яңа сүз, яңа адымнар, яңа җиңүләр көтә. Өченче миллиард тоннаны алар чыгарырга тиеш. Катламнарда басым саклау цехы начальнигы Марат Фәсхетдинов белән очрашабыз. Аңа утыз өч яшь. Югары белемле, Уфада нефть институтын тәмамлаган. Шуннан бирле Җәлилдә. Җитәкче булып күптән түгел генә эшли. Җаваплылыкны бөтен күңеле белән сизә. «Салкыннар безнең өчен куркыныч иде! Безнең хуҗалыкны күз алдына китереп карагыз: мең чакрымнан артык су куу торбалары. Утыз насос станциясе. Һәммәсе 300 скважинага су кудырып тора. Тәүлеккә алтмыш тугыз мең кубометр су кудыртабыз. Ә безнең эш җайланмалары илле градус салкынга дип көйләнмәгән. Кешеләребез нык, алар салкынны да җиңә ала. Ә механизмнар? Көн суыта башлагач ук, операторлар үзләре шалтырата башлады: «Бездә ни хәлләр? Нәрсә эшләргә?!» Диспетчерлыктан өч көн чыкмадык. Бик күп торбаларның, насосларның язмышы кыл өстендә иде. Байтак операторларыбыз авылларда яши. Мәсәлән, Мәхмүт Гыйльфанов 125 нче КНСка хезмәт күрсәтә. Сугыш һәм хезмәт ветераны. Авария факелы янганын күреп, ул станция янына ашыга. Атка утырып чаба. Һәм ике тәүлектән артык шуннан китми. Насослар туктаган була, манометрлар туңа. Ул солярка ягып, иске шиннар яндырып, станцияне туңудан саклап кала. «Үзем түздем, атны ничек түздерермен икән дип кенә борчылдым»,— дип шаяртты ул соңыннан.

Производствоны автоматлаштыру цехы электригы Борис Михайлович Граханцев та бәйрәм табынын ташлап эшкә ашыга: «Җәлил поселогына 63 нче станция су кудыра иде. Ул да туктады. Сап-салкын. Металлны ап-ак коры бәс сарган. Бияләйне салып, бармакны тидереп карасаң, бармак кайнар суга тыккан шикелле кабарып, куыкланып чыга! КНС-

ларда КИП дип аталган приборлар тора. Һәр станциядә 12—14 прибор. Алар һәр скважинага күпме су кудырылуын билгеләп, язып баралар. Сизгер һәм кыйммәтле автоматлар. Боларның һәммәсен суыктан саклап калу өчен күпме көч түгелгәнен төгәл генә берәү дә белми. Чөнки андый сизгер автоматларыбыз юк! Тәүлек буе керфек какмыйча, төтен-сөрем эчендә кайнаган мастер-операторларны, өзелгән кабельләрне үзәк өзгеч җил-бураннарда багана башларына менеп ялгаган монтерларны бер язмада гына санап чыгу мөмкин түгел. Әмма аларның һәммәсенә дә уртак булган бер мактаулы исемне атап китәргә кирәк: совет кешеләре алар, Татарстан нефтьчеләре. Җәлилчеләр. Алар шушы атаклы исемнәрне хаклы рәвештә йөртәләр, шушы данлы исемнәрне үз хезмәтләре белән баеталар, мәгънәсен тирәнәйтәләр.

Дан сезгә, дусларым, җәлилчеләр!..

Инде Җәлилдән кайткач, сиксәненче елның соңгы көннәрендә, 30 декабрьда газеталарда мондый информация басылып чыкты:

«Ел тәмамланып килгәндә «Татнефть» берләшмәсе коллективы зур җиңү яулады. Ул, 23 декабрьда сыек ягулык чыгару буенча бишьеллык планны үтәп, илебезгә 466 миллион тонна «кара алтын» озатты. Бу уңайдан «Әлмәтнефть», «Җәлилнефть», Лениногорск идарәсе коллективлары сизелерлек өлеш керттеләр.

Татарстан нефтьчеләре ел ахырына кадәр илебезгә бу бишьеллыкта планнан тыш 750 мең тонна сыек ягулык бирәчәк».

Бу хәбәр күп меңләгән нефтьчеләр хезмәтенең бишьеллыгына мәдхия булып яңгырады.

«...сыек ягулык бирәчәк». Әлбәттә! Булыр, планнар үтәлер, җиңү артыннан җиңү килер. Чөнки Татарстан нефтенең язмышы гүзәл кешеләр кулында. Чын кешеләр кулында. Совет каһарманнары кулында. Могҗиза тудыручылар кулында.

*1981 ел, январь — апрель, Әлмәт — Җәлил — Казан.*

Мөхәммәт Мәһдиев

# ТОРНАЛАР ТӨШКӘН ҖИРДӘ

ЛИРИК-ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## Кереш сүз

*Туган җирне сагыну дәрте бер вакытта да бетми икән...*

Әбелмәних Каргалый

...Безнең авылдан бер генә герой, бер генә космонавт, бер генә академик та чыкмаган. Гап-гади, иң гадәти бер авыл. Анда зур сулар, таулар, иркен болыннар юк. Бөтен булган байлыгы — урман, чишмәләр һәм кешеләр. Мин менә шулар турында сөйләргә телим.



...1976 елның октябренда мин Франциянең Париж, Марсель, Авиньон шәһәрләрендә йөрдем. Үзебезнең авылдан ерак, бик ерак идем. Эйфель башнясы янында басып торганда, Урта диңгезнең «Иф» крепосте урнашкан таш утравына катерда чыкканда яки Роден музеенда йөргәндә кая инде үз авылыңны уйлап тору, искә төшерү? Баш әйләнгән, тәэсирләр шундый көчле — нинди дер бер мизгелдә үзеңне онытып, югалтып торасың. Ләкин нәкъ әнә шул хәлдә — табигыйлекне югалткан бер хәлдә, нигәдер, минем йөрәгем сулыгып-сулыгып алды һәм Сан-Мартин бульварындагы затлы ресторанның купшы савыт-сабасын бер читкә куеп, туп-туры үзебезнең авылга кайтасы һәм искә төшкән кешеләр белән капка төбендә очрашып рәхәтләнеп бер сөйләшәсе килде. Мин моны — бу теләкне — берәүгә дә әйтмәдем, әйтсәм — я кыланчыклык, я бик нык чикләнгәнлек дип кабул итәрләр иде, әмма бу әсәрем шунда туа башлады дип әйтә алам.

Хәзер сәбәбен дә беләм: зур бульварларда йөргәндә, затлы рестораннарда ашап-эчеп утырганда миемне өзлексез бер фикер тукып торды: боларда күп нәрсә нәкъ бездәге кебек... Әйе, күбесе безнең ата-бабага таныш әйбер.

...Урам тулы халык — яше, карты-карчыгы, кызы-егете, французы-негры — барысы да джинсыга төренгәннәр. Киндер, безнең авылда гасырлар буе үстерелеп, тукылып, эрләнеп сугылган киндер. Моны бит

безнең авылда Хәдичәтти, Камиләтти һәм Кәшифәтти кыш буе утырып суга иде һәм сугып бетереп югач, киндер манарга Чүриле русларына илтеп бирәләр иде. Ә Чүриле руслары! Алтын куллар — буяучы, калайчы, тимерче, манучылар! Чүриле манучылары... безнең авылның күпме хатын-кызы еллар буенча Чүриле руслары манган йон оек, йон фуфайка (безнең авылда аны «куфайка» дип йөртәләр иде), йон, тула, киндер әйберсе киеп йөрде һәм Чүриле дигән сүз, ничектер, үзеннән-үзе «кешеләргә матурлык бирәм, кешеләрне матур итәм» дигән төшенчә белән бер булып киткән иде. Европа безнең ата-баба киеп узганны — Хәдичәтти, Камиләтти, Кәшифәтти сугып, Чүриле руслары манып биргән төсле киндер күлмәк, киндер ыштан кия икән хәзер.

Хәер, аңарчы мин Кипрда булган идем. Шунда, Фамагуста портында, дулкыннар янындагы бер ресторан төбендә безне милли киемнәр кигән киприоткалар каршы алды һәм бергәләп рәсемгә төштек. Миндә ул рәсем саклана: Кипр кызларының милли киеме — саф киндер күлмәк, киндер алъяпкыч икән. Чиккән, бизәкләнгән...

Минем башка әллә нинди уйлар килде. Чөнки, Парижда очрашуларның берсендә, француз журналисты әйтә куйды: без ди, читтән ат ите сатып алабыз. Үзенең диетик сыйфатлары буенча ат ите тавык итеннән югарырак бәяләнә, ат ите склерозга, картаюга каршы көрәштә иң әһәмиятле медицина чараларының берсе икән. Алай... тукта, моны безнең авылның тегүче Хөснетдин абзый:

— Һи-и, энекәш, ат ите ашаган кеше любой салкында атны бияләй белән җикми инде ул,— дип сөйләргә ярата иде. Без моны аңламый идек. Күп сүзле булмаса да, «расшифровка»ны ул үзе бирә иде: ат ите ашаган кеше — картаймый да, туңмый да, тузмый да... Галимнәр әле әйтеп ята торган сүзләрне Хөснетдин абзый әллә кайчан белгән икән...

Сан-Мартин бульварында йөргәндә мин чит илдән килгән туристларның, авыз күтәреп, шаккатып карап торган товарларына игътибар иттем: бу товар — кызылга каккан кайры тун иде. Кызылга каккан... Тарих өчен бу — үткән этап. Тунның акка, карага, кызылга какканы була иде һәм яшүсмер егетләр бездә аулак өйгә бары тик шул тунны киеп кенә киләләр иде. Пәлтә дигән әйбер ул бик соң — кырыгынчы елларда гына килеп керде, клубка инде «каккан» тун белән килү гаеп санала һәм егетләр сукно, бобрик, драп пәлтә белән киләләр иде. Башка җирдә ничектер, безнең авылда «пәлтә» үзенең дәрәҗәсе буенча дүрт-биш баскычка югары йөри иде.

Беренче урында — иң кыйммәтле драп пәлтә; икенче урында — бобрик пәлтә. Беренче дәрәҗәдәгесен киюче кеше авылда юк исәбендә иде, һәм авыл егете өчен каккан туннан котылып бобрик пәлтә кию зур, мөрәүвәт бер эш исәпләнә иде.

Өченче урында — сукно пәлтә. Моны шәбрәк егетләр армиягә киткәнче үк кияләр, алырлык хәле булмаганнар армиядән кайткач, соры шинельне Чүриле русларына мандырып, («Хәйбринең шинеле бик әйбәт чыккан!», «Нурминың шинелен икенче кат манарга алып калганнар!») пәлтә тектерәләр иде. Моның хәтта җыры да бар иде:

Дустым, пәлтә тектергәнсең,
Итәген бөктергәнсең.
Зәйтүн гөлләр арасында
Зифа буй үстергәнсең.

Дүртенче урында — пулсукна (полусукно) һәм брезентсыман материалдан тегелгән пальтолар иде, моны кигән егетнең дәрәҗәсе әлләкем булмый иде һәм яңа ачылган клубларның ишек төбендә уенга кермичә торучылар гадәттә «пулсукна» пальто киючеләрдән була иде. Утызынчы-кырыгынчы елларда, шулай итеп, безнең авыл кайры тун яки «как-

кан тун»нан баш тартты. Кырык еллардан соң бу тунның иң модалы киемгә әйләнүе, әлбәттә, гаҗәп... Алай гынамы... Утыз сигезенче елмы икән, җәй башында афәтле бер давыл чыгып, безнең авыл, урман өстеннән узды. Кырып узды. Без — урмансыз бер көн дә яши алмый торган халык — икенче көнне урманга бардык! Безнең авыл өстендәге төз, геометрик төгәллек белән үскән кара чыршылар кырылып беткән, авыр салмак ботаклы наратлар «әй, сез, безне яратканыгызны беләбез, әмма, шундый афәт вакытында безне табигать көченә тапшырдыгыз» дип рәнҗегән сыман, авып яталар иде. Авыл кара кайгыга батты. Ләкин күпмедер вакыт узгач, авылда яңа һөнәр барлыкка килде: сагыз әретү. Бер коймак, ике коймак, өч... Егылган агачларның җәрәхәтле төпләре ул елны җәй буе еладылар. Шуннан сагыз кайнату, сагыз сату модага кереп китте. Сагыз чәйнәү ашказаны асты бизләренең эшләвен яхшырта, сагыз тешләрне чистарта, имеш... Аны шундый итеп чәйниләр иде: ул бер ритмга корылган, фәлән тапкыр әйләндереп алгач, «чарт» итеп аны бер аттырып куялар иде. Сагыз чартлату ул бары тик уңганнар, булганнар эше генә. Чартлату — димәк, эш көйле, җайга салынган, моны чәйнәүче кыз — уңган диган мәгънәне аңлата иде.

...Карасам, бөтен урам — Сан-Мартин урамы — сагыз чәйни. Моны Академия утырышыннан кайтып баручы профессор да, метро себерүче негр да, секс-фильм барганда билет тикшереп торучы чандыр гәүдәле француз кызы да, Эйфель башнясы янында фотоаппарат асып йөгереп йөрүче америкалы турист та чәйни. Ә-ә, мин әйтәм, безнең авылның Миңлебикәттиләр, Шәмсетдин абзыйлар моны әллә кайчан чәйниләр һәм күршә-тирәгә, бала-чагага «бер коймак» итеп биреп тә чыгаралар иде, дим. Үзем шулай уйлап йөрим, ә кесәдә малайның заказы ята: әти, Париждан жвачка алып кайтырга онытма...

Их, син, мокыт малай. «Жвачка»ның чыккан урынында без синең белән җәй буе йөрибез, велосипедларны баллы куәт, алабай, кыңгырау, сандугач тәпие, дегет чәчәкләре өстенә аударып, тымызык баллы һаваны сулап сыйдырып бетерә алмыйбыз, каен җиләге исен иснәп, җиләкне таптап йөрибез, ә шәм кебек төз наратлар сыр-сыр ясаган эзләреннән Сан-Мартин урамындагы «жвачка»ны агызып, мөлдерәп елап утыралар. Ә без...

Безнең авылның Әсхәдулла абзый гомер буе киндер капчык асып йөрде. Киндер капчык дөньядагы иң җайлы сумкаларның берсе икән. Кешелек җәмгыяте капчыктан өстен булырга тырышып, күп әйбер уйлап тапты: саквояж, ранец, чемодан, ридикюль, планшетка, рюкзак, дипломат һәм тагын әллә ниләр. Кешелек җәмгыяте шуларны уйлап ятканда, безнең авылның Әсхәдулла абзый егерме чакрымлы Арча юлын таптый торды: иңендә капчык — «арыш капчыгы» иде. Аңа барысы да сыя: бер кило түбә кадагы, ике кадак хәлвә, чирек такта чәй, бер банка тәрәзә буявы, өч кадак замазка, ике өтерге, чебен даруы, хатынга кәшимир яулык, малайга уенчык автомобиль...

Хәзер Европа шуңа кайткан икән. Һәркемнең иңендә — киндер капчык. Яшь егетнең яки кызның иңендә киндер капчыгы булмау — модадан артта калганлык булып исәпләнә. Мин самолетка утырырга дип аэродромның бетон мәйданында басып торам, озатырга килгән кызым соңгы ялынычын әйтә:

— Әти, мөмкин булса, миңа киндер сумка алып кайт... — ди. Киндер сумка...

Әсхәдулла абзыйда андый киндер «сумкалар» ничәү булды икән? Һәм аны Европадан эзләп йөрисеме икән?

Хәтеремә бер егет кереп калган. Кешеләр тышкы кыяфәтләре белән үзләренең каян чыкканын әйтеп торалар. Сизәм: менә бу — чыкылдатып эшләп дөнья күреп яткан авыл малае. Ә монысы — әти-әнисеннән вело-

сипед, мопед, мотоцикл, «Жигули», «Волга»лык акча сорап — шул сызык буенча үсүче егет. Бу — бәрәңгенең кайда үскәнен белә, әмма аны казып алуны яратмый. Бу — итнең ничек кибеткә килүен белә, әмма силос кампаниясенә катнашмас өчен институтның здравпунктыннан яки поликлиникадан справка эзли. Һәм башка бик күп төрләләр. Ләкин мин күзәткән егет крестьян егете иде, зур куллы, озын гәүдәле, эре аяклы. Бәхете булган, университетның юридик факультетына кергән. Авылдан килеп... Инде нишләргә? Авылны онытырга иде бит! Шәһәрчә булырга иде! Егет күзәткәләп йөрде дә, бераздан озын чәч җиткерде. Метр да туксанлы егеткә озын чәч! Аннан, модага ияреп, ул чәчне юмас булды. Чәч толымнары тотам-тотам булып пальто якасын каплыйлар, пальтосы арттан каешланып килә иде. Бераздан егет китап-дәфтәрләрен киндер капчыкка салып җилкәгә асып йөри башлады. Киркәккә-кирәксезгә бик еш сигарет алып кабыза торган булды. Егет диплом алганчы киндер капчыктан бер дә аерылмады. Аның бик тә, бик тә европача буласы килә иде, шул максаттан чыгып ул үзенең авыллыгыннан баш тартты. Мин елмаеп күзәттем: авыллыктан баш тартам дип, киндер капчык асып, ул авылдагы ата-бабаларына кире кайтты. Ләкин үзе моны аңламый иде... Капчык дигәндә безме инде аны белмибез? «Күтүмкә» дигән капчык була иде. Ат җигә торган аркалык белән түшлекне аласың да, киндер капчыкның почмакларына берәр бәрәңге тыгасың һәм төен ясап, авыррак булган саен төен ныграк кысыла торган итеп, «күтүмкә» асасың. Диңгез флотында дәрестә миңа унөч төрле «диңгез төене» өйрәттеләр. Мин «диңгез эше» дигән фәннән имтихан биргәндә бишле алдым, чөнки унөч төрле төеннең җиде-сигезен авыл үзе өйрәткән иде.

Чит илдә йөргәндә без бер паркта булдык. Анда кафель, обой, полировка кебек әйберләрдән бөтенләй баш тартканнар. Киләсең бер кибет янына — анысы бурабзар (бурап эшләгән абзар). Аласың кофе. Утырасың... агач бүкәнгә. Өстәл урынына агач төбе. Бу — хәзер Европада иң югары культура шартлары дип исәпләнә. Безнең авылда дүрт житкән егетле бер гаилә бар иде, аларны Шәфыйкныкылар дип йөртәләр иде. Атасыз, ятим үскән бу егетләр колхозның бөтен эшен кырып эшлиләр дә, буш вакытларында өйләрендә башмак, күтәрмә, чабата ясыйлар иде, сәкегә җыелып тәмле итеп аш ашыйлар иде һәм аларның утыргычы бары тик бүкәннән генә иде. Әйбәт, әдәпле егетләр Гыйлмулла, Нуриәхмәт, Шәһидулла, Галиәхмәт агач бүкәндә утырып үстеләр дә Ватан азатлыгы өчен көрәшкә киттеләр һәм шул көрәштә башларын салдылар. Европа безне бүкән белән гаҗәпләндерә алмый.

Парижда без урнашкан отельнең исеме «Кургаш таба» иде. Бу исем миңа ошады. Кургаш икән кургаш. Таба — безнең юлдаш. Табада без коймак пешерәбез, кабартма, сумса, өчпочмак, бәлеш, ярма, кабак, дөге, бәрәңге, әнис салып ит турап бәлеш пешерәбез. Каз бәлеше була, кабак бәлеше, каздан баш-аяк бәлеше була. «Кургаш таба» кешеләре төнге йокы алдыннан безгә берәр стакан катык өләшеп чыктылар. Катык...

Безнең авылда катык стаканлап түгел. Катык бар, аны ашыйсы һәм вәссәлам... Ә хәзер төнге йокы алдыннан бер стакан катык ашап кую зур бер хәл икән. Европада да шулай, безнең курортларда да. Мин тыңлап йөрим:

— Ә сез, мадам, кичке катык эчкән җирдә күренмәдегез...

— Минем башым авыртып тора иде. Шуңа күрә постельдән кузгалмадым...

— Ах, мадам... Үземә әйткән булсагыз. Кичке катыкны эчми калырга ярыймы соң? Ничек инде сез үзегезнең сәламәтлегегезгә каршы үзегез үк көрәшәсез? Шулай ярыймыни?

Безнең авылда Хәдичәтти бар иде, аңа йомыш белән керсәң, ул «олан, катык ашыйсыңмы?» дип, базга төшеп китә иде дә, чиләк белән катыгын алып чыгып тавык үләнле ишегалдына утыртып куя һәм кашык алырга дип йортка кереп китә иде. Ул ишегалдында без ашаган катыклар... Хәзер шул мәсьәлә бик мөһим бер эш икән.

Яшь торгач, авылның байтак гадәте дөнья культурасына, әдәп-әхлак кагыйдәләренә кертелгәне беленде. Хәтта хәрби уставка да. «Строевой устав» дигән бик кырыс кануннар җыентыгы бар. Мин шул уставка гашыйк булдым. Анда коры гына җөмләләр белән кеше тәрбияләүнең, иләмсез, тәртипсез күренгән яшь егеттән солдат яки матрос «ясауның» кагыйдәләре беркетелгән. Арадан берсе: стройга баскач, иптәшеңнең кием-салымы рәтләп киелгәнме икәнен карарга (1 нче глава, 25 нче пункт), аны әйтергә, ярдәм итәргә диелгән. Бездә дә шулай: кышын юлда очраган кешенең бите-колагы өшегән булса, беркайчан да моны әйтмичә узмыйлар. Фәлән-фәлән кием астыннан киләксезгә фәлән кием күренеп тора икән — җай белән генә әйтмичә калмыйлар. Моның өчен бары тик рәхмәт әйтеп кенә узалар.

Ерак юлдан ат белән кайтканда да шулай. Тезелешеп кайткан атларның берсенә җыелалар да, арба өстендә гәп сатып баралар. Каршыга да шундый кәрван очрый. Күз күрмәгән кешеләр шунда әйтеп узалар: фәлән атның дилбегәсе аска төшкән, фәлән ат арбасының чәкүшкәсе чыккан, тәгәрмәче чыгарга мужыт... һәм башкалар. Калганын мин самолетта — Ватанга очканда уйлап кайттым. Чыннан да, моданың бик күбесе авыл белән уртак. Культуралы зур-зур шәһәрләрдә егетләр, ирләр ак оекбаш белән кара туфли кия башладылар. Бервакыт зур бер дәүләтнең президенты килгәнен телевизордан күрсәттеләр, ул самолет трабыннан төшкәндә игътибар иттем: модалы киенгән президентның аякларында ак оекбашлар иде. Сугышка кадәр безнең авылның да иң затлы модасы — ак оекбаш кию иде.

...Бу турыда язарга карар кылуыма тагын бер нәрсә сәбәп булды. Ничектер, «Борынгы Греция тарихы» китабын укып ята идем. Бер җөмләгә туктадым: борынгы греклар, диелә анда, күләгәне аяк белән үлчәп вакытны билгеләгәннәр. Тукта әле, тукта... Ә без? Ә без? Көтү чиратына чыкканда, Торна елгасы буенда җиләк җыйганда, Масра юлычдагы түр басуда — торналар төшә торган басуда — борчак чапканда без дә сәгатьне шулай белә идек бит!

Димәк, дөньядагы бөтен халыклар белән уртак гадәтләребез, уртак гамәлләребез бар безнең. Димәк, туганда ук бөтен холык-фигылебез, эш-гамәлләребез аркылы бөтендөнья халыкларына бәйләнеп туганбыз.

Бу әсәр — безнең авылда яшәгән, бүгенге буынга юньле әхлак-гадәтләр тапшырып, дөньядан киткән кешеләр турында.

Бу әсәр — илленче еллар яшьлеге турында...

## Кереш сүзгә өстәмә

Аэропорт. Ташкентка оча торган самолетка кеше утырта башлаганнарын көтәбез. Инде чемоданнар тапшырылган, кул әйберләре генә калган. Китүчебез — якын туганыбыз, утыз елдан артык инде Урта Азиядә башта партия органнарында, хәзер профсоюз җитәкчелегендә эшләүче. Тимер рәшәткәләр янына килдек. Багажга тапшырмаган яшел солдат капчыгын кулыма алам. Чамадан тыш авыр.

— Нәрсә бу? — дип сорыйм. Ул авыр сулый.— Нәрсә бу? Ташмы әллә? — дим, шаярып.

— Әйе, энем, таш,— ди. — Су буена төштем. Аннан ике төрле таш алдым. Берсе катламлы таш, икенчесе чыпчык ташы. Бәлки, ул таш-

ларга ата-бабалар баскандыр? Бәлки, сабый вакытта яланаяк аларга мин баскаңмындыр? Аннан урманга бардым. Нарат, чыршы күркәсе җыйдым. Аннан утын әрдәнәсеннән байтак әйбер җыйдым. Нарат, юкә, имән, каен бүкәннәреннән берәр тәгәрмәч кисеп алдым.

Ул авыр сулады.

— Ә безнең тегендә юк... Мин торган район үзәгендә дим. Анда болар юк...

Тимер рәшәткәле капка ачыла. Мин авыр капчыкны аңа кертәм. Кешеләр тимер ишеккә агыла башлый. Без хушлашабыз. Карыйм — туганның ике күзе тулы яшь. Мөлдерәгән...

— Чуер ташлар да байтак җыйдым. Анысы Торна елгасыннан,— ди ул.— Аннан соң Торна елгасында...

Аэропорт дикторының салкын тавышы аны бүлдерә:

— У стойки номер пять заканчивается посадка на самолет, вылетающий рейсом... по маршруту Казань—Ташкент. У стойки номер пять заканчивается посадка...

Аннан соң... Нәрсә аннан соң Торна елгасында? Нәрсә әйтмәкче иде икән ул? Тимер капка инде ябылган иде...

* * *

1979 елның декабрь ахыры. Миңа илле яшь туласы көннәр. Радиодан минем фәкыйрь генә иҗатым турында искиткеч җылы сүзләр сөйлиләр, кайсыдыр әсәрдән өзек бирергә җыеналар. Әдәбият тәнкыйтьчесе, минем мәшәкатьле ыбыр-чыбырлы тормышымны шактый яхшы белгән Фәрваз Миңнуллин сөйли: бу иптәшнең, ди, бөтен иҗаты — яшьлекне сагыну. Яшьлекне сагыну? Бу — минем өчен ачыш. Чыннан да шулай икән. Бәлки бу әсәргә исемне шулай кушаргадыр? Тагын менә нәрсә: автобиографик повестьларны еш укыйбыз. Бу жанрда инде безнең яшьтәшләр дә каләм тибрәтә башладылар. Ул әсәрләрдә еш кына ВУЗда укыган студентлык еллары турында сүз бара. Ә миңа андый бәхет эләкмәде. Буласы шул бәхетле көннәр урынына мин әледән-әле яшьлегемнең аерылгысыз бер өлеше булган хәрби хезмәт чорын телгә алам икән, укучылар гафу итсен...

## Төлке уйный торган орлар...

Җирс рәтсез якта халык һөнәрле була. Безнең авыл халкында бүгенге промышленность тармакларының бик күбесе эмбрион хәлендә яшәгән. Җир аз булган, җирне урманнан сугышып алу әле утыз дүртенче елларда да бара иде. Шуңа халык һөнәрле. Һөнәрләр болай бүленә: такта яручылар; балта осталары; тула басу, житен талку, маньлган йоннан әйбер бәйләү; киндер сугу, бау ишү, чабата ясау; күн аяк киеме тәзәтү; пыяла кую; тәгәрмәч, үрәчә, тугым, дуга әшләү; тегүчеләр: ак тегүчеләр, кара тегүчеләр; кирпеч сугу; итек басу (бөтен Казан губернасына йөреп); мунчала чыгару; базарга утын, такта, чабата, миллек, мунчала, шалкан, миләш, ылыс (русларның пасхасына), кипкән җиләк, кипкән шомырт чыгару; лесхозга гөмбә, чәчәк тажы, дару үләне, береслет (каучук ясау өчен), усак, зирек, тал кайрысы, чыршы, нарат күркәсе, куак чикләвеге, гөләп җимеше җыеп тапшыру.

Менә болар барысы да безнең авылда башкарыла. Бездә кемнәр генә юк? Калай түбә ябучы, самавыр, комган төзәтүче; буяу белән эш итүче; тире иләүче, күн ясаучы; таш белән эш итүче.

Агач, юкә төшерү, мунчала чыгару, такта яру, утын әзерләү белән гасырлар буе шөгыльләнгән халыклар алга таба китә алмаганнар. Аларның бердәнбер табышы — әхлакый югарылык. Экономик яктан алга китү өчен исә таш, тимер белән эш итәргә кирәк булган. Ә безд анны белмәгәннәр. Юньлелек — эшчәнлек булган, әмма киләчәк буыннар өчен корылмалар калмаган.

Безнең халыкның бөтен рухи дөньясы урман белән бәйле. Әкият, җыр, табышмак, мәзәк — бары тик урманга гына бәйле. Хәтта бәетләр дә шулай: фәлән кешене урман кискәндә агач баскан; фәлән кеше урманнан бүрәнә алып кайтканда, тауда аты ычкынып китеп...

Поездларга билет алу кыен заманнарда, билетсыз утырган егетләр ревизорларга эләккәч (ул елларда авыл кешесендә паспорт юк), актка яздырганнар:

— Фамилияң?

— Урманов.

— Исемең?

— Чытырман.

Һәм авыл советына еш кына шундый кәгазьләр килә иде: «Сезнең авыл Советы гражданины Урманов Чытырман Арча—Казан поездында билетсыз тотылды. Аннан тиешле 3 сум штрафны Казан тимер юлы идарәсенең...»

Бераздан бу фамилиянең нәрсә икәнен белеп алалар һәм егетләр тотылып яналар. Бары тик ветсанитар Хисмәт кенә, шулай эләгеп, яңа фамилия яздырып кайта:

— Синьязар Минтаяров,— ди.

Ул кәгазьнең дә авылга килгәнен хәтерлим.

Безнең урманның бер почмагы гел күз алдымда тора. Сугыш елларында җиләккә баргач, мин гел шунда чыгу ягын каера идем. Анда җиләк тә булмый иде. Телефонлы олы юл (бездә: чыбыклы юл) кырыендагы дүрт квартал почмагы ул. Анда юан баганалар утыртылган һәм аларның дүрт ягын квадратлап уеп кара буяу белән номер сукканнар. Әле дә хәтерлим: 217, 216, 196, 197 почмагы иде ул. Әлеге баганалар урман эчендә нәкъ кешесыман утыралар, алар нәрсәдер әйтергә телиләр, сөйләшергә омтылалар. Кешеләрнең аларга ихтирамы шулкадәр зур, утыз өченче елларда утыртылган ул баганалар илленче елларда төптән череп аудылар, әмма бер генә кеше дә аларны утын итеп өенә алып кайтмады. Әлеге чыбыклы юл буенда башлары корыган карт юкәләр, биек-биек ятим юкәләр бар. Нигә башлары корыды икән аларның? Аларның башларында күке, тилгән кебек кошлар утыра. Эссе көн. Дөнья тын. Кайдадыр тормыш бара, кайдадыр сугыш бара, кайдадыр шау-шу киләләр, ә безнең урмандагы юкәләрнең корыган башларында тилгән, күке тып-тын утыра. Телефонлы урман юлы сузылып иңкүлекләр аша еракка китә. Ул юлның ике башын да мин беләм. Бер башы Мөрәле дигән авылга — кара сазлыклы урамнары белән, гомер буе урманда, күлдә мунчала төшереп, еланнан чагылып яшәүче, бүре-төлкедән җәфа чигүче, әллә ниткән кырыс холыклы, әмма каты куллы — морҗачы, мунчала чыгаручылардан торган авылга таба бара. Мөрәле — гомер буена томан, яңгыр, саз эчендә яшәүче авыл булып күз алдына килә. Юлның икенче башы таш юлга барып чыга. Кояшлы көннәрдә ул як еракларга чакырып, зәңгәр аязлык булып күренеп тора. Бәхет, сәләдәт, маҗаралар, минем киләчәгем — шунда! Шунда! Болар әле вакытлы кыенлык, вакытлы газап, вакытлы ачлык... Шул юкә төпләренә ятып, юкәгә сөялеп мин еракка — таш юлга карый идем, күз күрмәгән якларга китәсем килә иде. Гомеремнең икенче яртысында мин бик ерак илләрдә булдым, әллә ниткән хикмәтле вулканнар, джунглилар, тау куыш-

лары, шәһәрләр, халыклар, буар еланнар, филләр күрдем. Әмма гомер буе минем йөрәгемне телеп-телеп сагыш кайнады, бала вакытта шул юкә төпләрендә, чыбыклы юл буенда ятканда уйлаган уйларым, миңа гомер буе тынгылык бирмәде, гел каядыр чакырып торды.

Урмандагы телефон юлы... Дөньяда моның кадәр серле тагын ни булыр? Аз гына җилгә дә сызгырып, урман шавына кушылмыйча, аерым бер хәтәр тавыш бирeп утыра иде чыбыклы юл. Без, малайлар, теләсә кайсы агачны теләсә нишләтергә хакыбыз бар, дип ышанып яшәгән малайлар, шул телефон баганасына килеп колагыбызны куеп тыңлый идек. Бу баганадан колакка бөтендөнья тавышы ишетелә, әллә кайдагы утраулар, җир тетрәүләр, тайфуннар — барысы да ишетелә кебек иде. Шуны тыңлагандагы дулкынланулар! Язмыш шаян: 1952 елның җәендә Балтыйк диңгезенең бер квадратында бик көчле шторм булып, эскадра белән элемтә югалды. Генштаб, флот штабы, база штабы офицерлары төн йокламады: эскадра кадәр эскадра белән элемтә юк иде. Шунда флот командующие белән телеграф аша сөйләшүне мин алып бардым: кул астымнан чыккан лентаны бер төркем өлкән офицерлар учларына алып торалар, борчулы кыяфәттә киңәшләшәләр һәм командующийның сорауларына кыска-кыска гына җавап бирәләр иде. Ә минем кулларым шулкадәр дерелди иде — моны күреп СНИС (Служба наблюдения и связи) начальнигы беренче ранг капитаны кисәтү ясады:

— Нәрсә син усак яфрагы кебек калтырыйсың? — диде.

Эскадра табылды, безнең вахта шул көнне бәйрәм итте, балачакның бер мәзәге исә минем хәтергә килде.

...Имеш, безнең авылның җир чикләрен билгеләгәндә халык риза булмаган. Күрше авылга күбрәк киткән икән. Шуннан киңәшкәннәр. Арадан бер абзый әйткән:

— Гөбернатырга тилиграм сугарга кирәк,— дигән.

Әйтүен әйткән, әмма ничек сугасын аңлатмаган. Үз өстенә дә алмаган. Ирләр алынмаган эшкә хатын-кызның тотынуы гаҗәпмени? Ике хатын, кулларына миләш таяк тотып, таш юлга чыгып киткәннәр. Телеграф баганалары тезелгән чыбыклы юлга житкәч, чирәмгә утырып, алъяпкыч алдына салган ипиләрен ашаганнар да, валчыгын бисмилла әйтеп кош-кортка сипкәч, телеграф баганасы янына килеп басканнар. Аннан миләш таяк белән ике яклап баганага суккалаганнар. Багана шаулаган. Ә болар шул шауга өстәп депеша җибәргәннәр:

Дөбер-шатыр, гөбернатыр,
Безнең сүзне тыңлап тор.

Аннан, губернаторга җир мәсьәләсендәге дәгъваларын сөйләп, авылга кайтканнар һәм халыкка:

— Гөбернатырга тилиграм суктык, бераз көтеп карыйк,— дигәннәр.

Безнең авылның исеме әллә шуннан «Гөберчәк» булып киттеме икән? Бер генә легендада, бер генә сүзлектә дә бу исемгә аңлатма әлегәчә табылганы юк...

Сүз башы урман иде бит әле. Урманга беренче баруымны хәтерлим: дүрт яшьләрдә булганмындыр. Аңарчы урман безнең басу түрендә могҗизалы стена, серле әкият булып торды. Офыктагы урман өсте теш-теш булып күренгәнлектән, бала вакытта мин аны безнең басу түренә сырты белән салынган мәһабәт пычкы дип белә идем. Менә, ниһаять, шул сихри дөньяның бер почмагына мине алып керделәр. Күзгә ташланган иң беренче нәрсә — күч-күч булып утырган абагалар иде. Болар иксезчиксез, болар серле дә, куркыныч та иде. Аннан миңа карт имән ботагында утырган бер кошны күрсәттеләр. Ул, ахырысы, миннән бик аз гына кечкенәрәк иде. Мәче башлы ябалак. Аның бите миңа кеше бите

булып күренде. Безнең урамда әллә ничә карчыкның, бер-ике картның бите нәкъ шундый. Ботак сыныклары ыргытып аны куркыттылар. Саргылт-соры иләмсез канатлары җәелеп ботактан күтәрелгәндә минем өскә җил бәрде. Ул, салмак очып, эчкәрәк кереп китте. Ул көнне безнең урманда бөтен кошлар сайрый иде. Агачлар арасыннан, күктән музыка ява, бөтен нәрсә зыңгылдап, яңгырап, шатланып тантана итә иде. Ахырдан, берничә еллар узгач, мин «уфалла» арбасы белән бу урманнан утын ташыдым. Абагалар беткән, мәче башлы ябалаклар да күренми иде. 1947 елда Ашхабадта җир тетрәде. Шунда безнең урманга леспромхоз килде һәм бездән агач озаттылар. «Ашхабадны торгызыр өчен» — урман кисүчеләрнең лозунгысы шушы иде. Леспромхозның шунысы ярый, күпме киссә, шуның кадәр утыртып китә. Әмма соңгы елларда аерым кешеләр кулына «Дружба» пычкысы килеп керде. Дуслык пычкысы урман өчен зур дошман булып чыкты. Урман сирәгәйде, анда киек-кошлар азайды. 1933 елларда исә әле анда тилгәннәр, урман тавыклары, төлке, куян, бүре, ябалак, күке, тукран һ. б. җан ияләре тулып ята иде. Торна елгасы дигән урынында язын торналар туктап бала чыгаралар иде. Урманнан бөркет килү үзе зур вакыйга була иде. Бөркет, гадәттә, җәйге иртәдә, кешеләр йокыдан торганчы ук авылга килә. Ул ындыр арты тирәсендәге берәр багана башына, узган елдан калган кибән, эскерт өстенә, эвеслек, абзар түбәсенә утыра. Кешеләр аны күрмиләр, әмма каралты-кураны ачып кош-кортны чыгарсаң, кош-корт шунда ук борчыла, шомлы авазлар сала. Авылга килгән бөркетне авылның бөтен кошлары сизә.

Бүрене дә шулай. Бүре көзге томанлы төннәрдә, язгы иртәләрдә килүчән. Авылда шундый кичләр була: бөтен дөньяны дымлы томан чорнаган, йорт тәрәзәләреннән анда-санда гына кечкенә саргылт утлар күренә, дөнья тын, куркыныч! Җир шары шушы билгесез томан эчендә әкрен генә, тигез генә шаулап әйләнә сыман, син аның әйләнгәнен тоясың. Менә шул вакытта, авыл читендә, кинәт кенә бер эт елап өрә башлый, авыл җанлана, бер эт тавышына башкалары да кушылып, бөтен авылда «эт концерты» башлана. Йортларның ишекләре шыгырдап ачыла, кешеләр абзар-кураны бер әйләнеп кереләр, абзарда сыер авыр гына мышнап ала, фонарь яктысында сарыкларның күзе гәрәбә булып яна, алар куркышып, тыбырдашып, берсен-берсе бәреп абзар стенасына сырышалар. Ә эт, елый-елый, баскыч астына кереп китә, әйтерсең ул хуҗасыннан сорый:

— Йоклама, йоклама, бүре килде, авылда бүре бар! Монда керсәң беренче мине алачак ул, мине сакла, мин сине саклармын!

Безнең авылда исә этләр бик сизгер. Урманлы җирдә шунсыз мөмкин түгел. Бер этне хәтерлим: абзарда сарык бәтиләгәнен дә сизә һәм баскычка килеп өреп хуҗаларны уята иде.

Бүре шулай бөтен авылны дер селкетә дә китә. Киткән була. Этләр, бичара, бик зур эш эшләдек дип бер-берсенә соңгы сәлам биреп алалар да йокыга яталар. Әмма бүре басу түрендә төн уздыра да, соры томанлы юеш иртәдә эвеслек тирәсенә килеп чыга. Анда иртәрәк чыккан казүрдәк, кичтән урамда адашып кунган сарык-фәлән булмый калмый. Кайвакытта колхоз атларын саклаучы малайлар әсәрешеп, ат чаптырып авылга кайталар.

— Фәлән атның арт санын бүре умырган!

— Фәлән тайны бүре алмакчы булган, атлар урап алып кына саклаганнар!

Мондый сүзләр еш ишетелә иде.

Безнең бабаларыбызның мәҗүсилек заманында бүре культына табынган булу ихтималын фольклорчылар еш әйтәләр. Шулайдыр, шулай булгандыр. Бүредән курку белән бергә, халык күңеленең бик тирән

төбендә бу җәнлеккә курку катыш яшерен ихтирам, олылау хисе ятканын белмибезмени?

— Кичә төнлә бүре килгән,— дип иртәгесен сөйләнгән хәбәр, шом катыш серлелек, зурлык, әһәмиятлелек белән йорттан йортка йөри иде. Бүре килгән... Әйтерсең, кабереннән торып борынгы баба, изге ата килеп киткән, ә без берни белмичә йоклап ятканбыз. Мондый шомлы ихтирамны мин Обь буендагы бер татар авылында аюга карата сиздем: аю төнлә тайгадан чыккан да, авылга килеп берәүнең бурабзар ишеген вата башлаган. Көче җитмәгән, китеп барган. Иртәгесен бу хәбәр йорттан йортка тапшырылды, урам почмакларында сөйләшеп торулар, капка төпләрендә аз сүз белән фикер алышулар булды.

— Ишеттегезме? Узган төн бабай килгән икән...

Бу җитди тын сөйләшүләрдә мин шулай ук борынгы бабаларның ерак гасырлардагы рухани авазларын ишеткәндәй булдым.

Бабалар, күрәсең, аю-бүре белән әвәрә килеп яшәгәннәр. Капкынга эләккән бүренең аягын өзеп качуы, төнге юлда ат каршына чыгып утырган бүреләрнең ат хуҗасын ничек иза чиктерүләре турында әллә ниләр сөйлиләр иде. Мин бик кечкенә идем әле, урман эчендәге Бимәр авылы руслары бүрене тере көе тоттылар. Авылга бүре килеп бик җәфалагач, бер аучы үзенең бакча артындагы иске коесы өстенә төнгә ит куйган. Кое өстендәге алдавычка бүренең килеп керүе булган, черек такта сынып, бүре коега егылып төшкән. Ул бүренең алдануын кызгану хисе белән сөйләгәннәрен хәтерлим. Буранлы кышның бер көнендә авылда хәбәр таралды: тире җыючы Низамига теге бүрене тунамыйнитми китереп биргәннәр. Низаминың улы Габдерәкыйп, шаян күңелле, фантазиягә бай малай, урамда хәбәр таратып йөрде: караган өчен бер тиен акча түлисе, диде. Ул көнне аларның капка төбе тулы малайлар булды. Габдерәкыйп аларны, универмагның хатын-кыз аяк киеме бүлегенә керткән шикелле өчәрләп кенә келәткә кертте. Мине ул иң ахырга калдырып үземне генә кертте. Теләгәнчә кара диде. Мин дөньяда курку катыш зур ихтирам белән бер әйбер янында да шулай каушаганым булмады кебек. Кышкы салкында арт һәм ал аякларын сузып катып калган, калын мехлы соры бүренең авызыннан ике яклап котчыккыч таза тешләр тезмәсе күренеп тора иде. Минем күзләремне яшь басты, тын буылып торды. Якын килергә куркып, үрелеп кенә бармак очын бүренең йонына тидереп алдым. Ерткыч булса да мондый хәлдә ул кызганыч иде. Аларны әле дә кызганам. Быел кыш үзебезнең авылдагы бер аучының берьюлы ике бүре атканын сөйләделәр. Колхоз фермасында бозаудан бер сыер үлгән дә, тиресен тунагач, түшкәсен басу түрендәге бер коры елгага илтеп аударганнар. Берәр көн узгач, шул тирәдә шофер егет түшкә ботарлап яткан өч бүре күргән. Һәм кайтып аучыга әйткән. Аучы исә, ак халатын бөркәнеп, ике көпшәле мылтыгын асып, шунда китеп тә барган. Берни дә сизмичә, кабалана-кабалана ит умырып яткан бүреләрнең икесен атып та алган. Өченчесе качкан. Бүреләр дә беркатлы булалар кайчак. Көпә-көндез карлы басуда йөрергә ярыймыни инде? Сугыш вакыты түгел бит, ирләр бар, аучылар бар.

...Келәттәге туң бүре түшкәсе кыш буе күз алдыннан китмәде. Хәер, ул заманда безнең әлифба, уку китапларында да бүре, аю, төлке турында байтак языла иде. Мин, мәсәлән, беренче классның «Туган тел» китабындагы бер шигырьгә ясалган рәсемне хәтерлим: кара күк йөзен ак төртке булып йолдызлар чуарлаган, кар диңгезенә чумып утырган салам түбәле авыл. Авылдан чыгып йөгереп килүче кешеләр, малайлар һәм алгы планда, телен янга чыгарып, койрыгын бот арасына кыстырган усал бүре ясалган... Кышкы кичләрдә китапның бу битен ачып укуы аеруча куркыныч була, әмма гел шуны укыйсы килә иде. Ул шигырьнең авторы кем булды икән?

Кышкы төн. Салкын. Карлар шыгырдый.
«Салкын, ай, салкын» дип бүре мыгырдый.
Ерткыч хайван — ашарга юктан
Телен тешләгән бүре ачлыктан.
Күн кичкә таба караңгылана.
Авылга бара уйланып әнә.
Бүре авылда — аны күрәләр.
Этләр, көчекләр чинап өрәләр.
Казык-сәнәкләр тоткан агайлар,
Таяклар тоткан малай-шалайлар.
Бүрене куалар.

Кышкы буранда тамак ялгап алырга дип килгән бүренең шулай куылып җибәрелүе кызганыч бер ассоциация тудыра иде: әйтерсең, ул бүре түгел, ә кабарга бер бөртек ризыгы булмаган гаиләнең, озын тәнәфестә йөгереп өенә кайтып, ач көе кире киткән кечкенә малае иде...

Кырык еллар узгач, университетның гыйльми китапханә залында мин үзебез укыган бу дәреслектән ашыга-ашыга шул битне эзләп таптым: бу минутта дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк иде.

Бу рәсем, бу шигырь нәкъ безнең авылныкы, безнеке иде. Кышкы кичләрдә мал карарга абзарга (сыер бозауламаганмы? Сарык бәтиләмәгәнме?) һәм башка йомыш белән абзар артына чыккан кешеләр еш кына басу түреннән, Масра юлындагы Му үзәненнән:

— Бүре ба-а-а-р! Бүре ба-а-ар! — дигән йөрәк тетрәткеч авазлар ишетеп керәләр иде. Һәм юлда кешесе булган йортлардан андый вакытта фонарь, кистән белән шул аваз килгән якка чыгып йөгерүчеләр була иде. Мондый хәвефкә очраган кешене йөрәкне сыкратып кызгану һәм шул ук вакытта аның бу хәленә кызыгу, көнләшү хисләре дә була иде. Ул бит тере бүре каршында басып тора! Озак еллар узгач, мин бөек Гетеның бер шигырен немец телендә укып гаҗәпкә калдым. Гете безнең авыл төнен, безнең балачакны язган. Мин бу шигырьне сүзгә-сүз татарчага тәрҗемә иттем:

Томаннарда, тирән ак карларда
Кышкы төндә ерак урманда
Ишетәм мин ач бүреләр улаганын.
Ишетәм мин ябалаклар елаганын
У-у-у...

Шунда мин безнең татар шагыйрьләре нишләп Гете, Гейне, Байроннарны турыдан-туры тәрҗемә итмиләр икән, дип уйлап утырган идем. Безнең урманнар, безнең бүреләр турында әллә никадәр матур шигырь бардыр әле шуларда...

Тере бүрене чыплап торып якыннан мин бары тик унбиш яшемдә генә күрдем. Октябрьның йомшак яңгырлы бер иртәсендә без сабакташ Мансур белән педучилищега барырга чыктык. Беренче дәрескә өлгерергә кирәк, ә моның өчен пычрак ерып нәкъ унике чакрым юл үтәсе бар иде. Яңгыр төн буе яуды. Әни әллә ничә тапкыр авыр сулап әйләнеп ятты: һай, коя да коя, бу бала ничек итеп кенә барыр инде, диде. Мин дә начар йокладым. Шулай караңгылы-яктылыда әни мине уятты, ашатты һәм озатып калды. Мансур да безгә кереп килә иде.

Авыл, капка-коймалар, урамнар, салам түбәле абзарлар барысы да лычкылдап җебегән — дөнья изелгән, яңгыр һаман сибәли. Тагын аз гына яуса бу ләҗердек җир йомшап, йортлар, карт агачлар, каралтыкура шуышып су буена таба түбән төшеп китәр сыман иде.

Ат абзарлары тирәсеннән барабыз. Яктырып килә. Ат абзарлары янында зур тирес өеме бар. Яңгырда пешеп, дөньяга җылы ис бәреп утыра. Кызгылт-сары тау. Шуның яныннан без кырт борылабыз да урман юлына чыгабыз. Шул тауны әйләнеебрәк (аның янында аеруча батках) авылдан аерылып яткан бер мизгелдә, тирес артыннан тауның үзе

төсле кызгылт-соры галәмәт биек торыклы бер эт килеп чыкты. Безнең авылда мондый эт юк иде бит! Масралар этедер! Башка авыл эте... Ят эт койрыгын бот арасына тыккан, авызыннан телен бераз чыгарган иде. Кинәт Мансур да, мин дә туктап калдык.

— Бүре!

Икебез берьюлы шулай кычкырдык. Һәм шул вакытта минем тыным буылды. Күзне яшь каплады. Соры койрык бездән ун адым чамасы гына алда юл читенә барды да утырды. Калганын без түгел, инстинкт эшләде. Мансур үзенең чиста бакыр тавышы белән:

— Бүре ба-а-а-р! — дип сөрән сала башлады, ә мин, юеш җиргә иелеп, ат тубы алдым һәм соры койрыкка аттым. Аннан тагын, тагын. Ат тубының берсе бүренең алдына ук килеп төште. Күрәсең, ул мондый хурлыкны күтәрә алмады, торды да юеш камыл басуына, әвеслекләргә таба китеп барды.

Мансур әле һаман кычкыра иде.

Ул көнне педучилищеда без генә сөйләдек. Төнлә дә йокы булмады: тулай торакта да без генә сөйләдек, чигереп-чигереп, әлләниләр өстәп-өстәп...

Ләкин монысы әле бик кечкенә вакыйга булган икән. Ул кышны бүреләр бик күп булды, кая карасаң, шунда бүре эзе иде. Яз җитте, без инде ике-өч көн саен кайтып йөри башладык. Училищега юл урман буеннан бара. Бер яктан калын стена булып урман сузылган, икенче якта иген басулары. Училищега килеп җитәргә дүрт чакрымнар кала сул якта зур кысыр басу. Сугыш башланганнан бирле анда чәчмиләр һәм ул басу узган елгы корыган биек әремнәре, билчәннәре, шайтан таяклары белән язга чыга да, җәй уртасына таба гына яшелләнә иде. Ул әле соры диңгез булып майның кояшлы җилендә дулкынланып утыра. Мин шул кысыр басу кырыннан ашыгып имтиханга бара идем...

Кинәт кенә минем күз алдында табигатьнең бөтенлеге, тигезлеге җимерелде. Нәрсә булды? Мин әле моны аңлый алмый идем. Шунда кысыр басуның ничектер селкенгәнен күрдем. Кай төше селкенә, ничек селкенә — моны белеп булмый. Туктап калдым. Йөрәк дөп-дөп килә. Текәлебрәк карагач, «соры диңгез»нең бер урында дулкынланганын, әмма бу дулкыннарның миңа таба тәгәрәгәнен аңладым. Тагы да текәлебрәк карагач, боларның бозау кадәр биек бүреләр икәнен белдем. Берәү, икәү, өчәү... Тагын берәү, икәү, өчәү... Алты! Я хода! Тагын берәү, икәү, өчәү... Бүреләр, кильватер строе сыман өч звенога бүленеп, әремле басуны ярып миңа таба киләләр иде. Шунда күк йөзендә кояш селкенгәндәй итте, күз алларым караңгыланды. Бу моментта бөтен планетада шушыннан да әһәмиятлерәк бер вакыйга да булмагандыр. Урман буендагы кояшлы басу юлында ялгыз бер малай һәм... тугыз бүре. Минем хәл котылгысыз иде. Чигенергә дә, алга барырга да җегәр җитми, кычкырырга тавыш юк иде. Нишләргә? Баш ватарга туры килмәде, чөнки берни эшләп тә булмый иде. Акрынлап айный башладым. Тукта, боларның берәрсе теге, узган көздә мәсхәрә ителгән бүре булса? Ул мине, һичшиксез, хәтерләп калгандыр. Ерткыч хайваннар хәтерле була диләр. Менә хәзер ул болай дип авыз ерып килсә: әһә, йонлач муен, эләктеңме инде? Теге вакытта үз авылың янында бик калай әтәчләнгән идең. Менә эләктеңме? Яки ул үзе булмыйча, аның нәселе булса? Болай уйласалар: әһә, синме әле ул узган көз безнең кодагыйны (я кияүне, шайтан белсен!) мәсхәрә иткән? Ат тизәге ыргыткан бит ул аңа, һи, әҗәткәнә... Менә хәзер исәп-хисапны өзәбез инде без синең белән...

Беренче төркем юлга килеп чыкты. Ара— йөз метрлар чамасы. Юлбашчы миңа борылып карады. Ничәдер секундлык киңәшмә. Бу миңа

эллә ничә минутлар тоелды. Мин әлләниләр уйлап бетердем. Күрәм — юлбашчы кузгалды. Юлны аркылы ярып беренче төркем яшь наратлы питомникка кереп китте. Икенче, өченче төркемнәр исә юлда туктап та, миңа карап та тормадылар. Күрәсең, юлбашчыдан шундый әмер булган: 1941 елдан бирле ач яшәгән, педагогика, психологиядән башка нәрсәне белмәгән бу йонлы муен белән авыз пычратып маташмаска. Моның белән барыбер әлләкем була алмыйсың. Сөяк белән тамак туймый. Арча ашханәсендәге сугыш чорындагы «рагу» белән бер инде бу. Алга, минем арттан, интервал саклаган хәлдә бер эзгә генә басып баруны дәвам итәргә. Азимут — 345 градус, ориентир — питомник түрендәге лесхоз баганасы. Җыелу вакыты — җиде ноль-ноль...

Ул көнне мин малайлыктан егетлеккә таба бер адым атладым. Юк, ни генә әйтмәсеннәр, бүреләр кешеләр кебек үк яман түгелләр. Мәсәлән, фашистлар кебек...

Безнең урман, гомумән, бүрегә бик бай иде һәм шуның белән серле дә, куркыныч та иде. Дөрес, бүреләр, урманны «культуралаштыргач», бераз кимеделәр. Шулай да күп, бик күп иде. Шуңадыр инде, авылда бүре толыплы кешеләр (юл йөрүчеләр, тегүчеләр) байтак иде.

Урманны «культуралаштыру» утызынчы елларның башында гамәлгә керде. Шуңарчы ул әле тоташ массив кына булган. Культуралаштыру аны йөзәр гектардан торган тигез шакмак кварталларга бүлү, аларны номерлау, берничә кварталдан соң зуррак визирь юлы ачу, билгеле бер урыннарда казыган юл (канаулы юл) яру, кордон, йорт салу, телефон юллары ачу кебек эшләрдән тора иде. Моның барысын да безнең авыл картлары эшләде. Урманда кунып ятып, атналар буе кайтмыйча эшләделәр. Урманга баруның үзенең экипировка тәртибе була. Безнең күрше Вәли картта ул болай: юкәдән матур итеп шакмаклап үрелгән сумка. Вәли карт аны уң җилкәсенә элә. (Хәзер халыкара туризм бик нык үскән чорда, чит ил аэропортларында, тимер юл вокзалларында бер илнең гиды икенче илнең интурист вәкиле белән бер-берсен шулай тиз табалар: уң як җилкәдә күн сумка). Вәли карт сак кеше, ул 1904 елгы рус-япон сугышында катнашкан солдат. Аның сумкасында кайрак, пәке, юкәдән үргән чехол эчендә шешә белән су, шырпы, ашау ризыгы. Билдә балта, бил буылган.

Визирь юлы ачуда аеруча зур мәхәббәт белән эшләгән Шәмсетдин һәм Шакир дигән ике карт хәтердә калган. Картлар тәмәке тартмыйлар, аракы эчмиләр иде. Эшчән, аз сүзле кешеләр. Икесенең дә билләрендә яссы каеш. Каешка балта кыстырылган. Болар урман кисә, төп чыгара, питомник утырта, канаулы юл кырыен чүп үләннәрдән чистарта, ботак яндыра, квартал баганалары ясый — кыскасы, урманны үз балалары кебек кадерләп, саклап тоталар иде. Кайвакытта алар, кечерәк кенә йөк ясап, утын — коры ботаклар, агач төпләре, сынык-санык төяп кайталар. Каршыларына очраган кеше, безнең авылның гадәте буенча, утынны кайда төягәннәре белән кызыксына, әмма бу картларның андый вакытта икесенә бер җөмлә бар иде:

— Урман бай ул...

Урманның һәр почмагында үзенә генә хас ис бар. Шуңа күрә безнең авыл халкы искә аеруча сизгер. Бу исләр ел вакытына, көн вакытына, һава хәленә карап үзгәреп тора. Парфюмериядә һәм кулинариядә очрый торган бөтен исләр тупланган анда. Менә «тупы урманы». Монда имән, өрәңге. Мондый исенең иң шәп вакыты — көз. Кыштыр-кыштыр коелган өрәңге яфраклары агач төпләренә тигез түшәлә. Җирдә әле җәйдән калган җылы бар. Яфрак белән түшәлгән имән, өрәңге тамырларыннан борынга имән мичкә, укроп, тозлы кыяр исе бәрелә. Ара-тирә борынга җир исе килә. Имән урманындагы көзге җир имән мичкәдә

тозланган ак гөмбә исен бәреп утыра. Түбәнрәк төшсәң — чыршылык. Кара чыршылар, кәүсәләренең төньяк кабыгын зәңгәр сакаллар үстереп бизәгән. Арткы рәттәге калын-калын ботакларын кинәт кенә җиргә таба борып, үз төпләрен үзләре төреп алганнар, агач төбенә бернинди кар, буран үтә торган түгел. Җәйге эссе көндә чыршы төбендә кое шипр исе, андый затлы шипрны бары тик Ленинград фабрикасы гына эшли. Ә зиреклек! Таллык! Таллыкка килеп кергәч, иң беренче эшең борынныңны кашу була, аның көньяк агачларына гына хас булган дарчин кебек кырыс, әмма затлы исе күзгә дә, биткә дә бәрелә, борын юлларын кытыклый. Юкәлек! Юк, мондагы ис бүтән бер урманда да була алмый. Монда яңа сугылып, кичә тарттырылган бодай оныннан пешергән кабартма исе — бары тик шул ис кенә килә!

Ул «төплек арты»! Анда кунган төннәр, бүредән курыккан атлар, анда яккан учаклар, ул учакларның көлләрендә пешерелгән бәрәңгеләр, шалканнар... Андагы еланлы сазлыклар, урман тавыгы ояларыһәм төлке уйный торган орлар... Күрше малае Шәйхулла, әтисе урынына ат сакларга килеп, «төплек арты»нда куна кала иде. Үзе белән ул мине дә алып баргалады. Мин, күрәсең, бик кечкенә булганмындыр инде, атларның көне буе гел ашап торуларын аңлый алмыйча гаҗиз булдым. Шәйхулла көлде дә көлде.

— Вәт, дурәк, ат бит ул, кеше түгел,— диде.

Аннан ул миңа бер тай тотып биреп, урманнан тайга атландырып кайтарырга вәгъдә итте. Мин кызыгам да, куркам да. Әмма Шәйхулла сузды: мендәрнең (ул тай, колын дип әйтми, ә сокланып, иркәләп «мендәр» дип кенә йөртә иде), диде ул, тоткач-тоткач настиящиен тотарга кирәк (безнең авылда чын, яхшы әйберне «настиящий» дип йөртәләр). Һәм ул көзнең моңлы, вак яңгырлы бер көнендә мине урманга алып чапты. Күзләре ут булган, борын тишекләре киңәйгән иде.

— Бүген,— диде,— мендәрнең настиящие!

Урман аланында утлап йөргән атлар арасыннан ул берьюлы ике кырыкмыш тотып килде. Мунчала аркалыктан ялганчы йөгән генә ясады да «мендәр» өстенә мине меңгереп тә куйды. Үзе дә шундый йөгән ясап кырыкмышка атланды. Һәм без авылга таба элдерттек. Дөрес, баштарак мин курыккан идем. Әмма мендәр шулкадәр җайлы, шулкадәр йомшак элдертте, ике чакрым узганны мин белми дә калдым. Аннан соң миңа иярле атларга атланырга, беренче тапкыр чит илгә чыккач, кыланып, гарәп аргамагына атланып йөрергә туры килде. Фил өстендә дә утырып йөрдем, әмма Шәйхулла тоткан мендәр белән урманнан кайтуым мәңге хәтердә калды. Бер генә мотоциклист та, бер генә «Жигули» хуҗасы да ул мендәрдән алган канәгатьлек хисен кичерә алмыйдыр...

Кайтканда без элдертеп кенә «маш» яныннан уздык. «Маш» — бөек дигән сүзме соң? Кырык метрлар чамасындагы биеклектә салынган вышкаларны бездә «маш» дип йөртәләр. Машны салган еллар... Мин әле бик кечкенә идем. Әмма урман буендагы шул калку урынга «маш салучы руслар килгән» дигән хәбәр минем йөрәкне кузгатты. Маш салу — ниндидер тышкы олы дөньяга омтылу дигән сүз инде ул. Көзге кичләрдә әти мине ындыр арты киртәсенә бастырып, урман буендагы маш салган җирне карата иде, ә анда ут яна.

— Менә, улым,— электр уты шул була инде,— дип әйтә иде әти. Күрәсең, аларның ниндидер бер станцияләре-фәләне булгандыр инде. Бераздан ул маш очлаеп күккә ашты. Малайларның ул көннәрдә бөтен сөйләгәннәре шул маш турында гына булды.

— Фәттах Рәуфе, иң очына менеп, әрҗә эченә кереп караган!

— Әптел Гаптелфәрте, иң очына менеп, күлмәген салып очырткан...

— Ике баскычына менсәң, Арча уч төбендәге кебек икән... (Маш җиде секциядән тора һәм аны җиде баскычлы дип йөртәләр иде).

— Очына менсәң, аяз көнне зәп-зәңгәр булып Балавыз урманы күренә икән. Казанны шул урман гына каплап тора ди... (Дербышки тирәсендәге урманны картлар Балавыз урманы дип йөртәләр иде).

Маш янына барганчы бер-ике ел үсәргә туры килгәндер әле. Машны беренче тапкыр олы малайлар белән җиләктән кайтышлый күрдем.

Күк йөзенең бик биек икәнлеген мин шунда тойдым. Озын-озын чыршы бүрәнәләрне тимер кучтил белән ялгап җиде бүрәнә биеклеге салынган очлы бер корылма зәңгәр күккә ашкан да, шомлы сызгырып утыра иде. Минем шулвакыт, шатлыктанмы, әллә бу мәһабәтлекне кабул итеп бетерә алмауданмы, сулышым кысылды, йөрәгем еш-еш типте. Бу — әллә ниткән тылсымлы көчкә ия, ихтирамга ия иде. Мин, әлбәттә, ике баскычтан ары менә алмадым, өстә кояшлы тыгыз җил уйный иде, бары тик ташбаш Габдрәкыйп кенә, очына ук менеп, күлмәген салып ыргытты. Аның алсу күлмәге, җилдә тирбәлә-тирбәлә, маштан бераз читтә бодай басуы кырындагы күкчәчәкләр өстенә килеп төште. Шуннан бирле бу маш минем йөрәгемнән китмәде, ул миңа һәрвакыт җанлы, алай гына да түгел, олы җанлы, миһербанлы, тылсымлы бөек бер шәхес булып тоелды, ә адәм баласы һәрвакытта да миһербанлы олы шәхесләргә мохтаҗлык тоя. Маш гомер буе безнең авыл халкына иптәш, юл күрсәтүче булды. Авылга кайсы яктан гына кайтып керсәң дә, иң беренче әнә шул маш күренә, шуны күргәч салкын бураннар, газаплы карлы юллар җиңеләеп китә, ә төннәрен урман буеннан узганда машны караңгы күктән сизәсең — ул мәһабәт шаулап сине каршы ала, озатып куя. Аның үз чырае, үз бите бар иде, ул миңа бала вакытта, ничектер, кайгылы-борчулы ананы хәтерләтә иде, кыскасы, безнең авыл өчен кырдагы, басу түрендәге бер ана иде ул.

1956 елның җилле коры бер җәйге көнендә маш ауган. Поездлан төшеп, урман эченнән чыгуга машны күрермен дип горизонтка күз ташлаган идем — басу түрләре ятим! Баштарак аңламый тордым. Бөтен әйләнә-тирәнең яме беткән, җир белән күкне тоташтыра торган мөлаем, кайгылы чырайлы карт ана үлгән, басу-кырларның рәте беткән иде. Чиркәве җимерелгән, мәчет манарасы ишелеп төшкән авыл да шулай нәрсәсездер кала — хезмәт халкының кул көче белән салынган сәнгать әсәренең югалуы — кызганыч. Безнең авыл табигатен очлап, камилләштереп, биеклек белән тоташтырып торучы маш инде юк...

Халык моңа шулкадәр изге итеп караган ки, маш җимерелгәч, андагы коры чыршы бүрәнәләрен ташып, ярты авылны кышлык утын белән тәэмин итеп булыр иде. Әмма авылдан бер генә кеше дә бер генә йомычка алып кайтмады. Машның коры, сөяккә әйләнгән бүрәнәләрен, ул машны күрмичә яшәгән үзәндәге күрше авыл халкы утынга ташып бетерде.

Бәхеткә каршы, каяндыр, кемнәрдер килеп, нәкъ шундый ук яңа маш салып киттеләр. Авыл нибары бер җәй машсыз, ятим яшәде. Икенче машка да акрынлап күз ияләнде, әмма теге, беренчесе йөрәккә якынрак иде, анысы «безнекерәк», балачак истәлеге буларак кадерлерәк иде.

Землемер баганалары, урмандагы «тәмәке тарту урыны» кебек эскәмияләр, беседкалар ун еллар, егерме еллар буе торалар, халык аларны саклап, кадерләп тота. Хәзер таш юллар кырыена тимер-бетон конструкцияләрдән ышыклану, автобус көтү корылмалары бастырып куялар, бераздан карыйсың — шуны теткәләп, ваткалап эштән чыгаралар. Ә землемер баганалары, урман баганалары, урман буендагы щитлар күпме еллар буе исән-имин тора. Без кечкенә вакытта (ихтимал, бу — авылдан безнең беренче чыгуыбыз булгандыр) басу түренә землемер баганасы карарга махсус бара идек. Андагы дулкынланулар! Зур өем

уртасында ниндидер серләрне үзенә туплаган хикмәтле багана утыра. Ул баганаҗын шома итеп уелган җиренә көйдерепме, кара буяу беләнме зур түгәрәк печать басылган. Бу печать сине шушы җиргә, шушы басуга беркетеп куйган: бу җир синеке, бу багана — синең чик сакчың, ышанычың.

Кышкы буран көннәрдә ерак басу чатларында, урман почмакларында бу багана әллә нинди серле булып күренә: ул, бер карасаң, кыймылдый кебек, икенче карасаң, юл чатына чыгып утырган бүре кебек. Еракта, кар диңгезендә, саргыл-соры булып утырган ул баганадан сискәнеп, буранда атлар да пошкыралар иде. Бу баганалар безнең якның бизәге, матурлыгы иде. Хәер, бу турыда М. Юнысның «Занзибар — зәңгәр болытлар артында» дигән китабына инде язылды бугай.

Безнең авылдан чыгып әнә шул машка, әнә шул баганаларга карыйкарый, теләсә кайсы якка ике чакрым бар — урманга килеп чыгасың. Тик Масра ягы гына кешене читкә алып китә. Ул — Арча юлы, анысы кешеләрне солдатка, сугышка озаткан, анысы — яралыларны, сирәк калган исәннәрне авылга кайтарган юл. Ә башка юллар — гел урманга.

Безнең урманның матурлыгын, мәгънәлелеген, акылын беләсегез килсә, аның эченә көзге вак яңгыр яуганда керегез.

Вак кына аланнарда икешәр, өчәр булып моңаеп утырган печән кибәннәре. Аларны киртә белән әйләндереп алганнар, ул киртәләрнең кайрысын пошилар килеп каезлаган. Карт юкәләр, вак яңгыр тамчыларын өсләренә җыеп, акрын гына шыбырдашып утыралар, әле яфрак бар, әмма инде соңгы атналар. Каен инде саргаеп яфрак коя, яфрагын койган каен чыбыклары күксел шәмәхә слива төсенә керә бара, бу вакытта авыл халкы аларны җыеп, ындыр табагы, урам себерү өчен себерке ясый. Юеш киртәле печән кибәннәре, җиләк исе, шипр исе бәреп торган коры ылыс түшәлгән чыршы төпләре — барысы да калгып, кышны көтеп уйга калган. Шулар янында көз килгәнне тыңлап тору рәхәт тә, сагышлы да... Киләсе елда да шулай күрешә алырбызмы? Без исән булырбызмы? Урманчы клеймә сугып сезне утынга ектырмасмы? Чыршы агай, сине йорт бүрәнәсенә дип кисеп урламаслармы? Әй, сез, печән кибәннәре, киртә буена килгән биек аяклы, кара ахак күзле беркатлы поши малайларына, кызларына бездән сәлам әйтегез! Әй сез, чыбыклы юл буендагы чокырлар, орлар. Иңкүлектә уйнаган төлкеләргә әйтегез: сак булсыннар, аучы килгәнен сизми калмасыннар!

Вак яңгыр сибәли дә сибәли, ә йөрәккә рәхәт — кан саф, күңел саф. Кычкырып бер җырлыйсы, шушы гүзәл мәһабәтлеккә гимн җырлыйсы килә:

> Кара урманныңлай уртасында
> Төлке уйный торган орлар бар...

Әмма моңа Рәшит Ваһапов моңы кирәк. Рәшит Ваһапов исә, безнең урмандагы бик күп мәһабәт агачлар һәм киек кошлар кебек, бу дөньядан китеп барды инде...

## Алай да чишмә бар әле...

Сафый абзыйның йорты урам рәтеннән бөтенләй читтә, су буена таба бүлтәеп чыккан тау битендә. Урам тормышы аңа кагылмый. Ул бөтен хуҗалыгы, бала-чагасы белән урам тормышыннан читтә. Үзе колхозның яшелчә бакчасын саклый. Сугышка кадәр һәм сугыш елларында колхоз кишер, чөгендер, кыяр, помидор, шалкан үстерә һәм көзен хезмәт көненә шуларны бүлә иде. Яшелчә бүлгән көнне китә пеше-

рẽнү! Чөгендер пәрәмәче, шалкан пәрәмәче, кишер бөккәне... Хәзер боларның берсен дә утыртмыйлар, үстермиләр. Рентабельле түгел икән. Халык хәзер кибеткә көйләнгән. Район үзәгеннән кибеткә кәбестә, помидор, кыяр килә. Хатын-кыз, сумкасын тотып, шунда таба чаба. Әмма үзе үстермәгән яшелчәдән хатын-кыз файдалана да белми. Хәзер чөгендер пәрәмәче, чөгендер катыгы, кишер бөккәне, кәбестә бөккәне, шалкан пәрәмәче, чөгендер, шалкан суы дигән ризыкларны әзерләүчеләр бөтенләй юк. Болар исәтлекләрдә генә. Бик кызганыч...

Ә Сафый абзый үз балаларының сумка тотып кибеткә йөриячәген уйламады, хәер, моның өчен аның вакыты да юк иде, колхоз бакчасын каравыллап, үзенең тау битендәге хикмәтле кыен бакчасын карап ул яши бирде.

Кызгылт бит, зәңгәр күз, очлы ияк. Сирәк сакал. Өстә — кызыл сатин күлмәк. Бакча — таулы. Киртләч-киртләч. Авылда бүтән мондый бакча юк. Киртләч саен койма буенда бер умарта — багана умарта. Кемнәр уйган? Сафый абзый моны ата-бабадан калган дип аңлата. Кеше, мәсәлән, бакчасында бары тик бәрәңге генә үстерә (безнең авылда әле дә шулай: ашъяулык кадәр җирдә дә бәрәңге үстерергә тырышалар). Әмма Сафый абзый бакчасында эшләр башкача: су буенда, койма баганасы хезмәтен үтәп, бер рәт зирек үсә. Шунда ук бер төп биек кара чыршы. Шунда ук колмак, таллар. Бөтнек үләне — бары тик Сафый бакчасында гына. Каерылып, дуамалланып үскән, өй урыны кадәр балан куаклыгы. Тагын әллә ниләр. Боларның кирәклеген, рәтен бары тик Сафый абзый үзе генә белә, авыл халкы исә аңа сәер кеше дип карап яши бирә. Сафый картның абзарына, утынлыгына кергән кеше юк. Аның бакчасына кеше аяк атламый. Чөнки үзләре өчен оялалар. Бөтен кешедә бәрәңге бакчасы. Ә монда? Ходай белсен, кыргый оҗмах? Башка кеше дә кыш чыга, Сафый абзый да. Хатыны Мөфлиха түти биш чакрымдагы күрше авылдан. Бөтен шөгыле — әлеге, күрше авылдагы туганы янына барып хәл белү. Язмы, көзме, буранмы, яңгырмы — бу ике туган һәр атнага бер тапкыр бер-берсенең хәлен белешәләр (димәк, атнага ике тапкыр күрешәләр). Кызыгы шунда: буранда алга таба егылып, җәфаланып чана тартып барган бер кешене очратсаң, бу, һичшиксез, я Сафый абзый хатыны Мөфлиха, я — аның туганы. Ерактан газап белән (әйтик, язгы юл өзеклегендә) «уфалла» арбасы тартып килгән, бөкрәйгән берәүне күрсәң, бу — шулар, я тегесе, я монысы. Шунысы кызык: бу арба яки чанада, һичшиксез, ел вакытына карап, мәгълүм бер «прейскурант» була. Әйтик, Мөфлиха түти үзенең сеңлесенә барганда, чанасына ике чиләк бәрәңге (тунга төреп), сарык бәтиләре өчен өч данә юкә миллеге, әле генә бозаулаган сыерга үз бакчаларыннан җәен чапкан бер учма печән, ашъяулыкка төргән бер бадьян балан, тагын бер уч мәтрүшкә салган була. Атна ахырында син шул ук юлдан Сафыйларга хәл белергә килүче бер түтине очратасың. Бөкрәеп арба тарткан. Ул — Мөфлиха түтинең туганы. Арбасына ул ике чиләк чамасы баз бәрәңгесе, өч-дүрт юкә миллеге, бер-ике бәйләм мәтрүшкә, чүлмәк белән угыз сөте, бүген пешергән ипи һәм бер пулән юкә утыны салган (чыра телергә бик әйбәт, яки коймак пешергәндә мичне ялкынландырып алырга).

Гомумән, бу ике туган ел буе, теләсә нинди һава шартларында, рәхәт газап күрәләр иде, бу дөньяда үзең эзләп алган газаптан да рәхәт тагын нәрсә бар?

Сафый абзый исә боларга берни әйтмәде, киресенчә, ике кыз туган очрашкач ул шатланып китә, келәтенең аннан башка беркем дә белмәгән урыннарыннан кәрәзле бал алып керә, боларны чәйгә утырта да, үзе тау башына — чишмәле тауга чыгып чирәмгә утыра иде. Ә чишмә гөрли, чурлый... Язын бу тау башына малай-шалай җыела, аннан соңрак, инде язгы ташулар кочәйгән чорда, монда егетләр җыела, язгы

кояшка шатланган кызлар. кәс-кәс басып, бу чишмәгә суга төшәләр, егетләр тау башыннан, Сафый абзыйның кояш жылыткан коймасына арка терәп, алар белән сүз уйнаталар иде.

Җәй көне... Җәй көне Сафый абзый шунда. Чишмәне ул карап тора, өстен яба, тамагын чүп-чардан чистарта, әйләнә тирәсендәге чүп үләнне йолка, үзенең хикмәтле, кирәмәтле бакчасына кереп югалганчы чишмәне бер әйләнә. Аннан, көндезге сәгать уникеләрдә, чишмә янында хатын-кыз кайнаша, уракчы хатыннар, яулыкларын артка чөеп, бит юалар, көлтә бавы чылаталар, өстикәгә су тутыралар. Уракчылар кайтып китүгә, даңгыр-доңгыр килеп, кулазак арбага мичкә салган өлкән ат караучы Әхмәдулла абзый төшә, башта чишмәдән агып чыккан ерганакка алып килеп, йөгән сабагын ычкындырып, аркалыгын бушатып, сызгыра-сызгыра ат сугара. Аннан озын агач саплы кара тимер чиләк белән мичкәгә чишмә суы тутыра башлый. Сафый абзый шунда бик бәхетле була, керт-керт атлап таудан чишмә өстенә үк төшә дә, бәрхет чирәмгә җайлап утырып кәеф-сафа кора. Ул караган чишмәнең суын бүген колхозның җитмешләгән аты рәхәтләнеп эчәчәк. Сафый абзый шатлыктан кызгылт-сары тар сакалын сыпыра, аның вак зәңгәр күзләренә очкын йөгерә һәм ул, бәхете ташыган кыяфәттә, болай ди:

— Алай да чишмә бар әле, име, Әхмәдулла?

Шул көе ул елмаеп кала.

Әхмәдулла абзый исә, зур гәүдәсен җайга кыймылдатып, агач саплы чиләк белән мичкәгә су тутырып маташа. Ул, гомумән, сөйләшергә яратмый, эш кенә эшли. Әмма Сафый абзый караган бу чишмәнең кеше тормышындагы әһәмиятен ул да югары бәяли һәм, сүзгә гадәттән тыш юмартланып, Сафый абзыйның әлеге лирик чакыруына ул да җавап бирә:

— А-а...

Бу инде туган телгә тәрҗемә иткәндә менә нәрсә дигән сүз: әйе, ы-ы, Сафый туган, синең бу чишмәң безнең барыбыз өчен дә кирәк, син дөрес әйтәсең, сиңа рәхмәт.

Чишмә тирәсендәге без исемен белмәгән куе яшел үсемлекләрнең сап-сары чәчәкләренә бал корты куна, чишмә өстендә бүре көянтәсе очып йөри, әллә каян гына төклетура быжлап килеп куна, Әхмәдулла абзыйның аты бу төклетураны кигәвен дип белеп тартылып куя — камыт бавы, бөят күне шыгырдап ала. Сафый абзый елмаеп, бәхет чәчеп утыра, Әхмәдулла абзый да, бүген үзенең артыграк сөйләшеп ташлавыннан кыенсынып калгансыман, һаман әле чишмә инешенә үрелеп яткан атын ачулана: аты чишмәгә суга төшкән бер кызның чиләгенә үрелеп, авызлыклары белән зыңгырдап, төкле кара иреннәре белән чиләк бавын кыймылдатып ята икән. Ә теге кыз ачуланмый гына түгел, шатлана ук: халыкның ышануы буенча, ат ирене тигән чиләктән су эчү иң изге эш. Ат эчкән чиләкне, шуңа күрә, чайкап та тормыйлар. Ат эчкән чиләктән эчсәң, йокың ачыла. Булачак киленгә исә болар барысы да кирәк...

Әхмәдулла абзый аркалыкны күтәрә, йөгән сабагын тарттыра һәм дилбегәне кулына ала. Аннан, мичкә өстенә менеп артын төрткәч, атка дәшә:

— А-а...

Ат моны аңлый: әйдә киттек, кичен сусап эштән кайтачак синең туганнарыңа, иптәшләреңә бу суны алып кайтып кую синең белән минем өскә төшкән изге бурыч, дигән сүз инде ул. Камыт агачы шыгырдый, мичкәдә су чайкала, арба ераклаша. Әмма Сафый абзый бәхетле.

Иртәгә шушы вакытта Әхмәдулла абзый тагын шулай су алырга төшәчәк, Сафый абзый тагын шулай чирәм өстендә иркенләп, хозурланып утырачак, һәм Әхмәдулла абзый ике-өч чиләк су алуга, Сафый абзый тирән сулап әйтәчәк:

— Алай да чишмә бар әле, име, Әхмәдулла?
Әхмәдулла абзый тагын, күп сөйләшенә инде дигән бер кичереш белән, әмма Сафый абзыйны яратып, аңа җавап бирәчәк:
— А-а...
Ә бераздан, кичкә таба, чишмә буена вак-төяк кыз бала җыелачак, анда инде яңа бәрәңге юу (аны пычак белән арчып булмый, чиләк белән чишмә тамагына куялар да, чурлап аккан суда дөбердәтеп көянтә башын тыгып болгаталар, яңа бәрәңге арчыла да бетә), бүген суйган тавыкны юу, ит юу кебек эшләр башлана. Сафый абзый акрын шыгырдап, билләрен тотып урыныннан күтәрелә. Чишмәгә тагын бер тапкыр карап ала да, үзе өчен генә әйтә:
— Алай да, чишмә бар әле...
Бу чишмә әле дә шулай чурлап ага, безнең авылдан читкә киткән кешеләр авылга кайткач, әле дә булса, беренче чиратта, шул чишмәгә төшеп битләрен, кулларын юалар, рәхәтләнеп суын эчәләр.

## «Елларга иминлек бирсен»

Минем кечкенә вакытта тыңлаган догаларымның берсе һәм иң еш ишетелгәне шул иде. Без кечкенә вакытта ук еллар бик әллә ни тыныч түгел иде. Моңа без ятлап үскән җырлар шаһит. Кайдадыр, Кытайда, канлы сугышлар бара иде һәм без җаныбыз-тәнебез белән Кытай хезмәт ияләре ягында, аларның азатлыгы ягында идек. Кайдадыр, Испания җирләрендә, азатлык өчен изге сугыш бара, ә без җыр беләбез, безнең симпатияләр азатлык өчен көрәшүчеләр ягында. Ул вакыйгаларга күптән түгел булып үткән гражданнар сугышы җырлары килеп тоташа, ә ул вакытта җырлар татарчага тәрҗемә ителә иде.
Тынычлык, иминлек шулай бик кадерле, ул безнең халыкның рухына сеңгән иде. Әнә шуңа күрә карчыклар, кеше өенә килеп кереп түргә узгач, сәкегә әдәп белән янтаеп кына утырып, болай сүз башлыйлар иде:
— Хәерле бәрәкәт бирсен йортка, исән-сау торамсыз?
Безнең авылда «исәнмесез» дип түгел, әнә шулай мәгънәле, озын итеп сәламләшәләр иде. Ирләр исә урамда очрашканда, йортка кергәндә бик гади сүзләр белән болай исәнләшәләр:
— Ни хәлләрдә тагын? («Тагын»ның бу урындагы ролен мин әле дә аңлый алганым юк). Яки болай:
— Ни хәлләрдә ятасыз тагын?
Мондый исәнләшүдә ниндидер кайгыртучанлык, әдәп, әхлак нормалары чагыла, тынычлык, иминлек теләү сизелә иде. Исәнләшүнең бу формасы белән бер рус кызы (укытучы) кызыксынган иде. Аларга кергән һәр кеше йорт хуҗалары белән шулай исәнләшә икән. Ул моны, күп ишетә торгач, язып алган һәм миннән тәрҗемә итүне сорады. Әмма тәрҗемә итеп күрсәткәч, ул шаккатты: «В каких обстоятельствах вы лежите?». Һәр халыкның үзенә генә хас сүз бизәкләре, сүз-әхлак чуклары була, аларны тәрҗемә итеп маташырга кирәкми дә.
Олылар сөйләшеп утырганда да ара-тирә гел әдәп-әхлак кагыйдәләре, иминлек теләкләре белдерелә иде.
— Елларга иминлек бирсен.
— Бәндәләрне ач итмәсен.
— Балаларга тәүфикъ бирсен,— кебек изге теләкләр белән сәгатьләр буе самовар янында сөйләшеп утыралар.
Авылның педагогикасы да күпмедер дәрәҗәдә эшләнгән. Гомуми педагогикадан тыш, һәр гаиләнең үзенчәлекле, үзенә генә хас үрнәге,

башкаларга тәэсир итү көче бар. Закир абзый, мәсәлән, гомере буе өендә, ишегалдында, урамда чисталык өчен көрәште. Күздән себерке әзерләп кую аның иң яратып эшләгән эшләреннән берсе иде. Закир абзый себеркесен тотып урамга әллә нигә чыга, ишегалдында бер салам яки бер бөртек пычкы чүбе күрсә тынычлыгын югалта, йорттагы халыкны сүгә, кыскасы, көне буе себерке, сәнәк белән мәш килә — аларның капка төбе, алар турысындагы урам тары бөртеге төшсә шуны табарлык дәрәҗәдә чиста була. Тәгәллек, чисталыкка мондый таләпне мин флотта гына күрдем. Учебный отрядта вакытта ук безне шулай өйрәттеләр: плацта бер шырпы табылса, часть командиры безне тезеп куеп болай ди иде:

— Ишегалды дуңгыз абзарына әйләнгән, анда шырпы ята. Ә бүген сугыш башланса? Ә?

Сугышка кадәр авылда аракы эчкән кеше барын мин белмим. Армиягә егетләр китәсе көннәрдә Бимәр русларыннан бал сатып алып, ачы бал ясаганнары хәтердә. Күрше авылда бик саран, эшлекле, таза тормышлы бер кеше бар иде. Бары тик аның турында гына сөйлиләр иде: Арча базарында такта саткач, бер чикушка ала да (250 гр), квартирга кереп, шуның яртысын чәй чынаягына салып ак күмәч белән манчып ашый икән. Калганын авылга алып кайта. Бшкача аракы белән чуалган кеше күренмәде. Ни хикмәттер, авыл халкының барысында да кушамат бар иде: бүре, чыпчык, карга, мәче, пошн, кәҗә, сарык, үрдәк, тавык, чеби, этәч, тәкә, тана, үгез һ. б. Әйтергә кирәк, бу кушаматлар борын заманнан ук килгән һәм нәсел буенча күчеп тапшырыла баралар. Әмма болар шул дәрәҗәдә кешенең характерларына, рәвешенә, холык-фигыленә туры килерлек итеп ябыштырылганнар ки, читтән килгән укытучылар класста тәртип бозган, начар укыган балаларга интуитив рәвештә нәсел кушаматын әйтеп ачуланалар иде.

— Фәләнев, нәрсә син кәҗә шикелле сикереп йөрисең?

«Фәләнев» хурлыгыннан елап җибәрә:

— Кушамат әйтергә ни хакың бар синең? — дип укытучыга бәйләнеп тә ала. Ә тегесе берни дә белми әле.

— Фәләнева, нәрсә сарык шикелле аңгыраеп калдың? — дип укытучы такта янындагы кызны ачулана.

«Фәләнева» такта яныннан туп-туры өенә йөгерә. Дәрес беткәнче тегенең әтисе килеп җитә:

— Праҗванҗә (прозвание) белән баланы хурларга ни хакың бар синең? — дип дулый.

1939 елда мәктәпкә Әсәдуллин дигән бер егет килде һәм, авылда кушаматның бик киң таралганына шаккатып, мәктәптә кушаматка каршы көрәш ачты:

— Кушамат әйткән баланың авызына сугарга рөхсәт итәм, — диде.

Ике-өч көн буе класс идәнендә кан тамчылары күренгәләде. Аннан тыелды. Дөрес эшләгәнме ул укытучы, ялгышмы анысын педагогика фәне белгечләре әйтер. Әнә алты малай үстерә торган такта яручы Әскый (Әсхәдулла) абзыйның үзенә аерым бер педагогикасы бар. Малай — алты. Яшь аралары — берәр дә, икешәр генә. Еллар авыр чак, йорт салып азапланган вакыт. Кием-салым җитми, кибеткә мануфактура (кием-салым, ситсыны авылда шулай дип йөртәләр иде) бик сирәк кайта. Ул арада фин сугышы башланды — кысынкы көннәр. Ә малайлар шук. Дөрес, эшлиләр көне буе. Чабата ясыйлар. Әмма чабата ясап бу дөньяда беркемнең дә алга киткәне юк әле. Кич була. Әсхәдулла абзый кичен чыгып китә, фәләнне-фәләнне күрәсе бар, иртәге көн өчен тегесен-бусын җайлыйсы, сөйләшәсе бар. Әсхәдулла абзыйның хатыны, өйалды ишеген ачып, төз лапастан зур-зур өч кочак арыш саламы алып керә дә ласылдатып идәнгә җәя. Монысы булды

постель. Безнеңчә — урын-җир. Тӛрткәләп, суккалап алты малайны шунда яткыра. Әмма малайлар бит әле ул! Салам бит әле ул! Шунда бер аунап алмыйча түзеп кара әле син! Һәм мәхшәр кӛне башлана. Бу мәхшәр тамашасы бер вакыт шул дәрәҗәдә кыза ки, кайда малай, кайда салам икәнен аерып алмаслык була. Нәкъ шул вакытта ишекне «дыкъ» итеп ачып ата кайтып керә. Бичара малайлар уен белән кызып моны әле белмиләр, сизмиләр. Әсхәдулла абзый да ашыкмый, бүреген ишек ӛстендәге чӛйгә элә, чикмәнен салып мич кырына куя, борын суын бушатып ала. Һәм бер сүз әйтмичә матчага үреләә. Матча астында исә ике-ӛч кӛн саен алыштырылып, яңартылып торучы җиде-сигез тал чыбыгы. Ата кеше шуның озынрагын сайлап ала. Чажылдатып салам ӛстенә берне селти, һәм шул тавыш белән шок алган малайлар, электрон-исәпләү машинасындагы тӛгәллек белән, салам арасыннан бер-бер артлы сыртлары, аяклары, йомшак җирләре белән сикереп чыгып кына торалар. Беренче кисәтү чажылдавын исәпләмәгәндә, тал чыбыгы нәкъ алты тапкыр сызгырып ала. Ник бер генә ыңгырашу, ник бер генә елау! «Педагог» тарафыннан ник бер генә сүз!

Малайлар эшлекле, тәртипле булып үстеләр, олысы гына сугышка китеп, 18 яшендә һәлак булды.

Халык арифметикасы — монысы гаҗәп күп тӛрле формада һәм катлаулы иде. Бер генә мисал: тун, толып, тире чалбар тегүче Хәсән абзый капка тӛбендәге бүрәнәдә утыра. Ирләр җыелган. Яшьләр дә бар. Хәсән абзый арифметикадан проблемалы мәсьәлә бирә:

— Алтмыш капка, һәр капкада алтмыш божра, һәр божрада алтмыш ат. Ул ничә була?

Кеше — очына чыга алмый гаҗиз. Алтмыш тапкыр алтмышның... Алтмыш божра атың... Алтмыш кырыкмыш капкаң... — дип буталып бетәләр. Хәсән абзый исә бармак, бармак буыннарын әллә нишләтеп кенә чукыштырып ала да, әйтә:

— Ике йӛз уналты мең,— ди.

Бу картлар, баксаң, алгебраның бер бүлегеи ӛйрәнеп, санның кубын табып утырганнар икән.

Бервакыт миңа турист булып Урта Диңгез илләрендә йӛрергә туры килде. Туристларның бик күбесенең чит илгә беренче чыгуы иде. Одессадан кузгалып китүгә, палубада сӛйләшеп барган хатыннарның сүзләрен хәтерлим:

— Чит илләрдә ашаганда шау итеп сӛйләшү модада икән...

— Юк, юк, алай гына түгел. Иң модалысы — ашаганда кычкырып кӛлү. Анда анекдоттан кычкырып кӛлмәү культурасызлык санала икән.

Мин монысын әйткән хатынга күз салдым: юан гәүдәле, саллы бер хатын. Салон-ресторанда ул кӛлгәндә теплоход суга сеңеп киткән сыман була иде. Чит ил рестораннарында да берничә кӛн шулай кӛлеп карады. Бераздан аңлады: мондый кӛлүче бер ул гына икән.

Шунда мин үзебезнең авылның тегүче Хәсән абзыйны хәтерләдем: алар гаиләсендә ашау вакытында сӛйләшү тыелган иде. «Хәсәннәр сӛйләшмичә ашыйлар икән» дип, телгә алып әйтүчеләр була иде. Берничә еллардан соң мин Сеченов, Павловларның хезмәтләре белән таныштым, медицинага караган кызыклы китаплар укыдым. Ризык әлбәт эшкәртелсен ӛчен, озак чәйнәп, сӛйләшмичә ашарга кирәк, диләр барысы да. Аннан шундый ук таләпне хәрби хезмәттә дә күрдем. Учебный отрядта рота-рота булып ашап утырганда, старшина әледән-әле:

— Разговорчики! — дип искәрткәләп тора иде.

Намуслылык, алдашмаучылык кебек сыйфатларны да халык үзе тәрбияли. Бу сыйфатлар уенда (хәрәмләшмә), сабан туенда (аяк чалма), бүрәнә күтәргәндә (авырлыкны тигез күтәрергә) һ. б. бик күп

урыннарда тәрбияләнә. 1938 елгы сабантуйда, йөгерештән килүче малайлар мәйданга килеп житәр алдыннан гына, йөгерештә катнашмаган бер ят малай кушыла да, уртага беренче булып керә. Моны сизмәгән картлар бу малайга бүләкне биреп тә өлгерәләр. Әмма бүләк алдакчы малайга кыйммәткә төшә: аны йөгерешче малайлар ил-умач итеп кайтарып җибәрделәр. Шуннан соң ул үз гомерендә бер тапкыр да кеше алдамагандыр.

Икенче бер вакыйга хәтердә: кемгәдер килеп кунак булган яшь бер ир урамда тавыш чыгарган, сугыша башлаган. Сүз белән тыя алмагач, ирләр ат дилбегәсе алып чыгып аның аягын-кулын бәйләделәр дә, урам уртасындагы чирәмгә салдылар. Теге сүгенгән саен башына бер чиләк чишмә суы коеп тордылар. Кыйнашу, сугышу, алдашу, сүгенү — авылда бик хурлыклы эш исәпләнә иде.

— Фәлән кеше бик ямьсез сүз әйтте, шул авызлары белән ничек ризык кабар икән ул,— дип карчыклар сөйләнә иде.

Халык рухын бер дә рәнҗетергә ярамый. Бәдрислам исемле ташбаш бер малай бар иде. Безне, кечкенәләрне, мәчет ишегалдына җыеп керә дә, кәрнизләрдән, тәрәзә өсләреннән чыпчык оялары актарып, алсу тәнле, әле йон чыкмаган бер кепка чыпчык баласы төяп төшә. Шуларны зур таш өстенә куя да, икенче зур ташны алып өсләренә бәрә. Без куркышып торып йөгерәбез, ә Бәдрислам шат. Аның ул гадәтен белгән карт-коры гел әйтә иде:

— Кош каргышы төшәр әле. Үзе дә шулай булыр әле...

Бәдрислам сугыштан да исән кайтты, әмма эш вакытында җир астында калып басылып үлде. Бу идеализм түгел, әхлак нормаларының бер чиге бар: шул чикнең теге ягына — начарлык ягына — адым атлаган кеше тормышта аның җәзасын таба. Ни өчен идеализм түгел? Шуның өчен ки, дини идеология бу дөньяда начарлык эшләсәң, җәзасын теге дөньяда күрерсең, дип өйрәтә. Ә монда — киресенчә.

Кешеләрдә коллективчылык рухы шулай ук ата-бабадан килгән матур омтылыш. Коллективчылыкның бик матур үрнәген безнең күрше Камәр түти мисалында күрергә була иде. Моның иң беренчесе шунда: шәһәрдә катык-сөт җитми дип, Камәр түти җәй буе өендә Казандагы, Арчадагы таныш-белешләренең кыска итәкле, яки кыска чалбарлы, озын ботлы җиде-сигез баласын асрый иде.

— Әйдә, ашасыннар, катык-сөткә бер киңәндереп җибәрермен,— дип Казан-Арча тирәсенә барган саен ике-өч бала ияртеп кайта иде. Икенчесе — Камәр түтинең мунчасы. Зур, кара мунча. Зур ләүкә, озын эскәмия. Зур казан, кисмәкләрдә су.

— Әйдә, бар, кайнар суы да, салкыны да житәрлек, баш җуарга әче катыгы бар, миллеге ләгәндә булыр. Муйчаласы (мунчала) тәрәзә төбендә, сабыны — әләүкәдә. Әйдә, бар, муйча кереп чыккач чәй тәмле була...

Камәр түти шулай ди-ди кечкенә якта бөтен күрше-тирәне йөреп чыга.

— Әйдә, бар, анда бер кеше дә юк, кышның көне муйча тиз суына ул,— дип әйткәләп йөри.

Беркем дә юк дип мунчага килгән хатын-кыз аптырап кала: Камәр түти ярты урам хатынын чакырган. Безнең авылда тәртип шундый: мунчадан чыгышлый хуҗаның ишеген кагасың, хуҗа чыккач, рәхмәт әйтәсең.

— Рәхмәт, Камәр түти, мунчаң бик эссе булды, рәхмәт, аягың-кулың сызлаусыз булсын...

Камәр түти гомере буе хатын-кыздан шуны ишетеп яшәде. Кара мунча, гади әдәп нормалары, гап-гади мөнәсәбәт, әмма шул мунча белән Камәр түти бөтен бер төбәкне беркетеп тора иде. Хәзер кеше саен

ак мунча, бер-берсенә кермиләр, мунчага әйтмиләр. Һәркемнең үзендә бар. Яхшымы бу? Әлбәттә, яхшы. Нәрсәнедер югалтмадымы күршеләр? Белмим...

Монысы кара мунча булды. Әмма авылда бер ак мунча да бар иде. Кырыгынчы елны ак мунчаны тегүче Хөснетдин абзый салып куйды. Тегүче Хөснетдин абзый һәм аның «Йосыф-Зөләйха» кыйссасына гашыйк хатыны Гыйльмениса ак мунчаны менә болай ягалар иде. Дөресрәге, бүгенге культуралы, укымышлы иптәшләр ничек якса — болар да шулай.

...Мунча томаланган. Киләсе кеше инде билгеле, сәгате, минуты әйтелгән. Киләсең, керәсең. Мунча өйалды. Сәке, идән сап-сары, нарат бүрәнәсе исе. Сәкедә акбүз җәймә. Стенада — мәтрүшкә, имән яфрагы, кура яфрагы, кура яфрагы катыш бәйләнгән каен миллекләре. Шүрлектә, чөйдә — мунча чабыну өчен кирәк булачак реквизит: сукно баш киеме — баш пешмәсенгә, аска киез, кулга бияләй — чабынганда кул пешмәсенгә. Авылның әйбәт гадәте — ярты сәгатьләр чамасы узгач, мунча хуҗасы килеп ишекне шакый һәм хәл белә: ис тимәгәнме, исәнсаумы, салкын су китерәсе түгелме, бар әйберне дә таптыгызмы, фәлән-төгән. Ярты сәгатьтән тагын. Ә Гыйльмениса апада боларга өстәмәсе бар: мунчага чакырылган кеше — кунакка чакырылган дип исәпләнә. Берәр сәгать узгач, Гыйльмениса апа мунча өйалдысыннан дәшә:

— Менә өйалдына чыгып хәл алып керегез,— дип китеп бара.

Чыксаң — гөжләп утырган самавыр. Карасаң — аш тарелкасына түбәләмә итеп өелгән кайнар коймак. Шикәр, варенье. Пешкән чәйнең хуш исе.

Гыйльмениса апаның мунчасыннан, шуңа күрә, өч-дүрт сәгатьсез чыкмыйлар иде. Мунчадан чыккач, сыйлау башлана. Авылда бары тик Гыйльмениса апа гына әзерли торган чөгендер катыгы. Үзе кызыл, үзе — катык. Яки яшел суган тураган катык. Уҗым катыгы аеруча тәмле. Монысы күз көне, җир тундыргач, сыер көтүе уҗым басуында йөргәндә була. Язын, сыер бозаулаган көннәрдә, Гыйльмениса апаның өстәлендә мунча чыгышыңа — өчаякта кыздырылган угыз сөте. Күмәч кебек күпереп пешкән, өсте кызыл элпәле. Кисеп ашый торган сөт!

Шундый күңел бөтенлеге белән яшәүчеләр авылда байтак иде. Арадан берсе — «бүре Әскый». Моны түбән очтагы алты малайлы Әскый белән бутамас өчен һәр очракта да «бүре Әскый» дип йөртәләр. Өй эчләре белән колхозда, урманда эшләп йөргән бу гаилә авылда, тынычлык, сабырлык, киң күңеллелек белән аерылып тора иде. Бу — бик үзенчәлекле гаилә. Сөйлиләр иде: боларның күршеләрендәге Дәүләтша карт колхозга ике-өч ел соңрак кергән. Әскый — беренче елында ук. Колхоз уңышны мул биргән, буралар, капчыклар тулган. Дәүләтша абзыйның атын тышауламый-нитми урамга чыгарып җибәрә торган гадәте бар икән. Аннан, кирәк булгач, эзли, йөгән тотып ат чакырып йөри:

— Баһ, баһ, баһ...

Ат җавап бирми, күренми. Йөри торгач, Дәүләтша читән аркылы гына кычкыра:

— Әсхадулла! Безнең ат сезнең келәттә түгелме?

Кереп карасалар — келәттә. Он бурасына башын тыккан да, рәхәтләнә. Күз төпләренә кадәр ап-ак булган.

— Һай, рәхмәт төшкере, бар, әйдә, бар, ниш.әп келәт пычратып йөрисең,— дип бүре Әскый атны куып чыгара. Әскыйнең келәт бикләмәгәнен сизеп алган ат анда еш кунак була.

Дөньяда иң тыныч урын кайда? Бүре Әскый сәкесендә. Бигрәк тә көзге яңгырлы көннәрдә, кышкы бураннарда. Аларга егетләр дә, малайлар да килә. Чөнки егетләре дә малайлары да бар. Керәсең, түргә узасың. Әскый үзе чабата ясый. Сәке тулы юкә, ясалганы, ясалмаганы.

Өйдә тынлык. Сәкегә утырасың. Бераздан кырын ятып терсәккә таянасың. Бераздан ул тереүне аласың... Һәм искиткеч татлы йокыга таласын. Безнең авылда «ял итеп ал» яки «йоклап ал» дип сөйләшмиләр, бездә — «таянып ал». Таянып алу, димәк, бераз йоклап алу. Әскыйлар сәкесенә артын терткән кеше «таянып алмыйча» калмый иде. Бу сәкедә бөтен бер буын егетләре яңгырлы көннәрдә, кышкы бураннарда «таянып» яшәделәр, аннан 41 елда сугышка киттеләр. Тагын шунысы бар иде: җәйге төнне егетләрнең кайберсе, үз өенә кайтып тормыйча, Әскыйнекеләр белән бергә алар печәнлегенә менеп йоклый. Чөнки йокының иң тәмлесе бары тик Әскыйләрдә генә...

Дөньяда иң тыныч кеше кем? Бүре Әскый. Аның рәвешен күргәч үк нервлар туарылып, бушап китә. Ашыкмыйча гына йөри, ашыккан кешене сүндерә белә. Үзе берәүдән дә ким эшләми.

Сугыш вакыты. Бригадир Шәвәли карт тыз-быз йөренә, эшкә кеше җитми, көннәр болытлы, кырдагы көлтәләрне яңгырга киткәнче эвеслеккә ташырга кирәк. Шәвәли йорт саен керә, выжылдап чыгып йөгерә:

— Тизрәк булыгыз, тизрәк,— дип ашыктыра,— бу вакытта нинди өйдә яту ди...

Шулай йөгереп Әскыйләргә килеп керә.

— Син, кордаш, давай, давай! Явымга киткәнче көлтәләрне кертеп бетерик! Бу ниткән эш чәй эчеп утыру бу вакытта!

Башка кешеләр капкада Шәвәли күренүгә, эш коралын алып чыгып йөгерәләр. Әмма Әскый — таш стена. Шәвәлинең бөтен инерциясе шушында килеп бәрелүгә сүнә, бетә.

— Кайгырма, Шәвәли, кайгырма! Әле киндер киптерерлек көннәр булыр! Әле, әле...

Шәвәли буылып, сүгенеп чыгып китә.

Әскыйнең малайлары да үзенә охшаган иде. Олы малае Нургаян сугыштан яраланып кайткач, амбарда кладовщик булып эшли башлады. Аңарчы эшләгән кладовщиктан халык бер дә риза булмады. Анысы авырлыкны тигезләр өчен үлчәүдәге бәрәңгене алып пәке белән ярып бирә иде. Бәрәңгене алай итеп дөньяда шул гына үлчәгәндер! Бу тәгәллек колхозчының күңелен рәнҗетә иде. Нургаян кабул иткәндә, шулай да, тегенең җитмәүчелек чыкты: алтмыш кило он, ике центнер бәрәңге. Гомуми җыелышка куйдылар: амбар, подвал ишекләре җидесигез йозак белән бикләнә иде, без тимәдек, түләсен дип тавыш чыгардылар һәм түләттеләр.

Нургаян исә амбарны төнгә генә бикли торган булды. Тамагың ачса — амбарга бар. Бер-ике уч борчак алып чыгасың икән, Нургаян аны күрми дә, әйбер дә әйтми. Малай-шалай рәхәтләнде, тук булды. Бер-ике ел эшләгәч, Нургаян авырып китте һәм амбарны икенче кешегә тапшырдылар. Ревизия вакытында Нургаянның да өстеннән чыкты: тугыз центнер ашлык җитми иде. Нургаянны төрмәгә утырталар икән дип сөйләделәр. Гомуми җыелыш җыйдылар. Нишлибез дип, халыкка мөрәҗәгать иттеләр.

— Эсписәйт! Эсписәйт! — дип ду кубып кычкырды халык.— Эсписәйт итик!

— Егетне батырмыйк! — дип колхозчылар аны йолып калдылар.

Әскый карт үзе ахырдан сөйләп йөрде:

— Безнең малайның әнә илле дүрт пот ашлыкка кәгазе туры килмәде. (Ул һич тә өстеннән чыкты, җитмәүчелек булды дип аңларга теләмәде.) Хөкүмәт эшендә андый гына була инде ул. Була ул, була ул...

Әскыйнекеләр гомер буе бер кеше белән конфликтка кермәде, егетләре беркем белән сугышмады. Боларның рәвешен күрүгә үк чыккан ачуың басыла, кан тынычланып китә иде.

«Елларга иминлек бирсен» дигән сүзләрне ишетүгә Әскый картның бөтен гаиләсе минем күз алдыма килә...

*
* *

Мин бу китабымның әлеге бүлеген язып бетергән көннәрдә авылга кайттым. Җәй иде, тук арыш башагы, бәрәңге чәчәге, урманнан алып кайтып капка төпләренә кибәргә тараткан кырлык үләне исе килеп торган җәй иде. Кайттым, күңел нечкәрде. Күршедә өлкәннәрдән туксан сигезенче яшь белән бара торган бүре Әскый генә калган. Кайтуыма әйттеләр: кичә төштән соң, Әсхәдулла абзый кинәт авырый башлаган. Үлем авыруы эләккән, ашаудан калган, имеш. Үз гомерендә беркайчан да ашыкмаган, бернәрсәдән дә өрекмәгән, каушамаган Әсхәдулла абзый үлемне дә тыныч каршы алыр, алыр...

Мин шәһәрдән алып кайткан кып-кызыл ике зур помидор тоттым да, авыру янына киттем.

Мәнә без уйнап йөргән «Әскыйләр ындыры», менә инде бераз үзгәртелгән ишегалды, менә яңа йорт. Теге без «таянып торган» сәкеләр, әлбәттә, инде юк. Ишегалдында ак мунча, мотоцикл, комбайн резинасы, электр кайрагы... Яңа заман, яңа рух. Ишегалдында житү чәчле ике егет — Әсхәдулла абзыйның иртә үлгән улы малайлары — мотоцикл белән мәш килеп яталар. Кердем, исәнләштем.

— Бабаегыз авырып киткән икән, хәле ничек? — дидем.

— Әнә бит,— диде егетләрнең берсе, кулын чүпрәккә сөртә-сөртә.— Әнә бит, мунча нигезендә утыра.

Мин имәнеп киттем. Чыннан да, мунча нигезендә тезләрен туп-туры кушырып, күптәнге, әллә кайчангы Әсхәдулла абзый утыра иде. Мин аның янына килдем, исәнләштем. Ләкин ул кеше танудан узган иде. Җитү чәчле егетләр сөйләделәр: кичә, авыру эләккәч тә, бабай каушап калган, ары-бире йөренгәләгән, әллә ничә тапкыр егылган. Әсхәдулла абзыйның колак төбе, ияге, бер як бит чыгынтысы кызгылт-зәңгәр булып канга каткан иде. Ул гел егылган. Аның күзләре пыялаланып киткән, ул берөзлексез метмелдәтеп нәрсәдер ашый иде, бераздан мин аның нәрсә икәнен белдем — жилет кесәсеннән алып кәгазен сүтеп шоколад конфет ашый икән, җәйге эссе һавада йомшап җебегән бу конфет картның кулларын, авызларын буяп бетергән. Танымаса да, мин биргән күчтәнәчләрне алды һәм помидорның берсен конфетлы авызына якын китереп сытып суыра да башлады.

— Ә, ә-ә... Әле кем була соң бу? Кайсы авылдан? Ни атлы? — дип, алмашынган күзләрен миңа текәде.— Кая барыш? Рәхмәт, күчтәнәчең өчен, рәхмәт.

Җитү чәчле егетләр, бабалары янына килеп, минем кем икәнлегемне аңлатырга керештеләр. Карт таныгансыман булды, әмма күзләре тагын алмашынды.

Ул помидорлы, конфетлы кулларын колагына күтәреп, кинәт кенә азан әйтә башлады:

— Аллаһе акбәр, аллаһе акбәр, аллаһе акбәр!
Ля илаһе илляла-һ! Ля илаһе илляла-һ!
Әшһәде ән-ля Мөхәммәде рәсулулла-а-һ!
Сөбхәнәзил вәл-кил вәл мәләкю-у-у-т!

Моны карап торуы бик авыр иде, мин читкә борылдым. Җитү чәчле егетләргә болай дидем:

— Абыйларыгыз, апаларыгызга бүген үк телеграмма бирегез. Көнегез — санаулы.

Егетләр дә, әниләре — килен дә — бераз каушап калганнар иде. Гомер буе тыныч яшәгән, кешене борчымау гына түгел, борчылган кеше-

ләрне дә тынычландыра ала торган «бүре Әскый»не мондый хәлдә калыр дип кем көткән? Мин авыр күңел белән капкадан чыгып киткәндә, Әсхәдулла абзыйның ачигъланган тавышы яңгырап калды:

— Азан әйтәм, азан! Аллаһе әкбәр, аллаһе әкбәр, лә иллаһе илляля-һ!

Бичара, үз гомерендә бер намаз укыдымы, шуның рәтен белдеме икән? Юктыр, юктыр...

Ул — крестьян иде, җирдә икмәк үстерүче, урман кисүче, юкәдән — чабата, агачыннан — башмак, мунчаласыннан бау ишүче иде. Ул намазның нәрсә икәнен белмәгәндер. Әмма — чиста, ипле кеше иде.

Шул көнне кич «бүре Әскый» өзелде.

*Ахыры киләсе санда*

## Гәрәй Рәхим

# Җөмләләр

### Язучы биографиясеннән

*Җәмәгатьчелек арасында зур язучы булып танылуга карамастан, ул һаман да әдәби әсәрләр иҗат итүен ташламады.*

### Кагыйдә

*Язучы киеме белән генә түгел, әсәрләре белән дә матур булырга тиеш.*

### Характеристикадан бер юл

*Ул үргә менүгә караганда түргә менүне артыграк күрә иде.*

### Бердәнбер яхшылык

*Дошманым бу дөньядан миннән алдарак китеп барды. Ул тәмугка минем өчен дә чират алып куячак, әлбәттә.*

### Кышкы сурәт

*Урамда безнең театр сәхнәсендәге шикелле адәм ышанмаслык әре кар ява.*

## Илдар Юзеев

# ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

ШИГЪРИ ТРАГЕДИЯ

Әсәр геройлары — XX йөз башы аренасында халык массалары һәм Тукай.

## ПРОЛОГ

Ераклыктан, түбәннән юл килә. Ул, күтәрелә-күтәрелә, биеккә — Кояшка таба бара. Чылбыр-чылбыр бәйләнеп, тезелешеп, юлдан халык килә. Ул бик ерактан, тарих төпкелләреннән килә сыман. Сүзсез җыр: «Тәфтиләү» туа. Аренада халык түгәрәк булып оеша.

Уртада — сиртмәле бишек. Ул гүя «Тәфтиләү» көенә тирбәлә. Көй «Бишек җыры»на күчә. Шагыйрьне халык тудыра сыман. Халык эченнән уртага, акбиләүгә төргән бала күтәреп, Ана чыга. Ул, саклык белән генә, баласын бишеккә сала, тирбәтә. Бишекне бөтен халык тирбәтә кебек...

Ананың бишек җыры

Бабаңнар да җырлаган,
Атаңнар да җырлаган,
Көеңне башлап җибәр
«Зиләйлүк», «Карурман»нан.
Кечкенәгә — олы бул,
Сүздә — ихлас, туры бул,
Залимнәргә — кургаш бул,
Көчсезләргә — юлдаш бул.
Әнкәңнең — теләге бул,
Әткәңнең — терәге бул,
Халкыңның — йөрәге бул,
Җиһанның — кирәге бул!

*
*  *

Бер абзый Апушны түгәрәк буйлап йөртә.

— Асрарга бала бирәм, кем ала?
— Алмыйбыз!
— Алалмыйбыз!
— Дөньяда ул — артык кашык, ким бала...
— Артык кашык, артык бала — алмыйбыз!
— Юктыр миндә кыйммәтле сатлык бала,
Дөньяда ул ким бала, артык бала!

— Алмыйбыз!
— Бармы бирәр шәфкатьле җан дөньяда?
— Алмыйбыз!
— Асрарга бала бирәм, кем ала?
— Алмыйбыз!
— Тамагы ач, ялангач, мескен бала...
Бер тиенсез бушлай бирәм, кем ала?
— Алмыйбыз!
— Бармы бирәр шәфкатьле җан дөньяда?
— Бар!
— Асрарга бала бирәм, кем ала?
— Мин алам!

Апуш кулдан-кулга күчеп йөри, кайберәүләр куып җибәрә. Ул шулай халык эчендә югала.

I

Ут кабынуга, мәчет күренә. Мөәзиннең азан әйткән тавышы. Мөнбәрдә — хәзрәт. Халык, егыла-егыла, аллага сәҗдә кыла. Бер читтә — европача киенгән хөр фикерле яшьләр. Аннан да читтәрәк — йөзләрен яулык, шәл белән япкан хатын-кызлар. Уртада — инде егет булган Тукай. Халык аны күрми. Газеталар күтәреп берничә малай йөгереп керә. Алар «Әлгасрел-җәдит», «Фикер» дип кычкырып, халыкка газета тараталар. Тукай, кулларын югарыга сузып, күккә текәлгән.

Тукай тавышы

Я, ходаем, бу дөньяга ник мине кылдың икән,
Нигә мин дә бу җиһанның артыгы булдым икән?
Җир йөзендә хөкем сөрә иң көчле — Ачлык патша.
Вөҗдан — пычракта таптала, иң өстә — алтын, акча.
Юктыр бу җирдә тигезлек, синдәдер безнең өмет,
Ач пәрдәңне, йөзең күрсәт, ярдәмең берлән терелт...

Шагыйрьнең күктән иңгән сыман тавышын ишетеп, масса сәҗдә кылудан туктый.

Арадан берәү

Лә илаһи иллалаһ!
Ходай тәгалә безнең ялваруга колак салды!
Икенчесе
Күктән иңгән сәләхият!
Өченчесе
Көйләп әйтә безнең гамьне, безнең моңны...
Хәзрәт
Ийякә нәгъбеде вә ийякә нәстәгыйнь!
Җиһанда көйле китап язган иң гали зат бер генә —
Мөхәммәт Рәсүлулла! Аллаһе тәгалә хәзрәтләре рухына көйле китап язу — аңа гына фарыз!
Тукай тавышы
Ач пәрдәңне, йөзең күрсәт, ярдәмең берлән терелт!
Я, ходаем!
Халык төркеме
Ач пәрдәңне, йөзең күрсәт, ярдәмең берлән терелт!
Берәү
Мөхәммәт пәйгамберебез...
Ул үзе түгел микән?

Икенчесе
Я ходай, бу — гали инсан,
Беләдер күкләр серен.
Шәкертләр
Юл күрсәт безнең милләткә...
Син күрен безгә, күрен...
Зыялылар
Без сине күптән көтәбез.
Син күрен безгә, күрен!
Чалмалылар
Лә илаһи лә иллаллаһ,
Син күрен безгә, күрен!
Кадимчеләр
Милләткә хезмәт күрсәтсәң,
Күрерсең бәхет түрен.
Хөр фикерле яшьләр
Без сине күптән көтәбез,
Син күрен безгә, күрен!
Хатын-кызлар
Яклаучыбыз, саклаучыбыз,
Син күрен безгә, күрен!
Барысы бергә
Син күрен безгә, күрен!

Халыкнын сәләмә киенгән иң түбән катламнарыннан Тукай сүзләренә «Әллүки» җыры күтәрелә, ана хәзрәт төркеменнән башка бөтен халык кушыла. Җыр курай, кубыз, скрипка, кашыклардан оешкан музыкаль ансамбльгә кушылып җырлана.

Хор
«Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй,
Башка килә уйлар төрле-төрле,—
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.
Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән,
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызылып-сызылып чыга күңленнән...»

Халык алдына, җырны дәвам итеп, Тукай чыга. Барысы да, үзәк өзгеч бу моңны таң калып, сихерләнеп тыңлый.

Тукай
«Хәйран булып, җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын,
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.
Түзәлмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй»,
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, Әллүки!»..
Халык *(Алдында басып торган европача кыяфәтле интеллигент яшь егетне күреп)*.
— Гап-гади инсан!
— Тукай!
— Безнеңчә әйттерә бу!
— Афәрин, Тукай!
— Браво!
— Җәдит бу, җәмәгать!
— Мөәзин булып азан әйтсә бу!
— Хәзрәт, әйт сүзеңне!

Хэзрэт
Мэрхэбэ, шагыйрь, мэрхэбэ!
Каршылыйбыз алкышлап.
Данла гомереңне дингэ,
Халкыбызга багышлап.
Тукай
Сезнеңчэ яшэү — мескенлек
Бездэй горур егетлэргэ.
Һич уйламыйм халкымны мин
«Кол бул!» диеп үгетлэргэ.
Гасыр арты гасыр уза —
Артта да кол, алда да кол...
Кара халык — байларга кол,
Сэүдэгэрлэр — акчага кол,
Бай-түрэлэр — патшага кол,
Патша үзе — аллага кол...
Хэзрэт
Дөнья — читлек... Риза булып
Йөз ел тордык, мең ел тордык,
Хак тэгалэ язганынча
Яшэргэ дип карар кылдык.
Тукай
Яшэешне чорнап алган
Катып калган кара коллык!
Хэзрэт
Шашма, егет, тыпырчынма,
Шул читлектэ коллыкта син...
Кол Галинең, Курсавиның
Язмышларын онытма син.
Борынгы Болгар илендэ
Бик мэслихэт дип тапканнар.
Акылы белэн узынганнар
Башларын да югалтканнар...
Сэлэтең зур, үз артыңнан
Ияртерлек тавышың бар,
Читлектэ дэ рэхэт күреп
Яшэү өчен табышың бар.
Тукай
Юк, мин кабул итэ алмыйм!
Хэзрэт
Уйла, шагыйрь, башка юл юк.
Тукай
Үз юлымны белмим эле...
Э сезнең юл — рухи коллык!
Хэзрэт
Халык безнең арттан бара.
Шул хак юлдан һаман барыр!
Азынмасын өчен адэм,
Коръэн — зарур, иман — зарур.
Тукай
Бармы хэзер арагызда
Мэрҗанидэй саф мэрҗэннэр?!
Хөкем сөрэ үзе өчен
Калтырап торган түбэн җаннар.
Сезнең мэслэк — наданнарны
Читлэштерү хакыйкатьтэн.
Юк, сезнеңчэ яшэп булмый!

Яңа гасыр таңы аткан!
Ишетәсезме, милләт көткән
Өмет-хыял якынлаша,
Хөр күңелле яшьләребез
Гасыр ишекләрен ача!
Халык
Хәзрәт, әйт абруйлы сүзеңне!
Хәзрәт
Җәмәгателмөслимин! Аллаһе тәгалә рухында әйтелмәгән көйле сүзне шәригать фарыз түгел дип таба!
Халык
— Хәзрәт хак әйтә!
— Безнең хәсрәтне җырлый — юл бирик!
— Фәрештәләрне качырып бетерделәр, имансызлар!
— Бәхетсез дәрвишне тыңлап торасыз!
— Җырлаган кеше моңлы — бәхетсез була!
— Җырламыйча да, шөкер, яшәдек әле...
— Дөрес!
1-зыялы *(яңача киенгән)*.
Ашыкма, хәзрәт, хөкем чыгарырга!
2-зыялы
Бик кистереп әйтмә, хәзрәт,
Хөррият яклы булсаң...
Күктән бирелгән сәләт бу,
Сәләхиятле инсан.
Иттифакчы
«Алла» сүзе белән башлап
Китте ул җырның башын...
Күккә күтәрик без аны —
Милләтнең сандугачын!
Барысы бергә
Күккә күтәрик без аны —
Милләтнең сандугачын!
Шәкертләр *(Тукайны күтәреп алып)*.
Хөррият нәбаты бул!
Уралчылар *(шагыйрьне күтәреп)*.
Эшчеләр канаты бул!
Иттифакчылар
Милләтнең бәгыре бул,
Өмете, кадере бул!
Барысы бергә
Милләтнең бәгыре бул,
Өмете, кадере бул!
Кадимчеләр *(күтәреп алып)*.
Озын гомер теләп җырла
Патша хәзрәтләренә!
*(Дога укыйлар.)*
Зыялылар
Урының — түрдә булыр,
Дошманнар — гүрдә булыр!
Хәзрәт
Лә илаһи лә иллалаһ,
Мин котлап дога кылам!
Хатын-кызлар *(ерактан, көчсез аваз белән)*.
Онытма без-бәхетсезләр,
Хокуксызлар барлыгын.
Иттифакчылар

Милләткә син — әләм бул!
Шәкертләр
Тугрылыклы каләм бул!
Уралчылар
Көрәшкә чыккан халыктан
Киләчәккә сәлам бул!
Тукай *(шәкертләр арасында калып)*.
Ихлас рәхмәт сезгә, милләттәшләр,
Багладыгыз миңа зур өмет.
«Милләт, милләт!» дибез... Ул кайда?
Киләчәккә барыр юл кайда?
Кемнәр аны алга алып бара?
Ияртерлек көчләр, сез кемнәр?
Иттифакчы
Ул — без, иттифакчылар!
Ачык — кемнең кемлеге.
Халкыбызны бөек күтәрәчәк
Мөселманнар берлеге!
Тавышлар
Яшә мөселманнар берлеге!
Тавышлар
Яшә мөселманнар берлеге!
Иттифакчы
Ничә гасыр милләт сыкрый-елый,
Үзебезнең җирдә — Ватан юк,
Дөрес әйтә шагыйрь, берләшкән юк
«Безнең милләт!» диеп атарлык.
Һәммәбез бер, бай да, ярлы да юк...
Уралчылар
Ачык — кемнең кемлеге:
Байлар, ишаннар фиркасы —
«Мөселманнар берлеге».

Сәләмә киемнәрдән, чабаталы, чал чәчле теләнче керә, түгәрәк әйләнә йөри-йөри, ертык бүреген тотып, хәер сораша.

Теләнче
Мөһаҗир мин...
Ач-ялангач: юк кием...
Бирсәгезче бер тиен!
Иттифакчы
Һәммәбез дә кардәш, туганнар без,
Шул мөселман каны тамырда.
Берләш бар Рәсәйнең мөселманы
Бердәм милләт булып калырга!
Иттифакчылар
Бөек милләт булып калырга!
2-иттифакчы
Кыйблабыз — төрек солтаны!
Кадимчеләр
— Татар түгел — төрек без!
— Солтан телендә укыйбыз
Иң затлы тел күреп без!

Берничә малай «Тәрҗеман» чыкты! «Тәрҗеман» сатыла! дип, газета өләшеп йөриләр.

Тавышлар
— Төрек солтанына — шан-шәүкәт!
Хәзрәт

Төрек солтаны хәзрәтләренә кылган догамны
аллаһе тәгалә кабул итсен!
Думачы
Ах, шулаймы? Рәсәй тәртипләре
Ошамыймы сезгә?!
Әгәр мөселманнар хөррияте
Кирәк булса, болай итегез!
Рәхим итегез!
Китегез!
Пожальте! Уходите!
Думачылар
Пожальте! Уходите!
Иттифакчы
Китәрбез!
Вә милләтне азат итәрбез!
Кадимчеләр
Китәрбез!
Теләнче
Мөһаҗир мин...
Ач-ялангач: юк кием...
Бирсәгезче бер тиен!

Ярлы халык кызганып, байлар чирканып хәер бирәләр

Ерак микән туган җир?
Халык
Кайда булдың, ниләр күрдең, мөһаҗир?
Теләнче
«Переписта кафер диеп
Яздыралар» дигәнгә
Алданып без китеп бардык
«Изге» дигән җирләргә.
Ышанып мулла сүзенә,
Төректә булдык олтан,
Әйләнеп тә карамады
Безләргә «изге солтан».
Анда безне бәхетсезлек
Көтәр дип кем уйлаган,
Анда — ачлык, анда — золым,
Мондагыдан — мең яман!
Халык
Мондагыдан мең яман?
Булмас!
Теләнче
Туган җирнең ипекәен
Кулга тотып ант итәм!
Чит җирдә солтан булганчы,
Илдә олтан бул икән.
Хак икән!
Халык
Кайда башка илдәшләрең?
Теләнче
Кайсы — вафат, кайсы — эшсез, —
Йортсыз-илсез аптырап,
Көн-төн йөри бичаралар
Бер кабым икмәк сорап.
Халык
Һай, мескен, һай, мәхлүк,

Һай, бичара мөһаҗир!..
Теләнче
Алып кайттым сезләргә мин
Соң сүзен туганнарның.
«Туган җиргә башны куеп
Үлсәмче» дигән зарын.
Халык
Һай, мескен, һай, мәхлүк,
Һай, бичара мөһаҗир!..
Теләнче
Сезнең нурлы йөзегезне
Күрәселәр бар икән,
Туган җиргә башны куеп
Үләселәр бар икән... *(Хәлсезләнеп егыла).*
Халык
Һай, мескен, һай, мәхлүк,
Һай, бичара мөһаҗир.
Җирсез һәм үксез булсаң да,
Кадерле шул туган җир!

Яктыра.

Думачы
Рәхим итегез! Китегез!
Думачылар
Пожальте! Уходите!
Тукай *(теләнчене күтәреп торгыза, халык арасында йөри).*
«Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кысн:
Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.
Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре,
Камчылар — шул иске камчы, башкалык — тик фәсләре!
Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер,
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!
Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл,
Бәйләмеш бу җиргә безне тәңребез (гыйззе вә җәл).
Иң бөек максат безем: — хөр мәмләкәт, хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ!
Ап-ачык бу бер җавaптыр, сүздә түгел, басмада:
Если лучше вам,
Туда сами пожалте, господа!»
Китмибез! *(Соңгы сүзләр думачылар арасында, аларга күрсәтеп әйтелә.)*
Халык *(Тукай шигырь сөйләгәндә, аның кайбер юлларын хор белән кабатлый).*
— Китмибез!
— Китмибез!
Тукай үе
Башта мең уй... Халкыбызга
Кайсы юлдан китәргә?
Ирекле җир бармы? Безгә
Кайда бәхет көтәргә?
Бу җирдә ничек яшәрбез?
Кем дөрес юлга әйдәр?
Һәм дөньяның иң алдынгы
Көчләре белән бәйләр?
Зыялы
Афәрин, Тукай! Китмибез!

Милләткә без моннан файда көтмибез.
Бүгенге көн хөррият чорында
Булыйк без тәрәккыять юлында.
Моның өчен мәдрәсәне яңартыйк,
Мал-товарны татарча да,
Чит телдә дә аңлатыйк.
Көнчыгышта, Европада дан тотыйк!
Дөнья базарларында мәйдан тотыйк!
Безнең халык маһир моңа тумыштан,
Яшьләр, алга, калмыйк яңа тормыштан!
Уң булсын юл вә җиңел булсын аяк!
Фән вә саф коръән — алда булсын маяк!
Т а в ы ш л а р
— Даешь дөнья базарын!
— Бохара! Мәскәү! Иран!
— Милләтнең көче — байлыкта!
— Әдәбият уку, моңлану — ялкаулар, хыялыйлар шөгыле!
— Европача эшлеклелек!
— Поехали!

Европача киенгән сәүдәгәр яшьләр, приказчиклар, рус, төрек, гарәп, татар телләрендә һәркем үз товарын мактарга тотына.

— Кызыл мал!
— Тире! Чәй!
— Рәмиевләр алтыны!
— Гаспринский сабыны! Төймә!
— Акчурин продукциясе!
— Итек! Читек! Кәләпүш! Канәфер! Тарак!
«Бәянелхак!» «Тәрҗеман!» «Вакыт!» «Шура!»
С ә ү д ә г ә р *(такмак әйтә, приказчиклар аның тирәли әйләнеп бииләр).*
Мы казанский сын купца,
Сам имеем лавка,
Серный спичка без конца,
Всякий русский тряпка
На толчке сидим себе
Просто от безделья,
Духи, мыло продаем,
Женское рукоделье.
З ы я л ы
Яшьләр, алга, калмыйк яңа тормыштан!
Т у к а й *(зыялыга күрсәтеп).*
«Бер егет, шәмдәй, буен катырып йөри,
Алга дип, милләт, синеʼчакырып йөри,
Белмисең, милләт, синең хаккың өчен
Нинди җырлар ул егет шапырып йөри.
Ул, синеңчен, милләтем, атылып йөри,
Армый-талмый, көн вә төн ватылып йөри;
Җаны һәм вөҗданы шул юлда фида:
Кайда бай күрсә, шуңар сатылып йөри.»
Т а в ы ш л а р
— Сарык тиресе ябынган бүре!
Сатлык җан!
Т у к а й
«И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,
Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк,

Мәдәният мәйданында урын алыйк,
Егыла-тора алга таба атлыйк, имди!»
Т у к а й у е
Аралашу — табигый хәл,
Борыннан килгән йола,
Мессинага [1] бәла килгәч,
Бар татар дәррәү куба.
Данте, Байронлы, Бальзаклы,
Моцарт, Гётелы илләр,
Бәлки, кай юлдан китәргә
Безне дә өйрәтерләр?..

Чиркәү чаңы кагалар.

М и с с и о н е р
Ишетәсеңме, ишетәсеңме?
Т у к а й
Кемнәр, нигә чаң кага?
М и с с и о н е р
Кардәшләрең, туганнарын
Агыла чиркәүгә таба.

Керәшеннәрнең Инсуска гыйбадәт кылулары ишетелә.

Кыргыйлыктан ерак китми
Булса да җир, йорт, аты...
Юк һәм булмас вак халыкның
Теле, әдәбияты,
Иле, мәдәнияты...
Башта алар бирешмәде,
Айлар, еллар актылар,
Баш тарттылар, тарттылар да
Барыбер тәре тактылар.
Изге Инсус тәгълиматы
Җиңә диеп фараз ит...
Т у к а й
Муллалар — соры корт булса,
Поплар — шул ук паразит!
Бу хәлдә берни үзгәрмәс,
Калыр ошбу торышта,
Әллә ни ерак китәлмәс
Татары да, урыс та...
М и с с и о н е р
Ишетәсеңме, күрәсеңме,
Алда да күрәсең бар...
Инсуска гыйбадәт кылып
Кайталар керәшеннәр.
К е р ә ш е н н ә р *(җырлап чиркәүдән кайталар, алда — тәре таккан поп бара)*.
Иманыңнан язган диеп
Кем уйлый, кемнәр уйлый?
Бисмиллаһи рахман рахим...
*(Миссионерны күреп)*.
Господи, ты помилуй!

---

[1] Италиядәге Мессина шәһәре бәхетсезлеккә дучар булгач, татар халкы, итальяннарга ярдәм итү өчен, акча җыя.

Миссйонер

Прогресска ирешерләр
Христиан булып алар,
Әкеренләп җырларын да,
Телен дә оныталар...

Тукай

Ишетәсеңме, күрәсеңме?..
Алда да күрәсең бар.
Нинди җыр җырлап кайталар
Чиркәүдән керәшеннәр?

Керәшеннәр *(җырлап узалар)*.

«И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.
И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган иң элек кылган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам.»

2-з ы я л ы

Кая бара безнең милләт,
Кая таба юл ала?
Күз йомып карап торабыз!
Бетә милләт, югала...

3-з ы я л ы

Кире кайтыйк Чыңгыз ханлы,
Алтын чорлы Урдага!
Ал кулыңа үч кылычын,—
Яңгырасын кыр-дала!

Тукай

Бабаларым — болгар дигән халыктан,
Тамырлары—баһадирдан—Алыптан.
Болгар иле Кояш көткән Шәрыктан
Җиргә афәт — монгол явы калыккан.
Кем буйсынмый — кылыч белән чапканнар,
Буйсынганга — «татар» аты такканнар.
Яу алдыннан барган коллар-татарлар,
Кем җиңелгән — «татар» диеп атарлар.
Килгән Чыңгыз болгарларга яу булып,
Яткан Алып үтәлмәслек тау булып
Карап торган ике гаскәр алыстан:
Чыңгыз белән Алып батыр алышкан.
Алып кинәт гөрзи белән тондырган,
Чыңгыз ханның билен сугып сындырган.
Качкан Чыңгыз: сугышыр көч калмаган,
Унике ел аңга килә алмаган.
Килгән Батый, килгән янә Субудай,
Егылмыйлар гөрзи белән сугудан.
Шәфкатьсезлек, җәбер белән алышта
Инде каршы торалмаган Алып та.
Яна Сувар, яна Биләр, яналар...
Ага сулар, яна-яна агалар,
«Болгар» сүзен утка-суга салалар,
Ә Алыпка «татар» атын тагалар.
Тагалар, тик Алып һаман буйсынмый,
Зинданнарга, читлекләргә ул сыймый.

Русларга да шул ук бәла, шом килә:
Фаҗигале һәм газаплы чор килә.
Тарих безне суга атты — батмадык,
Утта яндык, әмма рухны сакладык.
Коллыкта калганда да гали булдык.
Хурлыкка калмадык: Колгали булдык.
Чоңгылларга кереп киттек, болгандык...
Әмма чыкмый җаныбыздан болгарлык.
Дөресен әйт, тарих, бер дә яшермә:
Татары да, болгары да нәселдә...
Сугышчанлык канын без ил куш када
Юнәлтербез илбасарга-дошманга.
Кимсендерми, хурландырмый татарлык:
Эшләр кылдык «татар» диеп атарлык.
Ул исемнең үзгәрттек тә асылын.
Дәвам иттек Алыпларның нәселен.
Кайтыйк Мөхәммәдъярыбызга,
Галидәй изгеләргә,
Кыйссаларга, саф вә раушан
Тутыкмас күзгеләргә.
Кайтыйк та без халкыбызның
Уй-хисен алып китик,
Яңартып көнелләребездә
Тагы да ары илтик!
Бар милләтләр тату яшәп,
Бергә аралашсыннар,
Үч кылычы белән түгел
Җыр белән аңлашсыннар!

**Дәртле, көчле тавыш белән җырлап, биеп, бәйрәм итүче гади халык — рус егетләре, кызлары керә. Авыл кешеләре — ир-егетләр аларны ачык йөз, самавыр белән каршылыйлар. Хатын-кызлар оялып, тарсынып, яулыкларын ачкалап-япкалап, шул ук вакытта якты чырай күрсәткәләп, бер кырыйда басып торалар.**

Т а в ы ш л а р
— Кунаклар килгән!
— Әссәламәгаләйкем, күршеләр!
— Чтепан, здарово?!
— Мухаметзян, как поживаешь?
— Әйдәгез, кунаклар, чәй эчәргә!
— Рәхмәт, знаком, в другой раз, у нас сегодня —
праздник! Бәйрәм!
— А ну-ка, ребята, нашу русскую!

**Ирләр, хатын-кызлар, кычкырып, сызгырып, башларын горур тотып, күккә чөеп, җир селкетеп бииләр. Татарлар, бераз гына оялып, тартынып, әмма хәйран калып карап торалар.**

Т у к а й т а в ы ш ы
«Рус белән тормыш кичердек сайрашып.
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.
Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып.
Без шаярыштык вакытлар алмашып.
Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.»

**Бу шигырь, җыр-бию кинәт туктап, бүленеп әйтелә. Руслар, җырлый-бии, саубуллашып, китеп баралар. Тып-тын, күңелсез, караңгы булып кала. Кояш байый. Мөәзиннең монотон тавыш белән ахшам намазына чакырып, азан әйтүе ишетелә. Халык кичке намазга агыла. Караңгыда — сәҗдәгә китеп, дога кылучы халык шәүләсе. Тукай үзенең ике дусты белән, бу манзарага карап, уйга калган.**

Тукай уе
Гасырларны эш атыдай
Камыт киеп тартабыз,
Тик шулай да күршеләрдән
Йөзәр елга артта без.
Авырлыктан иелгәннәр:
Башларыбыз — тар аңлы...
Ә бит руслар да бәхетсез —
Тормышлары караңгы.
Ил өчен корбан булганда
Без ирекле, хокуклы...
Ә тынычта халыкларның
Иреккә хакы юкмы?
Беренче дусты
Милләтебез тормыш кормыш...
Икенче дусты
Бәйрәмсез, ямьсез тормыш...
Тукай
Үз хәлеңне уйламыйча,
Бер җирдә гамьсез тормыш!
Беренче дусты
Нинди хәлдә безнең милләт,
Йоклаганмы, үлгәнме?
Икенче дусты
Әллә инде өметләрен
Тумас борын күмгәнме?
Тукай
Гасырлары үткән аның
Буйсынып, башын иеп,
Башларын түбән идергән
Мәңгелек мәшгулият.
Су кирәк — кое казыйбыз...
Руслар — машина белән,
Без казыйбыз шул ук җирне
Кулдагы инә белән...
Беренче дусты
Шундый хәлдә безнең милләт...
Тукай
Халык — зур ул, көчле ул:
Тынычта — ат, ә сугышта
Арысланнан көчле ул.
Үлмәгән ул, сыгылса да
Авыр тормыш йөгеннән...
Башкаларның хәлен күреп,
Һуштан язып егылган.
Икенче дусты
Дөньяда — зур үзгәрешләр...
Нигә ул артта тора?
Тукай
Караңгы көчләр басканга
Шундый халәттә тора.
Беренче дусты
Бармы җирдә дөрес маяк
Барырлык туры карап?
Тукай
Үземне дә шул сораулар
Борчый — табалмыйм җавап.

Тик шулай да ачык миңа...
Беренче дусты
Безгә нишләргә кирәк?
Тукай
Давыл булып ташланырга...
Кара көчләргә, димәк!
Икенче дусты
Ә һуштан язган халыкны
Ничек уяту кирәк?
Тукай
Хәсрәтләнү генә җитми,
Аны уйлату кирәк.
Карурманны яктыртучы
Кояш вә шәмнәр кирәк,
Тәрәккыйга сәбәп булган
Көйче, рәссамнар кирәк.
Үз сурәтләрен төшереп,
Күзләрен ачу кирәк.
Бохара козгыннарына
Нәфрәт һәм ачу кирәк!
Күңелләргә рух өрүче
Бәйрәм вә туйлар кирәк,
Үзебезгә Шекспирлар,
Пушкин, Толстойлар кирәк!
Каләпүшнең тарлыгыннан
Ычкынып уйлау кирәк,
«Башкалар ни эшли?» ди-ди,
Җиһанны буйлау кирәк.
Фәкыйрь, эшче халык өчен
Тырышкан ирләр кирәк,
Шәхси тормыштан баш тарткан
Әдип, шагыйрьләр кирәк.
Театрда, рәсемнәрдә
Тамаша кылу кирәк,
Үзенең хәлен күрсәтеп,
Яшь аша көлү кирәк.
Дус кем, дошман кем икәнне
Аңлата белү кирәк...
Беренче дусты
Ә шулай да аңламаса?
Тукай
Үтергеч көлү кирәк!
Җырларыбыз искелеккә
Әйтелсен ясин булып,
«Уклар» булып һөҗүм итсен
Һәм суксын «Яшен» булып!
«Әйдә халыкка хезмәткә! (*Дуслары кушыла*)
Бу юлда һәр төрле хурлыкка,
зурлыкларга түзмәккә!»

**Урамнан кызыл байрак күтәреп, бердәм сафта эшчеләр уза. Иң алда — уралчылар Тукай Уралчыны кул күтәреп сәламли, әмма аларга кушылмый, тирән уйда кала**

Уралчы җыры
Иң зур дошман — капиталны
Һичшиксез җиңеп була
Бар милләтнең эшчеләре
Бергә тупланып кына!

**У р а л ч ы л а р**
Изелүгә вә золымга
Кайчангача түзәрбез?!
Түзмәбез без, капиталның
Чылбырларын өзәрбез!
Тетрәсеннәр фабрикантлар
Без җырлап узган чакта.
Җир язмышы — безнең кулда.
Хакыйкать — безнең якта!

**Т у к а й у е**
Кыюлар, гадел сүзләләр...
Әмма милләт яклымы?
Гадиләр, горур, көчлеләр...
Әллә алар хаклымы?
Әмма бармы ул көчләрдә
Җанга якын гүзәллек?
Бармы олуг саф идеал
Гүзәллекне төзәрлек?..

## 2

Азан әйткән тавыш. Кичке намазга барышлый муллалар, ишаннар керә. Халык аларга бил бөгеп, олылап юл бирә. Балет: камчылы ишаннар биюе. Бию туктала. Озын буйлы юан пәһлеван Карахмәтнең килгәнен күреп, шашып кул чабарга, кычкырырга тотыналар.

**Х а л ы к**
— Карахмәткә юл бирегез!
— Мөселман батыры!
— Яшә, Карахмәт!
— Ура, Карахмәт!
— Билбанзай!
— Әйләндереп сал дөньяларын!

Карахмәт, халыкны сәламләп, кулын күтәрә.

— Әйдә, күрсәт әле көчеңне!
— Французча көрәш!
— Юк, мөселманча!

Карахмәт алдына берничә көрәшче чыга. Сәүдәгәрләр, Карахмәттән җиңелсен өчен, аларга акча, сәгать бирәләр. «Пәһлеван» берничә көрәшчене җиңә. Халык сызгыра, кычкыра, данлап кул чаба. Аны, кулларына күтәреп алып, түгәрәк буйлап йөртәләр. Кулларына «Яшен» журналы тоткан берничә малай, сатирик рәсемнәр күрсәтә-күрсәтә, биләр.

**Х а ж и** *(йөгереп керә)*.
Ямәгать! Каравыл!

**Х а л ы к**
— Ни булды, Хажи?
— Кем тия?

**Х а ж и**
Коточкыч хәл, ямәгать!

**Б е р ә ү**
Таладылармы әллә?

**Х а ж и**
Аннан да яман!

**И к е н ч е с е**
Эчең авыртамы әллә?

Ө ч е н ч е с е
Банкротлыкка чыктыңмы әллә?
Х а ж и
Аннан да яман!
Ямагать, мин сезгә әйтәм!
Безнең шәһәремездә
Гәзитчеләр заһир булды,
Нишләргә инде безгә?
Ул каферләр, зобаныйлар
Азган саен азалар,
Могътәбәр олы затларны
Мыскыл итеп язалар. *(Кулындагы журналны селкетеп)*.
Күрдегезме, укыдыгызмы?!
Х а л ы к
Нәрсәне?
Х а ж и
Менә моны! *(Журналны ачып күрсәтә.)*
Б е р с е
Кем бу? Нәрсә бу?
И к е н ч е с е
Дөя!
Х а ж и *(елый язып)*
Дөя түгел, мөфти бу!
Х а л ы к
— Мөфти?!
— Тач үзе!
— Ни язганнар, укы әле, хаҗи?
Х а ж и *(укый)*
Көн-төн бәлеш ашый-ашый,
Зур корсагын кашый-кашый,
Бөкересе килеп чыккан:
Халык каһәре суккан.
Охшамыйм дисәң дөягә,
Корсакка күп төямә!
Х а л ы к н ы ң б е р ө л е ш е
Ха-ха-ха!
Х а ж и
Нигә авыз ерасыз?
Бер-бер чара күрү кирәк,
Нәрсә карап торасыз?!
Аллаһ тәгалә хәзрәте
Кыек эшләрдән тыйган:
«Бер-берегездән көлмәгез!» дип,
Коръәнгә язып куйган!
Х а л ы к *(көлүдән туктый)*
— Кем язган? Кем?
— Кул куйганмы?
— Кая, монда бир әле! *(Журнал кулдан-кулга күчә)*
— Шүрәле!
— Шүрәле?!
Х а ж и
Болар һич тә оялмаслар.
Куймасаң әгәр тыеп...
Мине... мине төшерерләр
Маңгайга мөгез куеп!
Күренергә оят хәзер

Мөфтинең йөзенә дә....
Болай булгач җитешерләр
Алланың үзенә дә!
Халык
— Алла сакласын!
— Алла сакласын!
Хаҗи
Әле шул гына җитмәгән,—
Була, диләр, тыятыр!
Мулла
Олуг гөнаһны туктатыйк!
Хаҗи
Бар, син Карәхмәтне чакыр!
Син халыкны җыя тор!

Югалалар. Балет. Шүрәле маскасы кигән, уклар тоткан хөр фикерле яшьләр бию. Бию тукталгач, ике «Шүрәле» «Әдәбият ахшамы» дигән афиша күтәреп, башкалары сәхнә, пәрдә коралар. Пәрдә алдына Тукай чыга.

Тукай
«Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да,
Күкрәк биреп каршы торам, миңа миллəт
Хәзерге көн мылтык, ук атар булса да.
Унга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам,
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам.
Шикләнмибез дошманнарның көченнән без,
Бу көнге көн Гали, Рөстәмнәргә тиң без,
Шагыйрь гомре хәсрәт, кайгы күрсә, күрер, —
Дулкынланмый тормый ич соң өлкән диңгез.
Яхшылыкка эреп китәм — балавыз мин,
Мактап сөйлим изге эшне — бал авыз мин,
Бер яманлык күрсәм, сүгәм, мактый алмыйм!
Ул тугрыда бик явыз, ай-һай, явыз мин!»

Баш ия. Кул чабулар. Тукай югала. Сәхнәгә — шәкерт киемендә Миңлебай күтәрелә. Ул музыкаль ансамбльгә кушылып җырлый.

Миңлебай такмаклары
Шәкертләре туза икән, кулларында музыкан,
Шул музыкан уйнаганда, Ишми ничек түзә икән.
Җанкәй җанаш, пумала баш, чыкма урамга яланбаш,
Иөрмә, шәкерт, кәләпүшсез, урыс булдың, ярамас.
Безнең Казанның кызлары киенмәсә дә матур,
Татар башы чокыр-чакыр, себермәсән дә такыр.
Үсә, пешә, тәмле була алмагачның алмасы,
Сузсаң Мәскәүгә җитәрлек ишаннарның чалмасы.
Бер ишан хәзрәт симерттем күркә, тавык ашатып,
Сагынсам, корсагын карыйм, чүмәләгә охшатып.

Такмакның һәр куплетын кул чабулар, көлүләр белән уза. Куркып утыручы берничә тамашачы, эш зурга китәр дип, чыгып качалар. Алар артыннан тагын берничә кеше китә. Миңлебай соңгы куплетын җырлау алдыннан Хәзрәт, хаҗи-ишаннар, муллалар, куштаннар төркеме һәм Карәхмәт күренә.

Тавышлар
— Хәзрәт, әнә алар имансызлар!

— Ишеттеңме эно, ни дилэр...
— Денсезлэр!
— Туздырырга кирэк ояларын!
— Тэмам аздылар дэһрилэр, халыкны котырталар!

Тамашачылар азая. Артистлар, моңа игътибар итмэскэ тырышып, тамашаны дэвам итэлэр. Сэхнэдэ — Хажи киемендэге артист.

Артист
Хажи абзый, кылган гөнаһын санап,
Изге Мэккэгэ киткэн ди, кабат.
Сахрада ул менэ шундый эш күргэн,
Эш күрмэгэн, йоклап киткэч, төш күргэн.

Хажиның алдында Алла пэйда була.

Хажи
Йэ алла, син кем?
Алла
Ныклабрак кара, хажи, таныйсың!
Хажи
Мин сине белмим!
Алла
Белэсең.
Хажи
Күргэнем дэ юк!
Алла
Таны, хажи, таны!
Хажи
Җенме?
Алла
Юк.
Хажи
Шүрэлеме?
Алла
Юк. Ач күзеңне, хажи, йэ, кем мин?
Ярдэм сорап көн-төн, башың орып,
Ялварасың кемгэ?
Хажи
Аллага. Син — алла?
Йэ алла, бар икэн күрэселэр...
Син бит күктэ... анда торасың...
Алла
Ачуыма түзэлмичэ төштем
Синең янга.
Хажи
Алда торасың?
Йэ, алла, үзең сакла!
Гөнаһ, казалардан якла!
Синең фэкыйрь, мескен колың мин.
Алла
Фэкыйрь? Мескен? Кол?
Гөнаһлардан гел саклаган саен,
Керэ бардың гөнаһ юлына...
Үзең сэждэ кылган Аллаңны син
Әйлэндердең кемгэ?! Колыңа!

Хажи
Йә алла... Коръәнне үбеп ант итәм,
Валлаһи-билләһи, сиңа тел тидергән юк!
Алла
Коръәндә ни дип язылган?
Хажи
Ийякә нәгъбедә вә ийякә нәстәгыйнь...
Алла
Дөрес! Адәм — Алла колы!
Хажи
Мин дә шулай димен, иншалла!
Алла
Шулай булгач, нигә Алланы син
Кәкре хәрам юлда йөртәсең?
Ярдәмеңә мине чакырып алып,
Судьяларга акча төртәсең...
Булдымы шундый хәл?
Хажи
Булды, аллакаем, булды...
Алла
Рух башлары, изге җаннар булып
Күренәсез халык каршында,
Ә асылда... яман-бозыклыкның
Кыласыз сез үзегез барсын да!
Җирдә түгел, күктә торган затка —
Сез миңа да кара яктыгыз...
Саф булыгыз диеп, адәмнәрне
Чакырырга бармы хаккыгыз?!
Тагын...
Хажи
Җитте, башкаларын әйтмә дә...
Гөнаһлымын, кичер... шуның өчен
Кабат китеп барам Мәккәгә. *(Китәргә кузгала.)*
Алла
Тукта!
Хажи
Әй алла!
Алла
Гөнаһларың һич бетәрлек түгел
Мең вә миллион тапкыр юсаң да...
Синең кебекләргә — Мәккә ябык! —
Гыйбрәт булсын барлык инсанга!
Хажи *(Күккә карап.)*
Йә алла, үзең коткар!
Алла
Минем исемем белән күп азындың,
Юк, бу юлы җиңел котылма...
Шундый фәрман: ошбу бозык җанны
Яндырырга... тәнкыйть утында!
Хажи
Коткарыгыз! Каравыл!

Чыгып йөгерә. «Алла» югала. Берничә артист, көч-хәл белән күтәреп, Кисекбашны чыгаралар.

Беренче артист
Бер заманны бу баш муенда булган,

Җаваплылык бераз уенда булган.
Тора-бара җаваплылык югалган:
Гәүдә, кирәксез санап, башсыз калган.
Ә баш кайда? Һич тә өметен өзми,
Елый-елый, мескен, хуҗасын эзли.
Һичбернинди үзгәреш юк муенда,
Башны эзләү һич кенә юк уенда.
И к е н ч е   а р т и с т
Алда торган җаваплылыкны тоеп,
Әйдә, башны илтеп муенына куйыйк!

Кисекбашны күтәрергә маташалар, әмма куптара алмыйлар

Б е р е н ч е а р т и с т
«Тыңлагыз, бу тик Карәхмәтнең эше,
Инде ул, мәгълүмегез, көчле кеше.
И к е н ч е   а р т и с т
Миңлебай, бар, тиз, Карәхмәтне чакыр!
Б е р е н ч е   а р т и с т
Чапты-китте Миңлебай чатыр-чотыр.
И к е н ч е   а р т и с т
Үтмәгәндер күз ачып йомган заман,
Килде дә житте Карәхмәт — каһреман.»

Өченче артист — Карәхмәт керә. Кулмс көчәнсә дә, Кисекбашны күтәрә алмый.

К а р ә х м ә т
Булмый!.. *(Елап җибәрә.)*
Б е р е н ч е   а р т и с т
Бу башта — йөзләп коньякның пары бар,
Бу башта — йөзләп гариза зары бар.
«Хәл итәргә!» дигән имза — мең вагон,
«Отказ! Отказ!» дигән тамга мең тагын.
Тәнкыйть сөйми, бу баш банкет ярата,
Казна малын уңга-сулга тарата.
Яр буенда мунчасы һәм дачасы,
Үз малымы, бар да казна акчасы.
И к е н ч е   а р т и с т
Камчылы ишан килеп төчкергән, ди,
Камчысы белән моны өшкергән, ди.
Өшкергәнгә бер тиен алмаган, ди,
Чөнки алмаган әйберсе калмаган, ди.
Алтынга әйләнгән малларын
Сберкнижкәгә салмаган, ди.
Ә баш? Янә утыра, ди, муенда,
Акылга утыру юк, ди, уенда...

Ишан-хәзрәтләр, куштаннар төркеме хәрәкәткә килә

Х а җ и
Ямәгать! Ни карап торасыз?! Бөтен ямәгать алдында рисвай иттеләр бит!
Х ә з р ә т
Ахыр заман фетнәкәрләре! Аллаһе тәгаләнең үзеннән көләләр!

Ишан
Хаҗи абзый, ничек түзәсең мыскылга?
Хаҗи
Патшадан солдат сорыйк!
Хәзрәт
Губернаторга барыйк!
Ишан
Камчыларга кирәк бөтен халык алдында!
Куштаннар
— Дәһриләр!
— Йөзе каралар!
— Денсезләр!
Ишан
Әйдәгез, арт сабакларын укытыйк! Җимерик шайтан оясын!
Хаҗи
Карәхмәт, җаның бардыр ич, сине дә мыскылладылар?!
Карәхмәт
Сытам! Җимерәм! Изәм!
Хәзрәт
Миннән фатыйха: башлагыз, бисмилла рахман рахим...

Яшьләргә каршы китәләр. Алда — Карәхмәт

Карәхмәт
Кем яза боларны?! Башың ике булса — чык!
Хәзрәт
Кем — фетнә башлыгы?
Хаҗи
Кем булсын — Шүрәле!
Карәхмәт
Кем ул — Шүрәле?! Күрен куркак булмасаң!

Тукай һәм хөр фикерле яшьләр стена булып басалар. Алар арасыннан Тукай чыга.

Тукай
Мин — Шүрәле!

Тынлык

Хаҗи
Менә ул аллаһе тәгаләдән көлүче!
Ишан
Карәхмәт, дин юлында күп тырыштың, коткар милләтебезне афәттән!

Алдында Карәхмәт торган ярсулы төркем кечкенә буйлы Тукай өстенә килә.

Карәхмәт
Синмени әле ул Шүрәле?
Синең үзеңнән бит, егет,
Эчең тотып көләрлек!
Җыр белән җиңәм дисеңме?
Җүләрлек бу! Җүләрлек!
Кил әле, кил якынрак.

Йәле, жыр белән кизән...
Миллион жырыңны юк итәм!
Сытам! Бетерәм! Изәм!
Жыр һәм алтын... Жыр һәм байлык...
Тигез түгелдер һич тә...
Шартлатып типсәң — ачыла.—
Дөнья тоткасы — көчтә!
Сытам! Бетерәм! Изәм!

. . . . . . . . . . . . . .

Тукай уе
Йөрәк барсын да күтәрә...
Әмма күпмегә чыдар?
Бик тиз генә жинә алмас,
Бер заман өскә чыгар!
Күпме авыр көрәш алда,
Безнең хәл түзәрлекме?
Бармы бер зат куша торган
Көч белән гүзәллекне?..

3

**Тукай ялгызы. Таң сызыла. Ул уй-хисләрен кәгазьгә төшерә.**

Тукай
«Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата. *(Хыялында Кыз җырын ишетә).*
Кызлар җыры
Шул вакытта уйла, шагыйрь, килде илһам уйласаң.
Кыз җыры
Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак җәйге таң.
Кызлар җыры
Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң...»

**Тукайның хыялы:** шигырь, ария, хор, балет. Чәчәкле көянтәләр күтәргән кызлар биюе. Алар арасында иң сылуы Мәхәббәт — уртага чыга.

Кыз
«Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә.
Кызлар
Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә.
Кыз
Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене.
Кызлар
Күктә аккошлардай ак, күчмә болытлар төркеме».

БАЛЕТ

**Уртага, ыргылып, хөр фикерле яшьләр чыга.** Кызлар, куркышып, оялып, йөзләрен яшерәләр. **Тукай** хыялындагы Шагыйрь бию. Ул кызларны караңгылыктан яктыга **чыгара өнди.** Мәхәббәт янына бара. Мәхәббәт йөзен яртылаш **яулык белән яшергән.**

Тукай тавышы
«И матур! Иренмәче, еш-еш кына көзгегә бак!
Күр йөзеңне! Нинди нурлы, нинди алсу, нинди ак!
Ул күзең йолдызлыгын һәм ул кашың кыйгачлыгын,
Ул авызның никадәр үпсәң дә туймаслыгын.

Кызлар «әбәү!» дип куялар.

Ихтыярсыз күңлен уйлар, миннән артык юк, диеп,
Сизми калып, син суларсың, мин матурмын, уф диеп...»

Мәхәббәт йөзен тулысынча ача. Егетләр «уф» дип куялар. Мәхәббәт Шагыйрь белән биергә чыга. Шагыйрь дә, кыз да сихерле бер дөньяда яшиләр: алар бәхетле! Шул вакыт Ата белән Ана чыгып, Мәхәббәтне кире сөйриләр. Әмма Мәхәббәт алар белән китми. Ата-ана, рәнҗеп, кызларын каргый. Мәхәббәт уксеп елый. Кире китәргә уйлый, әмма Шагыйрьгә сөюе көчле булып, ул хөр фикерле яшьләр арасында кала. Шагыйрьгә гашыйк булган Мәхәббәт биюе.

Ул Шагыйрьне хөр фикерле яшьләрдән аерылырга, тыныч тормышта бергә яшәргә өнди. Уйга калган Шагыйрь биюе. Ул тирән икеләнү кичерә: үзенең шәхси бәхетенә — мәхәббәтенә омтыла. Хөр фикерле яшьләр биюе аның икеләнүен бүлә. Ул бик зур сагыш, авырлык кичереп, Мәхәббәт белән мәңгегә саубуллаша һәм хөр фикерле яшьләргә кушыла.

4

Т у к а й
Төн. Салкын. Өмет гомемнән
Киметеп яшәү утын
Май тама, санап, кыскарган
Гомернең һәр минутын.
Һәр адымда — йөрәгеннең
Мылтыклы аулаучысы,
Булсачы өзек бәгырьнең
Хәлләрен аңлаучысы...
Гомерем көзенең уңышын
Тараттым, җыялмадым,
Күмелә сүнгән йөрәккә
Өметем — хыялларым.
Картайдыммы? Бу нинди уй?
Инде җитәлмәм кебек...
Барган саен ераклаша
Хөррият дигән өмет. *(Каләмгә тотына)*
«Җырлыймын, ләкин җырымнан файда бармы
халкыма?» *(Каләмен куя)*.
Куптәнме мин, яшьни-яшьни,
Җырладым илһамланып...
Илһамым бу шәм шикелле
Беттеме әллә янып?.. *(Йөри.)*
Язмый каләм... йокламый тән... *(Кәгазьгә иелеп)*.
«Файда бармы халкыма?»
Т а р ы ш
Бар, Тукай!
Т у к а й
Куктән ингән нинди тавыш?
У р а л ч ы
Юк, куктән түгел, жирдән...
Т у к а й
Уралчы?
У р а л ч ы
Шагыйрь!
Т у к а й
Саумы — төннәр юлдашы? *(Кочаклашалар.)*
У р а л ч ы
Ишетәсем килә минем
Шагыйрь дусның үзеннән:

Ник жырында — төшенкелек,
Ник өметең өзелгән?

Тукай

Милләтебез киләчәген
Караңгылык каплаган,
Кузгалган дисәм, сабыйдай
Тик бер адым атлаган.
«Бер генә милли бәхетнең безгә көлгән вакты юк»...

Уралчы

Ышанам мин, шагыйрь дустым,
Без көткән ул чор туар.
«Хөррият безнеке!» дигән
Иң кодрәтле жыр туар.
Җырлаучылар арасында
Синдәй шагыйрьләр булыр,
Бар җиһанны таң калдырган
Талантлы ирләр булыр.
Балерина кызларыбыз...
Алкышлар күмәр юлны...
Яңгырар үз көйләребез
Бәхетле, дәртле, моңлы!..
Халкыбыз шат, горур булып
Ил биргән түргә узар,
Бар халыклар белән бергә
Биеккә, үргә узар!

Тукай

Әүлия син, пәйгамбәр син,
Хыялга бай Уралчы...
Мин дә шулай хыяллана
Идем, дускай, моңарчы...
Хыялга юллар ябылган...
Кулларда — сынды кылыч
Сүнде көрәш авазлары...
Каракош инде — тыныч...

Уралчы

Патшага һәм капиталга
Нәфрәтен тыя-тыя,
Тын күренгән эшче халкы
Көч-гайрәт, акыл җыя.
Сан сыйфатка әйләнер дә...
Мөмкин булмас туктату!
Юл бер генә: капиталга
һәм патшага туп ату!
Өметең халык җанында
Шытар һәм яфрак ярыр.
Иң соңгы изге көрәшкә
Синең дә җырың барыр.
Шундый чор килер Рәсәйгә —
Бар җиһан күреп торыр:
Золым, ачлык, ялангачлык,
Булмагандай онытылыр.
Җәмгыятьтә һәр шәхес — бай
Муллык — чикләрдән узар
Дөньяның бай хуҗалары
«Ярдәм ит» дип, кул сузар!

Т у к а й
Муллык... Байлык... Тормыш ничек
Хәл итәр бу сорауны?
Ачлыкны күтәргән халык
Үтәрме ул сынауны?
Билгеледер: безнең байлар
Туклар, рухи җансызлар,
Зыялы дин башлыклары
Үзләре имансызлар.

У р а л ч ы
Борчылуың урынлы да..
Тик, Тукай, синдәй затлар
Юклыкта да, туклыкта да —
Беркайчан сынатмаслар!

Т у к а й
Бармы бер көч идеалны,
Вөҗданны саклар терәк?
Халкыбызны иярterлек
Саф яңа иман кирәк!

У р а л ч ы
Саф иманмы? Ач җаннарда
Җыр булып тулып килә,
Эшчеләрдә... синдә, миндә
Ул иман туып килә.
Сан сыйфатка әйләнер дә
Мөмкин булмас туктату!
Юл бер генә: капиталга
Һәм патшага туп ату!

Т у к а й
Әлбәттә, синең әйткәннәр
Җырга — куәт, сүзгә — дәрт.
Хыялың минемчәрәк тә,
Тоткан юлың үзгәрәк.
Патша хәзрәтләре белән
Сөйләшеп карау кирәк...

У р а л ч ы
Файдасы юк һәм булмас та...
Т у к а й
Соң тапкыр... аяк терәп!
Вату-җимерү... туп ату...
Әллә нәрсәләр тагын...
Кемнәр төзәр син юраган
Хөррият патшалыгын?

У р а л ч ы
Эшчеләр төзәр... дөньяны
Һәм сәнгатьнең үзен дә.
Гете, Пушкин, Шекспирлар,
Тукайлар нигезендә.
Мәңге эзләгән бәхетнең
Ишеген халкым кагар,
Татар — бәхетен революцион
Көрәш юлында табар!
Сау бул, шагыйрь, кичектермәс
Изге эшләрем көтә,

Көрәшкә кылыч кайраучы
Төнге дусларым кетә!
Т у к а й
Сау бул, дускай, хәерле юл!

Уралчы китә. Тукай төнге тынлыкта башта әкрен генә, аннан көчәеп ишетелгән жырны тыңлап тора.

У р а л ч ы л а р  ж ы р ы
Изелүгә вә золымга
Кайчангача түзәрбез?!
Түзмәбез без, капиталның
Чылбырларын өзәрбез!

Жыр тына.

Т у к а й
Ул китте... Сүнгән шәмемә
Янә ут төртеп китте,
Фикеремне сафландырып
Һәм дә яктыртып китте.
Киңәйде гүя сулышым,
Терелде рухым-жаным,
Алларымда гәүдәләнә
Яшәеш идеалым. *(Кәгазьгә иелә)*.
«Өстә бу ямьсез болыт баштан китәр, яңгыр явар,
Жиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары.
Шаулап аккан су булыр тау башлары, тау аслары,
Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнжәре, алмазлары!»

Көрәшкә чакыру музыкасы. Шагыйрь хыялында Гүзәл кеше — Уралчы образы туа.

## БАЛЕТ

Хөр фикерле яшьләр биюе. Кулларда — хәнжәр. Иң алда — Гүзәл кеше. Ул — аларның юлбашчысы, каракошлар белән килешмәс көрәшкә чакыручы. Гүзәл кеше иптәшләрен биеккә, Азатлыкка, Матурлыкка өнди, үз артыннан ияртә. Бу музыкада:
«Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнжәре, алмазлары!» —
дигән мотив яңгырый. Матур киләчәк — хыял музыкасы туа. Хыялны шомлы, куркыныч музыка бүлә. Каршыга алмаз кылычлы «каракошлар» килә. Хәнжәрләр, алмазлар ялтырый. Тигезсез көрәштә Гүзәл кеше егыла. Иптәшләре аны күтәреп алалар.
Матәм маршы. Түгәрәкнең бер кырыенда — халык массасы иркта көрәшүче Кәрахмәт белән мәшгуль: «Афәрин! Милләтебез каһарманы яшәсен!» дигән тавышлар. Хөр фикерле яшьләр, эшчеләр Уралчыны соңгы юлга озаталар. Тукай ике арада уйланып тора.

Т у к а й  т а в ы ш ы
«Көч белән бергә гүзәллекне жыйган диңгез кеби,
Ул иде өстен вә кул житмәс кеше, йолдыз кеби.

Уралчылар соңгы юлын күтәреп алалар.

Т у к а й  т а в ы ш ы
Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мескен, үлеп аңлатмагач?!»

Уралчылар
Ул иде өстен вә кул җитмәс кеше, йолдыз кеби!

Тукай, әкрен генә атлап, матәм музыкасына ияреп чыгып китә.

5

Гласный
Җәмәгать!
Калабызның иң могтәбәр
Кешеләре җыелды.
Олуг патша хәзрәтенә
Багышлыйбыз җыенны.
Бөтен Рәсәй халыклары
Бәйрәм итәләр бүген
Бөек Романов нәсленә
Өч йөз ел тулу көнен!
Тавышлар
— Шанлы падишаһ хәзрәтләре яшәсен!
— Олуг патшага ходай озын гомерләр бирсен!
— Романовлар мәңге яшәсен!
Гласный
Олуг нәселнең исемен
Мәңгеләштерү өчен,
Кызганмас диеп уйлыймын
Халкыбыз хәлал көчен.
Тавышлар
— Дөрес!
— Күк капусы ачылды!
— Файдаланып калыйк!
— Милләтебез файдасына булсын!
— Депутация барсын!
Бераү
Патша хәзрәтенә барып
Хөрмәт белән баш орыйк,
Кызларга гимназия һәм
Ятимнәр йорты сорыйк!
Тавышлар
— Афәрин!
— Изге эш булыр бу!
— Алла бирсә, алырбыз!
— Фәрештәнең «Амин!» дигән чагына туры килсен!
— Гласныйлар эше бу! Зуррагын сорыйк!
Зыялы
Әллә кемнәр барсалар да,
Кайталмаслар эш кырып,
Олуг патша хәзрәтенең
Күңелен күрмичә торып...
Тавышлар
— Дөрес!
— Бүләккә акча җыйыйк!
— Һәйкәл салыйк!
— Нишләргә?
Зыялы
Ни булса да сораганчы,
Ходаем насыйп итсен...

Башта мәдхия язылсын
Һәм аңа барып житсен!
Т а в ы ш л а р
— Дөрес!
— Кем яза мәдхияне?
— Иманкол мулла язсын!
З ы я л ы
Мәжлестәшләр фикеремне
Аңлады бугай инде...
Патша белән сөйләшерлек
Кем булсын... Тукай инде...
Т а в ы ш л а р
— Хак әйттең!
— Тукай?! Белмим шул, ай-һай!..
— Иманкол мулла да язсын!
— Тукай да язсын!
— Ул патша телендә дә, халык телендә
дә сөйләшә белә!
З ы я л ы
Тукай мәдхия бастырса,
Бик тә килешер иде,
Аның сүзе пайтәхеткә
Барып ирешер иде.
Әмма... белмим... язалырмы...
Аны борчу ярармы?
Тукай авыру хәлендә...
Һәм... көннәре санаулы...
Т а в ы ш л а р
— Тукай биредә!
— Әнә бер читтә утыра!
— Алып килегез үзен!
— Сорыйк Тукайдан!

Тукай чыга. Еш-еш сулыш алуына, чак-чак басып торуына карaганда, ул, чыннан да, нык авыру хәлендә. Шуңа күрәдер, аңа Икенче дусты ияргән.

И к е н ч е  д у с
Тукай дустым, хәлең яман...
Китик, бераз хәл ал да...
Т у к а й
Күк капусы ачылган бит!
Мөмкинлек — безнең алда!
Тыңлыйм сезне, әфәнделәр...
Г л а с н ы й
Сездәй шагыйрьнең нәкъ бүген
Милләткә кирәге бар...
Тукай әфәнде, сезләргә
Халыкның теләге бар.
Т у к а й
Беләм, һәммәгезнең сүзен
Тыңлап, ишетеп тордым.
Язган кадәресен сезгә
Укып бирергә булдым...
И к е н ч е  д у с
Үзе язды! Кирәкми дә
Ялыну — үгетләрең...

Т у к а й
Патша хәзрәте тыңласын
Халыкның өмитләрен.
Т а в ы ш л а р
— Рәхмәт, Тукай!
— Әйт, әйдә!
Т у к а й
«Кардан ак, сөттән дә аграк, актан ак
Падишаһ ачты «мөнафис» һәм канат.
Җыела халкы шул канатның астына,
Тулды өч йөз ел Романов нәсленә.

Алкышлар, патшаны олылау авазлары.

Һәр күренгәндә шималдан ак болыт,
Без көтеп тордык өмитләр, шат булып,—
Дип аны ул падишаһ һәм тәхтедер,
Дип шушында без татарның бәхтедер,
Дип гарип башларга энҗүләр төшәр,
Мәңге михнәт, мәңге рәнҗүләр кичәр...»

Туктап кала. Хуплау, патшаны олылау тавышлары.

— Мәслихәт!
— Милләтебезне күтәрдең!
— Чын шагыйрьсең икән!
— Аллага шөкер, Тукай иманга килә...
Т у к а й
Мәдхия тәмам булмаган...
Тик үзем генә беләм...
Ялгызым бер сөйләшим мин
Патшаның үзе белән...
Т а в ы ш л а р
— Яз, Тукай!
— Сөйләш, Тукай!
— Милләтебезне сынатма!
— Язып бетергәч, безгә дәш!
— Алла куәт бирсен!

**Зур бәйрәмгә багышланган манифестация башлана. «Боже царя храни»ны тәкрарлап, патша портретын күтәреп, гавам уза. Алар артыннан, шул ук портретны күтәреп, «яшәсен»нәр кычкырып татар руханилары, зыялылары һ. б. килә. Тукайның шигъри хыялында Патша портреты җанлана.**

Т у к а й
«Падишаһ, бу көнге парлак бәйрәмең
Котлыйдыр йөзләрчә мильон адәмең.
Җыела халкың ак канатың астына,
Ихтирамән затыңа, зур нәслеңә!»
П а т ш а
Кем исеменнән котлыйсың син, кем үзең?
Т у к а й
Татар халкы намыннандыр һәр сүзем.
П а т ш а
Котлауларга рәхмәт. Тагын ни кирәк?
Т у к а й
Халкыбызда сезгә өмет вә теләк:

Һәрвакыт: «Юкмы мөнафис?» сүзләре,
Тилмерә эзләп җиңеллек күзләре.
Мин бүген алып килдем сезгә аның
Өч йөз ел җыелган моңын вә зарын.
Патша
Бәйрәм көнне нинди моң да нинди зар?
Тукай
Халкым минем бер бәйрәмгә интизар...
Җирсез ул, хокуксыз һәм дә Ватансыз,
Билгеле, адәм яши алмый ансыз.
Кайдадыр бәхет өмет итә-итә,
Бер сынык икмәк эзләп читкә китә.
Яшәү эзләп бар Рәсәйгә таралган,
Сизәм: алар күңелендә ни яралган,
Франциядә заводларда якташлар
Газап чигә, инде илгә кайтмаслар...
Патша
Татар анда француз белән бәйләнгән,
Миңа каршы бунтовщикка әйләнгән...
Тукай
Чит илдә дә хокукы юк, ил ерак...
Үз илендә француз хокуклырак,
Зарын сөйләп; күршеләргә керсәң дә, —
Рус кардәшләр үзләре дә шул хәлдә.
Аптыраган халкым минем юл юктан,
Кая барса, котылалмый коллыктан.
Әллә инде татар атлы халыкны
Олуг патша хзрәтләре онытты?
Патша
Онытырга торган халык улмы соң?
Борчыган ул һәр патшаның тормышын.
Алып торган бөтен дөньяның котын,
Кем онытсын Чыңгыз, Мамай токымын?!
Ике йөз ел Алтын Урда чорын да,
Онытмыйбыз Куликово кырын да!
Тукай
Болгар җанлы бабамнар бирешмичә,
Мәңгелек коллык белән килешмичә,
Руслар белән бергәләп киңәшкәннәр,
Ике йөз ел туктаусыз көрәшкәннәр.
Дан, мәрхәбә Куликово кырына,
Донской атлы русның чын батырына!
Илбасарлар вәхшилеген акламыйк
Һәм шулай ук узганга үч сакламыйк.
Илбасарны чын халыктан аера бел,
Үч-нәфрәт халыкларны аерадыр.
Чор бәласе, фаҗигасе — җаннарда —
Тик үч алу дәрте сүнсен каннарда!
«Татар килә!» дип сабыйны куркытмыйк,
«Татар барда хәтәр бар» дип өркетмик.
Белә тарих татар һәм рус туганның
Наполеонны Рус җиреннән куганын.
Ирек алган каланың һәм авылның
«Татар килә!» дип кочаклап алуын.
Патша
Карасак та тарих битен актарып,

Ышанырбыз: батыр, сугышчан халык!
Мәгърифәтле дигән гали аты бар...
Т у к а й
Шул халыкның хокукка бит хаккы бар!
«Рус җирендә без әсәрле, әзле без,
Тарихында бер дә тапсыз күзге без.
Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?
Халкыбыз уртак Ватанда шактый ук.»
П а т ш а
Хәзергә тулы ирекә хаккы юк!
Патшага тугърылыкта — анты юк!
Декабристка кем иш булган? Шул — татар!
Пугачевка кем кушылган? Шул — татар!
Оста алар афәткә һәм фетнәгә,
Ирек куйсаң — аннан шәфкать көтмә дә!
Иң дөрес юл — аны читлектә тоту,
Тончыктыру, куркыту, кысу, йоту!
Мәгърифәттән читләтү, аңсыз итү.
Хәмер белән агулап, җансыз итү.
Хәзерге көн булса да ул зур халык,
Тора-бара бетәр тәмам вакланып,
Телдән, диннән, иманнан гайре калып,
Яши алмый нәсел-нәсәпсез халык.
Т у к а й
Ваз кичмәс халкым нәсел-нәсәптән,
Ата-баба рухы — безне яшәткән!
П а т ш а
Ә рухлары калыр безнең җаннарда
Державин, Карамзин булып каннарда.
Мәңге шулай: көчле — җиңә көчсезне,
Алла үзе ятим иткән ич сезне.
Һич үзгәрмәс бу канунны шул килеш
Тану кирәк: һичшиксез шулай тиеш!
Т у к а й
«Тиеш түгел» дигән затлар күпләгән!
П а т ш а
Россиянең Дантеслары бетмәгән!
Т у к а й
Халкым күпме ким-хурлыкта интекте,
Аның рухы кабул итми читлекне.
Чит-ят күрә җаным мондый дөньяны,
Юк, танымыйм яшәү диеп мин аны!
Туган идем бәхет, шатлык чәчәргә,
Мәҗбүр булдым кайгы җырлап яшәргә.
Килми калмас, чынлык дигән чор туар,
Халык бәхете турында да җыр туар.
Бар милләтләр тигез булыр — мин беләм...
Әмма ачык белмим — нинди юл белән?..
П а т ш а
Хыялланма, җиргә төш тә... эзгә күч...
Байлык, шөһрәт булсын дисәң — безгә күч!
Шереметьев, Юсуповлар шикелле
Хезмәт итү — бәхет юлы бит инде!
Т у к а й
Бар янә хезмәт итү мөмкинлеге

Ямашев һәм Фәезханов шикелле!
Бар янә хезмәт итү мөмкинлеге
Толстойлар һәм Пушкиннар шикелле!
Килер, бәлки, бер көн: патша дуслашыр
Шагыйрь белән... башын иел очрашыр
Мин сөйләшәм хәзер бары хыялда...

П а т ш а
Мәңгелеккә тәхетемә уярга:
Хәтта патша хыялына — уена
Шагыйрьләргә керү катгый тыела!
Халкыңа әйт һәм үзең дә кал белеп:
Романовлар тәхете ул — мәңгелек!

Т у к а й
Шул халыкныңмы хокукка хакы юк?!

П а т ш а
Бүген — бәйрәм... Патшагызның вакыты юк!
*(Югала.)*

Т у к а й
Шул халыкныңмы хокукка хакы юк?!
Г л а с н ы й
Тукай әфәнде, ни белән
Сөендерәсең безне?
Бәхетле ит көнебезне,
Барлык милләтебезне!
Х а л ы к
— Тыңлыйбыз, Тукай!
— Укы, рәхим ит!

И к е н ч е д у с
Тукай — шагыйрь дә, дипломат та!
Т у к а й
Күк капусы ачылмастыр, көтмәгез,
Рәхим һәм шәфкать тә өмет итмәгез!
Халыкларга өмет баглап торырлык
Патша канаты астында урын юк!

Халык телсез кала.

Х ә з р ә т
Лә илаһи иллаллаһ... Үзең сакла!
И ш а н
Ишеттегезме? Ишеттегезме? Хи-хи-хи!..
Х а җ и
Әйттем мин сезгә, ямагать!
И к е н ч е д у с
Нишләвең бу, Тукай?!
Г л а с н ы й
Ягъни мәсәлән, Тукаев?..
Т у к а й
Ярлы халык кая барсын, ятимнәр йортынамы?
Халыкка Ирек булмагач, ул приют чортынамы?

Хәзрәт «лахәүлә»сен укый. Тынлык.

Х а ж и
Өтермәгә аны, өтермәгә!

Хәзрәт
Халыкка гыйбрәт булсын!
Ишан
Камчыларга андыйларны, камчыларга!
Зыялы
Онытма шуны, Тукаев, вострок [1] бар бит!
Тукай
Куркытмагыз вострок белән:
Болай да бит мин — анда...
Без һәммәбез тарлык дигән,
Коллык дигән зинданда!

Карагруһчылар, руханилар, тар милләтчеләр түгәрәге Тукайны **һаман кыса бара,** ерактан караганда бу түгәрәк зинданга охшап кала.

«Һава юктыр, алалмыйм рух сулыш та,
Кабахәт бөркү уң, сул, аста, өстә.
Читен хәл: гайрәтең җитсә — ерып чык,
Әгәр җитмәс исә — бет, шунда тончык!

Сулышы кысыла бара, йөткерә, Аңа Икенче дусты килеп ярдәм итә.

Юк, түбән калмас бу җан фитратта гали булган ул,
Кисмәк өстендә кара кош — иттифакый кунган ул!»
Хаҗи
Ни карыйсыз сез, ямәгать,
Әйтмәде ул ни генә...
Аяз көнңе яшен суксын! —
Патшага тел тидерә!
Зыялы
Бер аягы кабердә бит —
Тыңларга кеше таптык...
Тукай
Сезнең белән бер дөньяда
Торганчы, үлем — артык!
Хаҗи
Әйдә, ишан, вакыт җитте,
Колларыңа камчы ал...
Сук җанына, җанына сук:
Чәчрәсен ал тамчылар!
1-зыялы
Тукай шагыйрьме, түгелме?
Берәү
Шагыйрь! Ул — халык улы!..
2-зыялы
Нинди шигърият булсын, ди,
Бәрәңге, ыштыр җыры...
Хәзрәт
Син укысаң безгә — такмак,
Ә без сиңа — бәддога!..
Халык
Бәддога алган адәмне
Алла каһәре суга!
Хәзрәт *(бәддога укый, халыкның зур төркеме аңа кушыла)*

---

[1] Вострок — төрмә. Ред

Т у к а й
Дөнья зинданында кылган
Иң соңгы догам шушы:
Очсын дөнья читлегеннән
Тарсынып күңелем кошы...

Тагын да ныграк хәлсезләнә. Шул вакыт, алкышларга, дан-хөрмәткә күмелеп, халы арасына Иманкол мулла уза.

Х а л ы к
— Юл бирегез, мохтәрәм шагыйребез Иманкол мулл килә!
— Афәрин!
— Яшә, Иманкол шагыйрь!
— Милләтебезне күтәрдең!
— Олуг Романовлар нәселенә багышлап мәдхия язга Иманкол мулла патша хәзрәтләре тарафыннан көме медаль белән бүләкләнде!
— Урра!
— Бәддога алган адәмне
Алла каһәре суга!..

Ат тояклары, камчылар тавышы.

— Атлы казаклар!
— Камчылар, кылычлар белән!
И к е н ч е д у с
Бәддога, каргыш, камчылар...
Алла — казак гаскәре!
Күрмим: кайда халкыбызның
Хөр фикерле яшьләре?..
Мин калам, Тукай, рәнҗемә,
Гажизлектән, юл юкка...
Т у к а й
Кит... минем андый дустым юк...
Кал мәңгегә коллыкта!
Икенче дус югала.
Б е р е н ч е д у с
Күрәм, хәлең авырая.
Син миңа таян, дустым...
Т у к а й
Тирәннән бер аваз килә,
Ул аваз каян, дустым?
Б е р е н ч е д у с
Үзең язган җырларның ул
Иң ачы һәм татлысы...
Х а л ы к х о р ы *(тирәннән, астан ишетелә)*.
«И мокатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы...»

Ул тынуга, еракта көчәеп икенче бер җыр ишетелә.

У р а л ч ы л а р ж ы р ы
Изелүгә вә золымга
Кайчангача түзәрбез.
Түзмәбез без, капиталның
Чылбырларын өзәрбез!

Тетрәсеннәр фабрикантлар
Без жырлап узган чакта,
Жир язмышы — безнең кулда,
Хакыйкать — безнең якта!
Т у к а й
Бу нинди жыр? Көчле, дәртле...
Таныш та бик, ерак та...
Гүя күптән көтелгән жыр
Якынлаша йөрәккә...
Б е р е н ч е д у с
Бистәләрдән... эшчеләрнең
Кайнап торган ягыннан...
Т у к а й
Көч һәм гүзәллекне жыйган
Әүлияңне сагынам...
Халкым, әйтче, гомеремне
Акладыммы?
Х а л ы к х о р ы
Акладың...
Т у к а й
Халкым, әйтче, өметеңне
Акладыммы?
Б е р т ө р к е м
Аклый алмадың...
1-з ы я л ы
Бердәм милләтне таркатып,
Нишләттең, кая илттең?
2-з ы я л ы
Татарны бөтен дөньяга,
Көлеп, мәсхәрә иттең...
Б е р т ө р к е м
Аклый алмадың!
Т у к а й
«Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.
Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш,—
Керләнеп беттем үзем, дөньяны паклый алмадым.
*(Егыла.)*
Юк! *(Дусты ярдәме белән тора.)*
Мин сыялмыйм андый шартлар, фани дөнья вактына,
Башны бөксәм, зур жинаятьтер олуг жан хаккына.
Ашкынамын мин әбәт бетмәс урынга, мәңгегә
Мәңгелеккә — мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!
Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим,
Бу кояш сүнсен, жиренә мин Кояш булмак телим!..»

Кояшка таба китеп югала. Кинәт Кояш сүнә, караңгы булып кала.

Х а л ы к
— Акылдан язды!
— Ул шашты!
— Юк, ул күкләргә ашты!
Б е р е н ч е д у с
Рухы белән кол булмаган
Илаһи бер заттыр ул...
Очты дөнья читлегеннән...
Мәңгегә азаттыр ул!

Кинәт тагын да нурлырак булып Кояш кабына. Күктән ингән сыман, Тукайның тавышы ишетелә.

Тукай тавышы
«Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул,
Алга барганнарга тик табла табылса: алла ул!»

## ЭПИЛОГ

Матәм маршы

Беренче дус

Кемне югалттык без, кемне?..

Халыкның төрле катламнары уянып, хәрәкәткә килә. Арада чалмалылар да бар

Халык
Кемне югалттык без, кемне?
Беренче дус
Кемне югалттык без, кемне?
Иң нурлы кешебезне.
Халык күкрәгендә типкән
Иң моңлы күчебезне.
«Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби
Ул иде өстен вә кул житмәс кеше, йолдыз кеби.
Халык
Без аны кайдан белик, мескен, үлеп аңлатмагач.
Беренче дус
Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кеби вөждан белән,
Аз гына кер кунганын да кай жиреннән кем табар.
Халык
Без аны кайдан белик, мескен, үлеп аңлатмагач.
Беренче дус
Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү?!
Халык
Без аны кайдан белик, мескен, үлеп аңлатмагач...»

Халык ташкыны, кайбер төркемнәрдән башка, Тукай рәсемен күтәреп, Шагыйрь омтылган биеклеккә — Кояшка таба бара.

Халык хоры

Җырлы идек, син тагын да җырлырак иттең безне,
Моңлы идек, син тагын да моңлырак иттең безне.
Җанлы идек, син тагын да җанлырак иттең безне,
Аңлы идек, син тагын да аңлырак иттең безне.
Көчле идек, син тагын да көчлерәк иттең безне,
Хисле идек, син тагын да хислерәк иттең безне.
Күтәрелдең биеклеккә — халыкка борып йөзең,
Биеклектә, тугрылыкта — син хәзер үрнәк үзең.
Уртак Ватан тарихында эзле иттең син безне.
Мәңге-мәңге тап кунмаслык күзге иттең син безне.
Сәнгатебез күкләрендә — Кояшыбыз, Аебыз,
Бар жиһанга күренерлек кадерле Тукаебыз!

*1980—1981*

Әмирхан Еники


# СОҢГЫ КИТАП

## КАРГАЛЫ

### КЕЧКЕНӘ КЕРЕШ

*Язучыны аңлыйсың килсә, аның туып-үскән җиренә бар.*

*Гете.*



Гади генә әйтелгән бик дөрес фикер булса кирәк бу... Чынлап та, әдипне яки шагыйрьне туган-үскән җиреннән аерып аңлау мөмкинме?!. Юктыр, бармасаң да, бик яхшы белү кирәктер аны тудырган илне-җирне. Бу «өйрәнүчеләр» өчен бик әйбәт киңәш. Әмма язучы үзен-үзе дә аңларга тиеш түгелме икән? Һәрхәлдә, тырышып карарга: кайдан мин, кем мин?.. Менә ни өчен, бөек Гетеның югарыдагы сүзләрен очратканчыга кадәр үк инде, минем туган җиремә кайтасым килә иде. Күп дистә еллар аша кайтып, бала һәм үсмер чакларымны күрәсем килә иде. Ниһаять, мин бу озын сәфәргә тәвәккәлләп чыктым. Шактый ук соңга да калдым шикелле, ләкин өлгереп булыр дип ышанам.

Уналты яшемә чаклы мин туган-үскән җиремдә, атам-анам канаты астында яшәдем. Менә шушы чорым мине кызыксындыра һәм тарта. Бу минем гөнаһсыз саф чагым. Үзем турында да, мине чорнаган тормыш һәм кешеләр турында да мин курыкмыйча чын дөресен яза алам.

Уналты яшем тулгач, мин туган-үскән җирдән дә, ата-ана оясыннан да аерылдым. Читкә китеп, ялгыз, үз көнемне үзем күреп, яши башладым. Һәм, әйтергә кирәк, бу ялгыз яши башлау минем өчен көтелмәгән дәрәҗәдә катлаулы, авыр булып чыкты. Ләкин мин анысына хәзергә кагылмыйча торам, чөнки ул зур тәвәккәллек һәм күп вакыт таләп итәчәк. Башта сүз әнә шул бик кадерле, бик кыска, әмма нихикмәттер шактый озын булып тоелган балачак турында гына барачак. Шушы үзе дә бик озынга сузылган, әмма үтеп киткәне сизелми калган гомернең дәвамын аңларга да беркадәр ярдәм итәр дип ышанам. Шуңа күрә мин мөмкин кадәр чынлыкта булганын гына язарга тырышачакмын (билгеле, күбрәк хәтергә таянып). Миңа калса, һәрбер биографик язма үзенә күрә тарихи бер документ ул, ә документ, үзегез беләсез, һәртөрле бизәү-шомартулардан азат булырга тиеш.

Әйе, мин әле онытылып бетмәгән туган туфрагыма кайтып, бик еракта калган иртә яшьлегемне якадан бер күңелдән кичерергә һәм язарга булдым. Хәерле сәгатьтә! Тик менә сүзне нәрсәдән башларга?

Сүзне шулай да фамилиядән башлыйсым килә. (Бу уңай белән ерак тарихка да беркадәр күз салырга туры киләчәк.) Барлык рәсми документларда минем тулы фамилиям Еникеев дип языла. Тик язучы буларак кына мин аны безнең әдәбиятта күптән килгән гадәт буенча «Еники» дип кыскартып йөртәм. Хәзергә әле бу фамилияне йөрткән язучы бер мин генә.

Әмма Еникеев бик борынгыдан килгән һәм шактый күп таралган фамилия ул. Минем туган авылым Каргалының, мәсәлән, ярты халкы диярлек Еникеевлар иде. Гомумән, бу авылда һәркемнең фамилиясе ата-бабасыннан күчеп килгән фамилия — бездә үз атасының исемен фамилия итеп алу бөтенләй булмаган. (Һәрхәлдә элек булмаган, ләкин безнең дәвердә сирәк кенә ала башлаганнар.) Шуңа күрә Каргалыда фамилияләр күп түгел. Иң күбесе Еникеевлар, аннары Терегуловлар, аннары инде Янгуразовлар, Утяшевлар, Сундюковлар китә. Тагын Мамлеевлар, Дивеевлар, Килмамитовлар да бар.

Безнең авыл башкорт жиренә унсигезенче гасырның ахырларында гына Тамбов губернасыннан күчеп килеп утырган. «Каргалы» дигән исемне дә аңа шушы яңа жиргә килеп утыргач кына биргәннәр, югыйсә, тегендә, Тамбов жирендә чакта, авылның исеме «Иди» булган диләр. Димәк, безнең борынгы төп жирләр Россиянең үзәгендә, тагын да конкретлаштырып әйткәндә, Темников дигән шәһәр тирәсендә икән — без әнә шуннан чыккан халык. (Темников хәзер Мордва республикасына керә.)

Ул жирләрдә торып калган Еникеевлар хәзер дә булырга тиеш әле. Шулай ук Пенза, Саратов өлкәләрендә дә аларны бар диләр. Әмма Уфа белән Казанда яшәп торганнары барысы да диярлек Каргалыдан чыккан Еникеевлар. (Үзе булмаса, атасы яки бабасы шуннан.) Хәер, Каргалыдан таралган Еникеевларны ерак Себердә дә, Урта Азиядә да, Кавказда да, кыскасы, Советлар Союзының бик күп почмакларында очратырга була.

Кемнәр соң ул Еникеевлар? Нинди халык? Нинди тамырдан чыгып үрчегән һәм шул хәтле таралган алар? Бу сораулар мине һәрвакытта уйландыра иде. Ишетеп белүем буенча, аларның нәсел очы бик ерактан килә икән, ә башкорт жиренә күчкәндә инде алар шактый ишле бер нәсел булганнар. Бу нәселдән төрле заманда зур гына дәрәжәле кешеләр чыккан, мәсәлән, элек патша хезмәтендә алардан полковниклар, хәтта генераллар да булган диләр. Революциягә чаклы ук Еникеевлардан землемерлар, агрономнар, врачлар булуы да мәгълүм. Безнең әдәбиятта да алар күренеп киткәләр: 1902 елда Нигъмәтжан Еникеев дигән укытучы Гогольнең «Ревизор»ын татарчага тәрҗемә итеп бастыра. «Аң» журналында Сәетгәрәй Еникеевның, кызганычка каршы, бик иртә үлеп киткән өметле шагыйрьнең берничә шигыре басылып кала. 1905 елдан соң дәүләт думасына да Каргалы кешеләреннән берәү сайлана — бу Гайса морза Еникеев. (Минем атама якын кордаш тиешле кеше.) Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйк, Гайса морза үткән гасырның ахырларында Уфа—Оренбург җирләрендә йөреп, бик күп башкорт җырларын язып алган һәм 1931 елны, үләр алдыннан, шуларның барсын да үз кулы белән Башкортстан хөкүмәтенә тапшырган. Аның үзен дә яхшы җырчы булган диләр.

Революция вакыйгаларында һәм гражданнар сугышында актив катнашкан кешеләр дә бар. Шуларның берсе, мәсәлән, Нигъмәт Еникеев, Казандагы татар-башкорт хәрби мәктәбенең комиссары — аны хәтерләүчеләр хәзер дә бардыр әле. Ә менә Исхак Еникеев дигән

партия работнигы утызынчы елларның башында «Кызыл Татарстан» газетасының редакторы булып торды... Аннары Хисмәтулла Еникеев дигән Каргалы кешесенең 1912 елны Лена вакыйгаларына катнашуы билгеле: ул баш күтәргән эшчеләр тарафыннан прииска хуҗалары белән сөйләшүләр алып бару өчен сайланган булган һәм шул чакта кулга алынып, төрмәгә дә ябылган. (Бу турыда архив материалы бар.)

Билгеле инде, Каргалыдагы башка фамилияләрдән, әйтик, Терегуловлардан да чыккан укымышлы һәм исемле кешеләр бик күп, ләкин бу очракта мин үз фамилиям белән генә чикләнергә мәҗбүрмен, чөнки сүз дә бит хәзергә минеке турында гына бара.

Тик, кызганычка каршы, мин үз фамилиямнең кайчан, кайдан килеп чыгуын моңарчы ачык кына белми идем. Гомумән, Каргалы халкының үткәне белән танышлыгым бик чамалы, бик өстән генә иде. (Каргалыда тусам да, миңа бит анда үсәргә туры килмәде.) Мәсәлән, безнең халык үзләрен «түмәннәр» дип йөртәләр. Ни өчен түмән, ни өчен, әйтик, мишәр түгел? Мишәрләр иленнән килгән халык ич, телләре дә мишәрчә, алайса эш нәрсәдә?.. Дөрес, килеп чыгышлары белән алар татар-мишәрләр, моны берсе дә инкарь итми, ә шулай да үзләрен ни өчендер «түмән» дип атарга гадәтләнгәннәр. Хәтта «татар» сүзен беркадәр өнәп бетермәү дә сизелә — гүя ул аларга көчләп тагылган исем. Моның, билгеле, бик ерактан килгән ниндидер бер сәбәбе булырга тиеш.

Аннары Каргалының бер катлау кешеләрен «морзалар» дип атыйлар иде заманында. Еникеевлар, Терегуловлар, тагын берничә фамилия менә шул морзалардан санала иде. Бүтән фамилияләр, мәсәлән, Утяшевлар белән Янгуразовлар, морзаларга кермәгән. Шулай итеп, Каргалы халкы сословие ягыннан икегә бүленгән: күпмедер өлеше морзалар булса, калган өлеше гади халык булып саналган.

Хуш, ә безгә — Еникеевларга һәм Терегуловларга морзалык кайдан килгән соң? Һәм, гомумән, кем ул морза [1], нәрсәне аңлата? Әгәр ялгышмасам, морза ул аерым хокук һәм өстенлек белән файдаланучы бер кеше. Әйтик, русның дворяны кебек. Димәк, җыеп әйткәндә, морзалар алар гади халыктан өстен торган үзенә аерым бер сословие. Ерак заманнарда алар хаким сыйныф — дәүләт терәге булганнар.

Шулай итеп, без фәкыйрегез дә, чыгыш җәһәтеннән морза булабыз. Дворян, ак сөяк — чыдап кына тор! Әле хәзер дә кайбер өлкән абзыйлар миңа беркадәр көлеп тә, әзрәк кенә үстереп тә «Морзам!» дип дәшкәлиләр. Минем моңа үпкәм юк. Әйдә, шулай да булсын ди... Дворяннардан кемнәр генә чыкмаган, аңа китсә!

Тик шул кадәресе бар инде, безнең «морзалыкка» тагын бер сүз өстәгәннәр: чабаталы, ягъни чабаталы морза! Мәгънәсе ачык булса кирәк: морзасын — морза син, әмма аягыңда мужик чабатасы. Тагы да ачыклый төшкәндә, аны болай аңларга кирәктер инде: Әйе, «морза» дигән хәтәр исем бар-барын, әмма аның реаль нигезен тәшкил иткән байлык та (мәсәлән, җир-сулар биләү) һәм ниндидер зур өстенлек (привилегия) белән файдалану хокукы да юк, бирелмәгән. Юкка гына бит халык та Карагалы морзаларыннан көлеп:

Бәләбәйгә барганда итектән дә читектән,
Бәләбәйдән кайтканда чабатага интеккән,

— дип такмак чыгармагандыр. Бәләбәй безнең өяз шәһәре, Каргалы морзалары елына бер тапкыр шунда дворянский собраниегә бара торган булганнар.

Ләкин ничек кенә булмасын, дәрәҗәле исем сакланган, титул рә-

---

[1] Хәзер әдәбиятта күбрәк «мирза» дип язалар. Ләкин безнең Каргалыда «морза» диләр иде — мин дә шулай алам. Ә. Е.

вешендәрәк тагылып та йөргән, хәтта безнең авылны да тирә-якта «Морзалар Каргалысы» дип йөрткәннәр. Әмма минем үзем өчен бу «морзалык» дигән нәрсә элektән үк шактый караңгы, чуалчык бер мәсьәлә булып кала бирде. Әлбәттә, аның бик күптәннән килгән тарихы булырга тиеш, төрле чорларны, төрле хәлләрне дә кичергәндер ул (гел генә чабаталы да булып тормагандыр), ләкин махсус эзләнмәгәч, болар барысы да миңа җир астында күмелеп яткан борынгы әйберләр шикелле билгесез иде.

Инде шушы китапны язарга җыенгач, мин һич югы үз фамилиямнең тарихын белер өчен эзләнә, сораша башладым. Ахырда үткән җәй Уфадан кызыклы гына бер материал табып кайттым. «Яңа Каргалы авылына ике йөз ел» дип атала ул. Ягъни Яңа Каргалының тарихы, тормышы һәм көнкүреше турында язылган очерклардан гыйбарәт зур гына бер кульязма. Аны шушы авылдан чыккан югары белемле, өлкән яшьтәге бер төркем кешеләр — Әбүбәкер, Әхмәт, Гали, Гомәр һәм Кәлимулла Еникеевлар, Заһир Үтәшев, Гыйниятулла Терегуловлар язганнар. Кереш сүзләрендә алар бу хезмәтне бик озак эзләнүләр нәтиҗәсендә, тарихи документларга һәм елъязмаларга таянып язуларын әйтеп үтәләр. Кульязма Каргалы халкының башкорт җиренә күчеп килгәнчегә кадәр булган борынгы тарихын да шактый ук тулы яктырткан. Менә шушы борынгы тарихка караган беренче кисәген профессор Гыйниятулла абзый Терегулов миңа инде бирел тә җибәрде. Билгеле, бу басылып чыккан хезмәт түгел, кульязма гына, шулай да мин аны ышанычлы чыганак дип табам һәм аннардан файдалану бер дә язык булмас дип саныйм.

Хуш, ниләр таптым мин ул кульязмадан?

Актара-карый торгач, минем өчен менә нәрсәләр ачыкланды: безнең бабайларның башкорт җиренә күчкәнче яшәгән урыннары, чынлап та, шул Тамбов губернасындагы (хәзерге Мордва республикасындагы) Темников дигән өяздә булган икән. Темниковның борынгы исеме Сары-Кылыч булган, имеш. Кайчан салынуы ачык билгеле түгел, ләкин Алтын Урда заманында аның исемен руслар Темников дип үзгәрткәннәр, чөнки анда Урданың гаскәр башлыгы, икенче төрле әйткәндә «темниге» торган. Шунысы кызыклы, бу «темник» сүзе русның «темь», «тьма», ягъни бик күп дигән мәгънәне аңлатучы сүзеннән алынган имеш.

Кайбер тарихчыларның язуына караганда, татар-мишәрләр Темников тирәсенә монголлар явы вакытында килеп, утырып калганнар, янәсе. Ләкин кульязма авторлары бу версияне катгый рәвештә кире кагалар. Алар иске тарихчыларга һәм борынгы елъязмаларга таянып, мишәрләрнең X гасырда ук инде көньяктан, ниндидер дала халыкларының кысрыклавы аркасында, бу якларга күчеп килүләрен исбат итәләр. Килгәннәр, төпләнгәннәр һәм шунда утырып та калганнар. (Бер Темников тирәсендә генә түгел, ә «мещера җирләре» дип йөртелгән шактый зур территориядә). Башта алар Болгар дәүләтенә буйсынганнар, болгарларга ясак түләгәннәр, ләкин идарә итү эшләре үз кулларында булган.

1239 елны мишәрләр илен монголлар басып ала. Йөз елдан артык алар шулар кул астында яшәгәннәр, ясак түләгәннәр, әмма идарә итү эшләре һаман үзләрендә сакланган. Ягъни башка халыклардагы, мәсәлән, руслардагы шикелле үк, аларның үз бәкләре (князьләре) булган һәм шулар идарә дә иткәннәр.

14 нче гасырның икенче яртысында Алтын Урда таркала һәм дәүләт буларак әкренләп юкка чыга. Әмма татар дигән исем кала. Бу исем белән рус елъязмалары Алтын Урда эчендәге төрки халыкларны, шул җөмләдән болгарлар белән мишәрләрне дә атаганнар. (Дөресрәге,

монгол явы белән килгән ниндидер кабилә исемен тора-бара мондагы төрки халыкларга да күчергәннәр). Димәк, татар безгә читтән тагылган исем. (Ихтимал, безнең халыкның татар дигәнгә озак вакытлар күнегеп китә алмавы шуңардан килә дә торгандыр). Ләкин ничек кенә булмасын, шушы исем астында заманнар үтү белән зур һәм бөтен бер миллӛт хасил була (яки формалаша диик). Болгары да, мишәре дә шушы татар дигән бер милләткә керә.

Хәер, мин читкәрәк тайпылдым шикелле... Яңадан кулъязмага кайтыйк. Сүз моңарчы гомумән татар-мишәрләр турында барды. Ә менә минем үз нәселем, ягъни Еникеевлар каян чыккан, кемнән башланган?

Кайчандыр, ерак заманда Бихан исемле бер князь (бәк) яшәгән. Шушы Биханнан тора-бара Кугушев, Акчурин, Кутуев, Муратов фамилияләре үрчеп, тармакланып чыккан. Ә Кугушевлардан берсенең исеме Еникей булган икән, димәк, болай була: Бихан, берничә буын аша Кугуш, аңардан Еникей... Бу Еникейдән тагын биш ир бала туган: Алакай, Идей, Терегол, Усангали, Иртуган[1]. Башкортстанга күчеп килгән безнең бабайлар менә шул Идей белән Тереголның дәвамы икән. Фамилияләре исә Кугуш улы Еникейдән башланып китә. Шуннан соң инде ул үзгәрмичә буыннан-буынга күчеп килә. Тора-бара Еникеевлардан Терегулов фамилиясе аерылып чыга. (Югарыда Идей белән Тереголның бертуганнар икәнен күрдек). Каргалы халкының да иң зур күпчелеге Еникеевлар белән Терегуловлар, һәм алар, чынлап та, үзара туганлык җепләре белән бик нык чуалып, бәйләнеп беткәннәр. Күрәсең, бу ике фамилия бик борыннан килә, шуңа күрә аларның күп таралуы бер дә гаҗәп түгел.

Инде үзләрен «төмән» дип йөртүләренә килгәндә, моны, минемчә, ике төрле аңлатырга мөмкин. Беренчедән, элек гомер сөргән җирләренә бәйләп, ягъни алар Темниковтан чыккан халык — «төмәнлеләр». Икенчедән, аларның элек кем булуларына карап та; билгеле ки, алар борын-борыннан хәрби хезмәт кешеләре булганнар. Алтын Урда заманында мең башы, ун мең башы булып торганнар, ә татарлар гаскәр башында торучыны кайчандыр «төмән» дип атаганнар. Миңа калса, менә шушы икенчесе дөресрәк булырга тиеш, ягъни алар нәселләре белән хәрби халык, алар — төмәннәр! Болай диюләрендә аларның үзләрен башкалардан аерырга теләү дә һәм кем булулары белән горурлану да ачык сизелсә кирәк. Монда тагын шуны да өстисе килә: мин белгән, күргән «төмәннәр» барсы да диярлек озын буйлы, төз, таза кешеләр, йөзләре дә аларның озынча, ак чырайлы, борыннары бик туры... Кара-сары, табактай түгәрәк йөзле, кысык күзле кешене минем аларда очратканым юк. Кыскасы, «төмәннәрне» монголлар белән бәйләү һич мөмкин түгел. Димәк, алар башка токым, башка тамырдан яралган халык. (Тарихчылар аларны кыпчак белән бәйлиләр, кыпчактан чыккан диләр).

Миндәге кулъязмада морза сүзе Иранннан чыккан һәм төрки халыкларга монголлар аша кергән дип әйтелгән. Шулай да мин безнең нәсел монголларга чаклы ук инде ниндидер бер өстен таифә (каста) булгандыр дип уйлыйм. Алтын Урдага буйсынгач та аларның үз җирләренә үзләре хуҗа булып калулары, гаскәр башлыклары булып торулары һәм морза исеме белән йөрүләре шул иске дәрәҗә-өстенлекнең дәвамы булса кирәк. Югарыда исемнәре телгә алынган Бихан да, аның токымы Кугушевлар да Алтын Урда вакытында да, соңыннан рус дәүләте кулына күчкәч тә һаман морза һәм князь булып кала биргәннәр. Димәк, буыннан-буынга күчә торган нәрсә икән ул исем-дәрәҗә!

---

[1] Исемнәр барысы да русча язылган. Татарча әйтелеше ничек, «Идей»ме, «Идэй»ме — ачыклавы бик читен. Ә. Е.

Билгеле инде, исем сакланса да аның реаль эчтәлеге гасырлар дәвамында күп үзгәрешләр кичерә. Башкорт җирләренә күчкәндә безнең бабайлар, гомумән, морза булып саналмаган — Петр I вакытында аларның барысын да казна крестьяннарына әйләндергәннәр. Тарих моның сәбәпләрен яхшы белә, ә бер сүз белән генә әйткәндә, алар диннәрен алыштырырга теләмәгәннәр. Кыскасы, чукынудан баш тартканнар безнең бабайлар, һәм нәтиҗәдә барысын да югалтканнар. Дөрес, соңыннан, Екатерина II вакытында, кайбер фамилияләргә, шул җөмләдән Еникеевлар белән Терегуловларга да, морзалык яңадан кайтарыла, әмма элек биләгән җир-сулары кире үзләренә бирелми... Әлеге «чабаталы морза» дигән эпитет аларга шул чакта тагылган да булса кирәк... (Газиз Гобәйдуллинның «Татарларда сыйныфлар тарихы» дигән китабында морзаларның һәм «йомышлы татарларның» ничек бөлгенлеккә төшүләре ачык күрсәтелгән.)

Кыскасы, безнең бабайлар Темниковтан күчеп китәргә җыенган чакларында казна крестьяннары булып исәпләнәләр. Бу хәл аларның күченүләрен бик нык читенләштерә, чөнки патша хөкүмәте башкорт җирләрен читтән килгән һәм морза булмаган кешеләргә сатуны тыя. Шулай да алар тәвәккәлләп чарасына керешәләр. Башта ерак Темниковтан Уфа — Бәләбәй якларына йөргеннәр (ходоклар) килеп җир карыйлар, күпмедер карап йөргәннән соң, Каргалы дигән кечкенә елгачык буен сайлыйлар. (Башкортстан картасында күрсәтелгән Чәрмәсән елгасына килеп коя ул). Елгачыкның уң ягында тезелеп киткән таулар, сул ягында җәелеп яткан кара туфраклы тигез ялан — иншалла, бәрәкәтле җир булыр, диләр карап йөрүчеләр... Җир хуҗасы башкортлар белән сөйләшүләр башлана. Ләкин югарыда әйтелгән патша указы килешүгә нык комачаулык итә. Шулай да, өметсез шайтаң дигәндәй, юлы табыла. Ике кеше — Чәрмәсәндә тегермән тотучы Әпсәләм Киекбаев белән хәрби сотник Әмирхан Хәлилов бу эшне үз өсләренә алалар. Икесе дә электән килеп калган морзалар, җир сатып алырга хаклары бар, шуңа күрә башкортлар белән сөйләшүне дә алар алып баралар. (Исемлек башына да иң элек үзләрен язып куялар.) Бары шулар аркасында гына безнең бабайлар Каңны башкортларыннан 14500 дисәтинә җирне илле ел срок белән арендага алуга ирешәләр. Аренда договорын төзү үзе дә бик озакка сузыла — чын булса, сигез елга! Менә шуннан соң гына 1773 елны егерме хуҗалык (йорт) — 14-е Еникеевлар, 6 сы Терегуловлар — ничәмә гасыр гомер иткән җирләреннән кубып, хатыннары, бала-чагалары белән арбаларга төялеп, мал-туарларын куалап яңа җиргә — Каргалыкай буена күчеп киләләр. Алар артыннан башкалары да һәм башка фамилияләр дә күченә башлыйлар. Кыскасы, бу күченү дә бер ун елга сузыла. Ахырда кечкенә елгачык буйлап утырган Яңа Каргалы исемендәге «төмәннәр» авылы барлыкка килә. Һәм шушы авылда минем бабайларның яңа тормышлары, яңа тарихлары башлана.

Менә шул. Мин дә алдымда яткан кулъязманы ашыкмыйча гына карап чыгып, ябып куйдым. Монда язганнар барысы да шуннан чүпләп җыеп алынды. Билгеле, анда кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар күп иде, ләкин аларның барысын да хәзергә калдырып торырга туры килде. Миңа бит безнең фамилиянең кайдан килеп чыгуын гына беләргә кирәк иде, һәм шуның белән генә чикләндем дә мин... Әлбәттә, фамилия тарихы ул буыннар тарихы, әмма бик озын тарих. Шуңа күрә бик кысып-җыеп кына мин үзем турында болай дип әйтә алам: ерак гасырлар түреннән, гүя Азов диңгезе томаннары эченнән чыгып, Ука — Мокшы елгалары буена күченеп килгән, шунда төпләнеп күпмедер заманнар үзенә-үзе хуҗа булып яшәгән, соңыннан исә төрле тарихи һәм иҗтимагый сәбәпләр аркасында төп урыннарын ташлап, башкорт җирләренә күчеп утырырга мәҗбүр булган «төмәннәр»нең бер гаилә-

сендә 1909 елның иске стиль белән февраль аенда мин дөньяга килгәнмен. Мәрхүм атам мин туардан бер ел элек кенә сатып алган коръәннең ахыргы битенә түбәндәге сүзләрне язып куйган: «Бән морза Нигъмәтҗан Әхмәтҗан углы Еникеев алдым ышбу каләм шәрифне 1908 нче елда 28 гыйнварда Эткол ярминкәсендә. Бәһасе 65 тиен көмеш. Һәм ушандук каләми шәрифне 1909 нчы елда 16 нчы февральдә пәнҗешәмбе көн дөньяга килмеш углым Әмирханга һибә кылып бирдем. Алла тәгаләдән озын гомер, бәхет һәм тәүфыйк сорап ышбу әлмөсхәр шәрифне хәтем көтеп кылырга насыйп итсен иде. Амин».

## Ике бөртек

Минем туып-үскән җирем икәү — Каргалыда туганмын, Дәүләкәндә үскәнмен. Димәк, миңа аларның икесе турында да сөйләргә туры киләчәк. Дәүләкәнне мин Каргалыга караганда күп мәртәбә яхшырак беләм, әмма Каргалы ул минем туган туфрагым, бөтен нәсел-нәсәбем шунда яшәгән, барлык якын һәм ерак кардәш-ыруым да шунда яшиләр иде. Билгеле, сүз дә иң элек аның турында барырга тиеш.

Авылның тулы исеме — Яңа Каргалы, ләкин телдә Каргалы дип кенә йөртелә. Төрле якларда бу исемдә бүтән авыллар да, мәсәлән, Ырынбур Каргалысы, Чистай Каргалысы кебекләр — булганга күрәдер ахрысы, безнең авылны «Уфа Каргалысы», «Бәләбәй Каргалысы» янә тагын «Морзалар Каргалысы» дип тә йөрткәннәр. Кыскасы, тирәякта шактый мәшһүр авыл булган ул.

Инде Каргалының үзен, аның кешеләрен һәм атам-анамның анда яшәгән чакларын тасвир итәргә керешкәнче, башта ук бер нәрсәне әйтеп куясым килә: мин атам-анама һәм якын туганнарыма моңарчы ничек дәшеп өйрәнгән булсам, бары тик шул рәвешчә язачакмын да. Хәзерге укучыларга бу бәлки бик сәер дә тоелыр, ләкин сабый чактан ук әйтеп өйрәнгәнне картайгач кына үзгәртәсем килми минем... Атамны — атакай, анамны — инәй, бабамны — бабакай, әбиемне — әбыкай («к»ны йомшак итеп); абыйлар, апаларны — агакай, дәдәкай (атам-анамның бер туганнарын) һәм тутакай дип атаячакмын. Бу дәшү рәвешләре барысы да төмәнчә, тик «инәй» диюем генә башкортча, чөнки телем ачылган чакта без инде Каргалыда түгел, Дәүләкәндә, башкорт өендә торганбыз. (Дим буе башкортлары «әсәй» димиләр, «инәй» диләр.) Әгәр телем Каргалыда ачылса, мин «анакай» дип дәшергә өйрәнеп киткән булыр идем. Хәер, Каргалының үзендә дә «инәй» диючеләр бар, ләкин бу форма кайбер киленнәрнең Каргалыга чит авыллардан төшүләре белән бәйләнгән булса кирәк.

Хуш, инде төп максатка күчик. Менә минем кулда атакайның төзеп калдырган шәҗәрәсе саклана: башына «Еникеевлар нәселеннән хөрмәтле булган бабаларыбызның исемнәре һәм кайдан чыгышлары» дип язып куйган. Зур гына бөтен бер кәгазьгә иренмичә һәр буынның тармакланып дәвам итүен сызык һәм вак түгәрәкләр рәвешендә төшереп чыккан. Кагыйдә буларак, шәҗәрәдә ирләр тармагы гына күрсәтелгән, шулай да бер кешедән башланган бу тармаклар саны 47 гә җиткән. Иң баштагы дүрт кырлы беренче шәкел эченә «Хансуар бабай Еникеев» дип язып куелган. Бу Темников өязендә яшәп, шунда вафат булган бабабыз икән. Аның улы Бәшәр Еникеев Темниковтан башкорт җиренә беренче килеп утырган бабабыз була. (Шәҗәрәдәге урыны да Хансуар бабайдан соң икенче түгәрәк шәкел эчендә). Димәк, атакай төзегән бу шәҗәрә бикерактан башланмаган, асылда ул Каргалыга күчеп килгәч кенә дәвам иткән һәм үрчегән буыннарны күрсәтә. Әлеге 47 тармак та яңа җирдә Бәшәр карттан тарала. Менә шул тармакларның берсе миңа да килеп җитә. Башы һәм дәвамы болай: Бәшәр —

Хәсән — Әхтәм — Әхмәтжан — Нигъмәтжан — Әмирхан. Шулай итеп, мин яңа жирдә алтынчы буын икәнмен — бу 150 ел чамасы вакыт эчендә бер тармакның үрчүе... Калган тармакларга тукталып тормыйм, алар бик күп. Тик шунысы гажәп, минем атакай үзенең шәҗәрәсендә 47 түгәрәк ясап, шуларның һәркайсына Бәшәр карттан таралган кешеләрнең исемнәрен язып чыккан. Бернинди язма чыганакка таянмыйча бары хәтердән генә! Дөрес, алар барысы да бер токым, бер авылда яшәүчеләр, ләкин шуларның бөтенесен исемнәре белән белү өчен нинди хәтер кирәк булгандыр инде. Югыйсә бит хәзер дәү этисен онытучылар да аз түгел.

Минем инәйнең шәҗәрәсе юк, шул сәбәпле аның ерак бабаларын мин белмим. Фамилияләре — Янгуразов. Темников өязендә Янгураз авылы булган диләр, бәлки нәсел очы шуннан килә торгандыр. Ләкин Каргалыдагы Янгуразовлар турында миңа шунысы ачык мәгълүм: беренчедән, алар Еникеевлар кебек морзалар түгел, икенчедән, аларны «Мулла халкы» дип йөрттәләр иде. Чөнки муллалык итү аларда буыннан-буынга күчә килгән — Каргалының иң беренче мулласыннан башлап, мин белгән Гыйният муллага чаклы. Морзалар үзләре дингә ихлас тотсалар да, муллалык итәргә яратмаганнар — бу изге эшне бүтәннәргә тапшырганнар. (Күченгән чакта ук инде хәзрәтне дә арбага утыртып алып килгәннәр.)

Инәйнең дә бабасы Габдрахман хәзрәт урта мәхәлләнең имамы булган, ләкин атасы Хәбибрахман нишләптер ата-баба юлыннан китмәгән, иген игү, мал асрау, шуның өстенә сәүдә дә итүне артыграк күргән. Гомумән Янгуразовлар «мулла халкы» дип аталса да аларның бөтенесе диярлек гади крестьяннар иде. (Мулла булу һәркемгә дә эләкми, вакансиясе бик аз аның.) Инәй ягыннан кардәш тиешле мин белгән Янгуразовларның күбесе җир эшен яратып җигелеп эшләүче таза тормышлы агайлар иде.

Минем атам Нигъмәтжан Әхмәтжан улы 1874 елны дөньяга килгән. Анам Бибихәдичә Хәбибрахман кызы 1872 елны туган. Димәк, ул атакайдан ике яшькә олырак булган. Җитеп килгән кыз чагында, башта әнисе, аннары этисе, илле яшенә дә житмәс борын, үлеп киткән. Инәй һәм ике сеңелесе — Мәрьям белән Кәримә ятим калганнар. Аталары Хәбибрахман, әйткәнемчә, таза тормышлы кеше булган — эре нараттан кара-каршы салынган йортын мин дә хәтерлим әле — бабакайлар (Әхмәтжан карт) куршесендә генә иде... Әмма кызлар кулында гына калган йорт-җир күпме генә сакланып тора ала! Ахырда кардәш-ыру үзара киңәшләшәләр дә, хуҗалык таралмасын, кызлар да тәрәксез калмасын дип минем атакайны, егерме яше тулар-тулмас, инәйгә өйләндереп, Хәбибрахман бабай йортына кертәләр. Атакай үзе дә бу өйләнүдән бик канәгать булган икән, миндә сакланган язмаларында: «Хәләл зәүҗәмә кушылу белән бәхетем алга китте» дип язып калдырган. Һичшиксез, инәй аңа бик кулай килгән һәм яраткан да ул аны... Шул яшьтән бәйсезлеккә ирешү, үз башына дөнья көтү һәм хуҗалык итү ул заманда, әлбәттә, зур бәхеттән саналган булырга тиеш. Инәйне бик сабыр, акыллы хатын дип торганнар иде, ә атакайның инде бик дәртле, куәтле чагы — шулай булгач, аларның килешеп, яратышып тату гына «дөнья көтүләре» бер дә гажәп түгел. Әлеге яшьли генә калган ике балдызны да (Мәрьям белән Кәримәне) үстереп, бик матурлап кияүгә бирәләр. Атакай үзенең әлеге язмаларында, инәйгә өйләнеп утыз биш яшенә хәтле Каргалыда үткәргән гомерен иң бәхетле, иң хозур чагы итеп саный. Һәм мин моңа бик ышанам, чөнки атакай үлгән көненә кадәр шул Каргалысын, андагы тормышын, кардәшләрен, дус-ишләрен сагынып яшәде.

Атакайны егет чагында бик чибәр булган диләр. Хәер, мин белгәндә дә ул чибәр иде: урта буйлы, җыйнак гәүдәле, җинел сөякле; кечкенә

җирән сакал-мыеклы чиста ак йөз, бик килешле тулы гына иреннәр, бик туры борын һәм күксел-соры, зур гына күзләр — әнә шундый иде ул. Сиксәнгә житкәндә дә ул сыгылып төшмәде, бөкересен чыгарып йөрмәде.

Аннары табигате белән дә егет кеше булуын сөйлиләр. Җитез хәрәкәтле, ачык күңелле, җор сүзле, уен-көлке яратучан иде диләр. Ул матур гына җырлаган да, гармунда да уйнаган, оста гына биегән дә. Туйлардан һәм мәҗлесләрдән аны бер дә калдырмаганнар. Бизәгән мәҗлесләрне. Хәтта аның яшь чакларын белүчеләрдән шуны да ишеткәнем бар: туй кайткан чакта ул төпкә җигелгән атка, йөзе белән тарантаска карап, атлана икән дә кияү белән кәләшкә гармун уйнап бара икән. Бик ук ышанып та бетәсем килми моңа, әмма шулай да дәртлекыю егетләр туй вакытында ниләр генә эшләмәгәннәр!..

Мин белә башлаган чакларда атакай инде кырыктан узган кеше иде. Җигүле атка арты белән атланып баруларын күптән оныткандыр билгеле, ләкин барыбер җырлый да, уйный да, кәефе килгәндә биеп тә алгалый иде. Эчке мәҗлесләрендә генә түгел, өйдә ялгыз утырганда яки ишек алдында эшләп йөргән чагында да җырларга ярата иде. Тик ни хикмәттер, атакайның бу җыр-музыка сәләте миңа бер дә күчмәгән — мин җырлый да белмәдем, берәр уен коралында уйнарга да өйрәнә алмадым. (Хәлбуки мандолина белән скрипканы тотып караган чакларым булды, ләкин барыбер берни дә чыкмады.) Ә менә атакайның нечкәрәк тавыш белән сузып кына җырлаганын читтән генә тынымны да чыгармыйча бик әсәрләнеп тыңлый торган идем. Мин, күрәсең, инәй ягына охшаганмын — инәй ягыннан берәүнең дә җырлаганын белмим. Үзенең дә җырлаганын миңа бер вакытта да ишетергә туры килмәде. Хәер, ара-тирә өйдә ялгызы калып, тәрәзәдән тышка тик кенә карап торган чагында ул, әллә нидә бер, авыз эченнән генә мөнәҗәткә охшатыбрак нидер көйли иде, ләкин минем колак салганны сизсә, шунда ук туктый да торган иде.

Әйе, инәй төсе-бите һәм табигате белән дә бөтенләй башка иде. Кыз вакытында ул, әлбәттә, ямьсез булмагандыр. Чем кара озын чәч толымнарын мин дә әле хәтерлим. Ләкин мин белә башлаганда ул инде шактый йончыган һәм ямьсезләнгән хатын иде. Күзләре бозылган, кызарып тора, тешләре дә төшеп бетә язган, аркасы да бөкрәя төшкән иде. Яшерә алмыйм, башка малайларның әниләре чибәр, ә минеке ямьсез дип пошынган чакларым да булды — ләкин бу чын сәбәбен белмәүдән иде. Ә чын сәбәбе ... хәер, иртәрәк әле ул турыда...

Ә тормышлары бер дә начар булмаган. Иркен, мул яшәгәннәр. Атакай күбрәк кәсеп итеп йөргән. Бу эшкә ул яшьтән үк тартылган, чөнки бабасы Әхтәм карт та, атасы Әхмәтҗан да иген-игү, мал асрау өстенә алыш-биреш итү белән дә шөгыльләнгәннәр. Дөрес, Каргалы үзе сәүдә җире түгел, атнага бер була торган кечкенә базары да соң гына җыелып, иртә таралып та бетә иде. Өч мәчетле зур авылда Гали байның таш кибетеннән башка бүтән кибет тә юк иде шикелле — белмим, истә калмаган... Бөтен халкы аның җиргә бәйләнгән, җир белән яшәгән (һәм җир өчен дип килгәннәр дә), ләкин һәрбер зур авылдагы шикелле, монда да базардан-базарга йөреп, алыш-биреш итүчеләр дә аз булмаган. Билгеле, төрлесе-төрле дәрәҗәдә — Гали бай кебек чардаклы, яшел түбәле өй, тимер ишекле таш кибет салдырган бик эресе белән бер рәттән Кырлайчы Хәллә абзый кебек бөтен «товары» кечкенә сандыкка сыеп беткән җәяүле «сәүдәгәре» дә булган алар арасында. Гомумән, авыл кешесе тик ятарга яратмаган, хәрәкәттә бәрәкәт дип, буш вакытында һаман базар чапкан, анысын алган, монысын саткан — ничек тә акча табарга тырышкан. (Ә акчаны ул бик яраткан.) Мин моны НЭП вакытында үзем дә бик яхшы күреп калдым.

Менә минем атакай да, әйткәнемчә, малай чагында ук атасына ияреп, Дим буенда һәм Ачылы күл ягында Акчуриннар[1] өчен йон җыеп йөргән. (Башкортларга чәй-шикәр илткәннәр, йон-ябага төяп кайтканнар.) Атакай үзенең әлеге язмасында башкортлардан дусларыбыз күп иде дип яза. Мәсәлән, Казанголда — Җәгъфәр карт, Ябалаклыда — Курмый карт, Кыдрачта — Сәфәргали агай, Буранголда — Җомагол карт — болар барсы да бай башкортлар, бик күп елкы, сарык биләгәннәр... Каргалыдан Дим буена 40—45 чакрым, Ачылы күлгә 30—35 чакрым булыр, ул заманда бу җирләр күксел үлән дулкынланып яткан, төрән кермәгән тоташ кылганлы сәхрә булган да, шул сәхрәдә аратирә башкортларның ак тирмәләр корып утырган җәйләүләре дә көтүкөтү утлап йөргән маллары гына очраган. Менә атакайның бабасы Әхтәм карт та, ул үлгәч, атасы Әхмәтҗан карт та шул башкортларга барып, ак тирмәдә ит ашап, кымыз эчеп берәр атна кунак булып ятканнар. Ә кыш кергәч, башкортлар үзләре дөя җиккән тар чаналарга ит-май төяп, Бүздәк ярминкәсенә барышлый да, ярминкәдән кайтышлый да безнең бабакайларга кереп, кунак булып китә торган булганнар. Әнә шулай күңелле, кызыклы итеп яза атакай бу аралашу — йөрешүләрне... Бик күп еллар узгач та ул әллә кайчан үлгән башкорт дусларын «фәлән агаем да төгән җиңгәм» дип сагынып сөйли торган иде.

Инде өйләнгәч, атакай сәүдә эшенә җиң сызганып дигәндәй керешә. Үзеннән соң туган братлары да үсеп җитә, шуңа күрәдер ахрысы, ул авыр крестьян эшеннән әкренләп читләшә, китә. Кибет ачып сату итми, базар йөри, ярминкәләрне калдырмый, нәрсә алып нәрсә сатканын мин ачык кына белмим, ләкин зур байларга күбрәк тире җыйган булса кирәк. (Моны аңардан калган әллә кайчангы иске, озын-тар гына исәп-хисап кенәгәсенә карап әйтәм. Ул анда елкы, үгез, кәҗә тиреләрен күпмегә сатып алганын гел генә язып барган).

Әйтергә кирәк, атакай татарча бик әйбәт укый-яза белә иде. Вывескалар укырлык, адрес язарлык русчасы да бар иде. Татарча слубе дә әйбәт иде, соңгы гомерендә яшьлеген сагынып җырлар да, башыннан кичканнәрне шигырь итеп тә язды хәтта. Срур тутакайның әйтүенә караганда, ул берничә кыш Төпкиле мәдрәсәсендә ятып укыган булган. Күбрәк укыса, бәлки мулла, бәлки мөгаллим була алган булыр иде. (Хәер, мулла булмас иде, нәселдә юк нәрсә, ә мөгаллимнәр күп чыккан безнең халыктан).

Әмма ул сәүдә эшен яраткан.

Ни дәрәҗәдә оста сәүдәгәр булгандыр — бу кадәресе икенче мәсьәлә. Ул бит асылда хис кешесе иде, җыр яраткан, уен-көлке яраткан... һәм җан иясен дә бик ярата иде. Бер вакытта да аның кулы җан иясенә күтәрелмәде — атка да ул сөеп, сыйпап кына дәшә иде. Кирәк чагында, без тавыкны да күршеләрдән суйдыра идек...

Хәлбуки, чын сәүдәгәрнең табигате башкачарак — хиссезрәк, катырак булырга тиеш түгел микән?.. Әйтә алмыйм. Ләкин ничек кенә булмасын, минем атакай чынлап торып сәүдә эшенә керешер өчен 1910 елның көзендә, Каргалыдагы йорт-җирләрен калдырып, сәүдә үзәгенә әверелгән Дәүләкәнгә күчеп китә. Бу вакытта әле миң бишектәге сабый — бары яшь ярымлык кына... Бердәнбер, бүтән бала юк.

...Хәзер инде инәйнең кара шәлен ачарга да ярый торгандыр. Әйе, аны иртә бөккән, күзләрен бетергән рәхимсез сәбәп әнә шунда: тугыз бала табып, берсе-бер исән калмаган. Сабыйлар туып, күпмедер үскәч, нәкъ сөендерер һәм сөйдерер чакларында гына үләләр дә киталәр икән. Кайсы кызамыктан, кайсы чәчәктән, ләкин күбесе эч авыруыннан. Билгеле инде, ул заманда йогышлы авырулардан балалар күп кырыл-

---

[1] Сембер губернасындагы сукно фабрикаларының хуҗалары. Ә. Е.

ган. Ләкин бит һәммәсе дә түгел, берсе китсә, берсе калган. Ә минә инәйнең берсе дә калмаган — нигә, ни өчен аның башына гына мондый фаҗига?! Ис-акыл җитми бу хәлгә! Югыйсә, әйтүләренә караганда, һәркайсы туган чакта туптай таза да булган имеш. Инәй үзе дә аратирә генә: «Мәрьямем бик матур булмакчы иде» яки «Тимербулатым бик тере — кулдан очарга гына тора иде» дип сөйләнеп куйгалый иде. Әмма ни үкенеч, тотып кала алмаганнар шул, тугыз бала очканнар да киткәннәр...

Мине иң гаҗәпләндергәне — ул чактагы кешеләрнең наданлыгы һәм көчсезлеге. Каргалы бит инде зур авыл, укыган кешеләре дә аз түгел, ә менә белеп-аңлап ярдәмгә килүче дә, һич югы дөрес киңәш бирүче дә булмаган. Бер фельдшер кисәге булган шикелле, ләкин ул да корчаңгы атларны гына дәвалый белгән. Кыскасы, медицина юк, хәтта морзаларга да!

Хәзер сорашканда, Срур тутакай (атакайның бертуган сеңелесе) миңа әйтә: җиңгәчәйнең сөте юк иде, баласын гел кулдан ашата иде, эч авыруын йоктыру күбрәк шуңардан иде ди. Бәлки дөрестер дә, тик минем бу хакта элек берәүдән дә ишеткәнем булмады. Инәй үзе хәсрәтен бер дә сөйләми иде, хәсрәте аның эчендә яшерен иде, һәм якыннан белгән кешеләр дә: «Хәдичәттәй бит ул ифрат та сабыр!» дип әйтә торганнар иде. Әйе, ана кешегә сабыр итүдән башка ни кала?!

...Шуннан соң менә мин унынчы бала! Мине корбаннар чалып, нәзерләр әйтеп, алладан сорап алганнар. Мин һичшиксез яшәргә тиеш булганмын. Атакайның Дәүләкәнгә күчүе беркадәр шул теләк белән дә булмадымы микән? — чөнки балалары тормаган иске урынны ташлап китүне үзләренчә хәерлегә юраулары бик мөмкин. Яңа урында бит яңа өметләр дә туа...

...Ике елдан соң, унберенче бала булып, Ильдархан исемле энем дөньяга килә. Тагын бер малай! Бичара инәй өчен нинди зур бәхет дисәм, бу ничектер бер генә яклы булыр кебек. Юк, бәхет дигән нәрсә алай саф килеш кенә очрамый ул тормышта.

Бөтен кардәш-ыру, якын туганнар безне «ике бөртек» дип йөрткәннәр. Ике бөртек!.. Әсләрендә кан калтырап саклыйсы, үстерәсе бар әле аларны.

## Төп нигез

Дәүләкәндәге тормышыбызны язганчыга кадәр туган авылым турында күргән-белгәннәремне сөйләп бетерәсем килә. Күңелемдә шулай саклана — башта Каргалы, аннары инде Дәүләкән.

Каргалыда 150 елдан артыграк яшәп килгән нигезебез бар — бу минем бабакай Әхмәтҗан карт йорты. Менә шушы нигезгә атакай белән инәй еш кына кунакка кайта торган булганнар. (Дәүләкән-Каргалы арасы ерак түгел, 40 чакрым чамасы гына). Инәй итәгендә энем белән мин дә, билгеле, кайтканбыз. Безне, ике бөртекне, тарантастан ук күтәреп алганнар, сөйгәннәр, кадерләгәннәр, әмма ләкин без аларны әле хәтердә сакларлык яшьтә булмаганбыз. Мин үзем, мәсәлән, бабакайлар йортын, андагы кайбер күренешләрне өзек-өзек итеп кенә 4—5 яшемнән хәтерли башладым шикелле, ә тулырак, ачыграк һәм күбрәк тә итеп күрә, хәтерли башлавым 7—8 яшемә туры килә торгандыр. Һәм болары да бабакайлар ихатасыннан әллә ни ерак китмиләр.

Бабакайларның ихатасы (ишегалды) бик зур иде, иркен иде, күп җире бәбкә үләне белән түшәлгән иде. Тик кое тирәсе, абзарлар алды гына мал таптаудан үләнсез такыр иде. Урам буйлап яңа койма сузылган, өч капка баганасы басып тора, ләкин капка үзе ни өчендер юк... Әллә такталары, әллә куллары җитмәгән, хода белсен!

Менә шул капкасыз баганалар арасыннан килеп кергәч, аз гына эчтәрәк, сул кулда бабакайларның алты почмаклы, калай белән япкан өйләре тора. Уң якта зур гына ак келәт, шул ук рәттә, ишек алдының түренә табарак янә берме-икеме келәт, чилник (лапас), тагын ниндидер каралтылар, ә иң түрдә инде терлек абзарлары. Алар барысы да салам түбәле, тик келәтләрнең кыегына буй-буй киртәләр дә салынган.

Сул яклап исә, «капкадан» шактый эчтә, таза бүрәнәләрдән салынган, ләкин инде җиргә чүгә башлаган янә бер иске генә өй бар. Аш ызбасы дип йөртәләр иде аны, миче бик зур иде, кочак-кочак салам кертеп ягалар иде. Шул гөрләп янган утта Мәдинә җиңгәчәй зур чуен тутырып бәрәңге (төмәнчә — бульба) пешерә иде. Терлекләр өчен булса кирәк, ләкин кайчагында безгә дә салып бирә иде. Без, җыен ыбыр-чыбыр бала-чага түгәрәкләнеп утырып, агач табактагы кайнар бәрәңгене үзебез азаплана-азаплана әрчеп, эре тозга тидереп, кара арыш ипие белән бик тәмләп ашый идек. Аннары бу өйгә кышның салкын көннәрендә туган бозауларны һәм бәрәннәрне ябып тоталар иде. Минем бәрәннәргә исем китә — алар өч-дүрт көннән инде өйне бетереп чаба башлыйлар, зурая төшкәч, мич башына хәтле сикереп меңәләр. Ә бозауларны озак тотмыйлар, бераз аякландгач та икенче бер җылы урынга күчерәләр... Соңыннан «аш ызбасы» юкка чыкты — кайчан, ни өчен сүткәннәрдер, белмәдем. Беренче герман сугышы вакытында утынга түгел микән?!

Истә калганы тагын аш өеннән арырак кара мунча. Кергәч тә уң якта учак, учак өстенә чуер таш өелгән, шуңа терәлеп үк торган тәбәнәк ләүкә, ә каршыда кечкенә чалыш тәрәзә. Морҗа-мазар юк, якканда төтен чыксын өчен ишеген ачып куялар, шуңа күрә мунчаның бөтен эче корым сылагандай кап-кара. Ләкин ни хикмәттер бу кара корым кием-салымны буямый иде.

Бик кечкенә чагымда бабакай белән әбыкайнең мине шул мунчага алып керүләрен аз гына хәтерлим. Зур, түгәрәк тазга утыртып юындырдылар, аннары бастырып комганнан җылы су белән коендырдылар. Ләүкәгә яткызып, чабып та караганнар. Ләкин монысын мин бер дә яратмаганмын имеш — разбой сала башлаганмын.

Ә менә 12—13 яшьләремдә булган бер «вакыйганы», һич тә онытасым юк. Кышкы салкын көн иде. Абзаннан килгән кодача (җиңгәчәйнең сеңелесе) белән без икәү утын ташып, кара мунчаны ягып җибәрдек. Башта эче төтен күзләребезне кисте, тамак төпләренә утырды, бераздан учак ялкынланып янарга тотынгач төтен кимеде, чыгып та бетте диярлек. Без мунчаның ишеген дә ябып куйдык. Кызу гына чытырдап янган утка карап янәшә утырабыз, нәрсә сөйләшкәнебезне белмим, тик шул чакта мин, ничектер тилереп китеп, калын гына киенгән кодачаны кочаклап үбәргә тырышып карадым. Хәтта битенең кай җирендәдер авызымны тидереп тә алдым. Кодача әлләни ачуланмады да, бары: «Куй, маташма!» дип кулымны гына алып ташлады. Ул инде буй җиткән таза кыз иде, бәреп очырса да хәленнән килерлек иде. Ләкин очырмады — күрәсең, балага санады.

Кара мунчага бәйле «истәлекләр» шуның белән тәмам. Янә бабакайларның бөтен ишегалдына ямь биреп торган, урта бер җирдәрәк сиртмәле кое да бар иде. Чатлы баганага тимер кендек белән утыртылган озын сиртмәнең җирдәге калынрак башына зур гына бүкән тагылган, ә югарыдагы нечкә очына таза бау, бауга шомарып беткән колга, колгага кара чиләк беркетелгән. Кое янында калын бүрәнәне чокып эшләгән су тулы озын улак тора, көтүдән кайткан сыерлар, сарыклар иң элек шунда йөгерешеп баралар. Кем дә булса кара чи-

ләкне коега су алырга төшергәндә сиртмәнең калын башындагы әлеге бүкәнгә атланып, һавага күтәреләсе килә иде.

Коеның бурасы тәбәнәк иде, шуңадыр ахры, безнең ише вак балачаганы ул тирәгә җибәрмиләр — кое үзенә тарта дип куркыталар иде. Чынлап та, барып, коеның тирән караңгы төбенә иелебрәк карап торсаң, ничектер баш әйләнеп киткәндәй була иде. Әгәр шуннан тартып та алса? — юк, белеп куганнар безне куркыныч-серле кое янынннан!

Иң аргта читәннән үргән, салам япкан терлек абзарлары иде, ләкин мин аларны яхшы белмим, чөнки бердән, бәләкәй чагым, икенчедән, абзарлар җәй көне гел буш тора диярлек. Кояш баер алдыннан гына сыер-сарыклар көтүдән, атлар эштән кайтып керәләр. Ә мине сыер сөзмәсен, ат типмәсен дип һаман саклыйлар иде.

...Абзарлар артыннан ук бәрәңге бакчасы башлана. Монысын яхшы хәтерлим, чөнки ызаны буйлап, җылы йомшак туфракка ялан тәпи бата-бата күп чаптым. Бакча бик озын, түбән таба сөзәкләнеп инеш ярына чаклы төшә. Яр астында инеш — Каргалы инеше (русча Каргалинка) диләр аны. Ул бик сай, бик кечкенә, чуер ташлар өстеннән сырланып ага — кайбер төшләреннән аяк чылатмыйча сикереп чыгарлык. Кер чайкарлык кына яту урыннары да бар. Кисмәк бүрттерерлек, кабык чылатырлык су җыелсын өчен кайбер җирләрен әзрәк ташлар белән дә буганнар.

Инеш кечкенә, тар булса да үзәне шактый киң, ярлары да шактый биек. Язгы ташу вакытында кар суы шул ярларга сыеша алмыйча котырып, атларны агызып китәрлек булып килә диләр, ләкин мин бу тыныч — юаш кына агып яткан инешнең андый чагын бер вакытта да күрмәдем (язын-көзен без Каргалыга кайтмый идек).

Инешне кичеп, каршы яр өстенә күтәрелгәч, тар гына тугайлык башлана. Тугайлык тип-тигез, урыны-урыны белән бәләкәй генә урмандай кычыткан, алабута, шайтан таяклары үсеп утыра, чирәм җирләрендә бозаулар йөри, казлар ята, сугып киптергән зур-зур кизәк өемнәре тора.

Бу тугайлыкны тау итәге дияргә дә ярый, чөнки аз гына баргач та биек, текә тау башлана... Тау гына түгел, таулар! Инеш буйлап, бер сафка баскандай, тезелешеп килә бу ак маңгайлы кызыл таулар. Дәүләкәннән кайтканда иң элек әнә шул тауларны, аннары авылның нечкә манараларын күрәсең. Каргалы кешеләренең җырларына да кергән ул таулар.

> Каргалыкай тавы киртләч-киртләч,
> Киртләчләре бетәр кар киткәч.

Әйе, киртләчләр күп, болар — кәҗәләр таптап салган сукмаклар. Әмма тауның түбәсеннән итәгенә кадәр кар сулары ерып төшкән «сырлар» да җитәрлек.

Каршыбыздагы тауга кайчан менүемне хәтерләмим — билгеле, кечкенә чагымда үзем генә менә алмаганмындыр инде, ләкин үсә төшкәч, Каргалы малайлары белән бергә, әлеге кәҗәләр төсле, ул тауларда күп йөрергә туры килде. Безнең турыдагы «урталык тавы» дигәненең өсте тип-тигез иде: рәхәтләнеп чап, уйна, көрәш! Борынрак заманда Каргалының җиткән кызлары һәм егетләре дә шушы тауга менеп төрле уеннар уйный, күңел ача торган булганнар. Ул заманны Срур тутакай бик яхшы белә һәм бик тәфсилләп матур итеп сөйли дә. Кызлар бик горур, бик строгий, ә егетләр бик тыйнак, әдәпле булганнар имеш, сакчылы уйнаганда егет кызны куып җиткәч, кычкыртып кочакламаган, ә кул очын иңбашына тидереп кенә алган имеш. Бәлки, бәлки... Ләкин мин үскәндә яшьләрнең тауга менеп уйнаулары беткән иде инде, тик ара-тирә генә аллы-гөлле чуар киемле кызларның кояш баер алдыннан тау түбәсендә тезелешеп, авыл өстенә карап утырганнарын әзрәк хәтерлим әле.

Соңрак, 24—25 елларда яшьләрнең җәйге уеннары ялан якка, тимер юл буендагы чирәмлеккә күчкән иде инде. Өч мәхәлләнең дә яшьләре шунда җыела иде. Егетләр, кызларның нинди\ләре генә юк! Ул чакларда авылга Бәләбәйдән, Уфадан, Казаннан бик күп укучы яшьләр кайта иде. Алар арасында иске формаларын саклаган яшел фуражкалы, яшел тужуркалы картрак студентлар да очрый иде. Шәһәрчә киенгән бик сылу туташлар да бар иде. Авылчарак киенгәннәре дә бик көяз-ыспайлар, шуның өстенә шактый кыю-шаяннар да иде. Каргалы яшьләренең әнә шул кичке зур уеннарын мин дә бер-ике тапкыр күреп калдым. Миңа 14—15 яшьләр булгандыр, инде ис кергән, хыял эшли, күзләрем — кызларда гына! Тик кызганычка каршы, мин әле кызлар арасына кереп китә алмыйм, мин әле егет булып җитмәгәнмен — кыюлык та, әрсезлек тә юк әле миндә. Шуның аркасындадыр инде мин Каргалы кызларыннан берәүгә дә гашыйк була алмыйча калдым. Ә егет булып өлгергәч, миңа инде туган авылыма кайтып йөрергә туры да килмәде. (Соңгы кайтуым 24 елның җәендә булды шикелле).

Әйе, Каргалы ул минем бала чагым. Хәтирәләрем дә бала чакныкы. Иң элек, әнә югарыда язганча, бабакайларның иркен ишегалларын, келәт, кое, читән абзарларын, өй ишегеннән чыгуга каршыда гына басып торган мәһабәт тауларын күргәнмен. Шул ихата эчендә генә йөргәнмен, уйнаганмын, тавыклары, чебиләре белән танышканмын, аргач каз бәбкәседәй башымны үләнгә төртеп, йоклап та киткәнмендер бәлки,— бу минем әле бары өч-дүрт яшьлек чагым гына булгандыр. Азрак үсә төшкәч, урамга чыкканмын, күрше-тирә малайлары белән таныша башлаганмын. Бабакайлар йорты авылның нәкъ уртасында, каршыда гына агач мәчет — аны «урталык мәчете» диләр иде. Мәчет ихатасы кырыннан ук авыл зираты башлана. Анда иңкәйгән, кыйшайган иске кабер ташлары күп, яңалары бик аз, рәшәткәле каберләр дә күп түгел. Үсеп утырган агачлар бөтенләй юк диярлек, тик кайбер рәшәткәләр эчендә генә сирень куаклары күренә. Әмма зыярат өсте бер дә таптанмаган кылганлы куе чирәмлек иде. Чирәмдә җир җиләге күп була иде, ләкин аны нигәдер җыючы да юк, бары без, вак бала-чагалар гына, курка-курка кереп җыйгалый идек.

Терәлеп торган күршеләребез — уң якта бәлеш Усман, сул якта Әсәләй Шәрәфетдине. Усман абзый безгә якын кардәш — аның атасы белән минем инәйнең атасы бертуганнар. Үземне белә башлагач, иң беренче кереп йөрүем дә шуларга булды. Чиста җыештырылган якты, похтә өйләрен әле дә булса онытмыйм. Усман абзыйның өч улын беләм, шуның уртанчысы — Ибрай исемлесе минем беренче уйнап йөргән дустым да иде. Яшькә күпмегәдер олырак таза, базык малайга ияреп, мин Каргалының инеш буйларында, тау-чокырларында күп йөрдем. Ибрайның агасы, өрлектәй таза Хәсән абзый танылган көрәшче иде. Ибрай үзе дә көрәшергә бик һәвәс иде, кыстый-кыстый мине дә көрәшергә мәҗбүр итә һәм, билгеле инде, чөеп кенә ташлый иде. Шулай да мин аңардан көрәшергә шактый ук өйрәнеп калдым һәм бил ныгый төшкәч, үзем дә кайбер малайларны әйбәт кенә әйләнедереп сала башладым. Хәзерге вакытта Ибраһим Янгуразов отставкадагы полковник, Уфада тора, ә мин бары тик сержант кына. Күрәсез, чин ягыннан да безнең аерма бик зур.

Бабакайлар урамы авылның иң озын һәм иң төп урамы — буе бер өч чакрымга сузыла торгандыр. Югары башы — югары оч, түбән башы — түбән оч дип йөртелә. Һәр ике очта да якын һәм ерак кардәшләребез бик күп. Кайтып-китеп кенә йөргәнгә күрә, мин аларның бик якыннарын гына беләм, югары очтан, мәсәлән, Рәхмәтулла абзыйларны, Зурәттәкайларны («тутакай» сүзе шулай кушылып әйтелә), түбән очтан Саттый җизниләрне, Сәгыйть бабакайларны... Ләкин алар бары-

сы да диярлек мине һәм энемне беләләр иде, кунакка барганда яки үзләре килгәндә безне «Хәдичәттәйнең ике бөртеге» дип, назлап, мактап, тәүфыйк теләп башларыбыздан сөяләр иде.

...Хәзергә кадәр оныта алмыйм бик иртә күңелемдә уелып калган бер күренешне. Ул чакта миңа күпме булыр? — дүрт яшьләр чамасы, шуннан да артык булмас. Җәйнең җылы-матур бер иртәсендә бабакай белән әбыкай читән тарантаска янәшә утырып, мине дә үзләре белән алып, каядыр барырга чыктылар. Каршыдагы мәчет тыкрыгыннан уздык, тимер юлын чыктык, аннары такыр юлдан җирән алашаны әйбәт кенә юырттырып, яшел кыр буйлап киттек. Әйтәсе дә түгел, миңа бик күңелле, бик рәхәт иде. Бөтен тирә-ягым бик киң, бик якты — сулда тезелеп киткән Каргалы таулары, ә унда һәм алда офыкка китеп югалган чуар иген басулары. Әбыкайның итәгендә мин ялт-йолт каранып барам. Җирдән берәр кош күтәрелсә, шуңа башымны каерам, юл буенда берәр күбәләк талпынса, аңа да сузылмакчы булам. Шулай озак кына бара торгач, без ахырда ерак бер яланга җитеп туктадык. Хәзер менә чамалыйм, бу мөгаен Әркәсле яланы булгандыр — авылдан кыйбла тарафындагы ерак кырларны каргалылар әнә шулай дип йөртәләр иде. Без килеп туктаган җир тип-тигез сәхрә иде. Кайсы якка карама, бихисап чәчәкләр, ә җиргә төшкәч мин куе үләнендә бөтенләй күмелә яздым. Тирә-ягымда ниндидер кортлар тонык кына безелди, ниндидер кошлар пыр-пыр очып китәләр, ә бер кошчык каядыр биектә шундый өздереп, шашынып сайрый ла, әйтерсең менә безне күрүдән шатлыгы эченә сыймый, мескеннең! Аның тавышы бер якыная, бер ерагая, гүя мине үчекли, ләкин мин аны күрә алмыйча йөдәп беттем. Мин әле ул кошчыкның тургай икәнен дә белми идем. Әмма миңа бик рәхәт иде, бик кызык иде — гүя мин моңарчы һич күрмәгән өр-яңа бер дөньяга килеп чыкканмын. Билгеле, хәйран калганмындыр инде, кая карарга, нәрсә эшләргә белмәгәнмендер... Йөрисем-йөгерәсем килгәндер, чәчәкләрне дә өзәсем килгәндер. Ләкин әбыкай мине ни өчендер үзеннән ерак җибәрми, гүя ашыкмаска кушкандай әкрен генә «чү, бәбкәм!» дип әйтә тора.

Ә бабакай атын тугарып, үләнгә җибәргәч, бераз читкә китеп, чирәмгә кара җиләнен җәйде дә намаз укырга кереште. Башта аяк үрә, аннары тезләнеп укыды. Тирә-ягы куе үлән, шау чәчәк, менә шул үлән-чәчәкләр эченнән бабакайның нечкә муены белән кырпу бүреге генә күренә. Якты һавада күзгә күренмәс әлеге кечкенә кошчык, талпына-талпына, һаман өзелеп-өзелеп сайрый, үләндә йөргән җирән алаша да әледән-әле башын селкеп, тимер авызлыгын чыңлатып куя, ә без әбыкай белән бер читтә нидер көткәндәй тын гына басып торабыз.

Бабакай белән бәйле тагын бер хатирәм саклана. Әлеге авылдан чыгып китә торган каршыдагы тыкрык буенда, мәчет ихатасы артында, аларның читән белән әйләндергән ындырлары бар иде. Ындыр әллә ни зур да түгел, урта бер җире тап-такыр. Менә шул ындырда көлтә таптатканны хәтерлим мин. Көз башы булгандыр инде, көннәр әле аяз, тымызык, бик җылы да иде. Ындырның тап-такыр уртасына бодай көлтәләрен, башлары белән эчкә каратып, зур түгәрәк итеп, тезеп салганнар. Бабакай җигүле арбага минем ише ыбыр-чыбыр бала-чаганы төяп, шул көлтәләрнең башларын аты һәм арбасы белән таптатып, әкрен генә әйләнеп йөрде. Озак әйләндерде ул безне — тәмам кинәндек без бу рәхәткә! Көлтә таптау — ашлык сугуның бер ысулы икән ул. Ләкин моның белән генә эш бетмәде әле. Таптатканнан соң шул ук көлтәләрне хатын-кызлар чабагачлар белән алмаш-тилмәш дөпелдәтеп сугарга тотындылар. Бусы да бик кызыклы иде — дәртле сикерешә, күңелле гупылдаша чабагач башлары апайлар кулында!..

Ындырда иртә көзен ашлык сугу — бу авыл эшенең иң хозур чагы дияр идем мин...

Гаҗәп бу хәтер дигәнең! Күпме нәрсә онытыла, эзсез югала, ә кечкенә бер вакыйга гомер буена диярлек истә саклана. Ләкин минә бабакайның үзен ни сәбәптер ачык кына күз алдыма китерә алмыйм. Дөресрәге, китерсәм дә ничектер еракта томанлы итеп күрәм. Ул юка гына гәүдәле, кәҗә сакаллы бер кеше иде, буйга да бәләкәй иде шикелле. Һәм күпләр аны очарга торган җиңел сөякле бик житез карт иде дип сөйлиләр. Бәләкәй булуына карамастан мәчеттә ул бөтен кешедән калка биреп утыра икән. Холкы белән дә, күкерт шикелле, бик тиз кабынып китүчән иде диләр. Уларын, киленнәрен утлы табага бастырырга яраткан булса кирәк. Ләкин бик тиз сүрелә дә икән. Андый чагында һәркемгә ачык чырай да тәмле сүз. Әбыкайга ул, мәсәлән, «Якты көнем!» дип кенә дәшә иде.

Мин аның озын ак күлмәк, кара комзол, йомшак кара читекләр киеп йөргәнен әзерәк хәтерлим. Тагын бер нәрсә бик нык истә калган: кайнаган самоварны өстәлгә китереп куйгач, бабакай аның моржасыннан утлы күмергә кечкенә лимон кабыгын төшереп җибәрә иде. Менә шуннан бөтен өй эченә гаҗәеп бер тәмле хуш ис тарала иде. Бу хуш исне минем әле дә булса онытканым юк, ләкин аңардан да битәр ул заманда авылда лимон булуына гаҗәпләнәм. Күрәсең, Бүздәк яки Дәүләкән базарыннан алып кайткаңнардыр инде. Дәүләкәндә җиләк-җимеш подваллары да бар иде, аннары бик юка гына сурәтле кәгазьгә төргән лимоннарны Муллаҗан исемле агай, беләгенә кәрзин асып, урам буенча «лимон, кемгә лимон?» дип кычкыра-кычкыра сатып та йөри иде. Гаҗәп бит!

Бабакай турында белгәннәрем шушы урында өзелә дияргә дә ярый. Унҗиденче елның җәендә, кыска гына авырудан соң, ул Каргалыда вафат була. Шулай итеп, мин бабакайның үлгәнен белсәм дә, ак кәфенгә төрелгән гәүдәсен үз күзем белән күрмәгәч, бу югалтуны артык авыр кичермәдем бугай. Дөрес, аңлыйм да, тоям да кебек: бабакай юк инде, базар саен диярлек безгә килмәс, безне — «ике бөртекне» җитәкләп йөрмәс, юксынырбыз да, сагынырбыз да без аны, әмма чын хәсрәт дигән нәрсәне без әле юньләп белми идек.

Әбыкайны инде мин яхшы ук хәтерлим. Бабакайдан соң әбыкай дүрт ел яшәп, егерме беренче елны бездә, Дәүләкәндә вафат булды. Миңа ул чакта уникe яшь, зиһен кергән, күңел күзе дә ачыла төшкән... Бүгенгедәй исемдә: егерме беренче елның гаять коры, эссе җәендә бездә ваба (холера) чире пәйда булды. Ара-тирә шул чирдән үлүчеләр дә була башлады. Ачлык әле килеп җитмәгән иде, әмма елның килеше бик өметсез, бик хәтәр иде.

...Бер көнне иртәнге чәй янында мин йокыда күргән төшемне сөйләдем: имеш, ниндидер читтән килгән чапанлы кешеләр безнең урамда өй саен дөя өләшеп йөриләр икән. Әле берәүнең, әле икенченең, әле өченченең ишегалдына кереп, кечкенә башлы, кәкре муенлы дөяләрне, калдырып чыгалар икән... Шуны ишетү белән әбыкай бик куркынып миннән сорады: «Ай бәбкәм, ул дәвәне безгә дә кертмәделәрме?»... «Юк шикелле,— дидем мин икеләнебрәк. — Безгә хәтле килеп җиткәннәрен күрмәдем». Шуннан соң әбыкай бераз тынычланган кебек булды, шулай да авыз эченнән генә нидер укып, битен сыйпап куйды.

Әмма аның куркуы юкка гына булмаган икән. Сөйләгән чакта төшнең хәтәр мәгънәсен мин белми идем, белгән булсам, бәлки сөйләмәстә идем. Ә баксаң, төшкә кергән дөя ул газраил имеш! Берәр якынын үләргә булса, шул юаш хайван төшкә керә имеш!.. Дөрес, төшне минем алдымда юрамадылар — моны мин бары тик соңыннан гына белдем. Ә белгәч, ул хәерсез дөя безгә дә килеп җиттеме-юкмы дип үз алдыма озак кына азапланып баш та ваттым.

Ләкин ничек кенә юрама, ваба чире шулай да безнең өйгә килеп керде. Нәкъ менә әбыкайга ябышты ул, һәм өч тәүлек дигәндә аны алып та китте. Зал белән янәшә кечкенә бүлмәбез бар иде — ул шунда ятты. Чире бик әшәке, бик каты булгандыр ахрысы, чөнки атакай белән инәй көне-төне яныннан чыкмыйча аны карадылар. Көзән җыерудан басарга дип берөзлексез кайнар су ташып тордылар... Фельдшер да килеп китте шикелле, ул киткәннән соң өйгә сасы карболка исе таралды. Тагын нинди чаралар күрелгәндер бу коточкыч үләткә каршы, белмим, истә калмаган, ләкин безне әбыкай яткан бүлмәгә якын да җибәрмәделәр. Инде җан биргәч, карчыклар юып, кәфенләгәч кенә безгә: «Балалар, әбыкаегызны күреп калыгыз» дип керергә куштылар. Ләкин мин кермәдем, йөрәгем җитмәде,— мин гел читтә, ишегалдында үземә урын таба алмыйча һаман йөреп тордым... Каргалыга безнекеләр ничектер хәбәр итеп өлгергәннәр, җирлисе көнне, кырык чакрым җирдән, атын ак күбеккә батырып, Нигъмәтулла дәдәкай килеп житте. Башка ул-кызлары килә алмадылар, күрәсең, хәбәр итәргә өлгермәгәннәрдер, аннары елы да бик хәвефле иде шул.

Әбыкайны үлгән көнендә үк җирләделәр. Өйдән алып чыкканда шактый гына кешé җыелган иде. Башта мәчеткә илтеп, яшел чирәмдә генә җеназа укыдылар, аннары мәет ташый торган сай-озын әрҗәгә салып, өстен палас белән каплап, Илибатыр (Элеватор) артындагы яңа зиратка алып киттеләр. Әрҗәнең баш-башыннан һәм аркылы таякларыннан күтәргән кешеләр, әбыкайны бик кызу алып бардылар — безнең шәригать шулай куша икән. Картлар, муллалар утырган атлар, арттарак калсалар, юырттырып куып җитәләр иде... Әле күзгә ерак, әле җәйнең уртасы гына, ә дөнья инде көйгән, саргайган иде ул елны... Үлән үзеннән-үзе уалырга тора, аяк астыннан вак чикерткәләр як-якка чәчри, хәтта кошлар да очмый иде...

Зиратка барып җиткәч тә мин, каберга якынаерга кыймыйча, кешеләр артында читтә генә тордым. Әбыкайның гәүдәсен ләхеткә куйганда да якынаерга җөрьәт итә алмадым. Юк, булмаса-булмый икән! Сынсыз, өнсез бер хәлдә идем мин, тик сизәм — яшьләрем генә үзлегеннән ага иде... Әйтергә кирәк, үлем-бетемнән бик нык ятсыну, үлгән кеше тирәсендә чуаласы килмәү, бигрәк тә мәет йөзенә карый алмау миндә гомерлеккә диярлек сакланып калды. Хәзер дә нindидер бер мәҗбүрият мәет янына барырга кушса да мин аның йөзенә ничек тә карамаска тырышам. Әмма бу һич тә куркудан түгел. Кешенең тере кыяфәте һәм мәете шул хәтле бер-берсеннән ерак, гайре табигый нәрсә ки, мин, күрәсең, шуңа тиз генә ышана да, ияләшә дә алмыйм.

Шулай итеп, без әбыкаебызны кинәт кенә югалттык та куйдык. Намаз арты еаен ул: «И раббем, кыска сырхау, ансат үлем бир!» дип дога кыла торган иде. Менә кабул булды теләге. Хәер, сырхавы бик кыска булса да җан бирүләре, ай-һай, ансат булмагандыр. Чире нинди бит — ваба! Ләкин бер нәрсәгә торып-торып хәйран калам, ни хикмәттер, бу коточкыч чир безнең беребезгә дә йокмады, эләкмәде. Нәрсә генә саклап калгандыр — хәзергәчә аңлый алганым юк.

Безнең өйгә кергән бу беренче үлем иде, беренче зур мәет чыкты безнең өйдән... һичшиксез бик авыр кичердек без бу югалтуны. Бабакай үлгәннән соң әбыкай безгә ешрак килә һәм озаграк торып та китә иде. Шуңа күрә, без ике малай, аңа бик ияләшкән идек. Ул гәүдәгә тулы, таза карчык иде, холкы да сабыр — басынкы (бабакайның нәкъ киресе), һәм тәмле телле дә иде. Безне, тугыз баладан соң исән-имин генә үсеп килгән «ике бөртек»не, әлбәттә, бик аяган һәм яраткан булырга тиеш. Менә аның сабый чагыбызда башта мине, аннары энемне — чөя-чөя әйткән такмагы:

Бабасының нисе бу — тауга менәр таягы!
Әбисенең нисе бу — сөт өстендә каймагы!
Дәдәсенең нисе бу — кысып буар билбавы!,
Тутасының нисе бу — энже-мәрҗән кулбавы!
Атасына ай кебек, иңәсенә көн кебек,
Килеп киткән кунакларга куй б...лай юк кебек!

Әнә шулай үчтеки иткән ул безне... Моны мин күп еллар узгач, Срур тутакайдан ишеттем. Хәзер инде үзем дә әбыкай яшенә килеп житкән кеше, әмма минем сабый чагым аның әнә шул такмагында саклана.

## Туганнар

Бабакай белән әбыкайдан соң миңа иң якын туганнар булып, билгеле инде, аларның уллары белән кызлары калды. Болар атакайның ике энесе — Нигъмәтулла белән Мөхәммәдьяр дәдәкай һәм ике сеңлесе — Рокыя белән Срур тутакай. Энеләре Каргалыда, сеңелләре исә Уфада торалар иде. (Кияүгә чыккач киткәннәр). Аларның балалары да миңа шулай ук иң якын кардәшләр — туганнан туган гына, каргалыча әйтсәк, тудыклар булабыз. Без барыбыз да бер заманда үстек. Югалтулар күп булмады, тик Рокыя тутакайның бердәнбер улы Әнвәр генә сугыштан кайтмады, аннары минем энем Илдархан 49 яшендә үлеп китте. Калганнарыбыз хәзергә исән әле... Яшь ягыннан тиңрәкләребез балачактан алып, шушы көнгә кадәр, араларыбыз ерак булса да, һаман очрашып, күрешеп тордык. Ләкин кайбер кече яшьтәгеләре белән минем үземә бик сирәк очрашырга туры килде — мәсәлән, Нигъмәтулла дәдәкайның Идиятулласын мин бала чагында гына бер күреп калдым.

Инде килеп шуны әйтергә кирәктер, бу якын туганнарның берсе дә Каргалыда тормыйлар, күптән алар төрлесе төрле якка таралып беттеләр. Уфа, Казан, Мәскәү, Алма-Ата, Ташкент, Севастополь, тагын кайлардадыр яшәп яталар. Йөз илле ел безнең бабайлар яңа җирдә таралмыйча яшәгәннәр, ә минем буын ун-унбиш ел эчендә таралды да бетте.

Дөрес, Каргалыдан элек тә читкә китүчеләр аз булмаган, ләкин берсе китсә, бишесе кала дигәндәй, төп нигез һәрвакытта саклангaн. Һәм китүчеләр шул нигезгә гел кайтып йөргәннәр... Безнең нигез исә сугышка хәтле үк бетерелгән иде. Хәзер авылга кайтсаң, кемнең капкасына сугылырга белмәссең. Хәер, нигезләреннән аерылучылар Каргалыда бер безнекеләр генәме соң?! Күп алар, бик күп... (Хәтерлисездер, «Туган туфрак» дигән хикәядә авылга кунакка кайткан Клара бабасының ташландык, буш йорты урынына исе китеп, карап тора — бу уйлап чыгарылган нәрсә түгел, чыны шулай.)

Минем тудыкларның читтә балалары туып үсте, алар күптән өйләнеп яки кияүгә чыгып, үзләре инде балалар үстерде. Болар, безнең оныклар дип әйтик, Каргалыны әлбәттә белмиләр, күргәннәре юк, һәм күрергә бернинди теләк тә, ихтыяҗ да юктыр, минемчә. Аларның бит үз «туган туфраклары» Казанда, Алма-Атада, Ташкентта... Әле Каргалының үзендә туганнар да аны исләренә төшерәләр, сагыналар микән? Барлык җепләр дә күптән өзелеп беткән бит инде. Хәер, туфрагын бәлки онытмаганнардыр әле — әгәр аяклары җылысын тоеп өлгергән булса!

Инәйнең ирләрдән бер туганы да юк иде, сеңелләре — берсе Ташлыкүлдә, икенчесе Шәрлекулда иде. Шәрлекулдагы Мәрьям тутакайны

мин бөтенләй белмим диярлек, ул иртә үлгән шикелле, аннары Шәрлекул Дәүләкәннән шактый ерак булганга күрә без аңа кайтып та йөрми идек. Ә менә Ташлыкүлдәге Кәримә тутакайларга мин җәй саен кайтмыйча калмый идем. Кәримә тутакай белән Кәшшаф җизни безнең иң якын, иң яраткан туганнарыбыз иде. Ташлыкүл бер генә мәчетле авыл, җирләре тигез дала, туфрагы кара уылдык шикелле, игенне күп игәләр, уңышны да күп алалар иде. Гомумән халык анда таза тормышлы иде, Кәшшаф җизниләр исә авылның иң хәлле кешеләреннән иде. Йортлары зур, калай белән япкан келәт-амбарлары, лапас-абзарлары — барысы да таза-нык, ишегаллары бик иркен, өй янында матур гына бакчалары да бар — анда җәйнең эссе көннәрендә умарталар өзлексез гүү итеп тора иде. Мин аларга НЭП елларында кайтып йөрдем, ләкин бер вакытта да аларда ялчы-мазар күрмәдем. Бөтен эшне үзләре җимертеп эшлиләр иде. Кәшшаф җизнинең ул арасына керерлек ир баласы да юк иде, торганы кызлар һәм бөтен эш бары шул кызлар өстендә иде. Мәсәлән, миңа тиңрәк Наилә сабанын да сөрә, тырмасын да тырмалый, җитмәсә әле атка да иярсез генә атланып йөри иде. Дөрес, дүрт кыздан соң Кәримә тутакай бер ир бала да тапты. Тәлгать исемле иде ул, Кәшшаф җизнинең үзе төсле тыныч кына, сабыр гына бер малай иде... Сугыш башланган елны гына Тәлгать Куйбышевтагы планово-экономический институтны бетерә. Бетерү белән ирекле рәвештә фронтка китә һәм 1941 елның көзендә, Мәскәүне фашистлардан яклаган чагында һәлак та була. Бердән-бергә тия, дип халык юкка гына әйтми икән... (Минем «Ана һәм кыз» дигән хикәям Тәлгатьнең үлгәнен ишеткәннән соң язылган иде.) Атасы Кәшшаф җизни әле утызынчы елларның башында ук кыска гына авырудан соң үлеп киткән иде. Тәлгатьне апалары карап үстерде. Сугышның каһәре аларга нык тиде — Әминә белән Һәммәюннең дә ирләре шулай ук сугыш кырында ятып калдылар.

Әйе, заманында мин Ташлыкүлгә бик теләп кайта идем. Кәримә тутакайның аш-суы бик тәмле була иде. Алардагы шикелле куе сөзмәне, чөгендерле катыкны һәм күзәнәкләренә чык бөртегедәй май тулган тары беленен минем бүтән бер җирдә дә ашаганым булмагандыр. Аннары безне якын иткән тагын бер сәбәп — кызлары Әминә дә, Наилә дә безгә килеп, берничә кыш Дәүләкән мәктәбендә укыдылар. Кәшшаф җизни үзе дә базар саен диярлек килмичә калмый иде. Ул, мәрхүм, китап ярата иде, базарда очраган китапларның искесен дә, яңасын да җыеп алып китә торган иде.

...Еллар узды. Кәримә тутакай да күптән вафат. Дүрт кыз калганнар иде, шуларның өчесе хәзерге көндә исәннәр. Уфада төпләнеп, һәркайсы яңа квартирада бик әйбәт, тыныч кына яшиләр. Инде оныкларын үстерәләр... Тик кызганычка каршы, Наилә генә иртәрәк китте, ә ул араларында иң акыллысы, иң булдыклысы иде, аңа буйсыналар иде барысы да.

Мин аларга һәрвакытта бик соклана идем. Бердәм, чыдам, тырыш булып чыктылар минем бу кыз туганнарым. Тамырлары ныкка күрәдер инде, яшьтән үк эштә чынykканга күрәдер. Авыр сугыш елларында ирләр сынды, алар сынмадылар. Язмыш аларны кая гына ташламасын, һәр урында тормышларын матур корып, тук-бөтен яшәделәр. Хәерчелек аларга бәйләнә алмады!

Ярый, тыныч Ташлыкүлдән шау-шулы Каргалыга яңадан килик әле булмаса... Әйткәнемчә, анда ике дәдәбез — Нигъмәтулла белән Мөхәммәдьяр калды. Без хәзер шуларга кайтып йөрибез. Шул ук йорт, шул ук ихата — барысы да искечә. Тик елдан-ел без үсәбез һәм үсә барган саен авылыбызны күбрәк беләбез.

Ике бер туган икесе дә Герман сугышына алынган булганнар. (Без әле бәләкәй ул чакта). Мөхәммәдьяр дәдәкай соңрак китә һәм

озак та тормыйча, чәнчә бармагын имгәтеп, борылып та кайта. Ничектер, тиз ычкына дәдәбез!.. Мөгаен берәр төрле авыруын тапканнардыр, югыйсә чәнчә бармак өчен генә җибәрмәсләр иде.

Әмнә Нигъмәтулла дәдәкай сугышның башында ук китә, Австрия фронтында күпмедер сугыша, ахырда чолганышта калып, пленга эләгә... Өч тапкыр пленнан кача ул, тик өченче качуында гына дошман кулыннан ычкына.

Аның фронттан кайтып керүе шактый кызыклы. Унжиденче елның кара көзендә булса кирәк, безнең авыл турысыннан фронт ташлап кайтучы солдатлар төялгән эшелоннар үтә башлый. Шундый эшелоннарның берсеннән татар солдатлары: «Сезнең авылныкы Нигъмәтулла кайта-а! Арттагы эшелонда, хәбәр итәргә кушты-ы!» дип кычкырып узганнар имеш. Кемдер шуны ишетеп, чаба-чаба әбыкайларга килеп әйткән икән. Билгеле инде, өйдәгеләр бу яшендәй ялтырап киткән хәбәрдән башта сискәнеп-каушап, аннары чиксез шатланып, дәррәү аякка басканнар. Шунда ук ат җиктереп, якын туганнардан берәүне (Рәхмәтулла абзыйны булса кирәк) Бүздәккә чаптырганнар (ул заманда поездлар Каргалыда туктамыйлар иде), үзләре тиз генә мунча якканнар, тәкә суйдырганнар. Ләкин ул көнне, тәмам караңгы төшкәч, тирләп беткән ат буш кайткан... Өмит дигәнең гаҗәп нык, үҗәт нәрсә ул! Икенче көнне, өченче көнне, дүртенче көнне дә атны Бүздәккә куалар, эшелоннар да һаман уза торалар, әмма ләкин Нигъмәтулла-быз юк та юк. Өйдәгеләр, бичаралар, аптырап, гаҗиз булып, саргаеп бер атна, ике атна, хәтта бер ай көтеп карыйлар, аннары инде килеп әйтүче ялгыш ишеткәндер дип, әкренләп өмитләрен өзәләр. Әбыкай озак-озак кына намазлык өстендә утыра, ә Мәдинә җиңгәчәй казан янында тавышын чыгармыйча гына яшен коя.

...Һәм менә, инде кыш кергәч, чатлама суык төннәрнең берсендә Нигъмәтулла дәдәкай узып баручы эшелоннан авыл турысында сикереп төшеп кала. Өстендә иске бушлат, аягында каткан итекләр, бөрмәле капчыгын иңенә аскан — тимер юлдан чана юлына чыгып, кызу гына шыгыр-шагыр атлый-атлый, үзләренең ишегалларына кайтып керә. Аяк тавышын ишетеп, ике эт — Муйнак белән Алабай — баскыч астыннан өрә-өрә атылып чыгалар. Ләкин Нигъмәтулла дәдәкай бер дәшү белән өрүләреннән туктыйлар да, янына барып бөтерелә, чыйный, өстенә үк сикерә башлыйлар. Исең китәр этләрнең сизгерлегенә! Әйтерсең, дүрт ел түгел, дүрт кенә көн хуҗаларын югалтып торганнар!

Хуҗа башта ишегалдын әйләнеп, каралты-кураларны, абзардагы малларны карап чыга, шуннан соң гына өй ишегенә килә. Бу вакытта әле өйдәгеләр ятмаган була — Мәдинә җиңгәчәй нидер бәйләп, әбыкай исә сәкедә тәсбих тартып утыра. Тышкы ишекне кемнеңдер каты гына шакыганын ишетеп, җиңгәчәй үзе өйалдына чыга. Ләкин шунда ук борылып та керә. Артык каушаудан булса кирәк, ул төсе качкан хәлдә еламсырап: «Анакай, ишектә бер ир тавышы, әллә Нигъмәтулла инде» ди... Әбыкай «Ай аллам» дия-дия, әпен-төпен сәкедән төшеп, селкенә-селкенә чыгып китә. Һәм Нигъмәтулла дәдәкайны ияртеп керә... Сөйләшерлек тәкатьләре булмый, өчесе дә сәке кырына утырып, елашып алалар, аннары гына өйдә хәрәкәт башлана. Тиз генә мич тә ягыла, самовар да куела, таба да чыжларга тотына. Дәдәкайның аягына җылы пима бирәләр... Төн булуга карамастан, әбыкай кушуы буенча, урам аша гына торган Гыйният мулланы чакырып, никах яңарталар. Көн яктыруга инде мунча да өлгерә.

Бу язмада уйлап чыгарылган берни дә булмаска тиеш, шуңа күрә әйтәсем килә: Нигъмәтулла дәдәкайның Герман сугышыннан ничек кайтып керүен күп еллар узгач Мәдинә җиңгәчәй үзе миңа сөйләгән иде.

...Ике бертуган, әмма никадәр зур аерма! Бер анадан туып та бу хәтле бер-берсенә охшамаган братларны минем әле күргәнем дә юк диярлек. Кыяфәтләре үк башка: Нигъмәтулла дәдәкай урта буйлы, таштай тыгыз, какча гәүдәле, ә Мөхәммәдьяр дәдәкай буйга да кечерәк, гәүдәгә дә юанрак... Әмма иң зур аерма аларның табигатендә иде. Нигъмәтулла дәдәкай гаять житез, кайнар, тиктормас бер кеше булса, Мөхәммәдьяр дәдәкай, киресенчә, шактый басынкы, авыр кузгалышлы кеше иде. Һәм бу аерма ике туган арасында еш кына низагы да тудырган булса кирәк. Хикмәт шунда, Нигъмәтулла дәдәкай ялкаулыкның чын дошманы — үзе дә тынгы белмәгән, кешегә дә тынгы бирмәгән, шуның өстенә шактый кызу канлы да булган. Билгеле, әкрен, салмак, ваемсыз энесенә аңардан еш кына эләккән дә булырга тиеш.

Әйтәләр, Мөхәммәдьяр дәдәкай яшь чагында йокларга бик яраткан дип. Уятмасалар тәүлек буена да йоклый икән. Моны ялкаулыктан күргәннәр. Хәлбуки, Срур тутакайның әйтүенә караганда, бу аның шундый авыруы икән, тик үз вакытында моны берәү дә белмәгән.

Мөхәммәдьяр дәдәкай тыштан шулай мәнсез, пошамансыз булып күренсә дә, аның, минемчә, кызыксынган нәрсәләре дә бар иде. Мәсәлән, ул матур әйберләрне ярата иде, безгә килсә, шкафтагы төрле кызыклырак әйберләрне алып, әйләндереп-әйләндереп карый торган иде. Шулай ук китап актарырга, рәсемнәр карарга да ярата иде. Татарча да, русча да укый белә иде ул. Ашыкмыйча гына акыл да саткалый иде, үзенә күрә фәлсәфәсе бар иде аның...

Ә Нигъмәтулла дәдәкай дөнья куа, гәп сатып тик утыру кая ул — бөтенесенә өлгерергә кирәк. Кызу эш өсләрендә оек-чабатадан, алача ыштаннан, киез эшләпәдән өермәдәй бөтерелә иде. Каргалы басулары һәм печәнлекләре шактый еракта, бабакайларның печәнлеге, мәсәлән, авылдан биш-алты чакрым, «балота» дигән жирдә иде. Нигъмәтулла дәдәкай ялгыз. Унөч-ундүрт яшьлек кызы Зөләйхадан башка кул арасына керерлек беркем дә юк. Калган балалары үзе пленнан кайткач кына тудылар. Зөлайханы да ул бик иртә эшкә жикте.

Эшләргә, эшләргә! Эш аның өчен мәжбүрият кенә түгел, жан таләбе дә иде шикелле, ничектер дәртләнеп, ләззәт табып эшли иде ул. Аныңча, эшсезлектән дә оят нәрсә юк. Менә шушы нигездә безгә дә аңардан «өлеш» чыккалый иде.

Жәйнең бушырак вакытында Нигъмәтулла дәдәкай Дәүләкән базарына да чаптырып килеп житә иде. Кояш баер алдыннан гына килә, кояш белән бергә торып базарга йөгерә, анда эшләрен бетергәч, кайтып ашык-пошык кына бер-ике чынаяк чәйне каплый да, сары атын жигеп, капкадан ук юырттырып китеп тә бара. Ә без, ике малай, эшсез йөрибез, безнең ат та юк, сарык-кәжә дә юк, бер генә сыерыбыз бар, ул да көтүдә. Кыскасы, печән чабасы да юк, урак урасы да юк. Димәк, безгә, үсеп килгән ике малайга, урам таптаудан башка эш тә юк. Билгеле инде, Нигъмәтулла дәдәкай мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Кул-аягы таза малайлар эшсез йөрсеннәр имеш! Моның өчен ул атакайны да тирги, инәйне дә тирги, ә без инде аның күзенә күренергә дә куркабыз. Кайчагында исә тиргәп кенә калмыйча инәйгә туп-туры әйтә: «Жиңгәчәй, малайларның алмашка күлмәк-ыштаннарын карап бир, мин бу ике хөрәсән ялкавын алып китим әле булмаса, йөрмәсеннәр монда б... тибеп, миндә ипекәйнең тәмен белебрәк ашарлар!» — ди... Инәй дә риза була, ләкин икебезне дә түгел, мине генә жибәрә. (Ничек инде «ике бөртек»нең икесен дә жибәрсен ди? — юк, булмый, ярамый!). Шулай итеп, Нигъмәтулла дәдәкай мине кабык арбасына утыртып, кырык чакрымдагы Каргалыга дыңгырдатып алып та китә торган иде.

Авылда эш бер вакытта да бетеп тормый — иртә яздан кара көзгәчә. Кайчан гына кайтсаң да берәр «эш өстенә» туры киләсең, мәсә-

ләң, кизәк суктырган чакка... Каргалының үз урманы юк диярлек, агачны бик ерактан китерәләр, шул сәбәпле бөтен авыл җәй башыннан ук күп итеп кизәк суктыра. Бу шактый авыр һәм пычрак эш. Иң элек тирес өемен түгәрәкләп җәеп, аңа мичкә-мичкә су ташып, бик нык чылаталар. Шул ук вакытта ыштан балакларын сызганган берәр ир кеше, җәем уртасына басып, озын тезгенле атны әйләндереп куа-куа тиресне озак кына таптата. Шулай чылата һәм таптата торгач, тирес тәмам йомшарып, измә хәленә килә. Аннары инде чират кизәк сугучыларга җитә.

Бу эштә күбрәк житкән кызлар да үсмер малайлар. Ыштан балакларын тездән югары сызганып, күлмәк итәкләрен бөрмәләренә кыстырып, алар шома такта өстенә куелган пар калыпка тирес измәсен сәнәк яки куллары белән генә салып, таптый-таптый тыгызлыйлар да, шуннан калыпларын йөгертә-йөгертә читкә илтеп, чирәм өстенә каплыйлар. Кизәк тигез, шома, елтыр гына кара кирпеч булып төшеп кала.

Миңа, кунак малай булганга күрәме, әллә көче җитмәс дипме, калыпның сыңарлысын гына бирәләр иде. Сыңарлы калып белән сугуы әлбәттә күп җиңел, ләкин мин бу эшне баштарак бер дә яратмадым. Тирескә кулларым белән керергә чиркана идем, әчкелтем исеннән җирәнә идем. Әмма Нигъмәтулла дәдәкәй кушкан эштән котылу юк, аннары башкалар эшләгәндә тик тору мөмкин дә түгел... Чирканып-җирәнебрәк булса да тотынырга туры килә иде. Ә бераздан инде тиреснең үзенә дә, исенә дә әкренләп күнегәсең, парин! Хәтта әле көлешә-көлешә эшләгән кызлар янында, алардан калышмаска тырышып, җиңел калып белән кизәкне йөгерә-йөгерә чирәмгә илтеп салуы кызык та була башлый... Тирес җәеме никадәр зур булса да, ишле кулдан йолка торгач, без аны кояш баюдан күп элек бетереп тә куя идек. Шуннан соң кое янындагы озын улактан су сибешә-сибешә кул-аякларны бик әйбәтләп юабыз, кызлар мунча алдына кереп, чиста күлмәкләрен киеп, төзәтенеп чыгалар. Аннары инде ишегалдының тазарак, чирәмлерәк җиренә зур торыпша җәеп әзерләнгән табын әйләнәсенә җиңгәчәйнең каклаган ит турап пешергән өреле куе токмачын ашарга утырабыз. Барысы да — өреле токмач та, каймаклы катык та, бүген генә мичтән чыккан арыш ипие дә ашап туйгысыз! Ипекәйнең тәме монда башкарак икән шул! Аннары тагын авыз бер генә минут үз эшеннән туктап тормаса да кызлар үзара гел кызык сөйләп тә шырык-шырык көлешеп утыралар. Кемнән, нәрсәдән? — Кайчак аңламыйчы да калам, тик миңа да төрттермиләр микән дип эчемнән генә борчылып куям. Ә шулай да бик күңелле, бик хозур!.. Тирес сугуның ахыры дип әйтәсем килә.

Әнә шул рәвешчә Нигъмәтулла дәдәкәй мине «ипекәйнең тәмен белеп ашарга» өйрәтте. Бер кайтуда тирес суктырса, икенче кайтуда я печәнгә, я уракка алып бара иде. Кайчагында күрше малайларына ияртеп, ат куна да җибәргәли иде. Кыскасы, тик тотмый иде... Чын авыл эшен мин асылда бары шул Нигъмәтулла дәдәкәй аркасында гына азмы-күпме белеп калдым. Дөрес, мин әле бик яшь идем, үсмер малай гына, өстәвенә талчыбыктай нечкә-арык та идем, әмма ләкин аякка җип-җиңел оек-чабата киеп, шуңардан эш кешесенә әйләнүемне тоеп, пакустагы үләнне агач тырма белән селкә-селкә җыеп йөрү минем өчен бик кирәкле дә һәм бик файдалы да булган икән ул.

Бу урында шуны да әйтергә кирәк. Нигъмәтулла дәдәкәй никадәр кызу-кайнар кеше булмасын, ләкин ул бервакытта да тиктомалга кычкырмый һәм җикеренми иде. Ничектер мена киреләнергә урын калдырмаслык итеп, өзеп кенә куша белә иде. Инде сүзен тынлаучыга һәм янып эшләүчегә аңардан да тәмле телле кеше юк диярсең. Ә безгә,

бала-чагаларга, үзенекеме, күршенекеме — һич аермыйча, гел «бәбкәм» дип кенә дәшә торган иде. Минемчә, ул асылда йомшак-нечкә күңелле кеше булырга тиеш, чөнки мин аның йорт хайваннарына да шулай сөеп дәшкәнен еш кына ишетә идем. Әмма бер кабынып китсә, үзен белештермичә, кешене тетеп ташларга да күп сорамый иде. Әлбәттә, теле белән. Хәер, җиңел кабынып киткән шикелле үк ул бик тиз кайтып та төшә иде: әле генә бөтенесен пыр туздырган дәдәбез, баксаң, кай арададыр сүрелеп тә өлгергән — берни булмагандай ачык чырай белән һәркемгә ягымлы дәшеп, дөнья бетереп йөри дә башлаган. Аннары, сабыр холыклы җиңгәчәй дә аны, ярсу атны тыеп кына торгандай, гел тынычландырып кына тора иде.

Нигъмәтулла дәдәкай кебекләрне безнең Каргалыда, яшенә карамастан «Егет кеше, удалой!» дип йөртәләр. Тәвәккәл, кыю, житез, сүзгә тапкыр, туйлар һәм мәҗлесләр күрке — әнә шундый кеше иде Нигъмәтулла дәдәкай да. Өстәвенә ул озын көйләргә шактый матур, моңлы итеп җырлый да торган иде. Гадәттә аягүрә басып, бөеренә таяна биреп, тавышын әз генә калтырата төшеп, сузып җибәрә иде:

Утырдым ла көймәнең, ай, түренә,
Карадым ла суларның төбенә.
Су төпкәйләрендә һич кара юк,
Хак язганны күрми чара юк.
. . . . . . . . . . . . . .

Аңа, Нигъмәтулла дәдәкайга, хак язганны, дөресрәге — язмаганны, ничек итеп күрергә туры килгәнен чираты житкәч сөйләрмен әле. Ә хәзер башкасына күчик.

Мин Мөхәммәдьяр дәдәкай туен яхшы хәтерлим. Аны, шактый утырган егетне, егерменче елның салкын кышында түбән очтагы Мамлеевларның Хәнифә исемле кызына өйләндерделәр. Туйга Дәүләкәннән без дә кайттык. Миңа бары унбер яшь кенә, ләкин шуңа да карамастан, бертуганның малае диптер ахрысы, мине кияү егетләре арасына кертеп йөрттеләр. Башта әллә ничә пар атта түбән очка туй китте. Кияү, өч кияү егете һәм мин — «ярты кияү егете» өйдә калып тордык. Күп тә үтмәде, ат атланган бер егет, чаптырып килеп, кыз өендә никах укылганын хәбәр итте. Шуннан соң барыбыз да чыгып, пар атка төялдек тә, тын авыл урамын дәртле кыңгырау тавышы белән сискәндереп, җил-буран уйнатып, китеп тә бардык. Күчердәге дилбегә тоткан егет төптәге атның башын югары күтәрттереп, ә мичәүдәгесенең башын кырын салындырып кына алып барды. Үзенә күрә бер осталыктыр инде бу... Барып җиткәч, ишегалды түрендәрәк торган келәт сыманрак кечкенә бер өй каршында чанадан төштек. Кияү кергәнне көтеп утыручы кыз шушы өй эчендә икән. Каргалы туеның борыннан килгән мәжбүри тәртипләре бар: иң элек без, кулга-кул тотынышып, аллы-артлы тезелештек. Беренче булып башкияү егете, аның артыннан кияү үзе, аннары инде калганнарыбыз — иң коерыкта мин. Кияүнең өстендә яшькелт тышлы, бәрән эчле тун, башында кама читле бүрек, кулында кечкенә сандыгы — анда аның кодачаларга дигән исле сабын, ефәк чәчүргеч, түгәрәк көзге, тагын нинди бүләкләре. Минем өстә дә тун, тик тышсыз каеры тун (хәзерге заман яшьләренең исләре киткән дубленка), ә башымда патша казаклары кия торган зәңгәр постау түбәле, озын йонлы, галәмәт биек бүрек. Билгеле, бу бүрек минем өчен махсус тектерелгән дә, кибеттән башка үлчәп алган да түгел, бәлки толчокта бәрәр исерек солдат кулыннан сатып алынган булырга тиеш. (Ул елларда кием-салымны толчоктан гына табарга мөмкин иде). Бүрек күзләремне каплап тора, мин аны һич яратмыйм, кияргә хурланам, ләкин кимичә чарам да юк.

Хуш, кулга-кул тотынышып тезелешкәннән соң, башкияү егете ишек тоткасын тотып торучы житү-чая гына кыз белән нидер сөйләшеп алды. Барысы да көлештеләр, кызга бүләк бирделәр, шуннан соң гына кыз ишекне ачып, безне эчкә уздырды.

Кергәч, чәй табыны әзерләнгән өстәл тирәсенә утырыштык. Өстәл тулы өем-өем сый, чирек белән бал да тора... Яшь кәләшне без күрмәдек — ул чыбылдык эчендә утыра иде. Йоласы шулай, күрәсең, кияүне мөгаен чыбылдык-эчендә каршы ала торгандыр... Теге житү кыз безгә зур таба белән кайнар коймак кертеп куйды. (Ул кияү белән кәләшне шушында карау өчен махсус куелган икән. Бәлки әле үзе дә яшь килендер). Егетләр нигәдер ашыгалар иде, коймакны аннан-моннан капкалап, берәр генә чынаяк чәй эчтеләр дә, кияүгә хәер-дога теләп, урыннарыннан тордылар. Без чыгып киттек. Мөхәммәдьяр дәдәкай ни өчендер шактый ук кызарып һәм уңайсызланган төсле дә булып, кәләш янында үзе генә торып калды.

Аннары инде без, кияү егетләре, башка кунакларга кушылып, кыя ягыннан туй күтәрешкән кешеләрнең мәжлесләренә йөри башладык. Арада мин, йоннары күземә кереп торган хәшәрәт бүрекле малай гына булсам да, әйтергә кирәк, мәжлесләрдә игътибардан һәм сый-хөрмәттән бер дә читтә калмадым (чөнки кияүнең «читтән» кайткан якын туганы). Бу самогон заманы иде, ул чакта аны «күмүшкә» диләр иде. Башта руслардан ала торган булганнар, аннары инде үзләре дә «куарга» өйрәнгәннәр. Миңа шул сасы нәрсәне миңа да әз генә эчертеп карадылар. Мин аңардан өтелдем, буылдым, үлә яздым, шуннан соң «тәкъдим» итүче булмады.

Туй кыз ягында ике-өч көн дәвам иткәннән соң, егет өенә кайтты. Хәзер егет ягыннан баручыларга ияреп, кызны озатучы туганнары да килделәр. (Аларны бездә «жиңгәли баручылар» дип әйтәләр)... Кышкы айлы кич иде, түбән очтан югары очка таба кыңгырау тавышлары белән бөтен авылны шаулатып килгән әллә ничә пар ат, ялгыз атлар бабакайлар ихатасына чаптырып ук килеп керделәр. Шул чакта кемдер мылтыктан да атып җибәрде. Каршы алучылар күп иде, кайтып керүчеләрнең күбесе кызмача иде, шуңа күрә буталыш, шау-шу да көчле иде. Кияү атын ишек төбенә үк китерделәр, киленне чанадан ак киез өстенә төшерделәр. Нигъмәтулла дәдәкайның кызы · Зөләйха киленгә кашык белән бал-май каптырды. Икенче, үрәчәле чанада кайткан килен әйберләрен — яшел сандыгын, урын-җирен җырлый-җырлый өйгә керттеләр.

Туй кияү ягында да ике-өч көн барды булса кирәк. Билгеле, бу тарафта да туй күтәрешкән якын туганнар кыз ягын чиратлашып йөртеп, кунак иттеләр. Ләкин мин монда «кияү егете» түгел идем инде, башка балалар белән бергә буталучы малай гына, шуңа күрә безнең тарафтагы мәжлесләрне күрмәдем дә диярлек. Һәм туйның кайчан беткәнен дә ачык кына хәтерләмим. Кияү өендәге соңгы мәжлес тә, «жиңгәли килүчеләрнең» кайтып китүләре дә төнлә булган, ә без, ыгы-зыгыдан тәмам арган бала-чагалар, төрлебез төрле урында йоклап калганбыз.

Әнә шулай үтеп китте Мөхәммәдьяр дәдәкай туе да. Өйдә хәзер яңа кеше — яшь килен. Бусы инде миңа икенче жиңгәчәй — Хәнифә жиңгәчәй була. Ак чырайлы, юка-жиңел генә һәм бик житез дә икән үзе. Ләкин оялчан әле, өй эчендә дә бөркәнчек ябынып, зурлардан битен яшереп йөри. Басынкы, авыр кузгалышлы Мөхәммәдьяр дәдәкайга бик кулай килгән диләр аны... Чынлап та алар соңыннан бер-берсенә ансат кына яраклашып һәм яратышып яшәделәр. Балаларны да күп үстерделәр.

Бу ике дәдәм турында тагын бер вакыйга минем хәтеремдә саклана — форсаттан файдаланып мин шуны да сөйләп үтәсем килә. Шул ук егерменче елның җәе. Мин янә Каргалыда. Кем белән кайтканымны белмим — атакай да, инәй дә янымда юк иде. Ә күргәнем, исемдә калганы менә нәрсә: өйнең зур як түрендә, агач кәнәфидә өч авыл карты һәм алар янында шәльяулык ябынган, укалы камзул кигән әбыкай утыра. Алардан читтә, ишек төбендәрәк Нигъмәтулла белән Мөхәммәдьяр дәдәкай басып кына торалар. Ә мин әбыкай янында аңа елышып кына утырам. Өйдә киеренке тынлык. Бары әбыкай гына ашыкмыйча нидер сөйли, ә картлар алларына караган килеш ара-тирә башларын гына селкеп куялар. Нәрсә турында сүз бара — мин әле белмим, тик бераздан гына төшенеп алдым: әбыкай үзе исән чакта уллары белән кызларына аталарыннан калган мал-мөлкәтне бүлеп бирергә булган икән. Картлар исә менә шушы бик мөһим эштә аңа үзләренең гадел киңәшләре белән ярдәм итәргә тиешләр икән. Шуннан соң бар булган мөлкәтне — ат, сыер, сарык кебек аяклы малларны, абзар, келәт, лапас, мунча кебек каралты-кураларны, ниһаять арба, чана, сбруй һәм шактый күп эш коралларын бүлгәләүгә керештеләр. Башта әбыкай үзе кемгә нәрсә бирергә теләвен әйтә, аннары картлар, үзара әзерәк мәслихәтләшкәннән соң, кыска гына итеп ризалыкларын белдерәләр: «Ярый, аллага тапшырдык, шулай булсын! Игелеккә язсын!» диләр. (Кайчагында сүз озаккарак та сузыла, ләкин гел риза булышу белән бетә)

Кемгә нәрсә тигәнен мин әйтә алмыйм инде, ләкин картлар хөкеме гадел булгандыр, ахрысы, чөнки шунда тыңлап торучы ике туганның берсе дә ризасызлык белдереп сүз әйтмәде. Моңарчы шома гына барды бу эш. Ахырда чират иң төп милеккә — шушы сөйләшеп утырган өйнең үзенә килеп җитте. Монсы инде шома гына узмады. Башта шуны әйтергә кирәк, бу өй 1906—07 елларда гына салынган бик яңа өй иде әле. Бүрәнәләре дә юньләп каралырга өлгермәгән, түбә калае да шул килеш, бер тутыккан җире дә юк. Үзе алты почмаклы өй — зур ягы дүрт стеналы, кече ягы зурысына кушып салынган өч стеналы... Зур (яки түр) якның урамга таба, ә кече якның ишегалдына чыга торган ишек-болдырлары да бар. Менә шул өйне кемгә калдырырга яки ничек итеп бүләргә? Әбыкай әйтә, мин Мөхәммәдьярымда калам, аңарда торачакмын, шуңа күрә зур якны аңа бирәсем килә, ди... Беразга авыр тынлык урнашты, башлап сүзен әйтергә бераү дә ашыкмый иде. Ләкин шул чакта — һич көтелмәгән бер хәл — Нигъмәтулла дәдәкай мич буена чүгәләде дә йөзен ике кулы белән каплап, тавышын ничек тә чыгармаска тырышып, җыларга да тотынды. Бу хәлдән әбыкай да, картлар да бер мәлгә тынып, тәмам аптырашып, югалып калдылар. Ә мине әллә нишләтеп җибәрде дәдәкайның җылавы, әйтерсең, йөрәгемне кемдер кысып тотты, хәтта куркытып та җибәрде. Олы ир кешенең җылавын минем әле бер дә күргәнем юк иде.

Картларның берсе, ниһаять, иплән кенә әйтте аңа: «Нигъмәтулла, нишләвең бу, куй, ярамый! Сүзең булса әйт, әйтергә хакың бар, ә без тыңларбыз, мәслихәтләшербез, шулай булмыйча!» — диде. Шуннан соң Нигъмәтулла дәдәкай бераз тынып торды, азрак тынычлангандай булды, аннары борын очындагы эре яшь бөртеген сыпырып ташлады да, ашыкмыйча тыелып кына сүзен әйтә алды: «Анакай, кәбәм, ни бит... үзең дә беләсең, бу өйне мин иңнәремдә күтәрдем, мин бит бүрәнәләрен үзем кисеп, үзем урманнан ташыдым... Шуның өченмени миңа өч кенә стена?.. Өч атның да икесен Мөхәммәдьярга дидең, сүз әйтмәдем, инде өйдән мәхрүм итмәссең дигән идем, анакай кәбәм!»

Әйе, бик киеренке, авыр бер ара иде бу... Мин Мөхәммәдьяр дәдәкайга карадым — ул ишек төбендәрәк таш сын шикелле басып тора,

йөзе ак, тавышы-тыны юк. Нинди генә хөкем чыгарсалар да алдан ук риза кебек — шундыйрак бер кыяфәт иде аңарда. Әмма иң авыры һичшиксез әбыкайга иде — хәлиткеч сүзне бит ул әйтергә тиеш. Зур улының һич көтмәгәндә йөзен каплап, җылап җибәрүе һәм үпкә катыш әрнеп, ялварып әйткән сүзләре аңа нык тәэсир итте булса кирәк, ничектер кинәт кенә сүнеп-боекланып, тирән уйга калгандай башын да салындырып, күпмедер вакыт сүзсез-өнсез генә утырды. Аннары үз алдына авыр гына бер сулап куйганнан соң, ашыкмыйча әкрен-тыныч кына яңадан сүзен башлады: «Нигъмәтулланың бу өйдә хакы күбрәк икәнен мин белмичә, кем белсен. Дөрес әйтә ул, иңнәрендә күтәрде... Ходай шаһит, улларым икесе дә миңа газизләр... Ләкин мин аларның чамаларын да беләм бит. Нигъмәтуллам, иншалла, өйсез калмас, яңасын салырга да хәленнән килер. Ә Мөхәммәдьярга авыр булачак, төп нигездән аерырга ярамый аны. Юк, Нигъмәтуллам рәнҗи күрмәсен, өйнең зур ягын Мөхәммәдьярга калдырыйк, шуңа сезнең фатиха бирүегезне сорыйм, кардәшләр!»

Билгеле, мин әбыкай сүзләрен 60 елдан соң үземчәрәк яздым, әмма төп мәгънәсе шулай иде дип бер дә икеләнмичә әйтә алам. Әйе, ана кеше төпчек улының мәнфәгатен яклады, чөнки төпчек улы шуңа бик мохтаҗ, хәтта шуның өчен генә ул Мөхәммәдьярында калырга да тели иде. Ләкин картлар бу өй мәсьәләсендә үз хөкемнәрен әйтергә ашыкмадылар. Бер якны да кыерсытырга теләмичә үзара җайлап кына мәслихәтләштеләр... Нигъмәтулла да хаклы, Гаффә (әбыкайның исеме) тутайныкы да дөрес... Ничек итеп аларны килештерергә?.. Аннары мәсьәләнең бу ягы да бар: өйгә төп хуҗа кем? Төп хуҗа, әле үзе исән чагында, аналары инде. Димәк, аның ихтыяры беренче нәүбәттә искә алынырга тиеш. Шулайрак фикер йөрттеләр картлар һәм ахырда өйнең зур ягын Мөхәммәдьярга калдыруны тиеш таптылар. Ләкин шуның белән бергә Нигъмәтулла дәдәкайны юатып та үгетләп тә әйттеләр: «Син, Нигъмәтулла, Мөхәммәдьяр түгел, син бөтенләй башка. Өч стенаны бик тиз дүрт тә итәрсең, теләсәң, алты почмаклысын да булдырырсың, еллар гына имин торсын. Бу дөньяда бөтен нәрсә фани — кешенең малы да, җаны да, тик аңа карап, арагыз бозылмасын, бер-берегезгә терәк булып тату гына яшәгез... Ә син, Мөхәммәдьяр, мал кадерен бел, әрәм-шәрәм итмә, бетерүе ансат булса да, табулары читен... Атагыз, мәрхүм, нәселегездә хөрмәткә ия бер зат кеше иде, анагыз, Гаффә тутай, ил каршында абруйлы бер карчык — аның хәер-догасын алып калырга тырышыгыз!» — диделәр. Ике бертуган бу нәсихәтне баш иеп кенә тыңладылар, күңелләрендә ни булгандыр — икесенең берсе дә авыз ачып, сүз әйтмәделәр. Шуннан соң барысы да кул күтәреп, озын гына дога кылдылар.

Әнә шулай уелып калды бу вакыйга минем хәтеремдә. Күп нәрсәләр онытылды, әмма ни хикмәттер, бусы миңа онытылмады. Бәлки Нигъмәтулла дәдәкайның чүгәләп җылавы яки әбыкайның хәсрәтле уйчан йөзе моңа сәбәптер — хәзер инде моны аңлавы да һәм аңлатуы да бик читен. Һәрхәлдә бала чактагы аңсыз, әмма сизгер күңел эше бу — күргәннәрдән нәрсәнедер шунда ук ташлаган, ә нәрсәнедер бабай булгач та онытма дип саклаган.

Биредә тагын шуны өстәп әйтәсем килә, минем атакай мал бүлешкәндә өлешкә керүдән баш тарткан икән. Сәбәбен әйтә алмыйм, бәлки сугыш елларында болай да бик нык какшаган хуҗалыкны таратып, авылдагы туганнарын артык зәгыйфьләндермәс өчендер, ә бәлки андагы хуҗалыкка күптән катнашы булмаганга һәм күчә кермәгәнгә күрәдер... Соңгысы дөресрәктер дип уйлыйм. Шулай да атакайга бер тарантас тигән иде шикелле, ләкин атыбыз булмагач, ул тарантас та Дәүләкәнгә кайтмады.

Бу вакыйгадан соң бер ел үтүгә әбыкай бездә ваба авыруыннан вафат булды. Яшәрлеге бар иде әле, безнең үсә төшкәнне дә күрәсе килә иде. Ләкин, үзе әйтмешли, язмыштан узмыш юк. Шулай да бу фани дөньядан аерылганда җаны тыныч булгандыр диясе килә, чөнки балалары алдында ул үзенең соңгы бурычын да үтәп китте.

Ул җәйне искиткеч корылык иде, бөтен нәрсә янды-көйде һәм артыннан егерме беренче елның коточкыч ачлыгы да килде. Бу хакта мин вакыты җиткәч сөйләрмен әле, хәзер исә шуны гына әйтәсем килә: ачлык елны без Каргалыга кайтып йөрмәдек, шулай ук Каргалының үзеннән дә килүчеләр булмады кебек... Шуңадыр инде мин андагы туганнарның бу афәтле елны ничек үткәреп җибәрүләрен белмим диярлек. Әлбәттә, җиңел булмагандыр, интеккәндер, бәлки ачыкканнардыр да, чөнки җир, бичара, чәчкән орлыкны да кайтарып бирмәде (Ярый, алабутасы булды әле). Бигрәк тә Мөхәммәдьяр дәдәкайга бик авырга килгәндер, бәхетсезлегенә каршы, бүлешкәндә тигән ике атның берсе нишләптер зыянлаган да булган. Шулай да алар ачлык тырнагыннан исән-имин котылганнар иде.

Минем яңадан Каргалыга кайта башлавым я егерме икенче, я егерме өченче елга туры киләдер ахрысы... Ләкин соңрак шуны яхшы беләм, әлеге төп йортта Нигъмәтулла дәдәкай үзе генә тора иде инде. Ике тәкә башы бер казанга сыймый дигәндәй, күрәсең, ике гаилә дә бер өйгә сыя алмаган. Ничек кенә булмасын, ике брат үзара килешкәннәр дә, Нигъмәтулла дәдәкай зиярат буендагы урамнан буш урын алып, шунда Мөхәммәдьяр дәдәкай өчен бүрәнәдән, салам белән япкан, җыйнак кына ызба торгызган. Янә өстәп бер ат та биргән. Шулай итеп бер-берсеннән бик нык аерылган ике туган ике җирдә һәм ике йортта яши башлаганнар. Ихтимал, бу икесе өчен дә хәерлерәк булгандыр.

Мин инде кайтканда, билгеле, гел төп йортка кайта торган идем. Чөнки бу әбыкайдан калган йорт, сабый чактан ук мине шунда алып кайтканнар... Бөтен истәлекләрем дә бары шул төп йорт белән бәйләнгән. Күптән нигезе бетерелсә дә мин аны онытканым юк һәм яңадан йөз ел яшәсәм дә онытмам дип уйлыйм.

Хәзер миңа атакайның ике сеңелесе турында да, кыскача гына булса да, сөйләргә кирәктер инде. Болар Рокыя тутакай белән Срур тутакай. Иң гаҗәбе шул, болар да ике бертуган братлары шикелле үк бер-берсеннән бик нык аерылалар иде. Бөтен яктан да. Рокыя тутакай табигате белән бик тыйнак, юаш, чынлап ачулана да, зарлана да белми торган, азга да канәгать, аздан да сөенә торган, бик саф күңелле һәм туган җанлы кеше иде. Гәүдәгә дә чебеш кебек юка-ябык кына, шулай саклана ул минем күз алдымда... Ә Срур тутакай бөтенләй башка. Ул чибәр, сылу, үткер, яшьтән үк бик зиһенле, ирләрдә булмаган акыл үзендә, сүзе һәм тотышы белән кешене үзенә карата белә. Җырга, музыкага сәләтле, хәтта артистлык кабилияте дә бар аңарда. Кыскасы, гранд-дама!.. Хәзер Срур тутакайга сиксән алты яшь, ә хәтеренә һәм ачык зиһененә исең китәр... Алар арасындагы аерма тагын шуннан гыйбарәт. Рокыя тутакай укымыйча калган яки бик аз укыган, ә Срур тутакай үз теләге белән Уфага китеп пансионатта торып укыган, хәтта күпмедер вакыт Петербургта да булып кайткан. Укуын бетергәч, Каргалыга кайтып, учительница булган — балаларны русча укыткан. (Шуңа күрә «мөгаллимә» димим.) Әйе, ул үз заманының белемле һәм алдынгы туташы. Аңа мондый юллар ачылуның, минемчә, ике сәбәбе бар: беренчедән, аның яшьлеге 1905 елдан соң татар дөньясында башланган уяну, күтәрелү, мәгърифәткә омтылу чорына туры килә (ә безнең Каргалы кешеләренә укуга омтылу элек тән үк хас нәрсә), икенчедән, ул туганнары арасында иң кечесе, төпчек кыз, җитмәсә, характеры да заманча тәвәккәл-кыю, шуңа күрәдер инде аның

теләгенә каршы төшәргә базмаганнар. (Ә минем атакай исә аның укырга омтылуын һәрвакытта яклап килгән — моны Срур тутакай үзе әйтә)... Кыскасы, Срур туташның тормыш юлы бәхетле һәм матур башлана.

Ләкин инде Рокыя тутакайның тормышы бөтенләй икенче юлдан китә. Иң элек аны яшьли генә Ибәтулла исемле җизнәсенә кияүгә бирәләр. Эш шунда ки, Ибәтулла җизни башта әбыкайларның дәү кызы Зөләйха тутакайга өйләнгән була. Ләкин бәхетсезлеккә каршы, Зөләйха тутакай беренче баладан ук үлеп тә китә. Үзе дә, сабые да... (Аның исемен соңыннан Нигъмәтулла дәдәкайның беренче кызына кушалар.) Менә шуннан соң, безнең татардагы гадәт буенча, тол калган җизнигә балдызын бирәләр... Ибәтулла җизни өйләнгәч тә Рокыя тутакайны Уфага алып китә һәм алар шунда әйбәт кенә тора да башлыйлар. Әмма ләкин бәхет дигәнең бер килмәсә-килми икән ул, яки килсә дә, күзгә кояштай, бик тиз югала икән. Инде менә Ибәтулла җизнинең үзенә әҗәл чире эләгә — астыртын усал яман шеш чыга аның муенына. Өмит аз, котылу чарасы юк диярлек (хәзер дә юк әле ул), җизнинең хәле көннән-көн начарлана бара. Ахырда аны Каргалыга алып кайталар. Күпмедер вакыт аталары өендә ятканнан соң, 1917 елның январь башында, әйтергә кирәк, көтелмәгән бер чактарак, Ибәтулла җизни ниһаять җан бирә. Кырыкка да җитмәгән тап-таза кеше!

Көтелмәгән чактарак дидем. Әйе, гаҗәеп бер хәл! Язмышның мәкерле шуклыгы димме, ничек итеп аңлатырга да белмим, ләкин Ибәтулла җизнинең үлүе... нәкъ менә Срур тутакайга никах укыткан көнгә туры килгән икән. Хәзрәтләр никах мәҗлесеннән чыгып, җеназа укырга киткәннәр. Шулай итеп, бабакайлар өенә зур шатлык тирән кайгы белән бергә, бер үк көнне җитәкләшеп кергән... Хәер, моны әйтүе генә ансат.

Мин үзем, гәрчә туйга кайткан булсак та, бу хәлне һич тә хәтерләмим. Җиде яшьлек бала гына идем әле мин... Аннары кыш үзәге, бик салкын чак, Ибәтулла җизни, әйткәнемчә, аталарында вафат, гәүдәсен дә шуннан алып чыкканнар, билгеле, безнең ише җылы өйдә утыручы вак бала-чаганың бер нәрсә белмичә калуы гаҗәп тә түгел... Бары күп еллар узгач кына Мәдинә җиңгәчәй миңа бу хакта сөйләде. Хәйран калып һәм аптырап мин, ничек булды соң ул, ник туйны кичектермәделәр икән дип сорагач, җиңгәчәй болай диебрәк аңлатты: әҗәлнең көнен-сәгатен алдан белеп булмый шул, ә туй көне Срурның каникул вакытына туры китереп, алдан ук билгеләнгән иде. Ашсулар әзерләнгән, кунаклар чакырылган, хәзрәтләргә әйтелгән, инде тәгаенләнгән көне килеп җиткәч кенә аны ничек үзгәртәсең?.. Бик читен эш бит ул, туй хәтле туйны кичектерүе... Алланың язганы шулдыр инде, ахыры хәерле була күрсен диделәр дә никаһны укытырга булдылар. Шатлыгы, кайгысы бергә узды шулай итеп.

Рокыя тутакай Ибәтулла җизнидән берсеннән-берсе кечерәк өч бала белән кала. Әлбәттә, кайгы баштан ашкан... һәм минем шушы урында Ибәтулла җизни турында кайбер ишетеп белгәннәремне әйтеп үтәсем килә. Ишеткәннәрем исә түбәндәгедән гыйбарәт: Ибәтулла Тèresгулов моряк булган, хәрби флотта хезмәт иткән, япон сугышында катнашкан. Минем тутакайларга (башта Зөләйхага, аннары Рокыяга) әнә шул компаниядән кайткач өйләнгән икән. Яхшы ук грамоталы да булган ул.

Срур тутакайның сөйләвенә караганда, Ибәтулла җизни подпольедагы революционерлар белән бәйләнеш тоткан имеш. Моның әсасы менә нидән гыйбарәт: Уфа губернаторының канцеляриясендә җизнинең авылдашы Әхмәтсолтан Терегулов дигән кеше хезмәт иткән. Бу инде

укыган кеше, статский советник, губернатор канцеляриясендә зур гына урын биләгән булса кирәк. Мәсәлән, Уфаның татар яшьләре спектакль яки концерт куяр өчен рөхсәтне губернатордан еш кына аның ярдәме белән алганнар. (Монысын миңа Хәсән Гобәйдуллин сөйләгән иде). Һәм шушы кеше, ягъни Әхмәтсолтан Терегулов, Уфа социал-демократлары белән яшерен бәйләнештә торган имеш. Цюрупа һәм Брюханов кебек күренекле большевиклар белән шәхси таныш та булган диләр. Билгеле инде, губернатор чиновнигы белән подпольедагы социал-демократларның бәйләнеше ниндидер бер максатка хезмәт иткән булырга тиеш. Кыскасы, алар Әхмәтсолтан Терегуловтан үзләрен кызыксындырган мәгълүматларны алып торганнар булса кирәк. (Шундый сүз дә бар: революционерларга берәр төрле куркыныч туа башласа, Терегулов аларга шуны алдан хәбәр итә икән). Ләкин бу хәтәр эштә кемдер аша элемтә тотарга кирәк булгандыр бит, чөнки губернатор чиновнигы үзе турыдан-туры бәйләнешкә керә алмагандыр инде. Һәм менә безнең жизни, Ибәтулла Терегулов, Әхмәтсолтанга якын кеше, әнә шул элемтәче ролен үтәгән дә имеш. Моның дөрес булуына дәлил итебрәк, Срур тутакай шундый бер кызыклы гына факт та китергән иде: Ибәтулла жизни төрле сылтау белән бер ел эчендә генә ундүрт мәртәбә тора торган фатирын алыштырган булган. Ни өчен?.. Билгеле, конспирация өчендер инде... Әлбәттә, болар барысы да сүз генә, кулыбызда бер төрле дә документ юк, ләкин бит кайчагында сүзнең дә ниндидер нигезе була. Мәсәлән, Әхмәтсолтан Терегулов революциядән соң да Уфада кала һәм совет органнарында хезмәт итә. Тазартулар вакытында да аңа тимиләр. Элеккеге патша чиновнигы булса да! Бу бит инде юкка гына түгелдер.

Ә безнең жизнигә килгәндә, ул япон сугышын күргән, хәрби флоттан кайткан кеше, димәк, аның күпмедер дәрәҗәдә революция рухы белән сугарылган булуы бик табигый. Андый кешеләр аз булганмыни ул заманда.

Жизнидән калган өч бала үсеп җитәләр, кеше булалар, тик Рокыя тутакайга тагын да бер зур хәсрәт кичерергә туры килә — бердәнбер улы Әнвәр Ватан сугышында һәлак була. Чыдамлыгына исең китәр! Әнвәр турында сүз чыкканда мин аның елаганын бер вакытта да күрмәдем. Тик шунда сүзсез генә елмая биреп утыра — әллә хәсрәтен яшерә, әллә Әнвәрен күз алдына китерә... Шулай зарланмыйча, сыкранмыйча гына үлеп тә китте ул... Ә калган икесе, Рауза белән Ләйлә, исәннәр. Болар минем иң яраткан туганнарым. Алар үзләре дә бик туган җанлылар. Бигрәк тә Рауза! Сугыш аркасында утырып калганга күрәмедер, бөтен игътибары-кайгысы аның туганнарына күчте.

Инде яңадан туй хәлләренә килсәк, минем, дөресен генә әйткәндә, искә төшерерлек нәрсәм юк диярлек. Туйда, үзегез беләсез, өй тулы кеше, ыгы-зыгы, шау-шу — кая монда җиде яшьлек малайга барысын да күреп бетерергә?! Тик бер нәрсә хәтеремдә ачык саклана: Срур тутакайны кияү йортына аллы-артлы ике ат җигелгән ябык повозкада алып киттеләр. Эченә кереп утыра торган мондый чананы минем беренче күрүем, ихтимал шунадыр ул онытылмыйча сакланган да. Хәер, тагын бер нәрсәне әзрәк хәтерлим әле: бу — бай Гали йорты, чардаклы, яшел түбәле, авылда бер шәп, матур йорт. Срур тутакайны менә шул йортка китереп төшерделәр, чөнки жизни тиешле кеше шушында фатирда тора иде. Эчендәге бүлмәләренең ике якка ачылмалы биек, ап-ак ишекләре әле дә булса күз алдымда. Зур якты зал, бик күп кунаклар, өзлексез җыр-музыка, ләкин болар барысы да төштә генә кебек, хәтта мәҗлес хуҗасы жизнинең үзен дә ачык кына хәтерләмим. Бусы гаҗәбрәк тә инде, чөнки никадәр бала булсам да жизни дигән затны мин аера, күрә белергә тиеш идем. Ә бәлки аерган-күргән бул-

сам да күптән оныткандыр — алтмыш өч ел узып китте бит ул туйдан соң!

Әмма мин, тора-бара, әкренләп күрдем, белдем, таныдым бу яңа җизнине, һәм озак еллар дәвамында ул минем иң нык хөрмәт иткән кешем булып калды. Кем иде соң ул минем җизнәм?.. Иң элек шуны әйтергә кирәк, ул Каргалы кешесе түгел, читтән килеп, күпмедер торып, шунда гына Срур тутакай белән танышып, аңа өйләнгән кеше иде. Исем-фамилиясе аның — Шәрифҗан Хәмидулла улы Сүнчәләев. Тарихта күбрәк Шәриф Сүнчәләй исеме белән билгеле шәхес. Шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйнең бертуган агасы. Казандагы учительская школаны бетергән үз заманының укымышлы, алдынгы бер кешесе. 1917—18 елларда революция вакыйгаларына якыннан катнашкан, Уфада Галимҗан Ибраһимов белән бергә «Ирек» газетасын чыгарышкан, Уфа губернасыннан Учредительный собраниегә депутат булып сайланган, Октябрь революциясеннән соң, Башкортстан республикасы төзелгәч, андагы мәгариф эшләре белән җитәкчелек иткән, егерменче елдан коммунист, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе... Уфада аның исеме белән аталган урам да бар.

Шәриф Сүнчәләй турында төгәлрәк һәм тулырак мәгълүматны Риза Ишморат истәлекләреннән алырга була — Риза аның шәкерте, миңа караганда да ул аны күптәнрәк һәм күбрәк белә. Минем исә күңелемдә ныграк, тирәнрәк сакланганы — Шәриф җизнинең саф кешелек сыйфатлары. Әмма ничек кенә итеп аңлатырга моны? Ул тыныч, сабыр кеше иде, ул бик мөлаем һәм тыйнак кеше иде, тавышы да йомшак, кешегә мөгамәләсе дә йомшак иде. Үзе озын гына буйлы, какча гына кеше иде, бик пөхтә киенеп, гел чиста кырынып йөри иде. Болары тышкы яклары, ә эчке яктан ул үтә әдәпле, инсафлы, нәзакәтле — кыскасы, аңарда гүя тумыштан ук килгән үзенә бер күркәм затлылык бар иде. Ирексездән сокландыра, хөрмәт кузгата торган мондый затлылык гадәттә иске интеллигентларда күбрәк очрый. Ул да чын мәгънәсендә интеллигент иде — бөтен яктан да! Ихтимал, шуңа күрәдер, мин Шәриф җизнине үзем өчен үрнәк бер кеше итеп саный идем. Дөрес, аңа охшарга, аның төсле булырга тырышмадым, чөнки бу кадәресе кулымнан килмәс иде (һәм табигатемә дә сыймас иде), әмма җизнәмнең күркәм кыяфәте һәм чын кешелек сыйфатлары мине бозылып китүдән, түбән тәгәрәүдән ничектер тыеп килде. Ә андый куркыныч, яшерә алмыйм, минем тормышымда булгалады.

Бу урында кайберәүләр ниндидер бер шәрехләү кирәклеген сизәм, югыйсә кайберәүләрнең җизнәмне артык мактап ташладың дип әйтүләре мөмкин. Ләкин хикмәт мактауда түгел, һәм андый теләгем дә юк минем. Хикмәт шунда ки, Шәриф Сүнчәләй һәм аның замандашлары үткән гасырның ахырында туып, бу гасырның башында, дөресрәге ике революция арасында җитешкән кешеләр. Алар шул чорның азатлык рухы белән сугарылып, бик нык белем-мәгърифәткә омтылган һәм халыкка хезмәт итү максаты белән янган кешеләр. Һәм шушы хәл аларның идеалларын да, кешелек сыйфатларын да билгеләгән булса кирәк. Мәсәлән, Шәриф Сүнчәләйнең яки башка берәрсенең идеалы хөрлек икән, ул аны үз иркен сөю генә түгел, бүтәннәр иркен дә таныган, хөрмәт иткән, әгәр ул кешеләр арасында гаделлек булуын тели икән, иң элек үзе гадел булырга тырышкан һәм башкалардан да шуны көткән. Кыскасы, идеал белән гамәлне алар бер дип белгәннәр, аерып йөртмәгәннәр. Я, бу һәр заманда, һәрбер кеше өчен дә шулай булырга тиеш түгелмени?! Күрәсез, бер нинди арттыру, мактау юк монда.

...Фәлсәфә күпкәрәк китте, кире артка чигеник әле булмаса... Каргалыда туй үтеп киткәч, бер-ике айдан соң яшьләр өчәүләшеп, ягъни җизни белән Срур тутакай һәм җизнинең энесе Сәгыйть кода (Сәгыйть Сүнчәләй) Уфадан безгә, Дәүләкәнгә кунакка килделәр. Март

урталары иде шикелле, карлар эреп, ерганаклар юл ала башлаган кояшлы көннәр иде. Кунаклар хөрмәтенә бездә зур мәҗлес уздырылды. (Ул чакта безнең үз йортыбыз юк иде әле, арендага алган өч бүлмәле чибәр генә йортта тора идек). Мәҗлескә Дәүләкәннең мөхтәрәм кешеләре чакырылган иде. Заманның мәгълүм ике зыялысы, ике яшь, чибәр егет, икесе дә тройка костюмнан, кара кәләпүшләрдән, берсе, җизни тиешлесе, гармунда, икенчесе, кода тиешлесе, скрипкада өздереп уйныйлар. Әйтәсе дә түгел, алар үзләренең бөтен килеш-килбәтләре, тотыш-торышлары һәм уеннары белән мәҗлес кунакларын тәмам әсир иткән, тангга калдырган булырга тиешләр. Мин моны көнендә генә белеп бетермәсәм дә соңыннан ул мәҗлесне һаман искә төшереп сөйләгәннәрен күп ишеттем. Күрәсең, бу мәҗлес атакайның да дәрәҗәсен күтәреп җибәргәндер — кияве кем дә кодасы кем!

Әмма минем өчен иң истәлекле нәрсә — Сәгайть абыйның бүләк итеп биргән ике китабы булды. Мин әле мәктәпкә йөрми идем, хәреф-мазар да танымый идем, шулай да бу китапларга бик сөендем. Икесе дә катыргы тышлы, эчендәге битләре шоп-шома, хәрефләре дә эре-ачык һәм бит саен диярлек буяулы рәсем... Миңа әйтеп бирделәр: бусы «Су анасы», ә бусы «Борчак патша», язу танырач укырсың, диделәр... Язу танырач! Бу бит тиз түгел, мәктәпкә йөри башлагач кына, ә менә минем хәзердән үк беләсем килә: кем ул түбәтәйле малай, озын чәчле, шөкәтсез карчыгы кем тагын, ни өчен ул куркыныч карчык малайны куып бара?.. Ахырда көн саен шул китапларны карый торгач, атакай ярдәме белән булса кирәк, мин әкренләп кенә хәрефләрне аера, таный башладым, анмары тора-бара хәрефләрдән әз-әзләп сүзләр дә оештырырга өйрәндем... Ул китапларны ничәмә тапкыр «сукалап» чыгуымны әйтә алмыйм, ләкин көз җитеп, беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап кергәндә мин инде ташка басканны шактый ук «сөрә» белә идем. Шулай итеп, Сәгыйть Сүнчәләй үз кулы белән миңа «тел ачкычы» биреп китте.

Туганнар һәм туйлар турында җитеп торыр булмаса. Хәер, тагын бер туйны әйтеп кенә үтү кирәктер ахрысы. Бу — Абзан туе. Нигъмәтулла дәдәкәй шул авылга мине кучергә утыртып, балдызы туена алып барган иде. Миңа инде җиде яшь түгел, ундүрт яшь иде. Бәлки шуңа күрәдер, ә бәлки җәйнең бик матур чәчәкле вакытында һәм илнең дә тук, тыныч, имин чагында булып узганга күрәдер, ул туй минем күңелемдә гомергә онытылмаслык якты, тирән бер эз калдырды. Күп еллардан соң мин Абзан туенда күргән һәм кичергәннәремне «Җиз кыңгырау» исемле хикәямдә тасвир да иткән идем. Ә кара дугага асып барган җиз кыңгырау үзе әле дә булса миндә саклана.

Тагын нәрсә? Беттеме-юкмы? Үзем менә бик озынга китә түгелме дип борчылам да, кыска да буласым килә, ләкин шуңа карамастан, туктала да алмыйм: башлаган сүзне ничектер ахрына кадәр җиткерергә кирәк. Әйтик, шул ук туганнар турында... Әйе, аларның язмышлары да һәм гомерләре дә төрлечә булды. (Бу табигый хәл, кешеләр төрле вакытта туган шикелле, төрле вакытта дөньядан да китәләр). Атакай белән Рокыя тутакай шактый картаеп, үз түшәкләрендә, үз әҗәлләре белән үлделәр. Сөрур тутакай, шөкер, яши әле, һәм яшәр дә кебек, чөнки ул нык кеше, үзен карый да белә, яши дә белә. Ә менә Мөхәммәдьяр белән Нигъмәтулла дәдәкайның гомерләре шактый иртә өзелде. Фаҗигале рәвештә... Мөхәммәдьяр дәдәкайны сугыш вакытында хезмәт армиясенә алып, Уралга җибәргән булганнар — ул шуннан кайтмады. Әйтергә кирәк, авылына кайтып барган җиреннән югала ул. Вакыйга болайрак була: кырык дүртенче елның көзендә (шулай истә калган) минем атакай белән Мөхәммәдьяр дәдәкай һич уйламаган-көтмәгәндә Свердловск вокзалында очрашалар. Атакай Куандыкта торучы Кәримә тутакай кызлары җибәргән «вызов» буенча шунда китеп бара, ә Мөхәм-

мәдъяр дәдәкайның авыру сәбәпле хезмәт армиясеннән азат ителеп, өенә кайтып баруы икән. Ике бер туган бу очрашудан, билгеле, куаналар да, гаҗәпләнәләр дә һәм төрле яктан килеп тыгылган халык белән шыгрым тулы вокзалда күпмедер вакыт бергә дә булалар. Атакайның әйтүенә караганда, Мөхәммәдъяр дәдәкай бик бетешкән булган, өсте дә сәләмә, ашарына да юк икән. Вокзал каршындагы кечкенә базардан атакай ана, ничәдер йөз сумга, бер кирпеч икмәк тә алып биргән... Мөхәммәдъяр дәдәкайга кирәкле поезд алданрак килә, һәм ул кадерле «кирпечен» салган киндер капчыгын кулына урап тоткан килеш шул поездның бер тамбурына көчкә-хәлгә эләгеп, китеп тә бара... Һәм шул китүдән гаеп — өенә кайтып җитми. Ни булган, берәр бәхетсезлеккә юлыкканмы, юлда-мазар үлеп калганмы? — белүче дә юк, күрүче дә юк һәм бер кайдан бер нинди хәбәр дә юк. Олы кеше су төбенә киткән таш кисәгедәй юкка чыга да куя. Соңыннан, бу бик сәер-серле хәлне искә төшереп юраган чакта, атакай әйтә торган иде: шул бер кирпеч икмәге башына җитмәде микән бичараның? Ачлар, явызлар күп иде, бәлки шундыйларның берәрсе икмәген тартып алып, үзен поездан бәреп төшергәндер, авыру кешегә күпме генә кирәк соң?! — ди иде. Хәер, югалган кеше турында төрлесен юрарга була, әмма чын дөресен генә белеп булмый бер кайчан да.

Нигъмәтулла дәдәкайның язмышы тагы да аянычрак, тагы да фаҗигалерәк... Бусы инде колхозлашу елларында булган эш. Ул елларның гаять катлаулы вакыйгаларын, үтә кискен көрәшен сөйләп тору кирәк микән? Тарихтан һәм әдәбияттан без моны яхшы беләбез. Тик шуны гына әйтү кирәктер ахрысы, авыл җирендә бу вакыйгалардан читтән калган, бу көрәшнең кискен җиле тимәгән кеше юктыр, булмагандыр ул чакта. Менә Нигъмәтулла дәдәкайга да тия ул, әмма ничек итеп?

1930 елның октябренда аны авыл советына чакырып алалар. Моннан, сине волостька чакырдылар дип, Бүздәккә алып китәләр. Ә Бүздәктән Уфага озаталар. Һәм шул китүдән инде ул кайтмый — югала. Сәбәбе билгесез. Тагын юрарга гына кала. Кеше бит өеннән үз аягы белән чыгып китә, берни белмичә!.. Хатыны Мәдинә җиңгәчәйнең әйтүенә караганда, Нигъмәтулла дәдәкай ялган әләк корбаны булырга тиеш. Чынлап та ул бит авылның бер бае яки кулагы түгел иде, гади бер середняк! Әмма бик тынгысыз вакыт, хәлләр киеренке, көрәш кискен, мондый чакта берәүнең үчлек белән чагуы да кешене харап итәргә мөмкин. Һәм ул кеше үзе дә дәдәкай төсле кызу канлы бер адәм булса?!.. Андыйга үчләр һәрвакытта табыла. Кызганычка каршы, аның ише хәлләр булгалады ул чакларда.

Хәтерлисездер аның җырын: «Утырдым ла көймәнең ай түренә...» Тукта, мин әйттем микән — юк микән, Нигъмәтулла дәдәкай пленнан качкач, төшендә уникe кыр казы күргән. Нәкъ унике ел торып кала ул туган иленә үзенең гаиләсе белән... «Югалган» чагында иллегә дә җитмәгән иде әле, типсә-тимер өзәрлек тынгы белмәс... дәдәкай!..

Аңардан дүрт бала калды — икесе кыз, икесе ир бала. Баш баласы Зөләйха атасы югалганда җиткән кыз иде инде. Калган өчесе аталары пленнан кайткач туган балалар. Арада зурысы — Бибинур, ә кечеләре Идюк (Идиятулла) белән Шамил; Идюк олырак, ә Шамиле атасыннан аерылганда кулда гына була әле. Мин инде бу балаларның нинди хәлдә калуларын, нинди газап-нужа кичерүләрен тәфсилләп язып тормыйм, чөнки тәфсилләп тормыйча да укучы моны күз алдына китерә алачак дип ышанам. Тик шулай да аларның язмышлары турында кыскача гына әйтеп китмичә булмас ахрысы.

Зөләйха атасын алып киткәндә Каргалыда булмый — Уфада укып йөргән чагына туры килә бу көтелмәгән хәл. Ләкин ел саен ул каникул

вакытларында авылга кайтып, җәйге кыр эшләрендә атасына гел генә булышып, шул ук вакытта авыл яшьләре белән бергә спектакльләр, концертлар куюда якыннан катнашып йөри. Әйтергә кирәк, ул авылның күзгә бәрелеп торган бер чибәре иде. Йөзе-бите, буе-сыны ди сеңме — бер генә дә килмәгән җире юк иде аның. Шуның өстенә табигать аны башка әйбәт сыйфатлардан да мәхрүм итмәгән: атасы кебек бик матур җырлый ул, пианинода шактый ук оста уйный (Уфада Срур тутакайларда торган чагында үзлегеннән өйрәнгән), янә килеп акыл-зиһен, үзен тота белү җәһәтеннән дә күпләрдән аерылып тора. Бәлки беркадәр тәкәбберлеге булгандыр, ләкин үз бәясен белгән кайсы гына кызда юк ул?! Билгеле инде, мондый кызга күз атучылар күп габыла. Каргалының үзләренә артык нык ышанган кайбер актив егетләре дә Зөләйха артыннан бик «чирттереп» карыйлар. Әмма юк, Зөләйха аларның һәркайсын ике дә уйламыйча кире кага. Менә шул чакта «егетлеге» кыерсытылган кайберәүләр тарафыннан аңа карата: «Татыра[1] кызы! Борыныңны бик күтәрмә, соңыннан үкенергә туры килмәсен!» дигән төслерәк янаулар да була. Һәм озак та үтми Зөләйхада, бик табигый рәвештә, атасына килгән һәлакәт шул янаулар нәтиҗәсе түгелме икән дигән шик тә туа. Шик бер дә нигезсез түгел, чөнки вакыты шундый, аннары кире кагылган кешенең үч алырга яратуы да күптән мәгълүм нәрсә, тик менә яшерен эшләнгәнлектән аны тәгаен белүе дә фаш итүе генә бик читен.

Әлбәттә, бу көтелмәгән коточкыч бәхетсезлектән Зөләйха ниләр кичергәнен бары үзе генә белә. Әмма ул барысына да түзә, барысын да күтәрә. Башкача мөмкин түгел, таш белән бастырып куйсалар да ничек тә изелмичә чыгарга кирәк. Авылга кайтып тормый, Мәскәүгә Срур тутакайларга барып сыена, ә бераздан аспирантурада укучы безгә кардәш тиешле Шәрәфетдин Еникеевка кияүгә дә чыга. Башта алар Оренбургка китәләр, анда берничә ел торганнан соң Алма-Атага күчәләр. Ике баласы булуга карамастан, Зөләйха өзелгән укуын дәвам иттереп, институт тәмамлый. Шул рәвешчә Шәрәфетдин казакъ университетында математика кафедрасы мөдире булып, ә Зөләйха педагогия институтында казакъ яшьләренә рус теле һәм әдәбияты укытып, Алма-Атада тыныч-матур гына яшиләр., Билгеле, ул тегендә — «Каргалыкай буенда» калган инәсе белән энеләрен дә онытмый, аларга өзлексез ярдәм итеп тора, ә сугыш алдыннан барысын да үз янына, Алма-Атага китерә. Асылда ул, Зөләйха һәм Шәрәфетдин ике малайны «баздан» көн яктысына чыгарып, аякка бастыралар. Әйе, Шәрәфетдиннең Нигъмәтулла дәдәкай балаларына күрсәткән изгелеген һич тә онытырлык түгел. Алма-Атага китергәч, җиңгәчәйгә бер кечкенә, бакчалы өй алып бирәләр, һәм ул шунда булачак егетләре белән тыныч кына яши башлый. Аңарчы әле Бибинур, апасында торып, туташ булып житешә, институт бетерә һәм кияүгә дә чыга... Күпме мондый язмышлар безнең халыкта!

Бибинурның сугыш вакытында күргәннәре үзе бер тарих. Ләкин читкә тайпыласы килми — белешмә рәвешендә генә әйтеп китәргә туры килә. Бибинурның ире кызыл командир, сугыш башланганда алар ил чигендә торалар. Июнь таңында фашистларның беренче бомбалары алар өстенә ява. Бибинур, күкрәк баласын алып, ут астыннан котылып чыга, ә ире ил чиген саклап кала һәм шунда һәлак та була. Озын чигенү-качу юлы, күпме куркыныч мажаралы хәлләргә юлыгу, инде беттек дигәндә генә билгесез, әмма изге күңелле кешеләр ярдәмендә котылып калу — баласын күкрәгенә кыскан яшь ана шуларның барысын да үз башыннан кичерә.

---

[1] Татыра — Нигъмәтулла дәдәкайның кушаматы.

...Сугыш бетә, яралар әкренләп төзәлә, исәннәр һаман яши бирә. Бибинур да Казагыстанның Талдыкурган өлкәсендәге бер район мәктәбендә озак еллар казакъ һәм уйгур балаларын укытып тора. Шунда әкренләп үзенә йорт кора, хуҗалыгын булдыра, ут астыннан алып чыккан малаен үстерә, Ташкентка җибәреп вуз бетертә — әлхасил, бер эзгә төшкән тормыш үз җае белән һаман алга таба тәгәрәмәктә (искечә әйтсәк). Хәзер инде Бибинур пенсиядә, яңадан иргә чыкмады ул, гомерен уздырган җирдән һәм мәктәбеннән читкә китмичә, шунда хөрмәт казанган карт мөгаллимә булып, ялгызы тыныч кына яшәмәктә. Ачы язмышның ахыры әнә шундый, рөхсәт итсәгез, бәхетле дияргә дә ярый.

Идюк белән Шамилне утыз өченче елның салкын кышында миңа бер кайтып күрергә туры килгән иде. Бу вакытта бабакайлар йорты юк иде инде, каралтылардан бушаган зур ихата да хәзер ак ялан булып ята, тик шуның бер читендә кардан чыгып торган нечкә генә кара морҗа күренә. Тар гына сукмактан мин шуңа таба киттем. Бу — бер землянка икән. Траншея кебек аралыктан төшеп, нелеп кенә такта ишеген ачып кердем. Эчендә учак та казан, кечкенә бер сәке һәм түшәменә үк терәтеп уелган бәләкәй генә тәрәзә — шуннан көн яктысы төшеп тора... Сәкедә киндер күлмәк-ыштаннан, ялан баш ике малай утыра, инәләре юк, каядыр чыккан ахрысы. Мин малайларга дәшәм — җавап бирмиләр, «инәгез кайда» дип сорыйм, юк, дәшмиләр; «мин бит абыегыз булам, дәдәгез...» дип тә карыйм, барыбер тавышларын чыгармыйлар, тик шунда күзләрен тутырып, миңа карап торалар. Тагын шунысы гаҗәп, аларның бу карашында ятсыну да, уңайсызлану да һич сизелми, бары кешедән бизүгә охшаган ниндидер бер җан салкынлыгы гына чагыла иде. Менә җиңгәчәй дә кайтып керде, мине күреп исе китте, «әй, Әмирханым, Әмирханым» дип елап та алды. Мин исә бер теземне кочаклап, башымны юри югары каерып (гүя шулай иткәч, күздән яшьләр бәреп чыкмаска тиеш иде), таш сындай катып, сәке кырында тик кенә утыра бирдем. Җиңгәчәйдән юньләп берни сораша да алмадым, тәкатем җитмәде, хәер, үзе хәлләрен бераз сөйләп аңлатты. Зөләйхадән ярдәм еш кына килеп тора икән, шуның өстенә җиңгәчәй каен тузыннан сагыз кайнатып, хатын-кыз арасында саткалый икән, шулай итеп көннәрен-көнгә ялгап баралар икән әле. Шөкер ди, ачыкканыбыз юк ди җиңгәчәй, бичара!.. Татар хатыны шул.

Бу минем сугышка чаклы Каргалыга соңгы кайтуым иде. Күп еллар узгач, мин Ялтадан бер кайтышлый, Севастопольдә Шамилне эзләп таптым. Землянкада дәшми утырган кечкенә малай чын ир-егет булган имеш! Атасына бик охшаган, шундый ук чандыр төз гәүдәле, аксылрак чырайлы, туры борынлы, бәлки буйга бераз кайтышрак булыр... Атасы кебек житез, хәрәкәтчән, ачык күңелле, сүзгә дә юмарт икән. Ул хәрби флотта хезмәт иткән, укыган, квалификация алган, мин күргәндә дә хәрби корабльләрдә электрик булып эшли иде. Өйләнгән, баласы бар. Севастопольнең үзендә яңа квартирада тора.

Атасын бөтенләй хәтерләми, әмма сурәтен генә булса да бик күрәсе килә икән. Миннән дә «Атакайның карточкасы сездә булырга тиеш» дип кат-кат сорады. «Юк вет» дигәнгә дә ышанып бетмәде, гареп! (Каргалыча әйтсәк). Хәлбуки, Нигъмәтулла дәдәкайның солдатта чакта бер иптәше белән төшкән фоторәсеме бар иде, мин үзем дә аны ничектер күргән идем кебек, ләкин шул фоторәсем берәүдә дә юк, кая киткән, кемдә калган — һичкем белми. Ә Шамилгә бик кирәк икән ул бердәнбер «картычкы», атасын хыялында гына булса да терелтер өчен кирәк икән аңа! Мине вокзалга озата төшкәч тә кыенсынып кына тагын шуны кабатлады, «һич югы фотосын гына күрәсе иде бит» диде. Мин инде берәр җирдән таба алсам, җибәрермен дип аны юаткан булдым.

Ә менә Идюкне (Идиятулланы) теге землянка базында күргәннән соң миңа яңадан бер генә тапкыр да күрергә туры килмәде. Әмма беләм, ул да үсеп егет булган, армиядә хезмәт иткән, соңыннан заводта эшләгән, аннары бер рус кызына өйләнгән. Куйбышевтан ерак түгел Кинель дигән шәһәрдә үз йортында тора икән. Хатыны да шул Кинельдән, хатынының ишле туганнары да шунда яшиләр икән... Бәлки әле Идиятулла исемен дә үзгәрткәндер, хәер, кызыксынып сораганым юк, ә менә тормышы бик әйбәт дип ишеттем.

Мәдинә җиңгәчәй озак яшәде. Әмма бу озын гомернең үзенә тигән өлеше шактый кыска. Абзаннан Каргалыга килен булып төшкәч, Нигъмәтулла дәдәкәй белән герман сугышына чаклы дүрт-биш ел яшәп кала. Дүрт ел солдатка булып тора, кайнатасын һәм кайнанасын карап, бөтен хуҗалыкны үз җилкәсендә алып бара. Нигъмәтулла дәдәкәй пленнан кайткач, нәкъ унике ел алар тагын бергә торып калалар. Шуннан соң инде җиңгәчәй тол хатын булып картая. Дүрт баласы дүрт якта, ул шуларның әле берсенә, әле икенчесенә барып, кунаклап кайта-китә йөри. Ләкин гомеренең күбрәк өлешен Зөләйхада торып уздыра, аның балаларын үстерешә һәм сиксәннән узып, Зөләйха кулында вафат та була. Туып-үскән җире аның Башкортстандагы тын гына аккан ямьле «Түреш» буенда иде, мәңгелек урыны исә Казагыстанның гел селкенеп торган карлы-бозлы Алатау итәгендә. Татар хатынының типик язмышы түгелме бу?.. Хәер, мин һич тә гомумиләштерергә теләмим, мин, кичерегез, бала чагымнан ук күңелемдә сакланган бер җиңгәчәм турында гына сөйләдем. Ташлы туфрагы мамык булсын аның!

...Якын туганнар хакында сүз хәзергә шуның белән тәмам. Нәтиҗә ясап нәрсә әйтергә мөмкин?.. Без яшәгән дәвернең төрле чагы булды, төрле хәлләрне күреп үткәрергә туры килде, үкенечле югалтулар да, кызганычка каршы, аз булмады.

Ләкин мондый нәтиҗә ясау өчен генә «дәдәкәй тарихын» язып тору кирәк идеме соң?.. Кирәк иде, чөнки менә миңа — язучыга кагыла ул тарих. Ә язучы юкны бар итмәскә, барын яшереп тормаска тиештер дип беләм мин. Бигрәк тә үзе турында тәвәккәлләп язарга тотынгач!

*Ахыры киләсе санда*

Марсель Зарипов

# АП-АК КАРАБОДАЙ КЫРЛАРЫ

ОЧЕРК

*Язучы һәм журналист Марсель Зариповка 50 яшь тулды. Бүгенге көндә ул — иң актив иҗат итүче публицистларыбызның берсе. Татар һәм башка милләт укучылары иң әүвәл аны зур һәм үткер мәсьәләләр, бүген һичшиксез хәл итәлергә тиешле проблемалар күтәргән матур-матур очеркларыннан белә. Ул — «Советская Россия» газетасының үз хәбәрчесе. Аның иҗат итү рәвешенә төпле фәннилек һәм югары сәнгатьчәлек хас. Һәр мәкаләсе яки очеркы, хикәясе яки повесте беренче битләреннән, беренче юлларыннан ук укучыны җәлеп итә, биләп ала торган мәсьәләне уртага салып тикшерүдән башланып китә. Аның әсәрләрендә — заман тормышы һәм кешесенең мәшәкать-борчулары, үткәннәр, киләчәк хакында үткен караш, тирән сиземләү. Укучылар йөрәгенә якын, күңеленә хуш нинди генә нәрсәләр хакында язмый Марсель Зарипов! Бу яктан ул нечкә зәвыклы, тирән белемле булуы белән аерылып тора. Ул Идел буенда яшәгән борынгы бабаларыбыз тормышын, Казан тарихын бик яхшы белеп яза. Ул бүгенге көннең иң алдынгы урларе, тиңсез күренешләре булган КамАЗ һәм Чаллы фидакарьләре, Түбән Кама химиклары һәм Әлмәт нефтьчеләре, авыл хуҗалыгы җитәкчеләре һәм кешеләре хакында да бердәй яратып яки борчылып яза. Мәсьәләне күрсәтеп, проблеманы күтәреп кенә калмый, аларны хәл итәргә мөмкин булган юлларны, чараларны ачыклап, билгеләп тә куя. Бу җәһәттән ул бик өлгер, аның сүзе дәрәҗәле.*

*Ике дистәләп очерк, хикәя, повесть китаплары авторы, гаять тыйнак, шул ук вакытта һәрчак көр күңелле, шаян холык табигатьле каләмдәшебезгә илле яшь тулган көнне аңа һәрчак мул иҗат, сугышчан публицистика дәрт-дәрманы теләп калабыз.*

**Редакциядән.**



Утыз ике ел эшләү дәверендә селекционер Наталья Николаевна Петелина карабодайның дүрт сортын китереп чыгарган. Эшендә дә, гыйльми яктан да аның урыны-дәрәҗәсе әллә ни зур түгел. Ул — авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, Татарстандагы авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү институтының өлкән гыйльми хезмәткәре. Әмма хикмәт дәрәҗәдә-югарылыкта гынамыни соң? Аның бик күп еллар буе зур тырышлык куеп башкарган хезмәте кайбер калын-калын фәнни трактатлардан да, әллә ниткән эш урыннарыннан да югары торырлык.

Наталья Николаевна 1967 елда «майская» һәм «красностерелецкая» дигән сортлары белән Татарстанга күчеп килә һәм аның карабодайлары, уңышны аз бирә торган иске сортларны кысрыклап, ун елдан соң игелә торган карабодай басуларының туксан процентын яулап ала. Карабодай кебек ашлык өчен бу әллә нидә бер була торган күренеш.

Азнакай районыннан Наталья Николаевна Петелинага мондый

рәхмәт хаты язып җибәрәләр: «Краснострелецкая» дигән карабодаегызны мең гектар чамасы мәйданда барлык колхоз, совхозлар чәчәчәк. Яхшы сортлы карабодаегыз өчен сезгә бик зур рәхмәт!

Ихтирам белән И. Левин».

Ул арада инде тынгысыз Наталья Николаевна карабодайның яңадан-яңа сортларын китереп чыгара, алар хәзер сынау узалар, колхоз, совхоз басуларында урын алалар. Һәвәс агрономнар үз басуларына шул яңа сортларны чәчеп, нәтиҗәләрен Наталья Николаевна белән уртаклашалар. Андый хәбәрләшү селекционер галим өчен иң беренче ярдәм инде ул.

Белгород өлкәсендәге «Новая жизнь» колхозының баш агрономы, РСФСРның атказанган агрономы В. С. Швыркин институтка менә мондый үтенеч белән мөрәҗәгать итә:

«Наталья Николаевна! Сезгә бик зур гозеребез бар: безгә «сокури» дигән сортлы карабодаегызның орлыгын җибәрегезче. Безнең колхозда бөртекле ашлыкларның байтак сорты производство сынавын уза. Бөтен өлкә агрономнары безгә семинарга киләләр. Сезнең сортыгыз ошап китсә, аны ишәйтү-тарату хакында уртаклашып кайгыртабыз.

1978 ел, 17 апрель».

Ел азагында Белгород өлкәсеннән, агроном В. С. Швыркиннан җавап килеп җитә: «Хөрмәтле Наталья Николаевна! Сез җибәргән өч центнер орлыктан 65 центнер карабодай алдык. «Шатиловская-5» сортыннан уңыш җитмеш гектар басуда 9 ар центнер, ә «сокури» сортыннан 16,2 шәр центнер булды. Сезнең карабодайны без 2 июньдә (сездән орлык алгач) чәчкән идек. Буш җир булмады, шуңа күрә аны арышны яшел азыкка чабып алганнан соң гына чәчәргә туры килде. Дүрт гектар җиргә гектарына җитмеш биш килограмм исәбеннән, бер центнер нитроаммофоска кертеп, гадәттәге ысул белән чәчтек. «Шатиловская-5» карабодае унбишенче майда безнең басуларда кулланыла торган тәртиптә — гектарына алтмыш килограммнан, гадәттәге ысул белән чәчелде. «Сокури» сорты басуында чүп үләне юк, чип-чиста иде, ап-ак булып чәчәк атты «Шатиловская»дан соңрак чәчелсә дә, аның бөртекләре бер юлы диярлек ике-өч көн алданрак өлгерде.

Алдагы елда бу ике сортны, «шатиловская» белән «сокури»ны бер үк агротехника белән бер үк кырга чәчәргә уйлыйбыз. Ә ун гектар орлык участогын аерым чәчәчәкбез».

Минем Наталья Николаевна Петелина белән әңгәмәм аның эш урынында, Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү институтының кечкенә бер лабораториясендә РСФСРның карабодай басулары турында уйланудан башланды. Тагы да ачыграк итеп әйтсәк: « Сез әле әбәт ашадыгызмы?» — дигән сораудан башланып китте. Мин инде, үз нәүбәтемдә: «Галимнәр ашханәсендә нинди ашлар пешерәләр соң: карабодай боткасы белән гуляшмы, карабодай запеканкасымы, пудинг, котлет, биточкимы?» — дип сорадым.

Сүз шуннан башланып китте.

— Һәй, булмаганны! — дип, Наталья Николаевна кулын гына селекте. Мин аның шулай әйтүеннән үк нинди кеше икәнлеген, эшендә тырыш, сүзендә ихлас күңелле булуын аңлап алдым. — Каян килсен ул карабодай? Борын-борыннан карабодай игеп килгән төньяк-көнбатыш өлкәләр — Новгород, Псков яклары — хәзер аны бөтенләй үстерми. Әллә хәзер анда кояшның җылысы башкача микән? Рязань ягында, Башкортстан, Татарстан, Алтай, Ерак Көнчыгышта карабодайны исәптән төшереп бетермиләр әле бетерүен, ә менә башка якларда аны санга сукмыйлар. Калуга өлкәсендә—юк дәрәҗәсендә, Чувашиядә — уйлап кына карагыз! —нибары ике мең гектар чәчкәннәр. Ставрополь төбәгендә карабодай үстерәләр, ә менә Кубаньда аны кара

туфраклы басуларга кертмиләр. Красноярски краенда да карабодайга сан юк (мин иң элек шунда эшли башлаган идем, карабодай игү өчен бик әйбәт як икәнен беләм), Куйбышев өлкәсендә әле тагын утыз мең гектар чәчәргә була, Волгоградта карабодайны утыз мең гектарга җиткерергә мөмкин.

— Берьюлы меңәр гектарлап арттыру күп булмасмы соң?

— Бер дә күп түгел. Иген басуларында карабодай сигез-ун процент урын алса, бик әйбәт булыр иде.

— Хәзер күпме соң?

— Кайда ничек дигәндәй. Тулаем бер ярым-ике проценттан артык түгел. Арыш уңган җирдә карабодай да бик яхшы уңа, аның башка игеннәр өчен дә файдасы бар. Агрономнар миңа, карабодай бик яхшы фитокультура, ул эче җирләрне «савыктыра», карабодайдан соң бәрәңгене каты корт зарарламый, басуда чүп үләннәре бетә дип язалар.

Шулай сөйләшә-сөйләшә, без, планлаштырырга хакы һәм мөмкинлеге булган кешеләр кебек, карабодайны кай төшләрдә күпме арттырып булыр икән дип исәпләп-чамалап карадык һәм нәтиҗәдә шактый зур сан — миллионнан артык гектар китереп чыгардык.

Бөтен гомерен бары тик бер эшкә — яңа сортлы карабодайлар китереп чыгару эшенә багышлаган селекционер галимнең шулкадәр тырышулары бушка икәнен күреп ничек рәнҗүен күз алдыбызга китерәсездер. Чыннан да, карабодай белән хәл әйбәт түгел. Аннан да начаррак булуы мөмкин дә түгелдер кебек.

Карабодайны «төньяк җирләр дөгесе» дип атыйлар, алтмыш-җитмеш көн эчендә тишелеп чыгып, өлгереп җитүе белән ул игү өчен бик кулай ашлыклардан санала. Байтак өлкә һәм республикаларда аның иртә җитешә торган сортларын, берәр төп культураны җыеп алганнан соң, кабат чәчәргә дә мөмкин. Моннан 2500 еллар элек Һималай тавы итәкләреннән табылган карабодайның башта Төньяк Һиндстанга, аннан Непал, Корея, Японияга, Урта Азия һәм Якын Көнчыгыш илләренә таралуы юкка гына түгел. Моннан инде ул Кара диңгез буена күченә башлаган грек колонизаторлары аша Рәсәй җирләренә килеп эләгә.

Татар, башкорт, казакъ, үзбәкләр бу ашлыкны «кара бодай» дип атаганнар. Көнчыгыш төрки телләрдә бу ашлыкның үзенә аерым шундый исеме булуы Рәсәй җиренә карабодайны Батый хан яулары алып килгән дигән фикергә дә нигез булган, күрәсең, ләкин Бөек Ватан сугышы алдыннан тарихчы археологлар Ростов өлкәсенең Нижне-Гниловская станицасы янындагы борынгы сарматлар курганын казыган чакта карабодайлы бер савыт табалар, икенче бер гыйльми экспедиция Украинада Чернигов шәһәре янында чүлмәк белән моннан мең ел элек пешерелгән карабодай боткасы табалар. Борын-борыннан халыкның гореф-гадәт, йолаларында карабодай зур урын алып торган. Себер крестьяннары да, Урал тавының бу ягында да, Кара диңгез белән Балтик диңгезе арасындагы җирләрдә дә бу туклыклы, тәмле ашлыкның файдасын бик яхшы белгәннәр, аны төп икмәк — арыш белән бертәттән, бертигез иткәннәр, күп көч сорый торган авыр эш эшләр алдыннан карабодай боткасы ашаганнар. Узган гасырның атаклы агрономы һәм публицисты Александр Николаевич Энгельгарт нинди эш өчен нинди ашның файдалырак икәнлеге турында авыл кешеләренең мондый акыллы сүзләрен теркәп үтә: «Тозлы ит белән пешкән кәбестә ашы һәм карабодай боткасы ашасаң, әйтик, бер куб җир казыйсың. Карабодай урынына арпа боткасы ашасаң, бер кубтан кимрәк казыйсың, бәрәңге булса, тагы да азрак — кубның өч чирегеннән артмас».

Карабодай — яхшы саклана торган туклыклы, тәмле азык. Анда аксым, углевод, май күп, тимер, фосфор, кальций, бакыр һәм йод

эремәләре кушылган минераль тозлар, витаминнар, кузгалак, лимон, фолий, алма кислоталары кебек биологик стимуляторлар бар. Дөньяда аның иң күбе безнең илдә игелә, карабодай басуларының җитмеш проценты безнең илгә туры килә.

Шулай да башкаларга карагында күбрәк чәчү мактанып өчен сәбәп була алмый әле. Барыннан да бигрәге — булган мөмкинлекләрдән без ничегрәк файдаланабыз, — карабодайга булган ихтыяҗны канәгатьләндереп җиткерәбезме?

Революциягә хәтле хәзерге Россия Федерациясе җирендә карабодай бер миллион ике йөз илле бер мең гектар чәчелгән. Бөек Ватан сугышы алдыннан карабодай басулары ике йөз мең гектарга кимегән, шул сәбәпле уңышы да азайган: алты йөз егерме дүрт мең тонна урынына биш йөз алтмыш тугыз мең тонна гына җыеп алынган. Шулай да сугыштан соңгы беренче бишьеллыкта ук инде карабодай ике миллион гектар чәчелә, уңышы да арта.

Әмма шуннан соң карабодай басуында хәлләр үзгәреп китә. Гүяки авылга трактор, комбайн һәм башка машиналар — куәтле техника да килми, галимнәр яңа сортлар да чыгармыйлар, ашлама, химикатлар да арта бармый — карабодай басулары, карабодай уңышы елдан-ел кими бара. 1966—1970 елларда РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгының колхоз һәм совхозларында бер миллион ике йөз туксан сигез мең гектар карабодай чәчеп, гектар башына алты центнердан чак кына артыграк уңыш алалар. Шуннан соңгы бишьеллыкта карабодай кыры бер миллион да сиксән өч мең гектарга хәтле кими, уңыш биш бөтен уннан өч центнер була. 1979 елда «төньяк дөгесе» Россия Федерациясендә бер миллион йөз дә егерме өч мең гектар җир били, уңышы биш центнердан да ким була. Бишьеллыкның дүртенче елында биш йөз утыз биш мең тонна карабодай сатып алырга планлаштырылса да, дәүләт амбарына кергәне дүрт тапкыр кимрәк була, уртача тугызынчы бишьеллыктагы һәм 1913 елдагыдан да азрак. 1980 елда карабодай җирләре бераз арта, бер миллион йөз утыз мең гектар чәчелә, ләкин уңышы 4,6 центнердан артмый.

Шуңа күрә магазиннарда карабодай ярмасы, ашханәләрдә карабодай боткасы булмавы бер дә гаҗәп түгел.

Шулай да хикмәт нәрсәдә соң?

... Мәскәүдә Лермонтов исемендәге метро станциясе бар. Гадәти бер метро станциясе, туктаусыз кеше агылып тора, бер-бер артлы гүләп, поездлар килеп-китеп тора. Вагоннардан төшкән халыкның бер өлеше Харитоновский тыкрыгына элгү өчен эскалатор белән уңга китә, икенче өлеше сулга — Орликов тыкрыгына таба ашыга. Харитоновский тыкрыгында авыл «фән-техника революциясенең» закон чыгаручысы ВАСХНИЛ, Орликов тыкрыгында РСФСРның Авыл хуҗалыгы министрлыгы урнашкан. Минем карабодай басуларына, карабодай балы җыярга дип кырга күчкән умарталыкларга күп тапкыр барганым бар. Белешмә китапларны, иске отчетларны һәм өр-яңа гыйльми тикшеренүләрне карап-актаргалап чыктым, башка ашлыклардан туклыклылыгы белән аерылып торган «төньяк дөгесе»нең киләчәге белән таныштым. Карабодайга илтифат булмауның төп сәбәбе, минемчә, фән оешмалары һәм белгеч-практикларның метро поездында бергә килеп тә, станциядә төшкәч төрле якка аерылып киткән пассажирлар кебек, айры-чайры эшләп, уртак тел, уртак фикер тапмауларында.

Мәскәүдән мин ВАСХНИЛның үсемлекләр бүлеге гыйльми секретаре Григорий Трофимович Лавренeнкога шалтыраттым, хәзерге көндә карабодай белән эшләр ничек тора, алдагы елларга перспективасы ничек? — шуларны беләсем килә дидем. Гыйльми секретарь үзенең гомуми мәсьәләләр белән генә шөгыльләнүен әйтте, Орел өлкәсендәге

кузаклы һәм ярмалы ашлыклар буенча Бөтенсоюз фәнни тикшерену институтының директоры, биология фәннәре докторы Николай Михайлович Чекалин хәзер Мәскәүдә, шуннан файдаланып, сез үзегезгә кирәкле мәгълүматларны аңардан сорашып белә аласыз диде.

— Дөрес, карабодай белән эшләр әйбәт түгел элегә, — диде Чекалин, ВАСХНИЛда көрешкәч. — Ә менә аны үстерү, игү хакында төрле тәкъдимнәр, фәнни хезмәтләр җитәрлек. Игенчеләр шуларга таянып эш итсәләр, басулардан планда каралганча уңыш алуны тәэмин итәргә мөмкин.

Министрлыкның бөртекле һәм май бирә торган ашлыклар буенча Баш идарәсендә миңа болай дип җавап кайтардылар:

— Практикларның үз кыенлыклары да җитәрлек, әмма шулай да аларның фәнгә дә дәгъвалары байтак. ВАСХНИЛның бүлекчәләре яхшы орлык бик аз бирәләр, яңа сортларны бик озак, бик акрын чыгаралар.

Эшләр менә шулай икән. Киңәшле эш, уртак тел булмау, бер-беренә дәгъва, шелтә белдереп яшәү нәтиҗәсендә карабодайның башка ашлыклар янында дәрәҗәсе төшә бара, агроном-практиклар карабодай игәсе басуларга арыш, борай, арпа, солы чәчәләр. Хәзер селекция һәм генетика фәне биқ нык үскән заманда иске сортлардан я уңышы, я чыдамлылыгы, я ярмасының сыйфаты белән өстен торган яңа сорт китереп чыгару өчен күп дигәндә унбиш ел вакыт кирәк. Наталья Николаевна Петелинаның эше бу яктан караганда бик сирәк очрый торган хәл. Гадәттә яңа сорт карабодай бик сирәк туа, аны чәчәр өчен дә әйбәт җирләр күп түгел. Россия Федерациясенең климат шартлары ягыннан төрле-төрле булган өлкә, край һәм республикаларында егерме алты сорт карабодай районлаштырылган. Күпме бу, әллә азмы? Бу сорауга җавап бирүдән элек, районлаштырылган төрле сорт ашлыклар каталогына күз салыйк. Йөз кырык сорт бодай, җитмеш җиде сорт арпа, кукуруз һәм аның гибридлары туксан алты сорт диелгән анда. «Баһадир» дигән карабодай сортын колхоз һәм совхозларда 1938 елдан, «калининская» дигән бик иске сортны 1954 елдан бирле чәчеп киләләр. Унынчы бишьеллыкта карабодайның җиде яңа сортын чыгарып, районлаштыру планлаштырылган булса да, дүрт ел эчендә нибары дүрт кенә сорт тарала. Дөресендә, моның телгә алып әйтерлек исеме генә бар, чөнки тулаем карабодай басулары белән чагыштырганда яңа сортлар диңгездәге бер тамчы хәтле генә — нибарысы йөз кырык мең гектар чамасы! Хәер, Н. И. Вавилов исемендәге Бөтенсоюз фәнни тикшерену институтының коллекциясендә ике меңнән артыграк карабодай төре бар. Бер караганда, селекционерларга төрле шартларга яхшырак җайлашкан яңа сортлар чыгару өчен сайлап алырлык материал да күп.

Хәер, яңа сортлар турында күп сөйләп тә булмый. Һәрбер яңа төр үсемлек ул, ни дисәң дә, очраклы бер бәхет эше, моның өчен селекционерларга табигатьнең серен чишәргә, аның каршылыгын җиңәргә, өстәвенә, зур тырышлык, сабырлык кирәк. ВАСХНИЛның агрономнарны иң яхшы элита орлыклары белән тәэмин итәргә тиешле төп хуҗалыклары бу бурычларын начар үтиләр. Монда инде, теге-бу дип, язмыштан зарланып булмый, иң мөһиме, үз эшеңне җиренә җиткереп, намус белән башкарырга кирәк. 1977 елда төп хуҗалыкларның тәҗрибә участоклары, сынау басулары колхоз һәм совхозларга сорт яңарту өчен егерме сигез мең йөз дә алтмыш бер тонна яхшы эре орлык бирергә тиеш булсалар да, бу йөкләмәне кырык процентка гына үтиләр. Шуннан соңгы елда хәл тагы да начарлана төшә — егерме алты мең сигез йөз алтмыш ике центнер орлык урынына агрономнар нибары җиде мең җиде йөз утыз бер центнер гына алалар. Явымлы, салкын елда да, эссе, коры җәйдә дә шул ук хәл!

Ә чынлыкта эшләр ничек бара? Зур белгечләр, агроном-практиклар, галим абзыйлар — доктор һәм академиклар язган иң популяр дәреслекләрне, белешмә китапларын, гыйльми хезмәтләр, кулланма һәм тәкъдимнәрне ачып карасагыз, алар барысы да, төрле схема, таблица һәм исәп-хисаплары белән раслап, «майская», «краснострелецкая», «шатильская-5» сортлары «баһадир» сортына караганда уңышны бер ярым — өч центнерга күбрәк бирә диләр. Ә менә басуда чәчкечләргә нинди карабодай салалар? Наталья Николаевна Петелина чыгарган мактаулы «краснострелецкая» сорты 1978 елда җитмеш бер мең биш йөз кырык гектар җиргә чәчелсә, картайган «баһадир» ярты миллион гектардан артык җир биләгән. Шуны онытмыйк: «краснострелецкая» сорты моннан ун ел элек үк колхоз, совхоз басуларына кертергә дип тәкъдим ителгән. Ун ел инде аз вакыт түгел, теләк-дәрт булганда, эшне оештыра белгәндә күбрәккә дә ирешеп булган булыр иде. Әлбәттә, яңа сортларны мактау, иген игүчеләргә, менә монысы — әйбәт, монысы — начар дип, аң-белем бирү яхшы эш, әмма аң-белем тарату белән генә чикләнеп калмаска, тиз арада кирәкле чараларын күреп, яхшы сортларны яңа басуларга кертергә иде!

Карабодай кырында хәлләр әнә шулай. Россия Федерациясендә карабодай игү өчен Орел өлкәсеннән дә яхшырак җир бар микән? Анда Урта Россия төбәкләренә хас, үсемлекләр чәчәк атканда кырау төшми торган тигез һава. Бу өлкәдә кузаклы һәм ярмалы ашлыклар буенча Бөтенсоюз фәнни тикшеренү институты урнашкан, әлеге институтта карабодай белгечләре министрлыкның калган бөтен фәнни учреждениеләренә караганда да күбрәктер, шәт. Институт белән өлкә авыл хуҗалыгы идарәсе төзегән уртак планнарның исәбе-хисабы юктыр. Ул планнарда карабодайның уңышын арттыру һәм дәүләткә күбрәк сату мәсьәләләре каралган булган. Чынлыкта ул чараларның күбесе кәгазьгә генә теркәлеп калган. Күп уңыш бирә торган «скороспелая» сортын 1975 елда чыгарганнар, ә дүрт елдан соң җиде йөз гектардан чак кына артыграк, беренче җәйдәге чаклы гына чәчкәннәр. «Шатиловская-5» сортын моннан ун ел элек үк инде районлаштырган булсалар да, ул нибары сигез мең өч йөз утыз гектар гына җир били. Аның каравы, искереп беткән карт «баһадир»га, иң зур басуларны — илле җиде мең йөз туксан гектар җир бирәләр! Сигезенче бишьеллыкта уңдырышлы Орел кырларында карабодайның гектардан уртача чыгышы — алты бөтен дә уннан өч, тугызынчы бишьеллыкта биш тә уннан алты центнер була.

Хәер, уңышның бу кадәр аз булуына гаҗәпләнәсе юк, чөнки агротехника кагыйдәләрен үтәмиләр, идарә итү культурасы түбән, кулга ни эләксә, шуны чәчәләр! 1977 елда бу өлкәнең чәчүлек орлыкҗитештерүче хуҗалыклары колхоз һәм совхозлар өчен дүрт мең алты йөз центнер иң яхшы элита орлык үстереп бирергә тиеш булсалар да, нибары җитмеш центнер гына саталар. Шуннан соңгы елда әлеге бурычны яртылаш кына үтиләр...

Карабодай — бик нәзберек ашлык ул. Чәчәр алдыннан аны микроэлемент онына манчып алмасаң, аннан әллә ни зур уңыш көтмә инде. Чәчәк аткан чагында көннәр җил-яңгырлы булып, умарта кортлары бал җыймасалар, карабодай басуы серкәләнми кала, башаклары буш-кысыр була. Шундый нәзберекле яклары бик күп аның! Дөрес, табигать белән исәпләшми булмый. Шулай да сүзебездә гадел булыйк, бөтен гаепне бер табигатькә генә сылтамыйк.

Борынгырак елларда, элек-электән килгән гадәт буенча, һәр крестьян хуҗалыгы карабодай иккән. Уңышы булырмы-булмасмы дип борчылмастан, беркадәр җиренә карабодай чәчкән. Хәзер инде специальләшү һәм концентрация, ягъни бер төбәккә туплау дигән нәрсә карабодайга да кагылгач, ул эш белән иң хәзерлекле, белдекле

кешеләр генә шөгыльләнә. Татарстанда карабодай игү ягыннан Азнакай игенчеләре аерылып торалар. Алар иген кырларының уннан бер өлешенә карабодай чәчәләр, район хуҗалыклары сигезенче бишьеллыкта карабодай җирен бермә-бер арттырып, аның уңышын сигез бөтен уннан тугыз центнерга җиткерәләр. Чәчү җирләрен киңәйтү, оештыру һәм агротехника эшләренең сыйфатын яхшырту нәтиҗәсендә дәүләткә өч тапкыр артыграк карабодай саталар. Унынчы бишьеллыкта инде районда тугыз мең гектар мәйданга, ягъни барлык басуларның унике процентына карабодай чәчәләр. Республикадагы карабодай басуларының уннан бер өлешен чәчүче Азнакай осталары тулай уңышның егерме җиде процентын, ягъни өчтән берен бирәләр.

Ләкин Татарстанның башка районнарында карабодай игү белән бик начар шөгыльләнәләр. Азнакай игенчеләре дә, бу эштә зур тәҗрибәләре була торып та, бик аз уңыш алалар. Унынчы бишьеллыкта республика дәүләткә карабодай сату йөкләмәсен яртылаш кына үтәде.

Карабодайны аерым төбәкләрдә үстерү, аны игүдә аерым колхоз, совхоз, район һәм зоналарны специальләштерү байтак кына җитди мәсьәләләр кузгата. Шуларның берсе — карабодай игүчеләрне безнең химия промышленносте эшләп чыгармый торган махсус гербицидлар белән тәэмин итү, җитәрлек техника, аерым алганда, карабодайны киң рәтле ысул белән чәчәр өчен сызмалы тракторлар күбрәк бирергә кирәк. Болай чәчкәндә, гади ысул белән чагыштырганда, уңыш гектарына ике-өч центнер артыграк чыга икән. Хәер, «артык» дигәннән, карабодай боткасына шундый мохтаҗлык булган чакта аның берниндиартыклыгы юк. Авыл хуҗалыгы машиналарын бүлеп биргәндә ни өчендер карабодайны исәпкә кертмиләр, хуҗалыкларда ничек тә чарасын табарлар дип уйлыйлар, ә сызмалы тракторлар җәй буе директив культураларда — кукуруз, шикәр чөгендере, бәрәңге басуларында эшлиләр. Хәтта карабодай игүнең атаклы осталары да, — мин «Коммунизмга» колхозында булдым, анда карабодайны биш йөз гектар чәчәләр, — уңыш кимрәк чыгачагын белә торып, басуларының бер өлешен гадәттәге тар рәтле чәчкечләр белән чәчәләр.

Тагын да мөһимрәк икенче мәсьәлә — игенчедә «төньяк дөгесе» белән кызыксыну, бу ашлыкны игү файдалы икәнлегенә ышандыру.

Киләчәктә селекционерлар күп уңыш бирә торган, теләсә кайсы ашлык белән ярышырлык көчле карабодай сортлары китереп чыгарырлар. Ә хәзергә «төньяк дөгесе»нең мөмкинлеге бодай, арыш, арпа, солыдан кимрәк әле. Карабодайны дәүләткә сату бәясен өч тапкырга арттыру нәтиҗәсендә ашлыкларның экономик бәһасе тигезләште, аның рентабельлеге артып, өч йөз, дүрт йөз, биш йөз процентка җитүе табигый хәл. Әмма ашлыкны аз җыеп алу басуларның уңыш бирүе дигән күрсәткечне киметә. Унынчы бишьеллык чорында Азнакай игенчеләре гектар башыннан унҗидешәр центнер бодай уңышы алсалар, карабодай унбер центнердан аз гына артыграк була. Бу уңыш аермасын гектар исәбенә тапкырласак, утыз мең тонна ашлык ким җыеп алынган булып чыга. Алай гына да түгел, бу нәрсә күрсәткечләрне киметә, карабодай игүче хуҗалыклар фермаларда концентрат мохтаҗлыгы кичерәләр: «төньяк дөгесе»ннән алган экономик эффект икенче тармакта — терлекчелектә файда итми. Шикәр чөгендере үстерүчеләр, әйтик, хезмәтләре өчен патока, җом алалар, чөгендер өчен аларга шикәрләтә дә түлиләр. Карабодайны да үстерүе кыен саналган культуралар рәтенә кертеп, аның уңыш коэффициентын да исәпкә алырга кирәк түгел микән? Җир, басу-кыр белән эш итүчеләр өчен кайнар чакыру — өндәү, катгый күрсәтмәләрдән бигрәк эшнең мәгънәсе һәм файдасы кыйммәтрәк. Җитәкчелек эшендәге осталык,

уңышның сере — директив башлангычлар белән практик стимулларның бердәмлегендә. Карабодайның уңышы аз булуын агротехника җитмәү, идарә эшендәге ялгышлар белән аңлатсак, карабодай басуларының кими баруы аны игү файдалы булмаудан килә. Тәҗрибәле хуҗалар исәпләп карыйлар да карабодай урынына башка ашлык чәчүне кулайрак күрәләр, чөнки соңгылары натураль азыкны күбрәк бирә.

Партиянең егерме алтынчы съезды игенчеләр алдына иң мөһим мәсьәләләрнең берсе итеп карабодайны күбрәк җитештерү һәм дәүләткә күбрәк сату бурычын куйды.

Соңгы елларда карабодай турында кемнәр генә язмагандыр — тәмле карабодай беленен тансыклаган пешекчеләр дә, дәвага карабодай боткасы ашаучы диабетиклар да, татлы карабодай балы яратучылар да! Барысына да карабодай кирәк. 1977 елда «Советская Россия» газетасында чыккан бер мәкаләгә җавапларында РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан: тиешле чаралары күрелә, хәлне төзәтербез, карабодай кырлары зураер, уңыш та күбрәк җыелып, дәүләткә күбрәк сатылыр дигәннәр иде. Ә чынлыкта ничек булды соң? 1979 елда карабодай басулары кими, уңыш элекке чамасында кала, дәүләткә йөз мең тонна азрак сатыла.

Ә менә карабодай белән кызыксыну кимеми. Карабодай игү осталарына аны ничек карап үстерү, ничек чәчү, ничек урып-җыю хакында киңәш-ярдәм сорап язган хатлар һаман килә тора. Азнакай районының «Коммунизмга» колхозы звено башлыгы, Дәүләт премиясе лауреаты Фоат Сәгыйтович Шакиров (ул ел саен егермешәр центнер уңыш ала) миңа менә мондый бер хат укытты.

«Минем, агроном буларак, үз хуҗалыгымда бик күптән инде шул кыйммәтле ашлыкны үстерәсем килә, — дип яза Екатерина Ивановна Ильина. — Сездән бик үтенеп сорыйм: миңа егерме килограмм карабодай орлыгы сатып бирегезче. Ике посылка итеп, минем исемгә җибәрегез, акчасын я алдан ук, я соңыннан җибәрермен, бәясен әйтеп языгыз. Безнең өлкәдә карабодай юк.

Адресым: Псков өлкәсе, Гдовск районы, «Ремзовский» совхозы».

Елъязмаларда әйтелүенчә, уналтынчы гасырда ук карабодай иккән, карабодай белән сату иткән борынгы Рәсәй төбәге бит бу!

Ә армый-талмый, тынгылык белми торган Наталья Николаевна Петелина «красностремлецкая»ның кызы, «майская»ның оныгы булган «троянда» дигән тагын бер сорт карабодаен сынауга тапшырган. Бу яңа сортның язмышы ничек булып бетәр: басуларга бик тиз таралып, ап-ак чәчәкләреннән бал исләре аңкытып утырырмы, әллә игътибарсыз калып, бөтенләй онытылырмы?

Язмышы беренче юлдан китсә, бик әйбәт булыр иде. Икенчесенә дучар булса, әлбәттә, андый хәлне берни белән дә аклап булмас.

*

* *

*Бу очеркның газета өчен язылган варианты 1979 елның декабрь аенда «Советская Россия»дә басылган иде. 1981 елның маенда КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы «Карабодай, тары, ногыт борчагы, ясмык җитештерү һәм дәүләткә сатуны стимуллаштыру буенча өстәмә чаралар турында» карар чыгардылар. Бу карарда карабодайның күп уңыш бирә торган яңа сортларын булдыру, карабодайны дәүләткә унынчы бишьеллыктагыдан артык саткан кадәресе өчен 50 процент өстәмә акча түләү кебек чаралар белән берраттән, карабодай игүче колхоз һәм совхозларга комбиазык һәм бөртекле фураж сату да күздә тотыла. Союздаш һәм автономияле республикалар, край, өлкә һәм районнарның дәүләткә ашлык сату планы карабодай һәм тары буенча башкарылган очракта гына үтәлгән дип саналачак... Карарда бик җаваплы, җитди чаралар күрсәтелгән, бүгенге көндә карабодай игү эшен чикли торган субъектив сәбәпләрнең күбесе алып ташланган. Хәзер инде җиң сызганып эшкә керешергә генә кирәк.*

## Энҗе Мөэминова

# УЛ—ОСТАЗЫМ МИНЕМ

ОЧЕРК

Татарстан нефть промышленностендә Автоматлаштырылган информация системасы идарәсенең «ТатАИСнефть» — бинасы заманча җыйнак мәһабәтлеге белән җәлеп итә. Автобус тукталышы каршында гына булганлыктан, бу матур яңа бинага мин сокланып карап тора ала идем. Ә менә КПССның XXVI съезды ачылу көннәрендә исә, бу коллективның нефть промышленносте предприятиеләре арасында оештырылган ил күләм социалистик ярышта җиңүче булып, призлы урыннарны яулап алганлыгы билгеле булгач, минем күңелемдә әлеге бинаның эченә үтеп керү, аның кешеләре һәм аларның эшләре белән якыннан танышу теләге уянды.

— Нефть сүзе сезнең идарәгә тагылма сүз генә түгелдер дип уйлыйм. Әйтик, шушы мәлдә сезнең идарәгез әкияттәгечә юкка чыкты ди. Ул вакытта шәһәребездәге нефтькә бәйле производство тармакларында нинди хәлләр килеп чыгар иде?— дип сүз башладым мин идарәнең начальнигы Рубис Газизович Шакирҗановка мөрәҗәгать итеп.

— Ул вакыттамы?! Ул вакытта Әлмәттә генә түгел, ә без хезмәт күрсәтә торган бөтен төбәкләрдә — Азнакайда, Бөгелмә, Лениногорск, Баулы, Алабуга, «Ямашнефть», «Норлатнефть», «Прикамнефть» идарәләрендә, хәтта Әлмәт нефтьчеләре хезмәт күрсәтә торган «Себернефть» идарәсендә дә безнең юклык бик сизелер иде. Ниндидер сәбәпләр аркасында эштән туктаган скважиналар төркеменең «ашыгыч ярдәм» чакыру авазлары безгә килеп җитә алмас. Аларның озак тукталып торулары аркасында нефть чыгару тоткарланыр. Куркыныч булу ихтималы турында алдан ук хәбәр итә торган сигнал системалары эшләмәүдән янгыннар, зур аварияләр, шартлаулар килеп чыгу ихтималы күбәер. Күп кенә предприятиеләрдә эшнең барышы турындагы мәгълүматларны җыю ысуллары чирек гасыр элек булган хәленә кайтыр. Шуның аркасында штаттагы кешеләр саны бик күпкә артыр иде. Бу исә, үз чиратында, тагын күп кенә өстәмә чыгымнарга сәбәпче булыр. Саный китсәң күп инде алар. Аларның барысына да, менә хәзер, минем үземнең генә җавап биреп бетерүем мөмкин дә түгел! Ә шулай да кызыклы сорау бу.

— Инде хәзер Сез мине, Рубис Газизович, коллективыгыз һәм аның эше белән кыскача гына таныштырып китсәгез икән?

— Безнең идарәдә тугыз цех бар. Без информация тапшыруларын җыйнау җайланмалары белән эш итәбез. Нефть промышленностена хезмәт күрсәтә торган мондый идарә илебездә берәү генә.

Коллективта меңнән артык кеше эшли. Күбесе яшьләр. Тугыз йөздән артыгы «Коммунистик хезмәт ударнигы» исемен яулап алды. Ике кешебез идарәнең «атказанган эшчесе» исемен йөртә.

— Хәзер инде шул әйбәт кешеләр арасыннан иң-иң әйбәтен, сезнең идарәгезнең «биографиясен» чагылдырырлык бер кешене сайлап алыйк. Аның турында сөйләгәндә, сезнең эшегез көзгедәге кебек чагылырлык булсын. Андый кешегез бардыр дип уйлыйм.

— Бар ул андый кеше.

... Берничә минут үтүгә, бүлмәгә үтә җитез хәрәкәтле, мыегына чал керә башлаган, чәченә бөс кунган сөйкемле бер кеше килеп керде.

— Сез күрергә теләгән, әйбәтләрнең дә әйбәте, безнең атказанган эшчебез менә шушы абзый була инде. Ул безнең производство бүлеге начальнигы, партбю-

ро члены, гадел, туры сүзле, эшлекле кеше, — дип таныштырды мине Рубис Газизович аның белән.

Ул — Миргаяз Газетдинович Мәгъдәнуров икән. — Күптән түгел генә без аның алтмыш яшьлеген билгеләп үттек.

Миңа бу кеше бик таныш кебек күренде.

Әйе. Исемә төште. Мин аны беренче мәртәбә подполковник киемендә, күкрәге орден һәм медальләр белән бизәлгән килеш Җиңү бәйрәме көнне хәтерләп калган идем. Ул чагында мин аңа: «Исәнмесез, Мөхәммәт абый, ничек болай килеп чыгасы иттегез безнең якларга?» — дип, чак-чак кына эндәшмичә калган идем әле. Чөнки ул үзенең бөтен буй-сыны, килеш-килбәте, йөрүе, хәтта сөйләшүе белән дә өлкән шагыйребез Мөхәммәт ага Садрины хәтерләткән иде. Ә аннан соң миңа аның, гади киемнәрдән, машинадан төшеп, менә шушы бинага кереп киткәнен күп мәртәбәләр күрергә туры килде.

— Минем бөтен гомерем диярлек элемтә эшендә үтте. Укытучы була язып кына калдым. Минзәлә педучилищесын тәмамлагач, бер ел гына җидееллык мәктәптә математика укыттым. Финляндия сугышы башланган елны Ленинградка Хәрби элемтә училищесына укырга җибәрделәр. Училищены тәмамлауга, Бөек Ватан сугышы башланды. Сугыш эчендә өч ел кайнадым. Танкларга каршы сугышкан 543 нче полкта булдым. Сугыштан соң хәрби элемтәче булып хезмәтемне дәвам иттем. Чирек гасыр гомер шулай үтеп китте. «Яраткан эш — җан азыгы»,— диләр бит. Тыныч хезмәткә кайткач та шул эшемә керештем. Безнең эш бит кызык та, авыр да. Яратып эшләгәч, аның авырлыгын сизмисең дә инде. Быел менә нефтьчеләргә хезмәт күрсәтә башлаганыма да егерме ел тула... Безнең бу идарә 1973 елны гына оешты. Аңа кадәрле «Татнефть берләшмәсенең элемтә бүлеге» дип йөртелә иде. Мин анда өлкән инженер, ә аннан соң баш инженер вазифаларын башкардым... Җиттеме?

— Юк! Сөйләгез әле, сөйләгез. Әле мондагы төп эшегез турында бер нәрсә дә әйтмәдегез ләбаса.

— Мин алай күп, озын сөйли белмим. Хәрби хезмәттә өйрәнелгән. Сез, булмаса, башта менә бу язманы укып чыгыгыз. Аннан соң минем сөйләгәннәр сезгә яхшырак аңлашылыр, — дип, ул минем алга зур форматлы, шактый ук калын китап китереп куйды.

Идарәнең, 1980 елда эшләгән эшләре буенча, «Татнефть» берләшмәсенә бирү өчен хәзерләнгән аңлатмалы язмасы иде ул.

Мин шул язманы укыйм. Аңлашыла да кебек, аңлашылмый да.

Аңлашыла — чөнки безнең телдә язылган. Аңлашылмый — техник терминнар белән чуарланган. Һәм мин, ирексездән, мәктәптә укыткан вакытта булган бер вакыйганы исемә төшереп, үз алдыма елмаеп куйдым.

Логарифмалар темасына кереш дәрес үткәрә идем. Бер әни кеше дәресемә кереп утырырга рөхсәт сорады. Һәм дәрес ахырында ул миңа: «Дәресегезне бигрәк гайбәт үткәрдегез. Балалар сезнең һәр соравыгызга җавап биреп тордылар. Мин генә бер нәрсә дә аңламадым. Сез татарча сөйләдегез, югыйсә...» — дигән иде. Бу язманың кайбер урыннарын укыганда мин дә үземне шул әни хәлендәрәк хис иттем.

Ә менә Мәгъдәнуров өчен бу сүзләр — ипи, тоз, су дигән кебек гап-гади! Ул үз эше турында сөйләгәндә җанланып, кызып-кызып, сине бу эш турында нәкъ менә аның үзе кебек үк белүче дип хис итеп сөйли. Миңа, барыннан да бигрәк, аның кайсы гына тармак турында сөйләмәсен, һәрвакыт, уңышлары белән янәшә эштәге кыенлыклар, хәл итәсе проблемаларны куеп сөйләве ошады.

— Без нефть производствосындагы һәр төрле мәгълүматларны, автомат рәвештә җыя һәм тапшыра торган аппаратларга хезмәт күрсәтәбез. Бездә алар өч төркемгә бүленәләр: мәгълүматларны тапшыру аппаратлары. Боларга телефон, телеграф челтәрләре керә. Автоматика һәм телемеханика аппаратлары. Радиоэлемтәсе аппаратлары. Моннан тыш тагын, катодлы саклагычларга хезмәт күрсәтү дә безгә карый. Боларга кыскача гына аңлатма биргәндә, менә болай була.

Автомат телефон, телеграф аппаратлары аша объектлар һәм предприятиеләр белән турыдан-туры элемтәгә керергә мөмкин. Мондый аппаратлар бездә бик күп

һәм бик күп төрле. «Телетайп»лар гына да йөздән артык. Хәзерге көндә без ТТ-48 маркалы ике каналлы аппаратларны күбрәк булдыру өчен тырышабыз.

Автоматика һәм телемеханика аппаратлары группалаштырылган скважиналарга, насос станцияләренә, телемеханика системаларына куела.

Катодлы саклагычлар скважина төркемнәрен һәм нефть үткәргеч үзәк магистраль линияне электрохимик ысул белән вакытыннан алда тузудан саклыйлар. Күгәрүгә каршы көрәшәләр. Алар скважиналарга капиталь ремонт ясау чыгымнарын бик нык киметәләр. Бездә шулай сакланырга тиешле мең ярымга якын скважина төркеме исәпләнә. Шуларның һәр биш йөзенә капитал ремонт ясау өчен 1,5 миллион сум акча китә. Ремонт араларындагы вакытны озынайта алганда, бик күп акча янга кала. Һәр скважинаның җир астындагы өлеше 1700—1800 метрга төшә. Әнә шуның җир өстеннән 50—60 метр тирәнлектәге өлеше тизрәк күгәрә. Катодлы үткәргечләр шул урынны даими рәвештә металл белән каплатып торалар.

Бу ысул — нефть промышленностенда яңалык әле. Бөгелмәдәге фәнни тикшеренү проект институты (НИПИ) тәкъдим иткән яңалык. Ә аны башлап производствога кертү безнең идарәнең үз инициативасы.

Катодлы саклагычлар һәм автоматика аппаратларына хезмәт күрсәтүдәге иң зур кыенлык — транспорт мәсьәләсе. Объектлар хезмәт күрсәтү базасыннан ерак, таралып урнашкан. Бу кыенлык безнең радио элемтәгә бәйле эшләребездә дә бик нык сизелә. Тиешле урыннарга вакытында барып җитә алмый калабыз.

Безнең идарәгә 3000 нән артык радиостанция карый. Без радио элемтәсен яхшыртабыз, искеләрен ярым үткәргечле яңа типтагы аппаратлар белән алмаштырабыз. Бу өлкәдә безнең кыенлыкларыбыз күбрәк. Запас частьлар җитми. Скважиналарга җир асты ремонты үткәрү һәм капитал ремонт үткәрү бригадасы өчен тиз корылып җыела торган антенна мачталары кирәк. Кулдан ясалганнары белән генә эш итү радиостанциянең радиусын кечерәйтә.

Миргаяз Газетдиновичны хезмәттәшләре, күбрәк яшьрәкләре, үзара «Бабай» дип йөртә. Безнең белән бергә «ТатАИСнефть» идарәсе оешкан көннән башлап эшләүче, талантлы яшь инженер — идарнең техника бүлеге начальнигы Александр Степанович Слободчиков та эш урыннарын карап йөри.

Үтә дә катлаулы аппаратлар, шулар белән оста эш итә белүче кешеләрне күреп, мин сокланмыйча булдыра алмадым.

Кнопкаларга гына басасың яки хәреф һәм саннар гына җыясың: синең алда төрле язулы тасмалар пәйда була. Сөйләшергә теләгән кешең йөзләрчә чакрым җирдән сиңа җавап бирә...

Минем күз алдымда Әлмәтнефть идарәсенең бишенче промыселындагы телетайп аппаратлары, «Сәләйнефть» идарәсендәге акыллы машина — ЭВМ дистәләрчә чакрым ераклыктагы газ һәм нефть чыгаручы цехларның «йөрәк тибешләрен» күрсәтеп, язып аңлатып торды.

Без Әлмәт басуының иң биек урынына — Миңлебай юлы өстендә инде төзелеп бетеп килә торган «Алтай-3» радиостанциясенә юл тоттык.

Табигатьтә бүген март бураны хакимлек итә. Үргә күтәрелә барган саен, җәяүле буранның көче артканнан арта бара. Тизлеге аныкыннан күбрәк икәнен күрсәтергә теләгәндәй, без утырган машина бөтен көчкә алга чаба. Аңа каршы, телефон чыбыклары көлтәсен иңнәренә аскан таш баганалар йөгереп килә...

— Элемтәчеләрне шушындый көннәр җәзалый инде. Ә җәй көннәрендә — эшенле яңгырлар. Шуңа күрә хәзер мондый асылмалы чыбыклар белән эш итүне киметә барабыз, линияләрне, кабельләр суздып, җир астыннан үткәрәбез. Телемеханика линияләрендәге кабельләрнең озынлыгы гына да хәзер 6000 чакрымнан артып китә,— диде Александр Степанович.

Үз алдына уйланып, эндәшмичә генә барган Мәгъдәнуров, телефон трубкасын алып, кем беләндер сөйләшеп куйды:

— Мин — 45 нче! Килеп җитәбез...

Без урман буендагы зур бер бинаның ишегалдына килеп кердек.

— Менә бу безнең идарәнең яңа базасы булачак инде. Безнең автотранспорт паркы да шушында булачак. Катодлы саклагычларга бәйле корылмаларны төзү дә шушында планлаштырылган. Ә радиостанция күп элемтә урнаштыра алачак. Бер үк вакытта хәрәкәт итеп, күчеп йөрүче йөзләрчә объект белән бер юлы хәбәрләшеп тора алачакбыз, — диде Александр Степанович.

— Хәзер әле аның бер генә каналы эшли. Бая мин менә шуның аша элемтәгә кердем, — дип сүзгә кушылды Мәгъдәнуров. — Бу безнең унберенче бишьеллыкта тормышка ашырылырга тиешле зур планнарыбызның берсе.

Мин килгәндә Гөлүс Сәүбәнович телефон аша Казан белән сөйләшә иде.

— Сәбәбеме? Сәбәбе шул инде! Элек промыселлар балансында булган автомат идарә станцияләре хәзер безгә күчә бара. Аннан соң без төзүчеләрдән һәр елны 800—900 километр кабельле элемтә линияләрен кабул итеп алабыз. Безнең үсеш темпын шулар көчәйтә...

Гөлүс Мөхәммәтов бу идарәгә Куйбышев электротехника институтын тәмамлаганнан соң килгән Сарман егете. Ул биредә башта участок начальнигы булып эшләгән. Хәзер инде — производство бүлеге начальнигы урынбасары.

— Минем уң кулым. Дәртле, тырыш, уңган егет. Йөкнең авыр башын ул күтәрә, — диде иде Мәгъдәнуров аның турында.

— Миргаяз Газетдинович — минем өчен әти кебек. Ул үзен бер вакытта да кул астында эшләүчеләрдән өстен куймый. Аның белән һәр нәрсәне уртага салып сөйләшеп була. Шәхси тормыш мәсьәләләрендә дә үзенең акыллы киңәшләре белән ярдәм итә. Принципиаль, таләпчән остаз, — диде Гөлүс Мөхәммәтов.

— Гөлүс Сәүбәнович! Үз эшегезнең иң үзенчәлекле якларын тасвирлагыз әле.

— Безнең эш ел әйләнә, бер генә минутка да тукталып торырга тиеш түгел. Шуңа күрә безгә — бигрәк тә җаваплы кешеләргә — ял көннәре, бәйрәм көннәре күпчелек очракларда шартлы төшенчәләр генә булып калалар. Безгә чиратлашып төннәрен дә дежур торырга туры килә. Берәр төрле хәбәр килү белән, транспортны, кирәкле кешеләрне, техниканы аякка бастырабыз да, оператив төркем белән, юлга чыгып китәбез. Шуның аркасында кайчакта хатыннардан да «эләккәли». Алар безне югалтып, эзләргә дә чыккалыйлар,— диде Гөлүс Сәүбәнович, шаяруга күчеп. — Импульслы аппаратлар аша килгән хәбәрләр һәм карта буенча оператив төркем ярдәм кирәк булган урынның координатларын билгелиләр. Шуннан соң эшкә керешәләр.

Гөлүс Сәүбәнович белән бу сөйләшүдән соң минем күз алдымда менә нинди җанлы картина пәйда булды:

Асфальт юлдан бөтен көчкә сигнал бирә-бирә ашыгыч медицина ярдәме машинасы чаба. Димәк, кемнеңдер гомере кыл өстендә! Ашыгырга кирәк! Аның белән янәшә диярлек техника ярдәм машинасы бара. Аңа да ашыгырга кирәк. Сәламәт кешеләр өчен бик тә кирәкле бер объект ярдәмгә чакырган аны.

Һәр ике машинага да үз эшләрен бер тигез дәрәҗәдә үк яратып башкаручы фидакарь кешеләр утырган... Хәзер инде мин кабина ишегенә «ТатАИСнефть» дип язылган машиналарның нинди максат белән юлга чыкканлыкларын бик яхшы беләм.

— Ул минем остазым! — дигән иде Рубис Шакирҗанов мине Миргаяз Газетдинович белән таныштырган көнне.

Шул ук сүзләрне Гөлүс Мөхәммәтов та кабатлады:

— Ул минем остазым! Ул мине кешеләр белән эш итәргә өйрәтә...

Бу сүзләр Миргаяз Мәгъдәнуровның: «Мин укытучы була язып кына калдым», — дигән, бераз гына үкенүгә охшаган сүзләрен хәтергә төшерделәр.

Монда да үкенерлеге юк ич аның! Үзе белән бергә эшләүче, инде җитәкче булып танылган кешеләрдән: «Остазым ул минем!» — дип, горурлык белән әйтелгән сүзләрне ишетү, укытучыга бирелә торган бәядән дә олырак. Үзеңнең яраткан эшеңне шәкертләреңнән яраттыра алу җиңел эш түгел ул.

Хезмәтенә күрә хөрмәте, дигән канатлы сүзләрне «ТатАИСнефть» идарәсенең атказанган эшчесе, Ватан сугышы һәм хезмәт ветераны, коммунист Миргаяз Мәгъдәнуровка карата әйтергә дә ныклы нигез бар.

# ПРОБЛЕМАЛАРНЫҢ ҮЗӘГЕНДӘ — КЕШЕ

## Әдәбиятта яңалык тойгысы

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА

**Ринат Мөхәммәдиев, тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты:**

Бүген әдәбият һәм сәнгатебез алдында торган нинди генә мәсьәләләрне кузгатмыйк, олы юлдан, туры юлдан барырга телибез икән, ирексездән, Партиябезнең тарихи XXVI съезды материалларына, анда иптәш Л. И. Брежнев ясаган докладка мөрәҗәгать итми булдыра алмыйбыз. Партиябезнең эчке һәм тышкы политика өлкәсендәге чираттагы бурычлары белән танышканда күтәрелгән проблемаларның җитдилеге, масштаблылыгы һәм ни дәрәҗәдә интернациональ, кешелекле булуына сокланмау, гомумән, мөмкин түгел. Әйтик, тынычлык, иминлек өчен көрәш һәм илебез халкының тормыш-көнкүрешен тагы да яхшырту хакындагы сүзләр кемне генә битараф калдырыр икән...

Шуның белән бергә, әлеге җитди документта һәр кешенең күңеленә аеруча якын урыннар булуы да табигый. Күп милләтле совет әдәбиятына хезмәт итүчеләр, өчен, аерым алганда бүгенге татар әдипләре өчен, Л. И. Брежневның әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә ирешелгән уңышлар һәм алда торган бурычлар хакында олы кайгыртучанлык белән сөйләнгән сүзләре шуның бер үрнәге булып торса кирәк. «Минем карашымча, барлык укучылар, тамашачылар, тыңлаучылар совет сәнгатендә яңа дулкын күтәрелүен сизәләр. Соңгы елларда — һәм барлык республикаларда — талантлы байтак әсәрләр барлыкка килде»,— дигән югары бәя киләчәктә тагы да җитдирәк иҗат биеклекләренә рухландыра. һәм без — бүген «Казан утлары» журналының түгәрәк өстәле янына җыелган шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар һәм тәнкыйтьчеләр — ирешелгән уңышларны танып алган тәкъдирдә, киләчәктә яуланачак үрләр, алда торган идея-эстетик бурычлар хакында киңәшербез, бергәләшеп уйланырбыз һәм, кирәге чыга икән, бәхәсләшербез дә дип ышанырга кирәк. Әңгәмәбезне, шартлы рәвештә, «Әдәбиятта яңалык тойгысы» дип исемләп, фикерләребезне дә шул бер ноктага төби алсак яхшы булыр иде...

**Рафаэль Мостафин, тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты:**

Әдәбиятта прогнозлар ясау авыр, ләкин шулай да мөмкин эш. Тик моның өчен үткән юлга әйләнеп карарга, соңгы еллардагы тенденцияләрне ачыкларга һәм аларның киләчәктәге үсешен күзалларга кирәк.

70 нче елларның беренче яртысында игътибар үзәгендә поэзиябез булды. Ул яңа талантлар исәбенә баеды. Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Г. Рахим, Р. Харис, Р. Мингалимов, М. Әгъләмов, Зөлфәт кебек шагыйрьләрнең иҗаты нәкъ шул елларда ачылып китте. Поэзиябез яңа алымнар, яңа төсмерләр һәм аһәңнәр белән тулыланды.

70 нче елларның икенче яртысында поэзия бераз сүлпәнәя төште. Телгә алынган шагыйрьләрнең иҗаты да ничектер тоныкланып китте, поэзиягә яңа үзенчәлекле талантлар да көчле дулкын булып кушылмый тора. Аның каравы, алгы планга драматургиябез чыкты. Т. Миңнуллин, Д. Вәлиев, Р. Хәмид драмалары — моңа ачык мисал. Драматургиябез тарихында беренче мартәбә диярлек сәхнә әсәрләребез Бөтенсоюз аренасына чыкты. Д. Вәлиевның «Дәвамы»

илебезнең илледән артык театры куйды. Т. Миңнуллин драматургларыбыз арасында беренче булып К. С. Станиславский исемендәге Бөтенроссия бүләген алды.

Прозага килгәндә мәсьәлә шактый катлаулырак. Моннан өч-дүрт ел элек прозадагы торгынлык, төссезлек турында сүзләр йөри башлаган иде. Хәзер андый сүзләр ишетелми. Ни өчен? Бер карагандa, прозага моңарчы күренмәгән яңа талантлар да килмәде шикелле, формаль яктан да әллә нинди яңа ачышлар юк кебек. Шулай да мин прозадагы яңарыш турында сүз йөртергә мөмкин дип уйлыйм. Бу яңалык Г. Ахуновның «Идел кызы», А. Расихның «Сынау», М. Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала», А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән», Ә. Еникинең «Тынычлану», М. Юнысның «Табу һәм югалту», Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» кебек әсәрләрендә чагылыш тапты. Әйе, югарыда саналган әсәрләрнең берсендә дә формаль яктан «Америка» ачылмый. Ләкин аларда тормышның нинди дер яңа яклары, моңарчы язучылар игътибарыннан читтәрәк калып килгән яклары игътибар үзәгенә куелган. Әйтик, Г. Ахунов әсәрендә бу — Габбас мулла образы. Катлаулы, фаҗигале, уйландыра торган образ. «Сынау»да яшь буынның кайбер кире сыйфатлары турында сүз бара, һәм, әйтергә кирәк, бу проблема яңача, тормышчан нигездә алына. Шулай итеп, прозабыз соңгы елларда тормыш белән якынаю юнәлешендә үсә. Прозадагы яңалык тойгысын, бәлки, нәкъ шунда күрергә дә кирәктер.

**Туфан Миңнуллин**, драматург, **РСФСРның К. С. Станиславский исемендәге Дәүләт, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре лауреаты:**

Татар әдәбиятындагы үзгәрешләр турында сөйләгәндә һәм ул үзгәрешләрнең соңгы елларда нинди яңалык алып килүе хакында уйланганда, без иң элек гомум совет әдәбиятына, хәтта дөнья әдәбиятына да күз салырга тиешбез. Чөнки бер әдәбият та, бигрәк тә бүгенге коммуникацияле заманда, ялгыз гына үз эченә бикләнеп яши алмый.

Без яңалык тойгысын, иң беренче чиратта, форма өлкәсендә күрергә гадәтләнгәнбез. Күрәсең, анда ул күзгә ташланыбрак, өстәрәк ята торгандыр. Бүгенге заман әсәрләренең һәр жанрда елдан-ел кыскара, тыгызлана баруы — әнә шундый күренешләрнең берсе. Мисалга драматургияне алыйк. Әле кайчан гына пьесалар өчәр-



*Г. Бәширов: «Кайбер кешеләр, хәзер инде чишмәле, сандугачлы авыл турында сүз бармый, диләр...»*

дүртәр актлы иде. Спектакльләр өчәр сәгать уйнала иде. Бүген исә өч пәрдәле пьеса язучылар бөтенләй юк. Барлык пьесалар ике пәрдәле, хәтта бер пәрдәле әсәрләр ешрак күренә башлады. Шунысы кызыклы, әсәрләрнең күләме кимү фикернең тараюы хисабына бармый. Киресенчә, әсәрләргә салынган фикернең колачы киңәя, фәлсәфи яктан тирәнәя, кәгазьгә төшкән сүзләрнең кадере арта, әйтелгән һәр сүз саллылана бара. Нигә шулай? Чөнки бүген укучылар зур белемле, киң мәгълүматлы. Элегрәк, мәсәлән, «телевизор» дип язсак, телевизорның нәрсә икәнлеген укучыларның күбесенә аңлатып бирергә тиеш идек, бүген исә бот буе малай да әллә ниткән сүзләрнең мәгънәсен аңлый. Шуңа күрә син аларга буш сүз сөйләмә, фикер давай. Бала-чагасы шулай булгач, алардан дәүрәкләре нинди була инде?!

Әсәрләрнең эчтәлегенә кагылган яңалык, минемчә, шәхескә игътибар артуда. Хәзер язучылар үзләренең геройларын тирәнрәк тикшерәләр. Үз йөзе булмаган персонажлар кимегәннән-кими бара. Шуның нәтиҗәсендәдер, роман, повестьларда катнашучы геройларның язмышын тикшерергә күбрәк урын кала. Мисалга Чыңгыз Айтматовның «Гасырга тиң көн» исемле

романындагы персонажларны санап чыксак, аларның күп түгеллеген күрәбез. Романдагы һәр кеше җентекләп өйрәнелгән, язучы һәр героеның рухи анатомиясен ача, һәрберсен шәхес дәрәҗәсенә күтәрә. Шәхеснең психологиясен, рухын нечкәләп тикшерүгә корылган әсәрләр татар әдәбиятында да күбәя. Әмирхан Еники хикәяләре, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев повестьлары (бигрәк тә «Җомга көн кич белән» повесте), Атилла Расихның «Сынау» романы шуның мисалы. Нинди генә җирлектә язылмасыннар, аларның бер уртаклыгы бар — кеше язмышы.

**Мөхәммәт Мәһдиев, язучы, филология фәннәре кандидаты:**

Безнең прозага бөтен бер буынны тәрбияләрлек, бөтен бер буынга рухи азык булырлык әсәрләр кирәклеге, шуларның җитмәве турында инде әйтелде. Моны әйтү генә аз: прозабызны харап итә торган бер тенденциядән котылырга кирәк. Без, еш кына, безнең бөтенесе дә бар, без шәп, без күп язабыз, дип сөйләргә яратабыз. Бездә Айтматовның «Ак пароход» кебек, Распутинның «Соңгы срок» кебек әсәрләр күптән иҗат ителде, дип сөйлибез. Алай икән — ник соң бу әсәрләр союз аренасында күренмәделәр, шауламадылар? Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре татар-башкорт укучысы өчен буй җитмәслек сәнгать биеклеге булды. Распутинның «Соңгы срог»ы исә бөтен Советлар Союзы укучыларын тетрәтте. Димәк, Распутинның киңрәк адрес белән язылган. Соңгы еллардагы авыл тормышын без күп яздык, әмма Ф. Абрамовның «Йорт» романы бөтен язганыбызны томыкландырды да куйды. Безнең язучылар Ватан сугышында каһарманнарча көрәштеләр, сугыш турында күп очерклар, повесть, романнар яздылар. Әмма сугышның нәрсә икәнен без утыз еллар узгач, В. Быков, Ю. Бондарев әсәрләрен укып кына белдек.

Шулай булгач, нишләргә?

Бөтенсоюз әдәбияты дәрәҗәсенә ирешү өчен осталыкны арттырырга. Айтматов, Быков, Абрамов, Бондарев, Распутиннар осталыгына ирешү өчен тырышырга.

Без бүгенге көндә үзебезнең бер хикәябезне ниндидер Түбән Чокырча авылыннан пенсионерка Хәмдениса түти мактап язган хат белән генә канәгатьләнеп яшиалмыйбыз. Кайчан безнең китабыбызны, Айтматов китаплары кебек, чиратка язылып укый башларлар.

**Гомәр Бәширов, язучы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты:**

Әсәрләребезнең Бөтенсоюз күләмендә яңгырамавына без үзебез дә гаепле. Безгә артык тыйнаклык комачау итә. Фикердә тыйнаклык... Кайсыбер яңа әсәр чыккач укыйсың да, бу бик зур вакыйга булыр инде дип уйлыйсың. Кызыклы гына сюжет бар, геройлар бар, ләкин тарихка кереп калырлык фикер тирәнлеге җитми. Яңа образ, яңа характерлар җитми. Язу эшенә җиңелрәк карый башламадыкмы?



*С. Хәким: «Шагыйрь күңеле җирдәге изгелекне җырларга тиеш.»*

**Мөхәммәт Мәһдиев:**

Бездә язучылар сафы бик ишәйде, аларның саны һаман арту ягына таба бара. Әмма сан үзгәрешләре сыйфат үзгәрешен тудыра дигән мәгълүм положениене һич тә әдәби әсәрнең сыйфаты яхшыра бара дигән мәгънәдә генә аңларга ярамый. Үзгәреш диеп яхшыруны да, начарлануны да атап була бит. Мине соңгы елларда иң борчыганы — урта кул әсәрләрнең күбәюе. Ихтимал, минем үз язганнарым да шул


«урта кул» әсәрләргә керә торгандыр. Ләкин мин әле үз иҗатым турында түгел, гомумән, әдәбият турында сөйлим. Бүгенге татар прозасындагы күп кенә әсәрләр читтән торып укучы студентның имтиханын хәтерләтәләр... Аңа «начар» билгесе куеп булмый — ул нәрсәнедер белә; аңа «яхшы» билгесе дә куеп булмый — ул бик күп нәрсәне белми. Менә шуннан, зур газаплардан соң, «өчле» куясың. Әйдә, ярар инде, дисең. Күрәсең, язучыларның күп язуы, редакцияләрнең басылмаган әсәрләр белән күмелеп ятуы безне шуңа этәрә. Әйдә, ярар инде, бу иптәш күптәннән йөри бит, юньле генә иптәш күренә, басыйк инде, дип әсәрен бастырабыз. Әсәре басылган иптәш бераздан аны күтәреп Союзга килә, член итеп алуларын үтенә. Алыр идең — таланты юк, алмас идең — басылып чыккан әсәре бар бит. Әнә шулай итеп «урта куллар» сафы ишәя, әдәбиятның гомуми фоны төссезләнә.

**Вакыйф Нуруллин, язучы, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы:**

М. Мәһдиевнең чаң кагуы аңлашыла: яңалык, кимчелекләрдән арына барып, үзенә юл сала. Тулаем алганда, әлбәттә, әдәбиятыбызның төп төсен уңышлар билгеләде.

«Совет җәмгыятенең рухи тормышы һаман күп төрлерәк һәм баерак була бара. Бу — культурабыз, әдәбият һәм сәнгатебез эшлеклеләренең бәхәссез нәтиҗәсе». Партиянең XXVI съездында бүгенге совет әдәбиятына әнә шундый зур бәя бирелде. Бу бәя безнең татар әдәбиятына да тулысынча кагыла. Чыннан да, әдипләребезнең иҗат активлыгы елдан-ел арта. Әсәрләребезнең сәнгатьчә эшләнеше камилләшә бара. Һәрхәлдә, илебезнең әдәбият табынына куелган рухи азык (ягъни китаплар) арасында безнең әдипләребез өлеше йөз кызартырлык түгел. Съезд документларында бурычлар да бик житди һәм конкрет итеп күрсәтелгән. Менә шул ноктадан карaганда, бездә эшләр ничегрәк тора соң?

Дөресен генә әйткәндә, бүгенге прозабызда барысы да ал да гөл дип әйтерлек түгел шул әле. Билгеле, басылган әсәрләр арасында үзебезнең әдәбият өчен вакыйгага булырдайлары да күренгәләп ала. Соңгы ике-өч ел эчендә дөньяга чыккан әсәрләрдән Атилла Расихның «Сынау» романын, Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» повестен мин шундыйлар рәтенә кертәм.



*Ә. Еники: «Борчылу тойгысы ул — чын язучының табигатендә».* (Уңда Н. Арсланов)

Шулай да мин М. Мәһдиев фикеренә кушылам: безнең прозабыз әлегә урта кул дәрәҗәсеннән уза алмый. Талантлы прозаикларыбыз байтак булса да, кызганычка каршы, без әле Ч. Айтматов, В. Распутин, В. Быков, В. Астафьев, И. Авижюс, Ф. Абрамов әсәрләре белән рәттән торырлык, Бөтенсоюз күләмендә вакыйга булырлык повесть һәм романнар бирә алганыбыз юк. Бу мәсьәлә мине бер бүген генә түгел, күптәннән борчып килә. Чөнки мең еллык тарихы булган, заманында илебезнең бөтен төрки халыклары арасында исемнәре танылган Тукайларыбыз, Галимҗан Ибраһимовларыбыз, Такташларыбыз булган әдәбиятыбызда минем бүген дә зур фигураларны күрәсем килә.

Хикмәт нәрсәдә соң? Нигә безнең прозабызда ил күләмендә вакыйга булырлык әсәрләр һаман әле туа алганы юк? Моның төп сәбәбе, Гомәр ага әйткәнчә, безнең үзебездә булса кирәк: барына канәгать булып, әдәби традицияләребез бай дип тынычланып, пошмыйча, ямьмыйча яшәвебездә. Кайсыбызның әле авыл халкы арасында яшәп, аның тормыш-көнкүрешен ныклап торып өйрәнгәне бар? Кайсыбызның шәһәрдәге хезмәт кешеләре тормышын җентекләп өйрәнгәне бар? Ә бит шунсыз бүгенге укучының күңелен җәлеп итәрлек, аны чынлап торып уйландырырлык, аңа сабак яки үрнәк алырлык әсәрләр иҗат итү мөмкин түгел. Язучының үзе яза торган өлкәдә ныклы һәм заманча мәгълүматы булу мәҗбүри. Гариф Ахуновның моннан егерме еллар ук элек язылган «Хәзинә» романын әле һаман әйбәт роман дип телгә алабыз икән, Шамил Бикчуринның «Каты токым»ы чит илләрдә дә басылып чыккан икән, моның төп сере шунда, әлегә авторлар икесе дә үзләренең геройлары тормышын еллар буе һәр яклап өйрәнеп-белеп яздылар.

**Сибгат Хәким**, шагыйрь, РСФСРның М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты:

Яңалык... Гомеремнең ахырына якынлашкан саен, юлда йөреп узган кешнәремне уйлап шатланам. Олыгая төшкәч, картайгач, ул кайнап узган елларның кирәклеген ныграк тоясың икән. Еллар йомгагын әкренләп сүтәсең, уйларыңда үткәннәргә кайтасың — язылган, язылып бетмәгән, картлыкка да калган... Менә кайчан икән тешә икән ул тормыштагы активлык. Язучының активлыгына мин күп нәрсәне кертәм. Шул күп нәрсәне бергә җыйган сүз — тынгысызлык. Җанның тынгысызлыгы. Туктаусыз уйланып, борчылып яши торган җан. Мин аны үзем өчен эзләнү дип тә йөртәм. Күңел туктаусыз эзләнә. Нәрсәдер җитми аңа... Шул ук сүз белән янәшә торган тагын бер төшенчә: канәгатьсезлек. Үз-үзеннән канәгатьсезлек. Шагыйрьне шулар йөртәдер тәгаен. Сугышны күрдем, тамам арып, авырып кайттым. Бераз хәл кердә, яңадан шул урыннарга сәйрәде җан. Нәрсә калган, нәрсәне әйтеп бетермәгәнмен, әйтеп бетерәсе иде.



*Г. Ахунов: «Татар прозасы, татар драматургиясе ил күләмендә ныклап, зур йөк күтәреп чыга башлады.»*

Туган якка күпме кайттым икән мин үз гомеремдә. Кешеләр бер кунак булып килү дип кенә уйлыйлар. Ә мине кайтып-кайтып та сөйләп бетереп булмаган нәге хис газаплый. Шигырьдә, җырда язып карыйм, юк — ул хис тирәндә. Ә җир үзе гап-гади, кешеләре гади, яшәешләре гади. Җир һәм кеше, хезмәт һәм кеше... Тормышның нигезе... Кешелек дигән сүз үзе дә табигать эченнән калыккандыр сыман. Кешеләр торган саен шул табигатькә, гадилеккә кайтырлар. Мин хәзер үк инде нәрсәләрнедер оныта барганыбызны сизәм. Шагыйрь күңеле җирдәге изгелекне

җырларга тиеш. Ә ул миңа кайчак җәйге тын һавада уйнаган рәшә шикелле тоела. Кешеләрнең, буыннарның рухлары өзлексез уйный кебек анда.

Син тота алмаган хистән дә авыррак нәрсә юк дөньяда. Шул хис мине 1966 елны Германия Демократик Республикасына илтте. Аерылып бетмәгән сугыш хатирәләре, Мусалар язмышы илтте. Быел яңадан шул ук урыннарга чакырды шул хис. Нәрсә турындадыр зур итеп сөйлисе килә. Бөтен Европа буйлап әзлим мин ул хисне. Миңа аның бер генә юлы кирәк. Борчулы, драматик юлы. Шул юлны тапкач мин өемә ашкынам, кечкенә генә бүлмәмә ашкынам, инде миңа бүтән бернәрсә дә кирәкми, мин бөтен кешеләрдән бәхетле ул чакта.

Дөньяда иң яратмаган нәрсәм — китаплардан укып җыелган хисләрне яңадан кабатлау. Тормышның үзеннән чумырып алган хисләргә ни җитә! Яңалык, ничек бәхетле итәсең син шагыйрьне. Яшәсен тормыш, яшәсен борчулы җаным.

**Ризван Хәмид, драматург:**

Тормышның үзеннән чумырып алган хисләр турындагы фикерегезне куәтләп, Сибгат ага, әдәбиятта яңалык тойгысы, тормыш чынбарлыгын дөрес тасвирлауга якынаю белән бәйле, дип конкретлаштырасы килә. Һәр чор үз героен тудыра. Язучы, драматург аны алдан тоя белергә, ул геройны үсеш процессында, перспективалы итеп сурәтләргә тиеш. Без моны дөнья әдәбияты мисалында бик яхшы күрәбез. Әйтик, танылган Америка драматургы Теннесси Уильямс «Хыял трамвае» драмасын кырыгынчы елларда ук яза. Пьесаның үзәгендә — гади кеше, үзе әйтмешли, «йөз процентлы» американ. Аның яшәү принцибы — көчлеләргә зәгыйфьләр буйсынырга тиеш. «Заман безнеке хәзер»,— ди ул һәм үзен хуҗа итеп тота. Бу драма Америкада бик күпләрне шаккатыра, авторны уйлап чыгаруда гаеплиләр. Ләкин берничә ел үтми, бөтен Американы әнә шул персонаж кебек кешеләр басып ала. Белгәнебезчә, хәтта президентлар да гади фермерлар, артистлар арасыннан сайлана башладылар. Димәк, Теннесси Уильямс тормышта борынлап кына килә башлаган яңалыкларны алдан күрә алган.

Тагын бер бик кызык күренешкә игътибар итик. Ул — авторның әдәби персонаж язмышына карата мөнәсәбәте. Берничә мисал китереп үтик. Островскийның «Яшенле яңгыр»ында Катеринаның үлеме чынбарлыкка чакыру ташлау, рухи батырлык булып яңгырый. Ә Чехов пьесаларында шундый ук үлемне башка персонажлар хәтта сизми дә калалар. Үлем — көлке хәлгә әйләнә, көчсезлекне, булдыксызлыкны раслый. Гарсиа Лорка әсәрләрендә исә үлем, үтерешүләр яшәү нормасы итеп бирелә. Хикмәт нәрсәдә? Островский заманында кеше үзенә-үзе хуҗа булмаган, Чехов иҗат иткән чорларда кеше беркемгә дә кирәкми торган «югалган дәверләрне» тәшкил иткән, ә Гарсиа Лорка фашизм килүен күргән. Җыйнап әйткәндә, без әдәби яңалыкны авторның чорга һәм герой язмышына мөнәсәбәтендә күрәбез.



*Зәки Нури: «Яңалык тойгысы язучылар алдына зур бурычлар куя».*

Әлбәттә, яңалык формада да булырга тиеш. «Тәртибе — ноль» исемле бер француз фильмын карарга туры килгән иде. Фильм мәктәп тормышыннан алынган. Ул тамашачыны беренче кадрларыннан ук гаҗәпләндерә: персонажлар искиткеч зур гәүдәле, өстәл, урындыклар ярты экранны каплап тора. Соңыннан аңлашыла: бу кино кечкенә укучы бала биеклегеннән төшереп алынган икән. Аның эчтәлеге әллә ни шаккатырлык түгел, ә бу алым көтелмәгән зур эффект бирә. Иң әһәмиятлесе —

картина бик табигый кабул ителә. Димәк, форма яңалыгы табигыйлектән аерылгысыз булырга тиеш.

**Гариф Ахунов, язучы, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:**

Иптәшләр байтак кына кызыклы фикерләр әйттеләр. Әйтик, әдәбиятта яңа юнәлеш — миф, фантастика алымнарының прозага, роман-повесть кебек зур күләмле әсәрләргә килеп керүе турында сүз булды. Димәк, әдәбиятта яңалык төшенчәсен без, бер яктан, форма белән бәйлибез. Моңа мисал итеп Ч. Айтматовның «Гасырга тиң көн» романын, дөнья әдәбияты әсәрләрен китерәбез. Мин әдәбиятта форманың яңарып торуына һич тә каршы килмим. Форманың яңаруын, камилләшүен чор, дәвер үзе билгели. Без хәзер утызынчы еллардагы чамадан тыш ялыктыргыч сөйләп бирү алымы белән яза алмыйбыз. Заман тыгызлыкны, фәлсәфилекне, психологик тирәнлекне таләп итә. Әнә ул тирәнлекне һәм тыгызлыкны В. Астафьев, В. Распутин кебек яңа заман язучылары алып килә. Болары мифлар белән шөгыльләнми, болары рус тормышын — борынгысыннан башлап, бүгенгесенә кадәр — күңелдән уздыра, геройның хәзерге халәтен, психологик киеренкелеген үткәнгә бәйли, киләчәккә күз сала. Боларның иң отышлы яклары халык телен, халыкның мең еллык тарихын, гореф-гадәтләрен яхшы белү. Бездә андыйлар рәтенә Әмирхан Еникинең шигъри югарылыкка күтәрелгән һәм трагизм дәрәҗәсенә җиткерелеп драматикалаштырылган прозасын кертергә була.

Мин үзем, әдәбиятның тышкы кабыгы яңарудан бигрәк, аның эчке дөньясы баюын, кеше җанына отыры тирәнрәк үтеп керүен яклыйм. Бу мәсьәләдә Туфан Миңнуллин белән килешәм. Әмма ул әйтә, драматургиядә массовый сәхнәле, күп кешеле әсәрләр кими, аз кешеле әсәрләр, кеше җанына тирәнрәк үтеп керә торган әсәрләр күбәя бара, ди. Бу — нигездә дөрес фикер. Ләкин драматургия алга таба бары тик аз кешеле әсәрләр исәбенә генә үсәр дип фараз кылсак, бигүк дөрес булыр микән? Тарихны, эпиклыкны, халык массаларының океан дулкыннарыдай шаулап, яңа заман сулышын алып килүен югалтмабызмы аз кешеле, төгәлрәк итеп әйткәндә, дүрт-биш кешеле пьесалар белән? «Оптимистик» трагедияләр, «Любовь Яровая»лар, «Зәңгәр шәл» һәм «Ташкыннар» алып килде бит тарихи дәверләрне. Юк, мин драматургиянең бер яклы үсүен алга сөрмим, полифония дә, симфония дә булсын.

Бу сөйләшүдә, безне уртакул әсәрләр басып китте, соңгы елларда басылып чыккан романнарда һәм повестьларда уй-фикер юк, алар гамьсез язылган, диделәр. Килешү кыенрак бу бәя белән. Әдәбиятның үсешен, нигездә, талантлы әсәрләр билгели дип алсак картина киресенчә түгелме? Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Җомга көн кич белән» повестьларында фикер юкмыни? Алар гамьсез язылган әсәрләрмени? Альйк Мөхәммәт Мәһдиевне. Аның «Фронтовиклар» романы, «Ут чәчәге», «Кеше китә — җыры кала» повестьлары уй-фикерсез язылганмыни? Яки Миргазиян Юнысның «Табу һәм югалту» повесте, «Энҗе эзләүчеләр» исеме белән чыгарылган хикәяләр җыентыгы уй-фикерсез әсәрләрмени? Һич юк. Җитмешенче еллар башында әдәбиятка килгән Әхәт Гаффар, Марсель Галиев, бигенләй дә яшь Нәбирә Гыйматдинова хикәяләрендә дә уй бар, гамь бар, фикер бар. Бу — чынлап торып уйласаң — татар совет әдәбиятының соңгы еллардагы иң көчле агымы. Моңарчы булган байтак әсәрләрдән аерылып торган агым, яңалыкка, тирәнлеккә, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә битараф калмавы. Менә шуңа күрә дә татар прозасы, татар драматургиясе ил күләменә ныклап, зур йөк күтәреп чыга башлады.

**Азат Әхмәдуллин, тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире:**

«Зур йөк күтәреп, ныклап», диген сүзләрдә хаклык бар, әлбәттә. Фикер ягыннан булсын, жанр үзенчәлекләрен үзләштерүдә һәм формада яңа табышларга ирешүдә булсын — бүгенге әдәбиятыбыз һәм, аерым алганда, драматургиябез билгеле бер яңарыш һәм үсеш чоры кичерә.

Шулай да драматургиябезнең артта калуын да танырга тиешбез. Тормыштан, чынбарлыктан, җәмгыять үсешеннән артта калуын. Без гаҗәеп заманда яшибез. Ил күләмендә дә, дөнья күләмендә дә глобаль проблемалар, искиткеч катлаулы

мәсьәләләр туа тора. Димәк, җәмгыять үсешендәге яңа күренешләр, кешеләр аңында, дөньяга карашында килеп чыккан үзенчәлекләр билгеле бер гомумиләштерү һәм сәнгать иләге аша үтеп сәхнәгә чыгарга тиеш. Чынлыкта шулаймы соң? Кистереп кенә уңай җавап бирүе кыен.



*Т. Миңнуллин: «Язучы һәр геройның рухи анатомиясен ачарга, һәрберсен шәхес дәрәҗәсенә күтәрергә тиеш».*

Мәсәлән, тормыш тарафыннан көн тәртибенә куелган бер проблемага гына игътибар юнәлтәсем килә. Элек мәктәпнең төп бурычы балаларга гомуми белем бирү, аларга киләчәк тормышта, профессия сайлаганда кирәк булачак белемнәрнең нигезен бирү иде. Баланы хезмәт белән тормыш үзе тәрбияли иде. Хәзер мәсьәлә үзгәрде һәм катлауланды. Мәктәпнең балаларга хезмәт тәрбиясе бирүдә роле артты, алай гына да түгел, хәлиткеч төс алды. Бу — тормышчан һәм мөһим проблемаларның берсе генә әле. Ә бүгенге сәхнә шул проблемаларны хәл итүдә күпме ярдәм күрсәтә? Драматургларыбыз шул тормышчан проблемаларны сәнгать проблемалары итеп күтәрәләрме? Шул җәһәттән драматургиядә Диас Вәлиев алып барган эзләнүләр игътибарга лаек тоела. Аның «Дәвам», «Диалоглар» кебек драмаларында нәкъ менә кешенең кыйммәте, аның рухи байлыгы һәм гражданлык позициясе хезмәт процессына мөнәсәбәттә ачыла.

Бүгенге драматургия җиңеп үтәсе авырлыклар тематик киңлек җитенкерәмәүгә дә карый. Бездә революцион тарих темасы сыегайды. Бүгенге данлы эшчеләр сыйныфы, аерым алганда, нефтьчеләр турында, башка төр профессия кешеләре хакында пьесалар аз языла. Сәхнәдә яңа профессия кешеләре чагылу — ул шул ук яңа хезмәт формаларының сәнгатьчә чагылышы, тамашачыны хезмәт белән тәрбияләүдәге яңа бер төсмер ул. Театрда герой үткән һәм бүгенге хезмәт процессы тулы чагылмау, үзеннән-үзе, драматургиянең героик пафосы түбәнәюгә китерә. Ә тамашачыга героик пафосның, романтик күтәренкелекнең, публицистик үткенлекнең ни дәрәҗәдә кирәк һәм кадерле булуын Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр»ы тагын да бер кат раслады.

Бүгенге сәхнә стиль һәм форма яңалыкларына да сизгер. Мәсәлән, шартлы-метафорик алымнардан файдалану көчәйде. Шулай да соңгы еллар драматургиясендә сюжет ярлылыгы сизелә. Хәтта драматурглар һәм тәнкыйтьчеләр арасында сюжетка кимсетебрәк карау бар. Хәлбуки тыгыз, хәрәкәтчән һәм катлаулы сюжет пьесаның тамашачыга барып җитү мөмкинлеген бермә-бер арттыра.

**Туфан Миңнуллин:**

Еш кына без әсәрләрне теге яки бу темага язылуына карап бәялибез. Ләкин бары тик тема артыннан гына куганда кешеләрне онытып җибәреп ялгышабыз. Нинди генә темага язсак та, әсәрләребездә кешенең, бүгенге кешенең рухи дөньясына игътибар төп үзәктә булырга тиеш. Кем булып, кайда гына эшләвенә карамастан, һәр кеше безнең өчен кадерле.

Без ФТР заманында яшибез. Техниканың гаҗәеп тизлек белән безнең көнкүрешебезгә ныграк керүе, көчлерәк тәэсир итүе кешенең үз дәрәҗәсен киметмиме дигән сораулар еш әйтелә. Бәлки шулайдыр, бәлки кеше икенче планга кала барадыр? Бу сорауга төгәл җавап бирергә алынмыйм. Әмма әдәбиятта кеше үзен-үзе ныграк эзли башлады, үз кадерен аңлый башлады дип әйтеп буладыр. Проблемалар үзәгендә — кеше. Бу — әдәбиятның төп законы. Шул законнан читкә тайпылсак — без искеләр, аны намус белән үтәсәк — һәрвакыт яңалар. Чөнки заман яңарган саен, кеше-

ләр дә яңара, яңа кешеләр турында язу әдәбиятка һәр көн яңалык алып килә.

**Вакыйф Нуруллин:**

Тема мәсьәләсенә карата берничә сүз. Туфан, давайте, иптәшләр, әдәбиятта «тема» дигән сүзне кулланмыйк, диде. Туфанга хас булганча, бераз арттырыбрак, образлырак итеп әйтсә дә (чөнки «әдәбиятта тема» сүзен кулланмыйча мөмкин түгел), нигездә, ул хаклы. Чыннан да, тема актуальлегенә аркаланып, әдәби эшләнешләре ягыннан шактый сыек әсәрләр һаман чыккалап тора. Сүз дә юк, безнең әсәрләрдә хезмәт ияләренең тормыш-көнкүреше, уйхисләре, максат-омтылышлары чагылдырылырга тиеш. Ләкин безгә аларны тулы канлы образлар, җанлы кешеләр итеп, тормыштагыча бөтен рухи нечкәлекләре белән сурәтләп бирүгә ирешергә кирәк. Безнең геройларыбыз еш кына тар мөхиттә яши, үз каланчаларыннан торып кына фикер йөртәләр. Ә бит тормышта алай түгел. Бүгенге гади эшчеләрнең һәм колхозчыларның да ил күләмендәге, дөнья күләмендәге вакыйгалар белән якыннан кызыксынып яшәүләре һәм бу җәһәттән кайбер югары белемле интеллигентларга караганда да тирәнрәк фикер йөртүләре бересезгә дә сер түгел ләбаса!

Кыскасы, язучы халкына таләп зур. Бүгенге укучыны тема актуальлеге белән генә җәлеп итеп булмый. Аны, барыннан да бигрәк, безнең әсәрләрдәге кешеләрне рухи дөньясы, чынбарлыкка мөнәсәбәте нинди булуы кызыксындыра.

**Рашат Низамиев, шагыйрь:**

Әйе, әдәбиятның төп объекты — кеше, кеше җаны, кеше рухы. Адәм баласы биологик яктан гына үлә. Аның хыялы, күңел хәзинәсе, кылган гамәле, теләк-омтылышлары, акыл куәсе — үлемсез. Тормыш давылларының уртасыннан атлап баручы кеше кискен хәлләрдә кайсы юлны сайлый, нинди идеалларны юлдаш итә? Яңалык тойгысын, беренче чиратта, әнә шундый сорауларны сәнгатьчә хәл итә белү, димәк, кешене ачу, ача белү осталыгы белән билгеләргә кирәктер.

Әйе, сәнгать әсәре чын мәгънәсендә ачыш булырга тиеш. Шул чагында гына ул йөрәгебезгә һәм акылыбызга йогынты ясый ала, дөньяны танып-белүдәге рухи тәҗрибәбезне баета. Мисаллар эзләп ерак барасы юк. Әйтик, үзенең «Тынычлану» дигән хикәясендә гомернең бик тә кадерле нәрсә булуы, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең гаять тирән мәгънәгә ия икәнлеге турында сөйләп, Әмирхан ага Еники һәммәбез өчен дә зур ачыш ясады. Драматург Туфан Миңнуллин исә кыю рәвештә «Адәм баласына ял кирәк!» дип чаң сукты. Һәм шушы аваз һәммәбезне сискәндерде, айнытып җибәрде, тормыш мәшәкатьләренә чумган акылыбызны өскәрәк, югарырак күтәрде. Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» исемле повестенда яшәү мәгънәсе, кеше күңеленең матурлыгы хакында кат-кат уйландырды. Әдәбиятыбыз тагын да үссен һәм көчәйсен өчен әнә шундый ачышлар мул кирәк. Иҗат эшенең зурлыгын тойган өлкәннәр дә, «шедевр» язарга хыялланучы яшьләр дә бу хакта туктаусыз уйланырга бурычлылар.

Без — бүгенге көн балалары. Тирә-ягыбыз тормыш белән, серлелек белән, яңалык белән мөлдерәмә тулы. Яңалык үзе һәр язучыны сагынып, көтеп тора...

**Нури Арсланов, шагыйрь:**

Бу сөйләшүдә без билгеле бер фикергә килә барабыз шикелле: яңалык дигән нәрсә, чыннан да, иң элек әдәби әсәрнең тематикасында, проблематик чишелешендә, сәнгатьчә сурәтләү чараларында чагылыш табадыр ул. Әмма мәсьәләне шуның белән генә чикләп кую да дөрес булмас иде. Укучы күңелен яулап алырлык, аны мәхәббәт яисә нәфрәт давылларына салып тетрәтерлек хисләрне бирү өчен бик шәп тел дә кирәк бит әле, иптәшләр! Әгәр сүзләрең салкын, җансыз икән, алардан тормышчан кайнарлык бөркелеп тормый икән, өр-яңа теманы да әрәм итәргә мөмкин.

Әйтәсе килгәнем шул: безгә киләчәктә әдәби тел мәсьәләләренә игътибарны бик нык көчәйтергә кирәк. Көндәлек матбугатта чыккан кайбер шигырь үрнәкләрен укып караганнан соң аптырашта калырга, алай гына да түгел,— борчылырга, хафаланырга туры килә. Урынлы-урынсыз кулланылган сүзләр дисеңме, урамда яисә кайсыдыр төбәктә генә сөйләшенә торган сүзләр дисеңме,— гөнаһ шомлыгына каршы, һәммәсе дә оялмыйча шигърият түренә кереп баралар.

Һәркем үзе теләгәнчә, үзе аңлаганча гына яза башласа, әдәби телебез дә дөрес юлдан үсмәячәк. Әдәбиятның киләчәге —

яшьләр кулында, шуңа күрә яшьләр тел мәсьәләсендә аеруча сак булсыннар иде.

**Ә м и р х а н  Е н и к и, язучы:**

Тел һәм форма үзенчәлегенә кагылышлымы ул, сурәтләү объектына мөнәсәбәт белән бәйлеме, яңалык тойгысы — язучы өчен бик кирәкле сыйфат. Нури Арсланов дөрес әйтә: Бигрәктә ул яшьләрдә үткен булырга тиеш. Ләкин мин яңалык тойгысына борчылу тойгысын да өстәр идем. Юк, бу ике тойгыны бер-берсенә һич тә каршы кую түгел. Яңалык тойгысы — эзләнү, алданрак күрү, тизрәк аңлау... Ә борчылу тойгысы ул чын язучының табигатендә. Ихтимал, Достоевский белән Толстойны бөек язучы иткән төп сыйфат та шул борчылу тойгысы булгандыр... Безнең Тукайны гына алыгыз — бөтен иҗаты борчылудан гыйбарәт бит!.. Билгеле, бу тойгыдан хәзерге язучылар да мәхрүм түгел, чөнки заманының үзендә уйландырырлык һәм борчылырлык мәсьәләләр туып кына тора. Безнең заманда андый мәсьәләләр күбрәк тә һәм зуррак та әле. Әйтик, җир йөзендә тынычлыкны яки табигатьне саклау мәсьәләсе бөтен дөньяны борчый торган проблемага әйләнмәдемени?! Шулай ук безнең үз тормышыбызда да борчылырга мәҗбүр иткән тискәре күренешләр яки хәл ителүен көткән җитди мәсьәләләр азмыни? Кыскасы, гамьсезлек язучыга хилаф нәрсә, гамьсез язучыдан юньле әсәр дә көтеп булмый.

Әмма язучыны борчыган күп төрле мәсьәләләр үзәгендә кем тора? Әлбәттә, кеше!.. Чынлап та, тормыштагы бөтен яхшылык һәм яманлык, гаделлек һәм гаделсезлек, миһербанлык һәм кансызлык, матурлык һәм ямьсезлек, ниһаять, бәхет һәм бәхетсезлек кешегә, дөресрәге, кешенең кем булуына кайтып кала. Моның мең төрле мисалларын китерергә мөмкин булыр иде. Әйтергә кирәк, кеше гаять катлаулы һәм каршылыклы җан иясе, барлык уңай һәм тискәре сыйфатлар аның табигатендә булырга мөмкин. Тик берәүләрдә шуның уңае, икенчеләрдә тискәресе өстенлек ала. Ни өчен? Моның сәбәпләре бик күп, тикшерә башласак, без бик тирәнгә кереп китәр идек... Әмма бер хакыйкатьне ачык әйтү кирәктер: барысыннан да битәр, кеше җәмгыять әгъзасы ул, җәмгыятьтә, үзе кебек кешеләр арасында яши. Димәк, аның үз-үзен тотышы, тормыштагы позициясе турыдан туры җәмгыять үсешенә кагыла, барлык кешеләргә дә килеп тия. Минә ни өчен язучы беренче нәүбәттә кеше турында уйларга һәм борчылырга мәҗбүр. Безнең тормышта һәр төрле начарлык, түбәнлек, гаделсезлек булмасын өчен кешедәге тискәре сыйфатларны бетерү, яхшысын ничек тә үстерү язучының гражданлык бурычы... Миңа калса, әдәбиятның иң төп максаты да кешене яхшы итүдән, киләчәк кешесе турында уйланудан гыйбарәт.

**М ө д ә р р и с  В ә л и е в, журналның әдәби тәнкыйть һәм сәнгать бүлеге редакторы:**

Бу сөйләшүдә төрле буын язучыларының катнашуы үзе бер мәгънәле һәм кызыклы фал. Шуңа күрә бүген аксакалларның артык җитдилеге һәм сабырлыгы, яшьтәшләремнең исә гадәттәгедән акыллырак булып күренергә тырышуы да аңлашыла. Чыннан да, сөйләшү бик зур мәсьәләләр, әдәбиятның алтын баганасы булырдай канУннар турында бара.



*Р. Мостафин: «Мин прозадагы яңарыш процессы турында сүз йөртергә мөмкин дип уйлыйм».*

Әмирхан ага Еники дә, Нури ага Арсланов та, яңалыкка бигрәк тә яшьләр сизгер булырга тиеш, диделәр. Иҗатның, го-

мумән, яңалык тойгысыннан башка була алмавы болай да мәгълүм, әлбәттә. Өлкән язучыларның тел төбендә шундый бер киная ята шикелле: сүз күбрәк әдәбиятның киләчәгенә, димәк, яшьләргә кагыла, дип әйтергә телиләр бугай алар.

Яңалык тойгысы, һичшиксез, әдәбиятка яңа исемнәр килү белән дә бәйләнгән. Әдәбиятыбыз ирешкән биеклекләр яңа буын язучыларның ил-көн алдында җаваплылыгы тагы да зуррак булуын искәртеп тора. Гадәтсезлек һәм өлкәннәрне тәкъдир итмәү булып тоелмасын,— иртәгесе көннең иң яңа сүзен без яшьләрдән көтәбез. Шагыйрь Зөлфәт, прозаик һәм драматург Әхәт Гаффар язганнарны ныклы иман, чынбарлыкны заманның иң алдынгы карашлары күзлегеннән бәяләү, җәмгыятебезнең идея һәм әхлак нигезләрен яклап көрәшү кебек төп сыйфатлар берләштерә. Шулай да аерым әсәрләребездә китаптан килү һәм сүздән мөгез чыгарырга азаплану, мөһим мәсьәләләрне һәм кичерешләрне ваклау күренеп китә икән,— бу — яшь авторларның тормышка үз мөнәсәбәте, җитди фикере булмау билгесе. Вакытында «диагноз» куярга, яман чиргә әверелеп китәргә юл калдырмаска, яшьлеккә генә сылтамаска кирәк. Шуңа күрә, әдәбиятта, аерым алганда яшьләр иҗатында, һәртөрле «шартлылык», «миф», «көнкүреш» проблемаларыннан бигрәк, язучының тормыш позициясе дигән мәсьәлә борчырга тиеш безне дип әйтәсе килә.

Заманымның иң якты идеяләренә хезмәт итәргә әзерменме? Халкыбыз тарихын, бүгенгесен һәм киләчәген үз күңелемнән кичерә аламмы? Дөньядагы барча төсләрне туган илгә мәхәббәтем аша аерырлык көчем бармы? Чын мәгънәсендә яңалык тойгысы, күрәсең, менә шул сорауларга намуслы җавап биргәндә генә киләдер.

**Гомәр Бәширов:**

Чыннан да, тормыш позициясенең дөреслеге һәм ачыклыгы бик мөһим мәсьәлә. Язучы меңтөрле җепләр белән тормышка тоташкан. Ул, сейсмограф кебек, җәмгыятьтә булган үзгәрешләрне, заман таләпләрен сизеп, аларга үзенең мөнәсәбәтен һәрдаим билгеләп торырга, үзенең иҗаты белән вакытында җавап бирә барырга тиеш.

Авыл темасына язучы әдип буларак, миңе бу мәсьәлә барыннан да бигрәк менә шушы темага кагылышы ягыннан, шуңа бәйләнешле рәвештә кызыксындыра. Үз иҗатымда мин төп мәсьәлә, төп тема итеп элекке игенче агайның яңа заманда, ягъни совет власте шартларында кеше буларак үзгәрә баруын, яңа сыйфатларга ия булуын өзлексез рәвештә күзәтеп барырга тырыштым. Хәзерге авыл кешесе ниндирәк рухи тормыш белән яши, анда яңа җәмгыять кешесенә хас нинди сыйфатлар өстенлек итә? Шул ук вакытта аңа нинди сыйфатлардан арынырга кирәк! Бу тема минем өчен бервакытта да искерми, ул минем алдыма һәр заманда үз чорына хас таләпләре, үзенчәлекләре белән яңа булып килеп баса.

Безнең кешеләрнең холкында-фигылендә барлыкка килгән яңа күркәм сыйфатларны язу, ягъни совет җәмгыятендә кешенең рухи яктан үсә баруын күрсәтү — әдип өчен бик шатлыклы, һәм куанычлы вазифа. Мин андый сыйфатларны энҗе эзләгән кебек бөртекләп җыярга, аңа көчемне кызганмаска һәрвакыт әзер. Бу— тормышта яңалыкны күрергә тырышу дигән сүз.

Ләкин шушы үсеш процессында барлыкка килгән кайбер кимчелекләр дә күңелне борчый. Мәсәлән, тормыш-хезмәт шартларының кешеләр арасындагы мөнәсәбәткә торган саен ныграк тәэсир ясавы барыбызга да мәгълүм. Производство кешеләрне якынайта, фикердәшлек, рухи туганлык җепләрен ныгыта. Шул ук вакытта без кан кардәшләрдән ераклаша бармыйбызмы, туганлык, кешелек җылысыннан үз-үзебезне мәхрүм итмибезме? Минемчә, бу күренеш — социологлар һәм педагоглар тарафыннан да, әдәби әсәрләребездә дә һәрьяклап өйрәнелергә тиешле өлкә.

Табигатькә яңача мөнәсәбәт тәрбияләү дә хәзерге көндә язучылар өчен иң җаваплы бурычлардан берсе дияр идем мин. Табигый байлыкларыбызның иксез-чиксез булуы халыкта аңа карата ваемсыз, битараф караш тууга сәбәп булган. Чишмәләре, күлләре корып, урманнары, әрәмәләре киселеп, бер шыксыз хәлгә калган икән, андый авылда яшьләрне тоту мөмкин булмаячак. Туган якка мәхәббәт — абстракт бер нәрсә түгел. Яшьләрдә патриотизм тойгысын үстерү мәсьәләсен гомумкешелек хисләре тәрбияләү белән комплексга, туып-үскән төбәккә, аның табигатенә сак мөнәсәбәт белән бергә бәйләп карарга кирәк. Шуңа күрә дә авылларның

үз төсен, үз матурлыгын саклау авыл турында язылa торган әсәрләрнең дә төп максаты булырга тиеш.

Бу хакта сүз чыкканда кайбер кешеләр, хәзер инде чишмәле, сандугачлы авыл турында сүз бармый, бүгенге авылның табигате башкача, «заманча» матур булырга тиеш диләр. Әлеге иптәшләр, күрәсең, авыл пейзажына индустрия элементлары естәлүне күз алдында тоталар булыр. Файдалана белгәндә алар бер-берсенә һич комачауламыйлар, бәлки, киресенчә, берсенберсе тулыландыралар. Ә нигә хәзерге заман кешесе чишмәле, инешле, сандугачлы табигатьтән ваз кичәргә тиеш икән? Замандашыбызның матурлыкка ихтыяҗы тагын да арта, аның эстетик зәвыгы тагын да төрләнә, камилләшә бара бит! Безгә менә укучыларыбызны шул матурлыкны күрергә, шуннан ләззәт ала белергә өйрәтергә, моңа ирешү өчен, ул матурлыкны яңача, заманча күрсәтергә кирәк.

**Роберт Миңнуллин, шагыйрь:**

Яңалык тойгысы дибез. Кешегә якынаю дибез. Әмма балалар әдәбиятын, шул исәптән балалар поэзиясен, бөтенләй онытабыз түгелме? Биредә Т. Миңнуллин белән М. Мәһдиев күтәргән мәсьәләләр, Гомәр ага Бәшировны борчыган табигать һәм авыл проблемалары — барысы да балалар әдәбиятына да турыдан-туры кагыла. Әйтик, ялгызлык проблемасы. Безнең чорда һәр гаиләдә дүрт-биш бала үсте. Әле ул чакта безнең белән бергә Тимур да, Васек Трубачев та, маякчы кызы Илсөяр дә, Шәвәли дә булды. Алар безнең чын мәгънәсендә иптәшләребез иде. Ә хәзер аларга дәвамчы булып нинди геройлар килә? Һәр өйдә, һәр квартирада бер бала да бер телевизор гына калып бара түгелме соң? Балалар иң сизгер халык. Яңалыкка омтылучан җаннар. Ә без нәкъ менә яңалыклар заманында, информация «бумы» чорында яшибез. Баланы гаҗәпләндерү, сокландыру ифрат дәрәҗәдә авырлашты, катлауланды. Шуңа күрә балалар өчен язылган әсәрнең, аерым алганда балалар шигыренең, һәр детале, һәр хәрефе уйланылган, төгәл һәм гади (билгеле, кирәк чакта катлаулы да) организм булырга тиеш. Татар балалар поэзиясе бары тик уенкөлкеле шигырьләрдән генә тора дигән фикер уздыручылар бар бездә. Чынында шулаймы соң? Юк, әлбәттә! Балалар поэзиясендәге юмор, нигездә, шигырьне укучыга тәкъдим итү формасы гына ул.

Аннары, дидактика мәсьәләсе. Бала туганнан бирле үгет-нәсихәт белән шигырьдән башка да еш очрашып тора. Ләкин безнең байтак кына балалар шагыйрьләре ни өчендер дидактика белән күбрәк мавыга.

Яңалык тойгысын шигырьнең тышкы формасына гына кайтарып калдыру очраклары да бар. Экспериментлар кирәк, әлбәттә. Ләкин турыдан-туры нәниләрнең рухи дөньясында тәҗрибәләр уздыру, миңа калса, педагогикага да, этикага да сыя торган күренеш түгел. Андый шигырьләрнең төп кимчелеге — балаларның үз дөньялары чагылмауда, тышкы бизәкләргә генә корылуында. Һәр заманның — үз атрибуты. Заман үзгәрә. Иске атрибутлар белән бергә андый шигырьләр дә гамәлдән чыга бара. Чөнки безнең укучыбыз, шул исәптән, бала да, үзгәрештә, яңарышта, үсештә. Өлкәннәрне борчыган бик күп проблемалар аны да кызыксындыра, борчый. Бүген кызыксындырмаса, иртәгә кызыксындырыр. Көн кадагындагы проблемалар турында бүген сөйләшмәсәк, иртәгә соңлавыбыз бар.

**Ринат Мөхәммәдиев:**

Безнең сөйләшүдә яңалык тойгысы ул — киләчәкне күрү дигән формула да оешып килә шикелле.

Әдәбиятның киләчәген күзаллаганда, аның көннән-көн кешегә якыная барып, чор һәм заманның аеруча четерекле мәсьәләләрен конкрет шәхес рухы, эчке кичерешләре тирәнлегеннән каерып алып сурәтләргә, тасвирларга тиешлеге ачыклана төште. Күп милләтле совет әдәбиятларында иҗат ителәчәк әдәби җәүһәрләрнең кайбер төсмерләрен мин Ч. Айтматовның, Ю. Бондаревның, Н. Думбадзеның яңа романнарында һәм Г. Матевосянның психологик тирәнлек һәм табигый рух көрлеге белән аерылып торган хикәяләрендә күрәм. Бездә исә бу юнәлештә Ә. Еники һәм А. Расих, А. Гыйләҗев һәм М. Мәһдиев, драматурглардан Т. Миңнуллин үзгә бер нәтиҗәлелек күрсәтеп иҗат итәләр. Ләкин безгә бер нәрсәне һәрчак истә тоту кирәк, ул да булса — яңалыкның югары әхлак нормаларыннан, коммунистик идеяләрдән аерылгысыз булуын тану. Бу очракта Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр»ы гыйбрәтле үрнәк, минемчә.

Без әлегәчә, нигездә, проза һәм драматургия мисалында фикер йөрттек. Инде шигъриятебезгә килсәк, анда да яңалык — кеше күңеле, кеше рухының тирәнлекләрендә... Шагыйрьләргә, бигрәк тә яшь шагыйрьләргә, әйләнә-тирәне һәм замандашны гына түгел, барыннан да элек үз-үзләрен өйрәнергә, табарга һәм югалтмаска кирәк булачак. Моның бердәнбер дөрес юл икәнлеген шигъри мирасыбыз да ачык раслап килә.

Тагын бер мәсьәлә. Әдәби культура үскәннән-үсә бара, рухи байлык запаслары даберөзлексез артуга юл тота, алар белән танышу мөмкинлекләре дә киңәйгәннән-киңәя генә бара. Менә шундый шартларда, әдәби культура байлыкларына ирешеп тә, үзеңнең табигый авазыңны саклап калу, табигать һәм җанлы тормыш белән элемтә урнаштыру хәлиткеч факторга әверелачәк. Гомумән, әдәби иҗат язучы шәхеснең беренчел ачышларыннан гына гыйбарәт булырга тиеш дип беләм. Никадәрле генә шома һәм нәфис булмасын, әдәбиятның үзеннән килеп язылган әсәрләр — икенчел әсәрләр — чын мәгънәсендәге иҗат нәтиҗәсе түгел. Бу хакыйкать берөзлексез игътибар үзәгендә тотылырга тиешле.

**Рәдиф Гатауллин,** шагыйрь:

Үз-үзеңне табу, яңа сүз әйтү, табигый авазыңны саклап калу... Болар барысы да гаять катлаулы һәм зур мәсьәләләр. Шигырьдә, әлбәттә, мөһим шарт булган яңалык төшенчәсе белән безгә һәрвакыт очрашырга, шул хакта бәхәсләшергә, кайчакта исә ялгышырга да туры килә. Чөнки әдәби тема, образ, фикердәү рәвеше буларак абсолют яңалык бәлки бик бәхәсле дә нәрсәдер... Моннан бик күп еллар элек иҗат иткән грек, Рим шагыйрьләре бүгенге укучы өчен яңача яңгырамыймыни? Аларда безнең заман кешесе белән уртак якларны да һичшиксез күреп булыр иде. Әйе, дөнья — материянең үзе кебек үк иске дә, шул ук вакытта яңа да. Тормыш, яшәеш үзгәреп, үсеп тора; заман безгә Гамлет сорауларын гына түгел, яңа таләпләр, борычлар да куя — үзебезнең чорны җырлауны, дөньяга актив, коммунистларча мөнәсәбәтне калку итеп, һичкемне кабатламыйча, яңачаны күрсәтүне сорый. Ә бу инде һәр шагыйрьнең индивидуаль йөзе, шигъри куәте, эрудициясе, традицияләрне үзләштереп, үстерә алуы, фикер һәм хис концентрациясе, кыскасы, укучыга өр-яңа дөнья ачарлык таланты булу-булмау белән бәйләнгән.

Соңгы елларда шигырьдә, бигрәк тә яшьләр иҗатында, бер-береннән аерып булмый торган, бер үк тема, образлар, алымнарны үзләштереп мәйдан даулаган әсәрләр күбәя башлады. Индивидуаль йөзе, стиль, образлар беренчеллеге булмау — бу инде шагыйрьнең яңалыгы юк дигән сүз. Темада үткәннәр, тарихи чигенешләр белән мавыгу яки зур шәхесләр турында бик мәгълүм фактлар һәм әдәби образларны кабатлау, ваклау да күңелне борчый. Чын әдәби образлар, әсәрне яңа, калку итеп күрсәтәчәк монументаль, зур образлар — Такташ, Туфан, Сибгат Хаким әсәрләрендәге кебек тормышчан, укучыны уйландыра, рухына тәэсир итә, иртә ала торган геройлар, зур фикерләр, гомумиләштерүләр кирәк. Бу бигрәк тә поэма жанрына карый.

**Сибгат Хәким:**

Зур жанрда гына зур фикер әйтеп була дигән фикер белән килешеп бетмим. Шагыйрь җаны тибеп торган лирик шигырьдә дә бик күпне әйтергә мөмкин. Шулай да поэзиябездә киң сулышлы, эпик әйберләр күрәсе килә. «Гасырлар һәм минутлар» кебек, «Киләчәккә хатлар» кебек...

**Гариф Ахунов:**

Белеп, аңлап торабыз: әдәбиятыбыз ирешкән казанышлар зур һәм шул биеклекләрдән без ялыйсы текә үрләр дә бик ачык күренә. Гомумән, татар әдәбиятының, бигрәк тә прозасының соңгы елларда яңалыкка омтылуы, дөнья әдәбияты һәм күп милләтле совет әдәбиятының иң яхшы вәкилләре ирешкән югарылыкка ирешергә йөз тотуы сөенечле хәл, моңа һәр яклап ярдәм итәргә, моны хупларга кирәк. Әмма безнең әсәрләребезнең ил күләмендә бик соңарып, ун еллап вакыт узганнан соң гына чыгуы, чыккан сурәттә дә, оригиналдагы нәфисләгән, үткенләгән, тәэсир көчен югалтып чыгуы — менә бу безне чын-чынлап борчырга, уйга салырга, зур дөньяга чыгуның зур юлларын эзләргә мәҗбүр итәргә тиеш. Әйе, әйе, мәҗбүр итәргә тиеш. Без Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять»ен ил күләмендә яңгырата алмадык. Валентин Распутинның аңардан унбиш еллар соңрак языл-

ган «Соңгы срок» повесте яңгыраш тапты. Аяз Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын» романы русчада эзсез югалды, Чыңгыз Айтматовның «Ак пароход»ы дөньяның дистәләрчә теленә тәрҗемә ителде. Нәрсә, боларның сәнгатьчә эшләнешләре төрлечә димәкче буласызмы? Сәнгатьчә эшләнешләре түгел, алымнары төрлечә булуы мөмкин, әмма «Әйтелмәгән васыять» тә, «Урамнар артында яшел болын» да — киң сулыш белән, психологик тирәнлек белән язылган әсәрләр. Шулар янына тагын Атилла Расихның «Язгы авазлар» романын китереп куйыйк. Без аны, тирән социаль һәм психологик романны, русчага унбиш ел соңлап чыгардык. Чыгарган сурәттә дә оригиналдагы үткенлеге белән чыгара алмадык. Оригиналдагы үткенлекне саклау ягыннан бигрәк тә Әмирхан Еники повестьлары нык зыян күрделәр. Монысы инде авторларның үзләренә генә түгел, оештыру эшләренә дә бәйле нәрсәләр. Шамил Бикчуринның «Каты токым» романы татарча беренче вариантта бик таркау иде, аерым эпизодлардан тора иде, аны журнал редакциясе бер эшләде, күренекле язучы һәм бик оста тәрҗемәче Владимир Чивилихин икенче эшләде, яхшы итеп тәрҗемә итте, нәтиҗәдә роман ил күләмендә генә яңгырап калмады — чит илләргә дә чыгып китте. Без соңгы биш ел эчендә Мәскәүдә 167 китап чыгардык, ягъни моңарчы булмаган рекордлы санга ирештек, инде менә хәзер сан артыннан кумыйча, иң яхшы әсәрләребезне тиешле кондициядә, барлык шартын китереп чыгара башлау ягын карарга тиешбез. Азрак булсын — яхшырак булсын. Әсәрләребезнең сәнгатьчә зурлыгын, тирәнлеген, идея-социаль яңгырашын бик нык үлчәп, ефәк иләктән үткәрер заман җитте шикелле.

Соңгы елларда туган әсәрләребезнең әдәби камиллеген, яңалыгын ил күләмендә билгеләү, шуны Бөтенсоюз укучысына җиткерү өчен без талантлы һәм намуслы тәрҗемәчеләр табу, үзебездә дә аларны үстерү хәстәренә керешергә тиешбез.

Әдәбиятта яңа, зур, җитди әсәрләр, киң колачлы, масштаблы әсәрләр иҗат ителү өчен тагын бер шарт бар, ул — традицияләргә таяну. Татар совет прозасының, поэзиясенең, һиһаять, драматургиясенең бүгенге үсеше, бүгенге табышлары Тукайлардан, Галимҗан Ибраһимовлардан, Кәрим Тинчуриннардан башка була алмый. Тагын да арырак гасырларга китсәк, Кол Галиләрдән башка була алмый.

Бүгенге сөйләшүдә без үзебезнең әдәбияттагы яңалык тойгысы турында гына сүз кузгатып калмаска, яңалык тойгысын ил күләменә чыгару хакында да сүз алып барырга тиешбез. Бу өлкәдә зур һәм җитди эшне, әдәби тәрҗемәдән тыш, әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләр башкара. Әдәби тәнкыйтьнең һәм әдәбият белеменең партия Үзәк Комитетының мәгълүм карарыннан соң үсүгә, конкретлыкка таба юл алуын таныган хәлдә, без аларның әле һаман әдәби хәрәкәттән арттарак баруын, яңалыкны һәм үсеш тенденцияләрен шактый ук соңга калып билгеләвен әйтми булдыра алмыйбыз. Әдәби үсешебез өчен тәнкыйтьнең йокымсырау хәленнән чыгуы, әдәби хәрәкәтне әйдәп алып баруы бик мөһим.

**Кояш Тимбикова, язучы, республика журналистларының Х. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты:**

Әйе, әсәрләребездәге яңа сулыш хакында сүз алып барабыз икән, әдәбияттагы һәр яңа күренешне укучыга җиткерү турында да кайгыртырга иде! Мин басылып



*Р. Миңнуллин: «Көн кадагындагы проблемалар турында сөйләшүне артка калдырмаска кирәк». (Уңда — Р. Низамиев).*

чыккан әсәрләрне әдәбият сөючеләргә вакытында ирештерергә кирәклеген, китапларның тузанланып ятмаска тиешлеген генә күздә тотмыйм.

Заман рухы яңа әсәрләргә карата языла торган тәнкыйть мәкаләләренә дә үтеп керсен иде! Сер түгел: әдәби тәнкыйть бер үк әсәрне укучы эзләп алып өйрәнерлек итеп тә, аңа кул селтәп үтәрлек итеп тә «сүтеп» ташлый ала. Ерак тарихка ук китеп тормастан, соңгы 20—25 ел эчендә дә әдәбиятыбызның мактанычы булырдай кайбер әсәрләргә, кызганычка каршы, ялгыш бәя бирү очраклары искә төшә. Ә. Еники, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев кебек язучыларыбызның Бөтенсоюз мәйданында, дөнья әдәбияты киңлегендә яңгырый алмавына да бер сәбәп шулдыр, минемчә. «Йөрәк сере», «Рәшә» (Ә. Еники), «Өч аршын җир» (А. Гыйләҗев), «Мәхәббәт сагышы», «Әни килде» (Ш. Хөсәенов) кебек, хәзер әдәбиятта үзләренең мактаулы урыннарын алган әсәрләр, әле языла кына өлгергән елларында, миңа калса, урынсыз тәнкыйтьләнделәр. Бу хәл, әлбәттә, ниндидер усал нияттән тумаган. Әдәби тәнкыйтебездәге хаталар, мөгаен, хәзерлекле белгечләр җитмәүдән, тәҗрибәсезлектән килеп чыккандыр.

Бәхеткә каршы, бүген безнең Р. Мостафин, Т. Галиуллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Галимуллин, Э. Нигъмәтуллин, Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев кебек теоретик яктан хәзерлекле, дөнья әдәбиятыннан мәгълүматлы, әсәрләрне уртак уңыш итеп, үз итеп танучы, йөрәк аша үткәреп өйрәнүче тәнкыйтьчеләребез бар. Язучылар да, әдәбият сөючеләр дә алардан гадел тәнкыйть көтәләр. Әдип иҗатына мөнәсәбәт иң дәрәҗәдә саф, гадел, туры булырга тиеш икәненә үзәк матбугатта соклангысыз үрнәкләр бар. Ч. Айтматовның «Ак пароход» повестена карата фикерләр икегә аерылгач, кайбер тәнкыйтьчеләр әдипне чынбарлыкка тап төшерүдә гаепли башлагач, газета битләрендә гомуми фикер алышу оештырылды, соңыннан йомгаклау мәкаләсе бирелде, әсәр Дәүләт премиясенә лаек дип табылды. Бәхәсле тоелган әсәрләр турында ара-тирә газета-журналларда фикер алышулар алып барылса, безгә дә һич комачауламас иде...

**Ринат Мөхәммәдиев:**

Барлык бәлане тәнкыйтьчеләр өстенә аудару модага кермәсен иде. Шулай да яңалык тойгысы хакында сөйләшкәндә әдәби тәнкыйтькә куелган зур таләпләр турында сүз чыгу бик табигый. Л. И. Брежнев КПССның XXVI съездында ясалган докладында һич тә очраклы рәвештә генә «профессиональ фикер йөртү — әдәби тәнкыйтьчеләр һәм сәнгать белгечләре эше» димәде. Чөнки әдәби процесстагы яңа үрентеләрне, үсеш билгеләрен иң элек әдәби тәнкыйть күреп алырга тиешле. Күреп алырга, яңалыкка кул сузарга һәм уңай, яңа тенденцияләрне аерым бер кайгыртучанлык белән хупларга тиешле... Әлегә исә безгә бу җитенкерәми кебек...

**Зәки Нури, шагыйрь, «Казан утлары» журналының баш редакторы:**

Әдәбиятта яңалык тойгысы бүгенге көндә киләчәк төсмерләрен чамалау гына түгел, ул иртәгесе көндә үткәнебезнең һәм хәзерге яшәешебезнең закончалыклы дәвамын күрү дә. Партиябезнең олы политик форумында гаять киң колачлы эшләр программасы билгеләнгәндә, күңелгә кагылган әнә шундый яңалык җиле, киләчәк тойгысы язучылар алдына да зур бурычлар, җитди таләпләр куя. Остазыбыз Максим Горький сәнгатьнең үзе белән тиңләгән халык хезмәте елъязмасын без кешерухын канатландыра, йөрәккә яңадан-яңа дәрт өсти торган илһамлы, хәрәкәтчән сүзләр белән сурәтләргә тиешбез. Шундый әсәрләргә «Казан утлары»нда һәрвакыт түр урын бирелде һәм алда да шулай булачак. Әмма әдәбиятка карата съездда әйтелгән гражданлык пафосы, кимчелекләр белән килешмәүчәнлек, җәмгыять хәл итә торган проблемаларга катнашу бурычын без бер минутка да истән чыгармыйбыз. Конкрет алганда, мәсәлән, үз журналыбызда югары сыйфатлы әсәрләр белән нинди проблемаларга тизрәк якын киләсе иде соң?

Беренче. Зур коллективларда хезмәтне оста оештыра белгән, инициативалы, киң күңелле, кешеләргә игътибарлы җитәкче нинди була?

Икенче. Тормышта һәм эштә яшьләр белән өлкәннәр мөнәсәбәте. Биографияләре күпләргә гыйбрәт-үрнәк булырлык аксакаллар портретлы. Хәзерге яшьләрдә җаваплылык тойгысы һәм социаль яктан җитлегү ничек һәм ни өчен озаккарак сузыла? Кайберәүләрнең исә хезмәткә мөнәсәбәтләре ник бик үк җитди түгел, ә кайберәүләре политикада үтә беркатлы булып кала бирәләр? Егетләр белән кызларны эш-

кә һәм яшәешкә өйрәтүче яхшы остазга хас сыйфатлар. Ниһаять, яхшы белән бик яхшы үрнәкләр конфликты.

Өченче. Үзләрендәге кешелеклелек сыйфатларын акрынлап җуя-җуя банкрот булып калган тискәре персонажларның инде берничә әсәрдә рәттән я әчкечегә әйләнүе, я башына төшкән шул бәладән үлеп «котылу» сюжеты тагын кабатланмасын иде.

Безнең бу сөйләшүдә әсәрләребезнең теле, иҗатта аны һәммәбезгә оста куллану кирәклеге турында да әйтелде. Чөнки сүз бит ул безнең төп эш коралыбыз — культура коралы, әдәбиятның беренчел элементы. Нури Арслановның фикере бик урынлы: көн тәртибенә шул мәсьәләне махсус куеп, фикер, хис һәм аһәң бердәмлеге турында зур сөйләшүне, чыннан да, җентеклап әзерләргә һәм үткәрергә кирәк. Шигырь культурасын күтәрү таләбен катгый куйган уйланулар да шунда әйтелер иде. Чөнки реаль тормыш һәм проблемалар белән бәйле булмаган, бүгенге көннең нинди дә булса конкрет бер бурычын сәнгатьчә хәл итмәгән, кыскасы, яңа сыйфатлы детальләре яшәеш прозасыннан эзләп табылмаган шигырьләр шактый күп тә языла һәм, кызганычка каршы, әз дә басылмый әле.

Николай Седов *фотолары.*

**Гариф Ахунов:**

Билгеле, барлык проблемаларны бер сөйләшүдә генә билгеләп чыгарга мөмкин түгел. Алар безнең алдагы иҗатыбызда, языласы әсәрләребездә хәл ителергә тиеш. Шулай да бу сөйләшүдә мөһим бер фикергә килдек дип уйлыйм: әсәрләребездә күтәрелгән барлык проблемаларның үзәгендә кеше язмышы булырга тиеш, чөнки иҗатыбызның төп максаты — коммунистик төзелештә актив катнашучы яңа кеше тәрбияләү. Тиражлары елдан-ел арта баручы китапларыбыз аша, йөз дә өч меңле «Казан утлары» журналы аша миллионлаган укучыларыбыз алдында сүз алу безгә зур җаваплылык йөкли.

КПССның XXVI съездында иптәш Л. И. Брежнев: «Партия иң яхшы әсәрләргә хас гражданлык пафосын, кимчелекләр белән килешмәүне, сәнгатьнең җәмгыятебезне дулкынландыра торган проблемаларны хәл итүгә актив катнашуын хуплый»,— диган иде. Бу сүзләр безне илгә, заманга лаек яңа әсәрләр язарга, бөтен көчебезне, күңелебезне партиягә, халыкка хезмәт итәргә багышларга рухландыра. Әдәби хәрәкәтебездәге яңа тенденцияләр һәм яңа күренешләр, иҗади эзләнүләрнең төп юнәлешләре хакында барган бүгенге сөйләшүнең дә асыл мәгънәсен мин шунда күрәм.

## Фәрваз Миңнуллин

# ХИКӘЯ ҺӘМ ХИКӘЯЧЕЛӘР

Бездә хикәянең күптәннән килә торган ныклы традицияләре, сокланырлык осталары бар.

Революциягә кадәрге чорны искә төшереп тормыйм. 20—30 нчы елларны күз алдына китерегез. Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал, Ш. Усманов һәм К. Нәҗми, Г. Толымбай һәм М. Гали, А. Шамов һәм М. Әмир кебек әдипләрнең шул чор иҗатын искә төшерегез. Ул елларда хикәя язмаган берәр прозаик калдымы икән?! Юктыр, мөгаен. 40 нчы елларда да бирешми әле хикәя.

Тик 50 нче елларның урталарыннан, бигрәк тә 60 елларның башыннан хәл нык үзгәреп китә. Туфрагы ашланмаган гөл кебек, хикәя сула, шиңә башлый. Дөрес, бөтенләй шиңеп бетми. Мин Шабай һәм Габдрахман Әпсәләмов кебек мәрхүм әдипләребезнең, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин, Г. Минский, Г. Галиев кебек язучыларыбызның әйбәт-әйбәт хикәяләре чыккалап тора. Бу өлкәдә И. Гази белән Г. Мөхәмматшин аеруча күп һәм нәтиҗәле эшли.

Әмма гомуми хәлне алар гына үзгәртә алмады. Хикәя бер урында таптанды, бер югарылыкта кала бирде. Эшләр хәтта партиянең XX съездыннан соң да үзгәрмәде. Хәтта дим, чөнки XX съезддан соң урнашкан иҗади атмосфера барлык әдәби жанрларның үсешенә көчле йогынты ясады. Тормышның зур мәсьәләләренә багышланган романнар язылды, чорның актуаль проблемаларын күтәргән повестьлар активлашты, поэзиянең пафосы, яңгырашы үзгәрде, драматургия булып драматургия җанлана төште. Язмыш җилләре тик бер жанрны, хикәя жанрын гына читләтеп узды. Хикәя өлкәсендә башка жанрлардагы кебек кискен үзгәреш, сыйфат яңарышы күренмәде.

Билгеле, бу хәл җәмәгатьчелекне борчымый кала алмый иде. Соңгы 10—15 ел эчендә хикәя турында күп сөйләнде, күп язылды. Язучыларның гомуми җыелышларында булсын, секция утырышларында булсын, хикәя мәсьәләсе гел кузгатыла торды. 1972 елда Казанга кыргыз язучылары килгәч, җыелып, тагын бер ныклап сөйләштек. М. Әмир, И. Гази, Ф. Хөсни, Р. Мостафиннарның хикәя жанры, аның киләчәге өчен борчылып язылган мәкаләләре дә хәтердә әле.

Әдәбиятның иң оператив һәм иң сугышчан жанры ни өчен мондый хәлгә калды?.. Татар хикәясенең үсеш юлы нинди булачак? Яхшыруга таба барамы ул, әллә, киресенчә, начарланганнан-начарлана гына торамы? Шул сорауларга җавап таба алмыйча аптырап беттек. Ул арада укучы һәм әдәби җәмәгатьчелек каршында хикәянең абруе һәм дәрәҗәсе кими, репутациясе төшә барды. Моннан бер ел элек кенә И. Нуруллин, мәсәлән, хикәянең хәле сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да мактанырлык түгел, тиз арада гына рәтләнмәячәк тә, дигәнрәк фикер әйтеп чыкты.

Без өмет өзеп, кул селтәргә җыенып йөргәндә, хикәя терелеп һәм уянып, хәл җыеп яткан икән. 1980 елда дөнья күргән хикәяләр безнең бу жанр хакындагы пессимистик карашларыбызны шактый какшата һәм юкка чыгара язды.

Хикәяләр дигәндә, мин прозаның роман белән повестьтан кала бөтен төрләрен: әдәби парчаларны һәм новеллаларны, нәсерләрне һәм этюдларны, миниатюраларны һәм юморескаларны күздә тотам. Шушы мәкаләне язарга хәзерлек йөзеннән, «Казан утлары» һәм «Азат хатын» журналларында, «Социалистик Татарстан» газетасында, төрле җыентыкларда дөнья күргән 100 ләп хикәя белән танышырга туры килде. Нинди типтагы, нинди төрдәге әсәрләр генә юк алар арасында: шәһәр һәм авыл тормышына караганнары, тарихи һәм тарихи-революцион темага багышланганнары, аналитиклары һәм синтетиклары, романтиклары һәм символиклары, лириклары һәм драматиклары, сатириклары һәм юмористиклары, очеркка тартымнары, истәлеккә якыннары...

Бер мәлгә хәтта югалып һәм аптырап калгандай буласың. Очраклы төстә Истамбул базарына барып чыккан турист кебек, күз камаша, баш әйләнә башлый. Хәер, озакка түгел. Күпмедер вакыт узып, күз ияләнә төшүгә, һәр нәрсә үз урынын, үз төсен ала. Акрынлап, һәр хикәя үзенә лаеклы, үзенә тиешле «ояга» кереп утыра...

Характерлары төрле-төрле булган кебек, узган елгы хикәяләрнең сыйфатлары да төрлечә икән. Сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан көчлеләре бар, уртачалары шактый, йомшаклары очрый. Әмма зәгыйфь һәм чатак идеяле хикәяләр юк дияргә була. Бу — мәсьәләнең бер ягы.

Инде аларга тематик яктан чыгып якын килгәндә, гадәттәгечә, иң зур күпчелекне әхлак мәсьәләләренә багышланган, мәхәббәт проблемаларына караган хикәяләр тәшкил итә. Узган ел совет халкы Бөек Ватан сугышында җиңүнең 35 еллыгын бәйрәм итте. Шул уңай белән көндәлек матбугатта сугышка каршы язылган хикәяләр күп басылган, хәрби-патриотик тема активлаша төшкән. Аннары авыр сугыш елларында безнең республикада эвакуациядә булган кешеләр, шул кешеләр белән татар халкы арасындагы дуслык элементләре турында да елдан-ел күбрәк, тирәнрәк яза башлаганбыз. Б. Камалов, Л. Ихсанова, К. Тимбикова, И. Низамовларның әсәрләре шул хакта сөйли.

Күзгә нык ташланган тагын бер сыйфат: хикәя өлкәсендә сатирик һәм юмористик башлангыч көчәеп килә. Күңелле хәл бу! Беренчедән, хикәячеләребезнең әдәби осталыклары нык камилләшә баруы турында сөйләсә (беркемгә дә сер түгел, шәп юмор язу өчен нечкә тоем, абсолют «слух» кирәк), икенчедән, хикәя өлкәсендә сатирик һәм юмористик башлангычның көчәюе бездәге күңел һәм фикер хөрлеге турында, әйбәт иҗат атмосферасы хөкем сөрүе хакында, ягъни заманнарның имин булуы турында сөйли торган факт.

Бер генә мисал китерәм. «Социалистик Татарстан» газетасында Н. Мортазин дигән авторның «Күпер» исемле юморескасы басылган. Күргән-белгән кешем түгел, әмма язган әйберсе бик тә гыйбрәтле.

Кулмы, вакытмы җитмичә, төзәтелми яткан күперле бер авыл... Шул авылга практикага кайта Сиражи. Җимерек күпер өчен председательне гаепли Сиражи. Уза бер ел, шул авылга председатель булып кайта Сиражи. Җимерек күпер өчен район юл бүлеген тирги... Район юл бүлегенә кучәр Сиражи — җимерек күпер өчен тагын берәрсен тотып сүгәр Сиражи!.. Усал хикәя, заманча хикәя. Кызганычка каршы, тормышта кеше эшләгән эшне үз исәбенә күчереп, без дә сабан сөрдек, дип мактанып йөрүчеләр, бер эш өчен дә җавап бирми торган, бер гаепне дә үз өстенә алмый торган Сиражилар, адым саен булмаса да, очрап тора. Н. Мортазин шундый кешеләрдән көлә.

Аннары бездә истәлеккә тартым язмалар, өлкән буын вәкилләре — картлар һәм карчыклар турындагы хикәяләр күбәеп бара икән. Йөз хикәянең кырыкка якыны тегеләйме-болаймы өлкән буын вәкилләре, шуларның язмышы белән бәйләнгән. Г. Галиев, Г. Минский, Ф. Хөсни, Л. Ихсанова, Р. Төхфәтуллин кебек язучыларны аңлап та булсын, ди. Хәзер бездә С. Шәмси белән М. Галиев кебек яшь-яшь егетләр, Н. Гыйматдинова белән Ф. Хуҗиәхмәтова кебек яшь-яшь кызлар картлар белән «мавыга» башлады. Баштарак бу хәл нык кына аптыраткан иде. Ныклап уйлап карагач, аңладым: әллә ни пошыныр урын юк икән. Картлар-карчыклар дигәнебез үзебезнең әтиәниләребез икән ләбаса.

Дөрес, алар арасында төрле язмышлы, төрле характерлы кешеләр бар. Сирәк кенә булса да, М. Галиевнең Уразаевы («Төнге кыюлык»), Р. Кәраминең Нәгыйме («Кәккүк тавышы») яки М. Хәсәновның Зөбәрҗәте («Зөбәрҗәт») кебек гомерләрен бушка-заяга уздырган кызганыч кешеләр дә очрый. Кайсы, гомер буе талпынып та, һич югы бер тапкыр егет була, ихтыяр көче, принципиальлек күрсәтә алмаган. Икенчесе, күке кебек, картайганчы үз оясын корырга вакыт таба алмый йөргән. Өченчесе, тәти уенчыкка кызыккан сабый яки утка кызыккан күбәләк кебек, бер төнлек мәхәббәт өчен яшьлеген әрәм иткән... Хәзер бик үкенәләр дә, әмма соң — гомер узган, көлмәк тузган. Гыйбрәт алырлык язмышлар, кызганыч бәндәләр.

Өлкән буын дигәнебез — безнең әтиләр һәм әниләр дидем. Әтиләребез — Днепрогэслар һәм Магниткалар салган, илдә беренче колхозларны төзегән, дөньяны фашизм афәтеннән саклап калган буын. Әниләребез — алар белән кулга-кул тотынып, илдә социализм төзегән буын, сугыш китергән бөтен авырлыкны, бөтен бәла-казаны үз җилкәсендә күтәргән, яшьли тол калган буын. Ил бай булсын, дөньялар имин булсын, без бәхетле булсын өчен, гомер буе иза чиккән, гомер буе тир түккән буын. Инде шулар арасында, Ф. Абдуллинның Хатыйбы белән Латыйбы кебек, Ф. Яруллинның «Алдану» һәм М. Маликованың «Кызыл гөл» хикәяләрендәге картлар-карчыклар кебек, үзебез төзегән тормышның рәхәтен бераз үзебез дә күреп калыйк әле дип яшәүчеләр бар икән, моны алардан күпсенмик! Аларның рәхәтләнеп бер яшәп калырга тулы хаклары бар.

Картлар дигәнебез, өлкән буын дигәнебез, нигездә, Октябрь революциясен ясаган, илдә совет властен урнаштырган чын большевиклар, Ленинның якын көрәштәшләре: Р. Кәраминең Вәли абзыйсы («Ә көннәр уза тора»), Ф. Садриевның Бибигайшә белән Әхмәтша карты («Ә елга һаман ага»), С. Шәмсинең Кадыйр карты («Балконда»). Чорлар белән чорлар, кичә белән бүген, картлар белән яшьләр, буыннар белән буыннар арасындагы мөнәсәбәтләр елдан-ел актуальрәк төс ала барган бер заманда өлкән буын туплаган бай тәҗрибәне яшьләргә җиткерү, алардан принципиальлеккә һәм фидакарьлеккә өйрәнү, чорлар, буыннар арасында бәйләнеш һәм гармония эзләү, бүгенге яшь буынны әтиләребезнең революцион традицияләрендә тәрбияләү — бик изге һәм кирәкле эш. Шуңа күрә хикәячеләребезнең өлкән буын вәкилләренә, картларга еш мөрәҗәгать итүе аңлашыла. Алар иҗат иткән картлар арасында Г. Галиевнең Гобәйдулла бабае («Көтелгән көннәр»), Ш. Рәкыйповның Михаил Максимовичы («Комбат истәлеге»), Р. Төхфәтуллинның Газим белән Зәйнне, Мөкәррәмә белән Фәрәхшаты кебек («Ике каен, бер карама») таза үзәкле, нык иманлы кешеләр, ил, дөнья язмышы өчен борчылып яши торган, үзләрен бүген дә хуҗа итеп, тормыштагы һәр нәрсә өчен җаваплы итеп тоя торган кешеләр булганда — бигрәк тә...

Күрәсез, безнең хикәяләрдә төрле чорлар һәм төрле вакыйгалар, төрле буын кешеләренең тормышы сурәтләнә, төрле проблемалар һәм мәсьәләләр күтәрелә икән. Тик темалары һәм характерлары, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан никадәр генә төрле-төрле булмасыннар, аларның иң зур күпчелеге заман сулышы белән сугарылган, заманча яңгырый торган, «җаннары» заманча булган хикәяләр. Тагын да ачыклап әйтсәк, аларның күбесе — ил һәм халык язмышы өчен, дөнья язмышы өчен борчылып язылган, заман җилләренә йөз тотып язылган хикәяләр. Укучыда изге хисләр, матур тойгылар уята, укучыларга көчле тәэсир ясый торган актив хикәяләр. Алар белән танышканда, укучы буларак, тагын да сафрак һәм намуслырак буласың, тагын да матуррак һәм батыррак күренәсең килә башлый. Алар безгә кеше һәм граждании булырга ярдәм итә торган хикәяләр.

100ләп хикәя белән танышырга туры килде, дидем. Билгеле, бик теләсәм дә, һәр хикәяче иҗатына, узган ел дөнья күргән һәр хикәягә иркенләп туктала, тәфсыйллы анализ ясый алмыйм. Кыен хәлдән ничек тә булса котылу өчен, сыйфатларына карап, хикәяләрне төркемнәргә бүләргә туры килде. Ошаганнары, әйбәтләре кырыкка җыелды. Йөз хикәянең кырыгы әйбәт икән, кешегә ошарлык икән, бу инде — хәл зарланырлык түгел дигән сүз, мин әйтер идем, хәтта шәп дигән сүз.

Хикәя — әдәбиятның кыен һәм авыр жанры, дибез. Иң элек хикәянең кабатланмаган оригиналь образы, җитди һәм мөһим проблемасы, мавыктыргыч ситуациясе

булырга тиеш. Кайбер хикәяләрдә боларның берсе дә булмый диярлек. Безнең хикәячеләр язарга уйлаган, язарга җыенган әсәрләренең киңәйтелгән проспектын, планын бастырып чыгаргалыйлар. Аерым хикәячеләргә язучы буларак өлгергәнлек, фикер тирәнлеге, чын мәгънәсендә гражданин булу җитми. Алар вак мәсьәләләрдән зур фәлсәфә чыгарырга азапланалар, я булмаса зур мәсьәләләрне ваклап, кечерәйтеп ташлыйлар, зәвыгы чамалы булган укучыларга йөз тотучылар, күз яшьләре, сентиментальлек белән алдырырга тырышучылар очрый...

Бүген авылда зур үзгәрешләр бара. Моны, билгеле, хикәячеләр дә читләтеп уза алмый. Әмма, И. Юзеевның «Ул чәчәкләр ярата иде» дигән язмасын, Р. Төхфәтуллинның «Ике каен, бер карама» исемле хикәяләр циклын һәм узган ел дөнья күргән тагын берничә хикәяне исәпләмәгәндә, хикәячеләрнең күбесе бүгенге авылны берьяклырак сурәтлиләр — авыл халкының бай яшәвенә, тук яшәвенә сокланалар, авыл җирендә барган төзелешләр, андагы техника белән мактаналар. Кыенлыклар, хәл ителмәгән проблемалар алар игътибарыннан читтәрәк кала, әнә шул тук һәм бай халык арасындагы күңел ярлылыгы бераәүне дә борчымый. Эчкечелекнең көчәеп килүен күрмәмешкә салынабыз. Аерым хикәяләрне укыганда, без җенси мөнәсәбәтләргә, әхлак кагыйдәләренә артык иркен карый башладык ахры, дигән фикер дә туа.

Хикәяләрдә төрле төстәге, төрле характердагы кабатлаулар шактый еш очрый. Иң элек исемнәре кабатлана. Сүзне шулардан башлыйк: Ә. Еникинең «Картлар» исемле хикәясе бар иде инде. Узган ел аның янына Ф. Яруллинның «Картлар» исемле тагын бер шәп хикәясе өстәлде. Ф. Хөснинең «Өч хатын белән тормыш»ына Р. Мөхәммәтовның «Өч хатынлы ир» дигән хикәясе, Ә. Гаффарның «Соңгы сүзе» янына Р. Ишморатованың «Сүз» исемле әсәре өстәлде. «Социалистик Татарстан» газетасы үзенең 16 ноябрь санында Р. Фәизовның «Түләнмәгән бурыч» исемле хикәясен, ә нәкъ бер атнадан соң, 23 ноябрь санында Р. Төхфәтуллинның «Бурыч» исемле хикәясен басып чыгарган...

Безнең хикәяләрдә охшаш эпизодлар, кабатланган ситуацияләр очрый. Мәхмүт Хәсәновның күптән басылган «Дулкыннар ярга тәгәри» исемле хикәясендә Гарәфи исемле малай әнисенә шәп яңа ир, Ә. Галиевнең узган ел гына басылган «Хәмит абый» исмле хикәясендә бәләкәй кыз әтисенә шәп яңа хатын табып бирә. Хәтерем ялгышмаса, шундыйрак ситуация телевизион фильмнарда да кабатланган иде. Ә. Гаффарның «Ир» хикәясе Р. Төхфәтуллинның «Үзгәлем» исемле хикәясе белән охшаш ситуациягә корылган. Ш. Галиевнең «Рус казлары: га-га-га» дигән шигырен белмәгән кеше юктыр. Төптән ныклап уйлап караганда, Җ. Тәрҗемановның «Әтәч булып кычкыра беләсезме?» дигән хикәясе шул шигырьнең киңәйтелгән һәм үстерелгән варианты гына, һәрхәлдә «орлыгы» шул шигырьдән алынган. Без кабатларга, иярергә гадәтләнә башлаганбыз. Исемнәр кабатлана, ситуацияләр һәм вакыйгалар кабатлана, хәтта телевизион фильмнардагы эпизодлар кабатлана. Бизәми бу безне!

Безнең хикәяләргә хас кимчелекләрнең кайберләрен санап чыктым. Хәзер инде, ул хикәяләрне кемнәр язган, авторлары кемнәр,— дип сорарсыз.

Нихәтле генә сәер һәм гаҗәп тоелмасын, авторлары — гомер буе хикәя язган өлкән буын вәкилләре, яисә талантсыз килеш әдәбият тирәсендә гомер уздырып, чабата туздырып йөргән әрсез кешеләр. Бу ни хәл, диярсез. Яшьләр гел шәп хикәяләр генә язамыни, диярсез. Начар хикәяне яшьләр дә язадыр, тик аларныкын басмыйлар. Аксакалларныкын һәм әрсез кешеләрнекен басалар. Әрсезләр турында сөйләп тормыйм, анысы болай да аңлашыла. Ә өлкәннәр язганны хөрмәт йөзеннән басалар, кире борырга уңайсыз булганга күрә, һич югында, көн кадагына суга торган булганга басалар. Басалар һәм начар эшлиләр. Болай эшләп, без, беренчедән, укучыларны саташтырабыз. Анннары укучы һәм әдәби җәмәгатьчелек каршында аксакалларның һәм танылган язучыларның абруен, дәрәҗәсен төшерәбез. Шул хакта сөйли торган гыйбрәтле бер мисал китерим. Язучының 50 еллыгын билгеләү йөзеннән, «Азат хатын» журналы үзенең узган елгы март санында мәрхүм Х. Сарьянның «Хәерсез» исемле хикәясен баскан. Күренеп тора, изге нияттән чыгып баскан. Күренеп тора, йомшак хикәясен баскан. Монда авторның бер гаебе дә юк. Әмма «Азат хатын» журналын күпме кеше укыганын беләбез. Көм өчендер Х. Сарьян шушы бер

хикәя белән язучы булып калыр. Шундый кешеләрне, Х. Сарьян безнең әйбәт прозаик иде дип, ул «Әткәм һөнәре», «Бер ананың биш улы», «Егет сүзе» кебек җитди повестьларның, ярсынып һәм шашынып, гаҗәпләнеп һәм сокланып укырлык дистәләрчә хикәя авторы иде дип ышандырып карагыз инде! Мондый күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен, нәшриятта булсын, редакцияләрдә булсын, таләп һәркемгә бертөсле булырга тиеш.

*

Хикәя жанры өлкәсендә барган кызыклы үзгәрешләрнең күбесе яшь авторлар исеме белән бәйләнгән. Алар арасында кызыклы шәхесләр, әзерлекле кешеләр күп. Алар — татар әдәбиятына хас традицияләрне үзләштергән кешеләр, алар — рус һәм дөнья әдәбияты казанышлары белән таныш кешеләр. Яшьләр арасында Г. Бәширов һәм Ф. Хөсни кебек әдипләребез башлаган эшне дәвам иттерүчеләр, алга таба үстерүчеләр бар. Шулай да аларга иң нык йогынты ясаган кеше Ә. Еники дип уйлыйм. Моңа ышану өчен, М. Галиевнең «Төнге кыюлык», яки М. Маликованың «Сары тюльпаннар» исемле хикәяләре белән танышу да җитә. Хәер, Ә. Еники иҗатының тәэсире бер яшьләр белән генә дә чикләнми. Аның «Әйтелмәгән васыять», «Төнге тамчылар», «Тынычлану» кебек әсәрләре татар әдәбиятының бөтен жанрларына мәгълүм бер йогынты ясады. «Тынычлану»дан соң хәтта «Табу һәм югалту», «Сынау» кебек әдәбиятыбызның казанышы саналган әсәрләр дә төсләрен һәм яңалыкларын җуя төштеләр кебек...

Әмма ни генә булмасын, мин үзем мондый йогынтыга һич тә каршы түгел. Һәр әдәбиятның таяна торган традицияләре, һәр язучының яраткан укытучылары, остазлары бар. Шулай булган, шулай булачак.

Татар совет әдәбияты гомер-гомергә Тукай традицияләрендә үсеп килде. Бераздан Такташ, Җәлил традицияләре килеп кушылды. Соңгы елларда әдәби хәрәкәткә Ч. Айтматов, Дәрдмәнд, Ә. Еники, Х. Туфан, Ә. Давыдов кебек әдипләрнең тәэсире көчәйде. Аерым хикәяләрдә хәтта яшь Туфан — Туфан Миңнуллин тәэсире дә сизелеп китә: Ф. Садриевның «Ә елга һаман ага» һәм М. Галиевның «Аның бер көне», исемле хикәяләрен укыганда вакыт-вакыт Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренә хас авазлар чалынып китә шикелле. Мин барыннан да бигрәк спектакльдәге искиткеч җылы һәм романтик бер эпизодны — Әлмәндәр картның яшь, сылу Йөзембикә белән очрашу күренешен күздә тотам. Ф. Садриев һәм М. Галиев хикәяләрендә күңмедер дәрәҗәдә шуның кайтавазын ишеткәндәй булам...

«Төнге кыюлык»та Ә. Еники йогынтысы сизелә, «Аның бер көне»ндә Т. Миңнуллин пьесасының кайтавазы ишетелгәндәй була, дидем. Кешенең әлләниләр уйлавы бар. Шундый уйларга урын калдырмас өчен, кистереп әйтәм: Марсель Галиев — үзенчәлекле һәм кызыклы язучыбыз, ышанып һәм өмет баглап торган сәләтле яшьләребезнең берсе. Иҗат юлын ул шигырьдән башлады. Аны интеллектуаль поэзия вәкиле, уйлы-гамьле шигырьләр тарафдары дип мактадылар. Минем үземә М. Галиевнең прозасы якынрак. Шигырьләренә хас әйбәт сыйфатларын (фикер тыгызлыгы, кыскалык һ. б.) ул проза әсәрләренә дә күчерде. Авторның узган ел чыккан «Ул чакта» исемле җыентыгына кергән әсәрләре шул хакта сөйли.

Җыентыкка кергән повестьларның «Ак абагалар» дигәне бүгенге яшьләр турында язылышы белән дә яшьләрчәрәк, яңачарак повесть. «Ул чакта» исемле икенче повесте тагын да төзегерәк һәм җыйнаграк, камилрәк, тормышчанрак әсәр булып чыккан.

М. Галиев — күп һәм нәтиҗәле эшләүче автор. Узган ел ул өч хикәя бастырып чыгарды. Нигездә барысы да әйбәт хикәяләр. «Төнге кыюлык» дигәне аеруча нык ошады. Әсәрдә бөтен, төзек характерлар бар. Гыйбрәтле һәм тирән фикер бар.

М. Галиев повестьларын да, хикәяләрен дә укучыга тәэсир итәрлек итеп язарга тырыша. Тырыша торгач, арттырып та җибәргәли төсле. Эмоциональлек урыны-урыны белән кылану, купшылануга әйләнеп китә яза. М. Галиев рәссамнар турында язарга ярата. Аның күпчелек геройлары дөньяга рәссам күзе белән карыйлар, дөньяны рәссам күзе белән күрәләр. «Аның бер көне» хикәясенең төп герое Ниса әби авылын бик сагынганда Шишкинның мәгълүм картинасын карап юана... Әнә шундый егет инде ул безнең Марсель Галиев. Укучыны әсәрләре белән әсәртергә һәм шаккаттырырга ярата. Үзе дә иптәшләрен әсәртеп һәм шаккаттырып яшәргә, бераз гына кыланып яшәргә ярата!

Татар әдәбиятының үз традицияләрен тагын да баету һәм үстерү белән бергә, яшьләр безнең хикәянең төсен һәм кыяфәтен яңарта, заманга яраклаштыра төштеләр. Бүгенге татар хикәясе кайчак джинси костюм кигән, авызына пачкасы бер тәңкәлек «Мальборро» сигареты капкан, кара күзлекле фырт егетне хәтерләтә. Шул кадәресен дә әйтим, чама хисен югалтмаганда, безнең хикәягә мондый кыяфәт тә килешә икән. А. Ганиев һәм Ә. Гаффар, Ә. Гадел һәм М. Галиев, С. Шәмси һәм Х. Гайнетдинов, Н. Гыйматдинова һәм Ф. Хуҗиәхмәтоваларның хикәяләре белән таныш кешеләр минем белән килешерләр дип уйлыйм.

Әйе, яшьләр арасында өметле хикәячеләр күп, аннан да бигрәк, юмористлар күп. Юмористларның иң кызыклылары — Ф. Яруллин белән Ф. Шәфигуллин.

Ф. Яруллинның «Зәлифә ире» һәм «Картлар» исемле хикәяләренә сокланyымны белдерәм. «Картлар» дигәне бигрәк тә шәп. Вакыт күплектән, эч пошудан әй остарып китәләр болар бер заман. Мотоцикллар белән йөртмәсләр иде, транзистор акыртуны, пианино дыңгырдатуны тыярлар иде, алай итәрләр иде, болай итәрләр иде... Итәрләр иде дә, итә алмыйлар шул. Стакан эчендә давыл кузгатудан эш узмый. Юкка гына акыллы булып кыланалар, юкка гына дөньяны тәртипкә салып, шәп законнар чыгарып утыралар. Картайгач булмый ул...

Мәгънәле һәм заманча хикәя. Бүгенге тап-таза, яп-яшь егетләрне без тормышны белмәүдә гаеплибез. Күпме еллар буе урын өстендә кузгала алмый яткан Фәнис ифрат дәрәҗәдә тормышчан, заманча һәм оптимист хикәяләрне бер-бер артлы коеп кына тора! Уйласаң, хәйраннар калырлык...

1967 елда булса кирәк, «Казан утлары» журналы укучыларны Фаил Шәфигуллин дигән яңа автор белән таныштырган иде. Ул заманнарда яшь авторлар белән таныштыруның закон төсенә кергән үз тәртипләре, үз кагыйдәләре бар иде. Фаил белән дә нәкъ шулай таныштырдылар шикелле... Бер кәлтә шигырьләре басылган, артистларча төшкән фоторәсеме һәм ифрат дәрәҗәдә купшы итеп язылган танышу сүзе урнаштырылган иде. Мин фәлән авылда туганмын дип кенә калмый. Минем туган бишегем, дип «җиффәрә». Фәлән җирдә укыйм дип кенә чикләнми, яшьлек хыялларыма канат үстергән белем учагым, ди. Сүз иҗат мәсьәләләренә килеп җиткәч, яшь автор тагын да йөрәкләнеп китә, тагын да арттырып җибәрә. Үзе яп-яшь бер егет. Әле беренче тапкыр укучы алдына чыга. Аның инде шигъри алласы да мәгълүм, пәйгамбәре дә билгеле, әдәби кыйбласы һәм иманы да анык.

Әмма мине әле шул вакытта ук, боларның барсыннан да бигрәк, авторның тормыш юлы, дөнья күргән кеше булуы гаҗәпләндергән иде. Кайларда гына булмаган да, кем булып кына эшләмәгән ул... Шуннан бирле мин аның иҗатын күзәтеп барырга тырышам. Ф. Шәфигуллин шигырь һәм проза язды, балалар өчен һәм зурлар өчен язды, җитди әйберләр һәм юмор язды. Шулай да аның таланты балалар әдәбияты һәм юмор өлкәсендә аеруча матур һәм тулы булып ачылды шикелле. Бүгенге көндә Ф. Шәфигуллин — безнең иң өметле балалар язучысы, абсолют «слух»ка ия булган иң шәп юмористыбыз.

Мин сезне язучыларыбызның бер ел эчендә дөньяга чыккан хикәяләре белән таныштырдым, өстән-өстән генә булса да ул хикәяләргә хас уңай һәм кимчелекле яклар турында сөйләдем. Хәзер инде үземә аеруча нык ошаган яки мине әсәрткән берничә хикәягә киңрәк тукталырга рөхсәт итегез.

Сүзне әсәрткән хикәяләрдән башлыйм. (Һәр әсәрткән хикәя яхшы булмаска да мөмкин. Ул кадәресе аңлашыладыр, дип уйлыйм).

Беренчесе — А. Мифтахетдиновның «Келенеут» исемле хикәясе. Чукча кызы Келенеут чегән Ложкинны ярата. Тегесе, кыздан туеп, моңардан котылырга җай эзләп йөри башлый. Дөресрәге, бөтенләй башка җиргә күченеп китәргә була. Шуны сизеп алган Келенеут яратуын көч кулланып, кулына мылтык һәм пычак тотып раслый... Гел диалоглардан торган гыйбрәтле хикәя... Гадәттән тыш вакыйгаларга корылган экзотик хикәя. Мин аны кыргый кабиләләр турында «Вокруг света» журналында басыла торган кызыклы мәкалә кебек мавыгып укыдым...

Икенчесе — Д. Вәлиевнең «Портрет» исемле хикәясе. Шулай ук гадәттән тыш вакыйгага корылган, сирәк кешеләр һәм сирәк мәхәббәт хакындагы хикәя. Гомер буе ниндидер рәссам ясаган бер портретка гашыйк булып яшәгән хатын реаль тормыш-

та шул портретка охшаган кешене очрата. Очратуга муеннан гашыйк була. Яраткан эшен һәм баласы белән ирен ташлап, Никольский фамилияле шул кешене эзләп китә. Аның нянкасы, экономкасы булып яши. Ихтимал, ул үзен бәхетле сизгәндер... Бервакыт хатын үлә. Шуннан соң гына Никольский әлеге хатынның үзе өчен дөньяда иң кадерле кеше булганын аңлый... Нәкъ Г. Тукай шигырендәгечә: «Без аны кая белик, мескен, үлеп аңлатмагач»... Шактый кызыклы хикәя, классик әдәбият традицияләре җирлегендә язылган хикәя. Дөнья әдәбияты белән ныклап таныш булмаган, көнкүреш темасына язылган хикәяләрне укый-укый тәмам туйган татар укучысына бу хикәя, ихтимал, тансык аш булып тоелгандыр?! Әсәртүе дә шуннан киләдер... «Портрет» та, «Келенеут» та безнең әдәбият традицияләрендә язылган хикәяләр түгел.

Хәзер инде үз җирлегебездә язылган хикәяләргә тукталыйк. Алар — күп. Урын һәм вакыт булса, мин Н. Гыйматдинованың «Моңсызлар моңы», М. Маликованың «Сары тюльпаннар», Ә. Сәгъдиеваның «Палатада», Ә. Гаделнең «Ялгыз аккош», Р. Фәизовның «Күңелле көн» хикәяләренә рәхәтләнеп бер анализ ясар, Р. Кәрами, К. Кәримов һәм Батулла хикәяләре хакында да мактау сүзләре әйтә алыр идем. Шулай да үземә нык охшаган өч хикәя — Х. Камаловның «Куян күзе нигә кызыл?», М. Хәбибуллинның «Яңа өй» һәм Г. Гаффарның «Янгын» исемле хикәяләре турында берничә сүз әйтми уза алмыйм.

Исеменнән үк күренгәнчә, Ә. Гаффар хикәясендә сүз янгын, безнең яктагыча әйтсәк, пожар турында бара. Саксызлыгы һәм гамьсезлеге аркасында, Мәүлия исемле хатын, авылда ут чыгарып, алты семьяны йорт-җирсез калдыра. Әмма, Ф. Хөсни әйтмешли, мәсьәлә пожарда түгел, ә авыл кешеләренең шул хәлгә, шул янгынга мөнәсәбәтендә. Милиционер Шәйхулла янгын сүндерергә килгән машиналарны үз йортын уттан саклау өчен тота... Ут чыгарып, алты гаиләне урамда калдырган Мәүлия: «Ут сүндергәндә керфекләрем көйде, кияүгә ничек күренермен», — дип борчыла. Йортлары янып, урамда калган алты гаиләнең дә пожарга исләре китми. Киенепясанып, кичке биләмгә чыгалар. Я ходаем! Кая бара бу дөнья! Байлыктан симергән бу халык тагын ниләр кыланыр икән, дип шомлана башлыйсың... Ә. Гаффар усал, тормышчан һәм заманча хикәя язган.

Х. Камаловның «Иске дәфтәр» һәм «Куян күзе нигә кызыл?» исемле хикәяләре турында Фатих ага Хөснинең мәкаләсен укыгансыздыр. Мин нигездә ул мәкалә белән килештем. Тик бер ачыклык кертәсе килә. «Куян күзе нигә кызыл?» исемле хикәя, Фатих ага уйлаганча, Әнфиснең кырыс бәгырьле әтисе Гаптелмәнне гаепләү өчен генә язылмаган. Гаепле кешеләр бер Гаптелмән ага гына түгел. Эш аңа китсә, чалбар кигән лаборатория кызлары белән завхозны да, хәтта куян бәлешен ярата торган Әнфиснең үзен дә гаепләп булыр иде... Тик монда гаеплеләр юк. Монда кырыс тормыш чынлыгы гына бар. Сыерларга укол кадар өчен яшь куян каны кирәк, тәмле бәлеш пешерү өчен куян ите кирәк. Бу — хакыйкать, бу — мәҗбүрият. Әнфис моны үзе дә аңлый. Хикмәт башка нәрсәдә. Бала беренче тапкыр тормышның әнә шул мәҗбүрияте, кырыс рәхимсезлеге белән очраша. Аның бәгыре шуңа телгәләнә, аның җаны шуңа әрни... Уйландыра торган хикәя, көчле хикәя. Х. Камаловның «Иске дәфтәр» исемле хикәясе дә шундыйрак. Безнең Хисам Камалов дигән шәп прозаигыбыз, драматик һәм сатирик хикәя остабыз бар.

М. Хәбибуллинның «Яңа өй» — традицион татар хикәясе. Эчтәлеген сөйләп тормыйм. Драматик хикәя, тирән психологик хикәя, характерлар хикәясе. Характерларының һәммәсе кызыклы, һәммәсе тормышчан. Миңа аеруча нык ошаганы Нурислам образы булды. Автор мәхәббәтнең һич кем башына килмәгән якларын ача, кеше күңеленең, кеше җанының әллә кайдагы тирән чоңгылларына төшеп җитә. М. Хәбибуллинның төрле әсәрләре бар. Әмма «Чоңгыллар» романы белән «Яңа өй» хикәясе аның зур мөмкинлекләргә ия прозаик булуы турында сөйли.

Узган ел басылган хикәяләрнең теленә махсус тукталып тормаска булдым. Беренчедән, җанны рәнҗетерлек, бәгырьне телгәләрлек тел белән язылган хикәяләр очрамады. Икенчедән, тел турындагы сүзне бу өлкәнең үз белгечләренә калдыру дөрес булыр. Шулай да әдәби тел мәсьәләсенә караган бер фикерем белән уртаклашмыйча уза алмыйм. Язма әдәби телне шартлы рәвештә ике төргә бүләргә мөмкин булыр.

иде. Берсе — мәкалә һәм очерк теле, ягъни публицистика теле. Икенчесе — матур әдәбият әсәре, ягъни сәнгать әсәре тудыра торган тел. Публицистика телен яхшы, уртача, начар үзләштергән кешеләр булган кебек, язучылар арасында да телне белү һәм үзләштерү җәһәтеннән төрле кеше очрый. Ләкин хикмәт анда түгел. Хикмәт шунда: әлеге төрләрнең һәркайсын үз урынында кулланырга кирәк. Нихәтле генә камил һәм шома тоелмасын, публицистика теле белән сәнгать әсәре тудырып, матур әдәбият әсәре язып булмый. Ә бездә гомер буе публицистика теле белән хикәя язып йөрүчеләр бар. Начар хикәяләрнең өлкән яшьтәге язучылар иҗатында күбрәк очравы, бәлки, шуның белән дә аңлатыладыр...

Мавыгып, әллә кайларга кереп киттем бугай. Сүзне очлый, фикерне түгәрәкли башларга вакыт. Хикәя жанрының җанлана һәм активлаша төшүе күз алдында. Бу кадәресе шик уятмас, дип уйлыйм. Тик моның җирлеге кайда, сәбәбе нәрсәдә? Уйлана торгач, моңа да җавап таптым шикелле. Партиянең XXVI съездында сөйләгән докладында, әдәбият һәм сәнгатьнең бүгенге хәленә тукталып, Л. И. Брежнев: «...Барлык укучылар, тамашачылар һәм тыңлаучылар бер нәрсәне сизәләр: совет сәнгатендә көчле яңа дулкын күтәрелеп килә»,— диде. Аның бу сүзләре безнең әдәбиятка да карый. Бездә дә шундый бер халәт сизелә: әдәбият-сәнгать өлкәсендә, гүя, менә-менә көчле давыл, зур һөҗүм, язгы ташу башланырга тора. Хикәя шул турыда сөйли, шуңа ишарә ясый. Публицистика белән драматургия кебек үк, хикәя әнә шул туып килгән ташкынның, тиздән башланачак көчле әдәби хәрәкәтнең беренче хәбәрчесе, беренче карлыгачы, дип уйлыйм. Дөресрәге, шулай уйлыйсым килә!

# ШАГЫЙРЬНЕҢ КҮҢЕЛ ЯКТЫСЫ

Заман шагыйрьләрне төрлечә сыный: лауреатлар итеп тә, җитәкче-башлык итеп тә, мактап-чөеп тә, тәнкыйтьләп-сүгеп тә. Шул сынауларга чыдамыйча, масаеп киткән, яисә бөгелеп-сыгылып төшкән, я симереп ялкаулангaн пегасын ни белән куарга белми аптыраган, хур булган очраклар шактый. Төрле сынауларның берсенә дә бирешмәгән, үзенең намусын һәрчак саклый белгән, фидакарь каһарман затлар да бар. Алар иҗатта һәм тормышта үзләренең исеменә тап төшермичә, көнкүреш ваклыкларына күмелмичә, олы иманнарына хыянәт итмичә, илгә һәм халыкка армый-талмый хезмәт итеп гомер кичерәләр.

Зәки Нури — әнә шундый, тормышта да, иҗатында да батыр характерлы шагыйрьләрдән. Ул лирика һәм сатира-юмор өлкәсендә уннарча еллар буена бердәй активлык белән эшләп килә. Бу иҗат аңардан көн саен рухи һәм физик батырлык сорый. Шагыйрьне якыннан белүче һәркем аңардагы бу батырлыкны күреп тора. Белоруссия урманнарында партизаннар белән уздырган авыр көрәш еллары аның күңелендә гомерлек эз калдырган. Шуңа бирешми иҗат итү, озак еллар республиканың әдәби хәрәкәтен җитәкләү фидакарьлектән, көчле характердан башка мөмкин түгел. Зәки Нуриның «Шагыйрь китапханәсе» сериясендә чыгарылган «Күңел яктысы» исемле китабы[1] әнә шундый уйлар кузгата. Китапта шагыйрьнең кырык ел дәвамында язылган иң яхшы әсәрләре тупланган. Алар нигезендә шушы иҗатның идея-сәнгатьчә йөзе, әдипнең шәхесе турында тулы һәм объектив хөкем йөртергә мөмкин.

Шагыйрь укучының таләпчәнлеген яхшы белә, аның каршына ул ачык күңел белән килә:

> **Ачам сиңа китап битләремне,**
> **Йөрәгемне учка салган төсле.**
> **Шәфкать көтмим: әгәр алдаласам**
> **Чын дип әйтеп берәр ялган төсне.**

Шагыйрь чынлап та бу китапка заман сынавын узган әсәрләрен генә керткән. Аны бүлекләргә аерып төркемләгәндә дә моңарчы чыккан, укучының игътибарын җәлеп иткән китапларының исемнәрен куллана: «Ачык тәрәзә», «Ел буе яз», «Ут чәчеп һәм ук чәнчеп» һ. б.

Китапның гомуми рухын, асыл эчтәлеген аның исеме төгәл чагылдыра: «Күңел яктысы». Бу да яңа гына уйлап чыгарылмаган — шагыйрьнең 50 нче елларда басылган иң көр тавышлы китапларыннан берсенең исеме.

Күңел яктысы. Нинди эчтәлек сала соң шагыйрь бу төшенчәгә? Шәхесне бербөтен буларак характерлау өчен мөһим һәр өч шарт та шушы төшенчәдә бар: табигатькә, җәмгыятькә һәм үз-үзенә мөнәсәбәтнең эчке гармониясе. Җыентыктагы әсәрләрдән күз алдына килә торган лирик геройның иҗтимагый-әхлакый йөзен, гражданлык йөзен билгеләгән әйдәүче сыйфат — ул якты оптимизм. Аның күңел яктысы, барыннан элек, шушы сыйфатны эченә ала.

Киләчәгенә ныклы ышаныч белән атлаган хөр җәмгыятьтә иҗат итүче сәнгатьчәр өчен оптимизм ниндидер батырлык таләп итәрлек сыйфат та түгел кебек. Әмма бу беренче карашка гына. Һәр иҗади шәхеснең үз шигъри дөньясы, үзенчәлекле

[1] Зәки Нури. Күңел яктысы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981.

карашы, тормыш тәҗрибәсенә бәйле кайгы-борчылулары, таләп һәм бәяләре бар. Сугыш ,калдырган тирән яралар көн саен үзләрен сиздереп торган шартларда һәрчак оптимист булып калу җиңел эш түгел. Конкрет очракларда ул аерым батырлык эше дә. Зәки Нурига карата бу бигрәк тә шулай.

Шагыйрьнең оптимизм чишмәсе ватанга мәхәббәттән туа. Үзенең олы һәм вак кайгыларын ул ил мәнфәгатьләренә буйсындыра, шуның аркасында үзен һәрвакыт көчле итеп сизә. Менә аның сугыш елларында партизан учагы яктысында язган шигырьләреннән берсе — «Разведчик җыры». Анда ул: «Илемне сөйгән өчен мин көчле»,— ди.

Үтә дә гади юллар. Әмма аларда ничаклы самимилек һәм табигыйлек! Чөнки шагыйрь иң көчле дәлил — үзенең тормышы һәм түккән каны белән ышандыра.

Соңрак исә:

**Туган илем, синең тавыш көргә**
**Көче дә зур җырның, эше дә,**

— дип ача ул шигърияттәге оптимизм чыганагын.

Шагыйрьнең шәхесе сугыш елларында формалаша. Моны аның шул чордагы шигырьләрендә гәүдәләнгән эстетик кредосыннан күрергә мөмкин. Кан коюлы көрәшнең төп максатын шагыйрь яшәү матурлыгын саклап калу дип аңлый. Шушы идеал өчен сугышу аның каһарманын әхлакый өстен итеп куя, гуманист итеп күтәрә. Аның солдатында менә нинди кешелекле хыяллар:

**Җиңү килер — безнең учакларны**
**Салют итеп күккә чөяр ул.**
**Кем көрәшә сагынып шул чакларны,**
**Матур яшәр, матур сөяр ул.**

Зәки Нуриның эстетик идеалы да шушы нигезгә корылган.

Аның карашынча, камил шәхес батырлык белән матурлыкның аерылгысыз бердәмлегеннән барлыкка килә. Мәсәлән, Муса образын ул шулай күз алдына китерә: «Әйтә Муса: чын матурлык — Көрәштә батыр булу...» Иҗат җаваплылыгы турында уйлаганда шагыйрь Мусаның каһарман истәлегенә әледән-әле мөрәҗәгать итеп тора. Сугышчан командиры Константин Заслонов белән Җәлил сурәте аның күңелендә янәшә яши, берсе — солдат вөҗданы, берсе иҗат вөҗданы булып, тормышта юл күрсәтәләр. Табигый янәшәлек һәм мәгънәле маяклар...

**Дядя Костя күз алдында тора,**
**Кулларында мина уйнатып.**
**Ә Җәлилем — йөрәгемдә яши,**
**Иң җаваплы җырны уйлатып.**

Зәки Нурины хаклы рәвештә татар поэзиясенә үзенчәлекле агым — партизан лирикасын алып килүче итеп саныйлар. Әмма аның иҗатында иң зур урынны сугыш түгел, ә хезмәт темасы алып тора. Шигырьләрендә гәүдәләнгән солдат образы да асылы белән иҗатчы, гуманист солдат. Тыныч көнгә менә ничек сөенә ул:

**Чәчәк ата кебек үзе күңел,**
**Таң шикелле хис саф, уй якты.**
**Мине бүген бомба шартлап түгел,**
**Сандугачлар сайрап уятты.**

Лирик герой — хезмәтеннән ихтыярсыз аерылган егет. Тыныч хезмәтне сагынып кайтканга, ул аның кадерен белә. Эш сөю мотивы шунлыктан биредә аеруча мәгънәле яңгырый. Аның бөтен стихиясе — төзү, иҗат итү: «Әй, эшлисе килә, эшлисе лә, Тырыш кояш белән ярышып».

Соңгы унъеллыклардагы киң колачлы төзелешләр, тыныч хезмәт турында уйланганда, шагыйрь үзенчәлекле шигъри ачышлар ясый. Мәсәлән, республикабызда кыска вакыт эчендә барлыкка килгән Түбән Кама каласын ул: «Шәһәрне гүя краннар җирдән тартып чыгардылар»,— дип, һич көтелмәгән ракурстан тасвирлый.

Батырлык һәм матурлык гармониясе турындагы хыял аның төзүче геройларына да хас. Мәсәлән, Түбән Кама төзүчесе болай ди:

**— һөнәребез шундый безнең:**
**туган җирне матурлыйбыз.**
**Батырлар матур булсыннар,**
**батыр булсын матур! — дибез.**

Зәки Нуриның иҗаты дәвамында ачылачак күп сыйфатлары сугыш чоры шигырьләрендә үк бөреләнә. Моны югары гражданлык хисенең интим характердагы шигырьләргә үтеп керүеннән дә күрергә мөмкин. Шагыйрьнең тулы канлы рухи тормышы, мәгънәви яшәеше барлык януларны илне сөю кебек олы янугa кушудан барлыкка килә. 1944 елда язылган «Ялкын» исемле шигырьдә:

**Шуңа мин шат, йөрәктә саф**
**Ялкыным яши.**
**Илем өчен, синең өчен**
**Талпыну яши,**

— ди лирик герой үзенең сөеклесенә. Ватанга мәхәббәт һәм горурлык хисе «Тынычлык иле» кебек киң сулышлы шигырьләрдә бөтен тулылыгы белән гәүдәләнә. Шушындый көр аһәң, якты оптимизм табигать турындагы шигырьләрдә дә көчле чагыла.

Табигать темасы дигәннән, аның Зәки Нури иҗатында зур һәм үзенчәлекле урын тотуын әйтергә кирәк. Шагыйрь урманны табигать кочагында йөрешли генә күзәтүче түгел, ул — урман хуҗалыгы белгече. Шунлыктан табигатькә аеруча якын торып яза. Аның табигатькә мөнәсәбәте гаять кешелекле, күзәтүләре нечкә, фикерләве шигъри.

**Син һәрбер үләнгә, син һәрбер куакка**
**Әйтерсең ямь-яшел ут төртеп йөрисең,**

— дип мөрәҗәгать итә ул язга.

Яз — һәр шагыйрьнең яраткан темасы. Зәки Нури елның бу фасылын бөтенләй үзенчә җанландыра. Язны куәтле янгын итеп күз алдына китерә ул. Яшел янгын. Күңелне хушландыра торган сурәт! Көзне янгын итеп метафоралаштыру поэзиядә очрый торган күренеш. Алланып янган яфракларга, усакларга карап шагыйрьләр шулай уйлый. Янгын метафорасын язга карата куллану — шагыйрьнең тапкырлыгы һәм кыюлыгы дияргә кирәк.

**Салкыннарны диңгезләргә агызды яз,**
**Тирә-юнгә яшел янгын кабызды яз.**

. . . . . . . . . . . . . . . . . . .

**Тыңлыйм язны — һәр авазын ишетәм мин.**
**Үземне бер яфрак диеп хис итәм мин.**

Кеше үзе дә табигать баласы. Аның яшәү ритмы, хис хәрәкәте табигать ритмына кушыла. Шагыйрь табигатьнең табигыйлеген, үзенчәлекле бөтенлеген яклый.

**Юк, бакчалар кирәк түгел димим,**
**Юк, кимсетмим бүлмә гөлләрен,**
**Ләкин мең кат бәхетлерәк минем**
**Кыр чәчәген күргән көннәрем.**

Зәки Нуриның лирикасы ил батырларын, иҗади хезмәтне, тыныч көнне данласа, сатира-юмор әсәрләре әхлакка һәм матурлыкка ят күренешләрне камчылый. Бу жанрда аның үзенчәлекле шигъри теле, аһәңе, көлү алымнары бар. Аның халыкчан үткен тел белән язылган мәсәлләре, сатирик диалогары, фельетон һәм дүртюллыклары хәзерге шигъри сатира-юморда лаеклы урын билиләр. Алар арасында ташка уеп язарлык үрнәкләр күп.

Сүз сырлама ташка бастырырга
Кулда каләм булган өчен генә.
Фикер көчең таш кузгата алсын,
Ә булмасын — ташка үлчим генә.

Шагыйрь иҗатының интернациональ табигатен аның тәрҗемә эшчәнлегеннән аерып карау мөмкин түгел. Ул татар укучыларын илебез әдәбиятларының уннарча һәм уннарча күренекле вәкилләре белән таныштырды. Украин, белорус, әрмән һ. б. зур әдәбиятларның кече антологияләр рәвешендәге татарча шигъри бәйләмнәрен Зәки Нури эшләде. Әлеге китапта шагыйрь тәрҗемә эшчәнлегенең максатын билгеләп, болай ди:

Озын юллар тизрәк кыскарсын да,
Очрашсыннар җырда халыклар.

Кыскасы, шагыйрьнең әлеге зур тупламда чагылыш тапкан игелекле иҗаты аның юмарт күңел яктысы булып күз алдына килә. Оптимизм — аның даими юлдашы. Тормышны якты кабул итү, киләчәкнең яктылыгына чиксез ышану—шагыйрьнең иманы.

**НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# РУХИ ТУГАНЛЫК НИГЕЗЕНДӘ

Дөресен генә әйткәндә, бездә әдәбият-сәнгатьне өйрәнү методологиясен билгеләгән, теория мәсьәләләрен күтәргән, культура үсешенең төп закончалыкларын ачыклаган хезмәтләр еш чыкмый. Ә алар бик кирәк. Моны әдәбият-сәнгатьнең иҗтимагый тормышыбызда һәм кешелекклелек хакына барган киеренке көрәшебездә тоткан урыны таләп итә. Профессор Мансур Хәсәновның культура һәм әдәбиятыбыз үсешендәге олы мәсьәләләргә багышланган «Интернационализмның җанлы традицияләре»[1] исемле китабы әнә шул тансык рухи нигъмәтләр җемләсенә керә.

Болай караганда, авторның төрле елларда язган мәкаләләре җыентыгы ул. Әмма аларны бергә туплап укучыга ирештергәч, әдәбият-сәнгатебез һәм гомумән культурабыз үсешенең шактый тулы панорамасы күз алдына килеп баса. Җыентыктагы мәкаләләр һәм иҗат портретларын лейтмотив булып сузылган идеяләр берләштерә. Теория һәм методология мәсьәләләренә багышланганнармы алар, партиянең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге политикасын аңлаталармы, теге яки бу әдипнең культура тарихыбыздагы һәм әдәбиятыбыздагы урынын ачыклыйлармы — китапның төп аһәңен социалистик реализм методының чыганаклары, бу методның тамырланып үсеп китүенә һәм иҗат процессында мул җимешләр китерүенә хәлиткеч йогынты ясаучы объектив һәм субъектив факторлар, татар әдәбиятының үсеш закончалыклары, перспективалары турында җитди уйланулар, гомумиләштерүләр тәшкил итә.

Әдәбият-сәнгатьнең магистраль үсеш юлын күзәтү, бу хакта җитди нәтиҗәләр ясау өчен, әлбәттә, әдипләребезнең социалистик реализмга килү, аны үзләштерү һәм үстерү этапларын җентекләп өйрәнү зарур. Мансур Хәсәнов үзенең хезмәтләре белән

[1] Хәсәнов Мансур. Интернационализмның җанлы традицияләре. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

шушы хакыйкатьне раслый. Гомумән, татар художество культурасын, аның аерым чорларын һәм вәкилләренең иҗатларын анализлау җирлегендә автор, социалистик реализм — һәр милли әдәбиятның совет чорындагы эчке үсеше нәтиҗәсендә ирешелгән югары этабы, социалистик милләтләрнең әдәби-эстетик казанышы дип исбатлый. Ул социалистик реализм методының новаторлык асылына игътибарны юнәлтә. «Социалистик реализм принцибының үзендә үк новаторлык бар, чөнки социалистик реализмның асылы чынбарлыктагы төп үсеш тенденцияләрен күрсәтүдән, яңалыкка үсәргә ярдәм итүдән гыйбарәт» (54 бит). Совет художество культурасының новаторлыгы нигезендә дөньяга, чынбарлыкка яңача караш, яңа чынбарлыкны яңача гәүдәләндерү чаралары ята.

Автор социалистик реализм методының художник өчен бетмәс-төкәнмәс иҗади мөмкинлекләр ачуын, аның какшамас принциплары — чынбарлыкны революцион үсештә сурәтләү, коммунистик партиялелек, халыкчанлык һәм тарихилыкның тормышны дөрес сурәтләргә, тарихи үзгәрешләрне күрергә, тормыш конфликтларын дөрес чагылдырырга, кешеләр характерындагы яңалыкны ачарга ярдәм итүен ассызыклый. «Социалистик реализм формалашуның кайбер мәсьәләләре» исемле мәкаләдә Галимҗан Ибраһимов иҗатын бөртекләп анализлау җирлегендә аеруча ышандыргыч һәм дәлилле нәтиҗәләр ясала.

Шул рәвешле, китапта урын алган хезмәтләрнең бер үзенчәлеге — культурабыз үсешен һәм бу процессны фәнни тикшерүнең җитди проблемаларын күтәрүендә, ул проблемаларны бүгенге фәнни-методологик югарылыкта төпле, бай дәлилләр системасы нигезендә хәл итүендә. Җыентыкны ачып җибәргән «Сәнгать, халык, коммунизм» дигән хезмәтне генә алыйк. Бу күләмле мәкалә социализмнан коммунизмга күчү чорында партиянең рухи культура өлкәсендәге стратегиясен аңлатуга һәм фәнни анализлауга багышлана. Биредә коммунизм җәмгыяте культурасының төп үзенчәлекләре сыйфатлана, шуларга ирешү юллары күрсәтелә, рухи культурада дәвамчанлык, традиция һәм новаторлык мәсьәләләре тикшерелә, әдәбият-сәнгатьнең идеялелеге, партиялелеге, гуманизмы, интернационализмы, политика белән элемтәсе анализлана. Шул ук вакытта буржуаз культураның черен таркала баруы һәм аңа каршы эзлекле көрәш җәелдерү зарурлыгы исбатлана, хезмәт ияләрендә әдәби һәм сәнгати зәвык тәрбияләү өлкәсендәге кичектергесез бурычлар ачыклана, әдәбият-сәнгатькә партия җитәкчелегенең хәлиткеч чара икәнлеге ассызыклана. Күренә ки, хезмәттә никадәр җитди мәсьәләләр куелган! Һәм алар совет культурасының үсеш закончалыкларын һәм тенденцияләрен гәүдәләндерүче кыйммәтле тәҗрибәгә таянып хәл кылынган.

М. Хәсәнов җыентыгына киң колачлылык хас. Андагы һәр хезмәттә авторның зур эрудициясе үзен нык сиздереп тора. Хикмәт күтәрелгән мәсьәләләрнең җитдилегендә һәм төрлелегендә, фәнни яктан тирән эшләнешендә генә түгел, гәрчә бу — иң мөһиме булса да. Колачлылык фәнни-тикшерену офыкларының киңлегендә дә чагыла. Моның бик ачык бер мисалы — «Ленин тәгълиматы һәм татар иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү» исемле хезмәт. В. И. Ленинның һәр буржуаз милләт культурасында ике культура булуы турындагы тәгълиматы, культура революциясе хакындагы өйрәтмәләре нигезендә автор Татарстан республикасының казанышларын, татар халкының узган һәм бүгенге тормышын өйрәнүнең, иҗтимагый фикердәге барлык тармакларның торышын җентекләп анализлый, ирешелгән уңышларын барлый, җитешсезлекләрне, аларны китереп чыгарган сәбәпләрне ача, алда торган актуаль бурычларны, проблемаларны нигезли. Авторның «Иҗтимагый-политик фикер тарихын өйрәнүче галимнәрнең игътибары, һичшиксез, Татарстанның совет чоры тарихын, республикадагы социаль-политик процессларны, культура проблемаларын, интернациональ тәрбия мәсьәләләрен фәнни тикшерүгә юнәлдерелгән булырга тиеш» (96 бит) дигән нәтиҗәсе аерым игътибарга лаек. Татар халкының килеп чыгышын, татар халкы һәм татар милләте формалашуының аерым мәсьәләләре, узгандагы иҗтимагый-политик хәрәкәттә төрле социаль көчләрнең бүленешен өйрәнгәндә милли хәрәкәтнең аерым вәкилләренә, тарихи һәм әдәби күренешләргә, бигрәк тә революциягә кадәрге кондәлек матбугат органнарына бәя биргәндә партияле мөнәсәбәтне көчәйтү, буржуаз фальсификаторларның яла ягуларын фәнни нигездә һәм эзлекле фаш итү проблемаларын шундыйлар рәтенә кертергә мөмкин.

Китап авторының колач киңлеге янә шунда, ул теге яки бу теоретик проблеманы хәл иткәндә, әдәбиятка да, сәнгатькә дә мөрәҗәгать итә. Авторның анализы, нәтиҗәләре, гомумиләштерүләре ышандыра, дәлилләре нигезле. «Интернационализм һәм новаторлык юлыннан», «Хәрәкәттәге социалистик реализм» исемле фәнни-публицистик хезмәтләр — моңа ачык мисал.

Киң колачлылык традиция һәм новаторлык нисбәтен тикшергәндә аеруча ачык чагыла. Автор әдәбиятыбызның, гомумән культурабызның үсеш тенденцияләрен ачыклаганда узгандагы һәм хәзерге әдәби, мәдәни фактларны, күренешләрне төптән белеп урынлы куллана. «Интернационализмның җанлы традицияләре», «Социалистик реализм формалашуының кайбер мәсьәләләре» дигән хезмәтләрендә, иҗат портретларында ул узган белән заманчалыкның бәйләнешын аеруча оста ачып биргән.

Колач киңлеге шулай ук аерым культура эшлеклеләренең иҗатын тикшерү алымнарында да үзен сиздереп тора. Әйтик, Г. Тукайга («Тукай хакында сүз»), Г. Ибраһимовка («Әдипнең бөеклеге»), Г. Камалга («Татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучы») багышланган иҗат портретларында, әлеге әдипләрнең культурабыз, әдәбиятыбыз тарихында тоткан урыннары анализланып, аларның күпьяклы эшчәнлекләре бөтен тулылыгы белән тәфсилләнеп кенә калмый, хәзерге татар һәм тугандаш халыклар культурасына йогынтысы да ачып бирелә.

Китаптагы хезмәтләрнең янә бер үзенчәлеге шунда, аларда фәннилек публицистик ялкын белән үретелгән. Бу исә аларга партиячел дәртлелек, сугышчанлык, ышандыру көче өсти. Яшерен-батырын түгел, безнең әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланган байтак мәкаләләребезгә нәкъ менә публицистик ялкын җитми.

Катлаулы проблемаларга багышлансалар да, хезмәтләрнең теле йөгерек, җиңел аңлаешлы, кулланылган терминологиясе төгәл.

Китапның исеменнән күренгәнчә, андагы хезмәтләрдә татар совет культурасының, әдәбиятының интернационалистик асылын тикшерү үзәк урынны тота. Шуңа күрә дә җыентыкның әлеге хасиятенә аерым тукталу урынлы булыр.

Илебездә яңа тарихи гомумилек — совет халкы формалашуның яңа эстетик гомумилек барлыкка китерүен һәм аның төп үзенчәлекләреннән берсе интернационализм икәнен искәртеп, М. Хәсәнов татар әдәбиятын күп милләтле совет әдәбиятының аерылмас өлеше итеп карый, бу бердәмлелекнең нигезендә прогрессив объектив закончалыклар, шул исәптән интернационализм ятуын басым ясап күрсәтә.

Ул татар әдәбиятының интернационализмын тарихи планда да, иҗат практикасында тупланган тәҗрибә җирлегендә дә, әдәбият-сәнгать үсешенең гомуми фонында да, күренекле әдипләребез иҗаты мисалында да тикшерә. Шуңа күрә интернационализм әдәбият-сәнгать үсешенең билгеле бер этабында гына, аерым художникларның иҗатында гына чагылып китә торган күренеш булып түгел, ә культурабызның магистраль юлы, төп закончалыгы булып тоемлана.

М. Хәсәнов үзенең хезмәтләрендә әдәбиятыбыз интернационализмының тарихи чыганакларына, формалашу этапларына еш мөрәҗәгать итә. Бу тикмәгә генә түгел. Чөнки интернационализм чыганаклары һәм традицияләре өлкәсендә теоретик эзләнүләр алып бару, билгеле бер гомумиләштерүләр ясау өчен татар әдәбияты бик бай материал бирә. Автор, ул традицияләрнең башлангычын ачыклаганда, игътибарны хаклы рәвештә ике төп моментка юнәлтә. Аның фикеренчә, татар әдәбиятындагы интернациональ традицияләр, бер яктан, рус культурасы һәм рус теле ярдәмендә Көнбатышка ачылган «тәрәзәләр», икенче яктан, илебездәге төрки әдәбиятлар һәм гомумән дә Көнчыгышның алдынгы культурасы белән тыгыз бәйләнешләр җирлегендә тамырлана. «Интернационализмның җанлы традицияләре» дигән хезмәтендә автор әдәби дуслык чишмәләренең тибеп чыккан урыннарына аеруча уңышлы сәяхәт ясаган. Әлбәттә, бу сәяхәт аңа тарих сәхифәләрендә чәчелеп яткан җәүһәр-фактларны җыеп күрсәтү өчен генә түгел (хәлбуки, аның бусы да — бик кирәкле эш), ә гомумиләштерүләр ясау өчен кирәк. Ул әдәби элемтәләребез хакында сөйләүче фактларның объектив сәбәпләрен аңлату өчен дә зарур. М. Хәсәнов, демократик культура һәм әдәбиятларның элек-электән килә торган бәйләнешләре хакында сөйләгәндә, аларның нигезе булган объектив сәбәпләргә татар халкының географик урыны, тарихы, илдәге сәяси шартлар, университет эшчәнлеге һәм башка факторларны кертә.

М. Хәсәнов, интернационализм традицияләренең нигезен тикшергәндә, бер мәсьәләгә игътибарны юнәлдерә: «Халыкның рухи тормышында чын мәгънәсендәге интернационализм ул илнең экономик үсеше интернационаллашкан чакта гына, иҗтимагый көрәш аренасына эшче сыйныфы чыккач кына була ала, ягъни революцион азатлык көрәшенең пролетар дәвере башланганда гына була ала» (110 бит). Принципиаль әһәмияткә ия булган нәтиҗә бу. Югыйсә кайбер хезмәтләрдә азатлык көрәшенең пролетар этабына кадәрге демократик культура һәм әдәбиятларның үзара бәйләнешын һәм дуслыгын интернационализм гәүдәләнеше итеп күрсәтү очраклары күренгәләп тора. Сүз дә юк, культуралар дуслыгы һәм интернационализм арасында дәвамчанлык һичшиксез бар, чөнки пролетар культура һәм әдәбият буш урында барлыкка килми, алдынгы кешелек иҗат итеп килгән рухи хәзинәләрне кабул итеп ала һәм алга таба үстерә. Әмма кистереп әйтергә тиешбез: пролетариат культура элементларен тарихта күрелмәгән яңа югарылыкка күтәрә, дөресрәге, бу элементларнең яңа этабын ача. һәм әлеге этапның төп үзенчәлеге — интернационализм. Ул халыкларның үзара якынаюы процессы белән генә түгел, ә эшчеләр сыйныфының идеологиясе, политикасы, психологиясе һәм практикасы белән дә билгеләнә. Интернационализм, яңа иҗат методының бер нигез принцибы буларак, тормышны, характерларны өйрәнү һәм гәүдәләндерү алымына әйләнә.

Җыентыктагы хезмәтләрдә Октябрьдән соң милли культураларның күкрәп үсеп китүе, аларың социалистик эчтәлекне үзләштерүе шартларында интернационализм принцибының әеруча тамырлануы һәм шул үсешнең төп бер сәбәбе булуы ассызыклана. Автор әлеге процессның объектив нигезләрен ача һәм аларны төрле масштабтагы фактлар һәм күренешләр җирлегендә анализлый. Әйтик, «Сәнгать, культура, коммунизм» исемле хезмәттә күп милләтле совет культурасының интернационализмы бердәм коммунистик культурага бару закончалыгы буларак теоретик һәм политик-идеологик планда сыйфатланса, «Ленин тәгълиматы һәм татар иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү» дигәнендә бөтен рухи культурабыз үсешенең төп баскычлары мисалында тикшерелә. Ә инде «Интернационализм һәм новаторлык юлыннан», «Интернационализмның җанлы традицияләре» исемле әсәрләрдә интернационализм проблемалары әдәбият-сәнгать һәм аларның аерым тармаклары үсеше мисалында өйрәнелә. «Социалистик реализм формалашуының кайбер мәсьәләләре» дигән мәкалә, шулай ук алда телгә алынган өч иҗат портреты халыклар дуслыгы һәм интернационализмның аерым әдипләр иҗатында ничек гәүдәләнүен күрсәтә. Мәсәлән, Г. Ибраһимов иҗатын тикшергәндә интернационализмның бик күп чагылышларына игътибар ителә. Бердән, М. Хәсәнов язучының әдәби әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Ул интернационализмның Г. Ибраһимовны халкыбыз тормышын, үткәнен һәм киләчәген тар милли рамкаларда түгел, бәлки интернациональ принципларда торып сурәтләвендә, шулай ук башка халыклар тормышын яратып язуында, башка халык вәкилләренең мөләем образларын сынландыруында күрә. Шул ук вакытта автор әдәбият гыйлемендә һәм тәнкыйтьтә, иҗтимагый-политик һәм журналистлык эшчәнлегендә дә, культурабызның интернациональ элементларен ныгытуда да (бигрәк тә Гыйльми үзәккә җитәкчелек иткән чорда) Г. Ибраһимовның интернационализмын күрә. Ниһаять, әдип иҗатының интернациональ характеры бөтендөнья культурасы казанышларын иҗади үзләштереп кулланууы һәм башка милләт әдәбиятларына көчле йогынты ясавы белән бәйләнештә карала.

Кыскача күзәтүдән үк күренгәнчә, М. Хәсәновның яңа китабында бик күп актуаль мәсьәләләр күтәрелгән, алар бай фактик материал җирлегендә бүгенге методологик һәм теоретик югарылыкта хәл кылынган, шулай ук тагын да өйрәнелергә тиешле мәсьәләләр үзәккә куелган һәм шуның белән культура, әдәбият-сәнгать теориясенә, методологиясенә һәм практикасына җитди өлеш кертелгән. Автордан әлеге проблемалар, бигрәк тә интернационализм мәсьәләләре буенча монографик хезмәтләр көтәргә тулы нигез бар.

**ФЛОРИД ӘГЪЗӘМОВ,**
тарих фәннәре кандидаты

Муса Мөлеков,
филология фәннәре кандидаты

# ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНДӘ КАЛГАН МОҢ

Атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзи 1910 нчы елларда әдәбият мәйданына килеп, Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камаллар нигез салган демократик традицияләрне үстерүчеләрнең берсе булды. Ул үзенең барлык иҗат көчен, талантын халыкка хезмәт итүгә багышлады. Аның мәңге яшәр «Галиябану» драмасы һәм башка әсәрләре ярты гасырдан артык инде татар һәм башкорт сәхнәсеннән төшми уйналып килә.



...Мирхәйдәр Фәйзи 1891 елның 1 ноябрендә Оренбург губернасының Күкшел авылында туа. Әтисе Мостафа Фәйзуллин миллионер Хөсәеновлар утарында управляющий булып эшли. Мирхәйдәр унбер туганы арасында — иң кечесе. Шуңа да иркә булып үсә, көннәрен челтерәп аккан чишмәләр, чәчәкле болыннар кочагында уйнап үткәрә. Бу — хискә бай малайның «хыялый» күңелен тагын да баета.

Кышларын абыстайда беркадәр гыйлем өйрәнгәннән соң, Мирхәйдәрне Орскидагы бер мәдрәсәгә бирәләр. Әнә шунда инде ул китап уку белән мавыгып китә. К. Насыйри һәм башка мәгърифәтчеләрнең әсәрләре белән таныша. Беркадәр рус теленнән дәресләр тыңлый. Болар булачак драматургның күзен ача төшә. Аннан Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе... Тик, зур хыяллар белән килсә дә, Мирхәйдәр монда да артталык, искелек стенасына төртелә.

Беренче рус революциясе нәтиҗәсендә карашы беркадәр яктыра төшкән шәкерт, үзе әйтмешли «иске ысул белән укытуның зур дошманы булып китә»,

«Чүкеч» журналында, «Әльислах» газетасында мәдрәсә тәртипләрен курлап мәкаләләр бастыра башлый. Кызлар мәктәбе турында «Кирәкле гыйлемнәрдән гыйлем хисап, җагърафия, тарих, имла кебек дәресләрне укытмыйлар» дип ачынып тәнкыйтьләп чыга («Әльислах», 1908, 29 сан).

Ләкин Мирхәйдәргә мәдрәсәдә дәрес тыңлавын дәвам итәргә туры килми. Йөрәк авыруы көчәеп, докторлар аны укудан тыя. Әмма белемгә омтылган үсмер күңел төшенкелегенә бирелми. Үзлегеннән төрек әдәбиятын, рус классикасын укый. Абыйлары алдыра торган газета һәм журналларны даими укып бара. Озакламый аларда «Мирхәйдәр Фәйзи» имзасы белән шигырьләре басыла башлый. Ә 1912 һәм 1913 елларда ике шигырь җыентыгы дөнья күрә.

Ни хакында яза соң яшь әдип? Билгеле, утар тормышы белән чикләнгән, муллыкта яшәгән Мирхәйдәрнең бу чордагы иҗатында дөнья әле гаҗәеп матур булып күренә. Ул табигать хозурлыгын мактый, мәхәббәткә дан җырлый. Кешеләр яшәешендә дә гүзәллек күрергә тели. Бу әле Мирхәйдәр Фәйзи иҗатындагы романтик ашкыну, дөньяны матур итеп күрергә теләгән чор. Мәгърифәтчелек идеаллары белән әсәрләнеп кулына каләм алган яшь егет өчен табигый бер мавыгу.

Ләкин аның күңеле драматургиягә тартыла. Бу өлкәдәге беренче адымын ул тәрҗемә аша ясый. 1912 елда Мирхәйдәр русчадан балалар язучысы Клавдия Лукашевичның «Среди цветов» дигән пьесасын татарчага әйләндереп китап итеп чыгара. Гомумән, бу язучының балаларга әхлак тәрбиясе бирүгә, гыйлем эстәүгә өндәгән әсәрләре М. Фәйзине рухландыручы мәгърифәтчелек карашларына бик тә таңгал килә. Шуңа да ул аның дүрт пьесасын тәрҗемә итеп газета һәм журналларда бастыра.

Тәрҗемә белән шөгыльләнү аңа драматургия кануннарын өйрәнергә дә ярдәм итә. Бераздан инде Мирхәйдәр үзе дә пьеса язу белән җитди шөгыльләнә башлый. 1912 елны «Яшьләр алдатмыйлар» комедиясе дөнья күрә. Аны тамашачы яратып кабул итә.

Ләкин, ничек кенә булмасын, бу әсәрләр Мирхәйдәр Фәйзи иҗатындагы эзләну чорына карый. Аның исемен татар җәмәгатьчелеге арасында таныткан әсәр асылда «Кызганыч» мелодрамасы (1914) була. Чөнки ул татар драматургиясенә яңа тема — халыкка хезмәт итү темасын алып килә.

Бу һич тә очраклы хәл түгел. Нәкъ менә шушы елларда татарларда социаль прогресска, милли азатлыкка омтылыш көчәя. Ул, үз чиратында, иҗтимагый интереслар алдында шәхси теләкләрдән баш тартучы фидакарь җаннар таләп итә. «Кызганыч» әсәренең романтик геройлары Заһид белән Гәүһәр халыкка хезмәт итү юлында үзләрен корбан итүдән дә курыкмыйлар. Бөек Октябрь социалистик революциясе, гражданнар сугышы чорында һәм аннан соңгы елларда бу романтик әсәрнең еш уйналуының сәбәбе әнә шунда булса кирәк.

Иҗатының икенче баскычында М. Фәйзи капиталистик җәмгыятьнең фаҗигалар тудырган тәртипләрен күрсә дә, строй белән шәхес арасында гармония булдыру юлын таба алмый әле. Әнә шуңа да аның романтик геройлары һәлакәткә очрый. Ләкин тора-бара ул җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне ачыграк тоемерли. Авыл тормышын, крестьян хезмәтен якын күрә. Үзе теләп печән чабуда, игән сугуда катнаша, крестьян хезмәтенең авырлыгын да, ләззәтен дә татый. Кичләрен авыл яшьләре белән уеннарга чыга. Әнә шул тәэсирләр нәтиҗәсендә «Авыл бәйрәме» пьесасы иҗат ителә. Аның геройлары «Кызганыч» һәм «Тәкъдирнең шаяруы»ндагы геройлар кебек язмыш изүеннән зарланып яшь түкмиләр инде. Болар — җир уллары һәм кызлары. Алар әсәргә үзләренең уеннары, җырлары, мәхәббәтләре белән реаль тормыштан килеп кергәннәр.

Яңа теманы тасвирлау өчен яңа алымнар, сурәтләү чараларының яңа төрләре кирәк булуы ачыклана. «Авыл бәйрәме»ндә әнә шул юлдагы эзләну ачык тоемерләнә.

«Галиябану»... Татар драматургиясенең һәм театрның үсешендә гаять зур урын тоткан бу әсәр 1916 елны языла. Һәм менә алтмыш биш ел инде татар-башкорт сәхнәсеннән төшми, халык тарафыннан яратып карала. Кайберәүләр моның сәбәбен әсәрнең җыр-моң белән өретелүендә генә күрәләр. Әйе, моңга бай халкыбыз драманың бу ягын гаять үз итеп каршы алды. «Галиябану» үрнәгендә дистәләгән му-

зыкаль драмалар һәм комедияләрнең язылуы нәкъ шул турыда сөйли. Татар һәм башкорт опера сәнгатенең «чишмә башында» «Галиябану» драмасы тора дисәк тә хата булмас. Әмма, минемчә, «Галиябану»ны бүгенгәчә яшәткән сыйфат — ул әсәрнең гаять дәрәҗәдә халыкчанлыгында һәм чын сәнгатьчә эшләнешендә.

Шундый әсәр иҗат итәргә нинди нигез, нәрсә сәбәпче булган соң? Моңа бер сүз белән генә җавап бирүе кыен, әлбәттә. Әдипнең халык тормышына якынаюы, дөньяга карашының үсүе... Монда Беренче бөтендөнья сугышы китергән фәкыйрьлек, тигезсезлек тә, яу кырында байтак дусларының ятып калуы да зур роль уйнаса кирәк. Юкка гына әдип: «Бәдбәхет сугыш! Гөлдәй яшьләрне әрәм итеп бетерәсең. Ләгънәт сугышны башлаучы «җиһангир»ларга!» — дип, ачыктан-ачык нәфрәт белдерми! (Көндәлекләр, 1915 ел.)

Әсәрнең үзәгендә — мәхәббәт темасы. Автор аны гаҗәеп дәрәҗәдә көчле итеп сурәтли. Хәлил белән Галиябануның бер-берсен өзелеп сөюләре ифрат саф һәм ышандырырлык итеп тасвирлана. Бу геройларны тамашачы башта ук яратып өлгерә. Яратмаслык та түгел шул. Галиябану — тыйнак, эшчән, кешелекле кыз. Хәлил дә аңардан калышмаган. Шул ук вакытта язучы аларны беркадәр «бизи» дә төшкән. Икесе дә чибәрләр; өстәвенә Хәлиле тирә-якта дан тоткан гармунчы. Әнә шулай реалистик сыйфатларга беркадәр «күтәренкеләрен» кушып, М. Фәйзи бик тормышчан типлар иҗат итә.

Тамашачы якын күргән геройларның бәхетенә кулак Исмәгыйль һәм аның иярченнәре каршы төшә. Ике якта да гаять дәрәҗәдә көчле характерлар. Беренчеләре саф һәм ныклы мәхәббәткә ия булсалар, икенче якта — байлык, көч. Мондый бәрелеш фаҗига белән генә тәмамлана ала.

Шул рәвешле, әсәрнең үсешенә сыйнфый конфликт өстәлә. Бу инде «Галиябану»ны бермә-бер җитдиләндерә һәм шуның белән сәнгати кыйммәтен бермә-бер арттыра. Аны чынбарлык, конкрет чор белән ныклап бәйли.

Әсәрнең реальлеге андагы геройларның прототиплары булуы белән дә дәлилләнә. Мәсәлән, Хәлил образына «оеткы» салуда Башкортстанның Юлык авылыннан Вафа Әдһәмов сәбәпче булуы билгеле. (Алга китеп булса да әйтергә кирәк, 1919 елны М. Фәйзи үзе якын күргән шушы егет яшәгән авылга китапханә мөдире булып эшкә килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр үзе иҗат иткән геройларның прототиплары арасында яши). Бу атаклы драманың сюжеты да күктән төшмәгән, «Галиябану» көенең тарихы нигезендә яткан тормышчан вакыйгалардан этәргеч алып китә ул.

Җыеп кына әйткәндә, М. Фәйзи «Галиябану» драмасы белән татар әдәбиятына зур яңалык алып килде: ул унынчы елларда крестьян тормышындагы сыйнфый каршылыкларны күреп, аларны сәнгатьчә югарылыкта тасвирлады. «Галиябану» драмасы белән М. Фәйзи социалистик реализмга ишек шакый.

Бөек Октябрь социалистик революциясен драматург шатланып каршы ала. Илдәге вакыйгаларның әһәмиятенә ныклап төшенеп бетмәсә дә, үзе күптән хыял иткән яңа тормышка юл ачылуын тоя. Шуңа да карамастан, М. Фәйзи үзенең иҗатында яңадан романтизмга борыла. Аның «Урал суы буенда» (1918), «Асыльяр» (1918—20), «Ак калфак», «Адашкан күңел» (1923) кебек әсәрләре темасы белән дә үткәнрәк заманга караган, образлары да җирдән шактый аерылган. Сәбәп нидә соң? Романтик рухтагы әдип, революция булганның икенче көнендә үк дигәндәй, дөньялар үзгәреп, халык матур тормышта яши башлар дип көтә. Ләкин барысы да ул уйлаганча ук тиз көндә булмый. Гражданнар сугышы башлана—ил тифтән, ачлык, фәкыйрьлектән арына алмый тора. Матурлыкка, тормыш гармониясенә омтылган романтик язучыга ни кала? Билгеле, гүзәл тормышны хыялда тудыру. Әдипнең революциядән соң иҗат иткән музыкаль пьесалары әнә шундый эшчәнлек җимеше.

Билгеле, аларны бөтенләе белән хыял тудырган дию дөрес үк булмас иде. Мәсәлән, «Урал суы буенда» пьесасындагы вакыйгалар асылда тормыштан алынган. «Бай егеттән баш тартып, сөйгән егетемә, ярлыга кияүгә чыгуым турында Мирхәйдәр Фәйзигә мин үзем сөйләдем»,— дип яза бер хатында Зифа прототибы булган Гайшә Корбангалиева. Әнә шулай, бәхеткә ирешү өчен, бу пьеса геройлары буржуаз тәртипләрне, аның кануннарын таптап үтәргә тиеш булалар. М. Фәйзи үзенең тормыш

турындагы хыялларын Зифа теле белән әйтеп бирә. Язучының симпатиясе үз көче белән көн күрүчеләр — хезмәт ияләре ягында.

1922 елны Мирхәйдәр Фәйзи эш буенча Бөрҗән-Тангаур кантонының үзәге Темәскә күчерелә. Ул биредә урындагы театрга җитәкчелек итә һәм бер үк вакытта «Кызыл Урал» газетасын чыгара, әдәби түгәрәк оештырып җибәрә. Бу түгәрәктән Сәләх Кулибай, Батыр Вәлид кебек күренекле башкорт шагыйрьләренең күтәрелеп чыгуын исәпкә алсак, М. Фәйзи эшчәнлегенең кыйммәте тагын да ачыграк күренер.

Әдипнең иҗатында да реализмга таба борылыш сизелә. «Урал суы буенда», «Асыльяр», «Ак калфак» кебек әсәрләрендә уңай геройларын куе романтик буяуларга буяп, гадәттән тыш ситуацияләргә куеп иҗат иткән булса, «Кызыл йолдыз» пьесасында инде әдип чорның иң актуаль темасын — авылда яңа тормыш төзү өчен барган көрәшне тасвирлый.

Марксизм-ленинизм тәгълиматын өйрәнү, алдынгы эшчеләр, совет хезмәткәрләре белән аралашу һәм тормышның күзгә күренеп яхшыра баруы М. Фәйзинең дөньяга карашында зур борылыш ясый. Бу исә аның иҗатында тормышчанлык сыйфатларын үстереп җибәрә. «Кызыл йолдыз» пьесасында ул авылда барган сыйнфый көрәшне дөрес һәм ачык тасвирлап, комсомол яшьләр эшчәнлеге аша коммунистлар партиясенең җитәкче ролен гәүдәләндерә.

М. Фәйзи бер елга якын Уфада һәм Казанда торса да, калган гомерен Баймак эшчеләре арасында яшәп иҗат итте. 1928 елның җәендә аны соңгы юлга рудник эшчеләре озатты.

Атаклы драматургның кабере Баймак шәһәрендә, гражданнар сугышында яңа тормыш өчен көрәшеп һәлак булган батырлар белән бер зиратта, исеме алар исеме белән янәшә тора. Бу гадәти булмаган янәшәлектә символик мәгънә бар, минемчә. Мирхәйдәр Фәйзи дә көрәшче иде. Ул хезмәт иясенә матур тормыш даулап көрәште. Әнә шуңа да аның иҗаты халык күңелендә матур моң булып яши.

*
* *

Драматургиябез классигы М. Фәйзинең иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнү соңгы елларда шактый җанланды. Эзләнүләр нәтиҗәсендә байтак яңа материал: язучының хатлары, кульъязмалары, фоторәсемнәре табылды.

Журналның бу санында өзекләре китерелгән хат М. Фәйзинең дусты Хәмзә Батыршинга язылган. Алар арасындагы якын мөнәсәбәт әдип Бөрҗән-Тангаур кантонына килгәч башлана. Язучы үзеннән шактый кечерәк яшьтә булган бу акыллы егет белән «уйлар берлеге» таба. Х. Батыршин озак еллар мәгариф өлкәсендә, руда чыгару шахталарында җитәкче эштә, профсоюз эшендә була. Олы язучыга булган дуслык хисләрен гомеренең соңгы көннәренә кадәр күңел түрендә йөртә. Әлеге хат Хәмзә аганың хатыны, язучы белән якыннан аралашкан Мәһитап апада кадерләп саклаңган. Рәхмәт аңа!

Дустым Хәмзә!

Син, хат язмый дип, үпкәләп йөрмә тагы! Уфада рухланып, баш-күз алып бетеп булмый бит, каһәр. Берәүгә хат язсаң, икенчесенә ябышырлык дәрт калмый. Югыйсә авыл, авылдагы дуслар күңелемнең мөнбәре, мөнбәренең пәйгамбәре булып кына тирбәләләр. Уфаның зурлыгы алар каршында чүп; аларның кыйммәте Уфаныкыннан күп миңа.

Уфа — Оренбурдан да ямьсез бер кала икән. Шәүкәте дә, матурлыгы да юк. Шулай да булып чыккач, бер дә яратып тормыйм. Ирен яратмаган, көчләнеп бирелгән кыз кебек кенә йөрим. Ул миңа ак сакаллы карт ир төсле тоела. Энем, сез бәхетле бит! Авылда, табигать ардагында яшисез. Күзләрегез белән тауларны, кырларны, кояш баешларын күрәсез, аякларыгыз белән үләннәргә басасыз, телләрегез бәйсез, күңелләрегез гамьсез.

Мин ахыры шәһәр белән үзләшә алмам... Яз булу белән, сау булсам, бер авылны күңелемә кәгъбә итеп, калган гыйбадәтләремне каза итәрмен. Алларымда авыл, кәгъбәмдә, кыйбламда авыл; җәннәтем, бәхетем, тәхетем дә ул.

**Җанкәм, ялтыр тәңкәм,**
**Кояшым, аем,**
**Ашым, маем,**
**Былбылым, сөмбелем**
**Булдың син минем!..**

Менә, ишетмәсәң ишет, ике колагыңны биш итеп, авызыңны ишек итеп, истән таеп ишелеп китеп!.. Шәһәрне макта, авылда яшә, авылны макта, шәһәрне куырып аша, шунда булыр тамаша... Шәһәрләр кадалсын, кызлары гына калсын,— ул кызларны авыл малайлары алсын!..

Хәмзә! Бу каһәрле сүзләргә карап бик аптырамассың дип уйлыйм. Гәрчә ярым җитди язсам да, рухым белән таныш кешеләр бер шаяру дип кенә хисапламаслар. Калада бер айлык тормышым (җитмәсә Уфа кебек мәхәббәтсез бер калада) рухыма чак кына да җан өрә алмаганга, сүгеп үчемне алыйм ичмасам дидем.

Танымыйлар да түгел, арага алырга, ярдәм итәргә теләмиләр дә түгел. Тормышым тәэмин ителми калыр дип куркырлык эш тә юк. Ләкин һич берәү белән үзләшмим, бармыйм, кызыксынмыйм, илтифат итмим. Хәтта театрларга да барып йөрмим. Шулай булгач аннан ни хәер көтәсең инде. «Әти, мине бу карттан аерып алыгыз!» дип елыйсым килә.

*

* *

Уфада күп кенә кешеләр белән таныштым. Мөхәррир, шагыйрь, журналист, зыялы, бай, бай бәтчә, студент, комиссар, служащий, артистлардан байтак кына бәндәнең учына учым тиде. Ләкин күңелләренә күңелем тимәде. Җыелышларга чакырылгалыйм, бер генә бардым да биздем. Берничә кешеләрнең өенә барып йөрим. Бер туган таптым, бертуган кебегрәк карый ала торган яхшы күңелле кеше таптым. «Урал буенда»м белән халыкка күренеп алкышланып, хөрмәт казандым. Киләчәктә зур өметләр дә бар. Шулай булгач, гаеп үземә генә йөкләнеп калыр кебек тоела. Кулларыннан әллә ни килмәсә дә, тел пилмәне белән генә сыйлап калучылар булса да — «үзе бит» диярләр. Мәйле, анысына да риза!

Мирсәет Сафин дигән кешедә, бер бүлмә алып, тәрбияле генә торам. Уфада һәр нәрсә кыйбат. Утын үземнән, тәрбия һәм квартир өчен 20 миллион түлим. Айлык расход йөз миллионнан да ким булмастыр. Хәзергә кысылганым юк әле. Киләчәге дә шулай ялганып китәр дип өметләнәм. Моңа кадәр Уфа матди ярдәм күрсәтә алмады...

Кышкы сезон башланды. Дәүләт театры Мортазин идарәсендә дәвам итә. Зур, биек, шәп бинада. Ложалары, амфитеатры, галереяләре белән дүрт катлы. Спектакльләргә буш урын куйсалар да барганым юк. «Урал буенда»га гына бардым. Автор булсаң кыен икән, һич кеше сизмәгән гаепләр табып тынычсызланасың да утырасың. Нечкәләүчеләр гаепләр таптылар, әлбәттә. «Газетага да язабыз, җил уңаенарак киткәнсең»,— диделәр. Ә болай халык тәмам риза. Сәхнәгә мендереп, күтәреп маташтылар. «Мәкер вә мәхәббәт», «Һинд кызы», «Йосыф-Зөләйха»лардан соң «Фәрештә»[1] куелу уенда тора...

Сездә ни хәлләр бар? Кантон күчкәндә син дә Тамаста калган дип ишеттем. Техникумнар аркасында Тамас бик сүнмидер әле. Мин дә анда булсам икән дип теләп куям. Ләкин анда кайту уенда түгелмен инде. Галимҗан Ибраһимовка: «Казан тирәсеннән бер зуррак татар авылы бирегез»,— дип яздым. Ул үзе: «Мотлак Казанда торырга тиеш»,— ди икән.

Я нихәл егет, эшләр гөрлиме? Туй булмаган әле диләр. Булдырыгыз инде, миңа да бәлеш төбе җибәрерсез. Маһитап туташка (ялгыш түгелме?) бик сагынып күп сәлам ирештер...

Тагы ни языйм. Рәхәтләнеп кояш баеганны да күрә алмаган мәхбүсдә ни хәбәр булсын? Центральный урамнарда подручка да йөргәнем юк әле. Уфа янганда кызлары да янып беткәнме, ничек тә култыкка килеп тагылган кыз юк. Бәс, теге җырны болай дип тәслим ясарга кирәк була инде:

[1] «Фәрештә» — «Асылъяр» пьесасының баштагы исеме.

**Уфа дилəр, Уфа дилəр, Уфаны янган дилəр,**
**Уфаның кызларына да ялкын ялганган дилəр...**

Маһруй, Маһинур, Нəфисə, Мəрьям, Маһиэнүəр, Мөнəвəрə туташларга күп сəламнəр əйт. Миңа гашыйк булган булсалар, хат язсыннар. Юкка саргаеп йөрмəсеннəр... Җитəрдер инде.

«Мəкер вə мəхəббəт»не матур уйнадылар. Шəп декорация, зиннəтле киемнəр, бай постановка, яхшы гына көч белəн Шиллерның бу матур телле əсəре миңа матур хис калдырып Мортазин, Мортазина, Шагалиев, Сатторов, Сакаев дигəн сəнгатькəрлəрнең биргəн типларыннан риза булдым...

Хуш! Саулыкта күрешик...

**Чиклəвек ваттым теш белəн, күкрəктəге көч белəн**
**Көндез юанам эш белəн, өзелеп чыгам кич белəн.**

Монда чиклəвек ашау бик модада. Урман чиклəвеген урамда көнбагыш кебек сатып утыралар. Кичке гүлəньядə минем дə программага керде ул...

1922 ел, 25 ноябрь. Уфа.

## Икрам Фəйзуллин

# ШОДАДАГЫ КӨННƏРЕМНЕҢ ТАҖЫ...

ИСТƏЛЕК

...Күренекле драматург Мирхəйдəр Фəйзи 1900 һəм 1916 елларда Балтач районының Шода авылында яшəүче абыйсында кунакта булган. Аннары, 1923—1924 елларда, Казандагы шəрык китапханəсенең балалар бүлегендə эшлəгəн чагында да чираттагы ялын шунда үткəрде. Шул авылда туып үскəн кеше буларак, М. Фəйзинең бередə үткəргəн көннəре турында кайбер истəлеклəрем белəн уртаклашасым килə.

Бик вакытын белеп, халыкның язгы чəчү белəн урак өсте арасындагы бушрак вакытын чамалап килə иде ул безнең авылга. Килүе белəн абыйсының гына түгел, барлык авыл кешелəренең уртак кадерле кунагына əйлəнə иде.

Бик йомшак күңелле һəм тумыштан ук авылга гашыйк Мирхəйдəр абый, үзенə билгелəнгəн «кечкенə өйдə» урнашуга, гадəттə урамнарны урап кайта, яшьлəр белəн танышa башлый. 1916 елны килүендə, мин бик бəлəкəй булганга, кунак абыйны хəтерлəмим. Тик соңыннан аның атаклы көндəлеклəреннəн шул чорга караган юлларны укыгач, күп нəрсə ачыкланды. Көндəлеклəрендə ул Малмыж пристаненнан Шодага тарантаста утырып килгəндə күргəн табигать күренешлəрен сокланып тасвирлый. Табигатьне генə түгел, кешелəрнең холык-фигылен, халык тормышын да җентеклəп күзəтə.

Мирхəйдəр Фəйзинең бу якларга 1923—24 еллардагы сəфəре авыл тормышының үзенчəлекле чорына туры килде. Ул вакытларда безнең якларда сабан туйлары кар эреп бетү белəн, язгы чəчүгə чыкканчы ук үткəрелə иде. Башта урамнарда ат чаптырып карау, малайларның урам чатларында бил сынашы үткəрү була, моны «Əрапə кенə» дилəр иде. (Бездə «гарəфə» сүзен шулай үзгəртеп, «татарчалаштыралар».) Икенче көнне инде, төш вакытларында, авылның такыр басу туры килгəн урам очында, чын сабан туе була, күрше авыллардан да кунаклар килə. Бу сабан туйларына М. Фəйзи кайтып өлгерə алмады.

Соңрак, җомга көннәренең берсендә, Шода кешеләре, күрше Куныр авылы белән бергәләп, «Шода каршы» дигән тагын бер бәйрәм үткәрәләр. Гадәттә ул ике авыл басулары чигендә, Кубыр суы буенда, тегермән тирәсендә була иде. Ике авыл яшьләре бергәләшеп түгәрәк уеннары уйныйлар, бөтен тугай җыр-музыка тавышы белән тула, әле анда, әле монда я күмәк, я аерым биюләр күрәсең. Җәйнең иң матур вакытларында уздырыла торган бу бәйрәмдә 1923—24 елларда Мирхәйдәр Фәйзи дә катнашты.

Уракка төшәр алдыннан тагын бер халык бәйрәме үткәрелә иде. Берничә авыл аерым төркемнәргә бүленеп уздырыла торган һәм «җыен» дип аталган бу бәйрәм бишәр атнага сузыла, һәр төркемнең махсус исеме бар: «җуа җыены», «чукмар җыены», «зирек җыены» һәм башкалар. Шода белән Куныр авыллары бу бәйрәмнәр циклының өченче атнасына туры киләләр, су буендагы кичке уеннары аерым-аерым була, ә көндезләрен бер-беренә кунакка йөрешәләр.

Кунак язучы Мирхәйдәр Фәйзи бу бәйрәмнәрдә авыл яшьләре белән бергә җырлады, бергә биеде, авыл кызлары белән парлап әйләнде.

Шодадагы җыен бәйрәме күренешләре сизгер күңелле әдип өчен яңа иҗат дәрте, илһам чишмәсе тудырды. Менә аның биредә алган тәэсирләре турындагы кайбер юллар: «23 июнь, 1923 ел. Җыен манзараларын күбрәк күрер өчен ашау-эчүне, өйдәге кунакларны онытып, күбрәк урамнарда йөрим, үземне, күземне, күңелемне бәйрәм иттерәм...

...Низамга кепкамны биреп, үзем аның кәнителле кызыл кәләпүшен киеп йөрим. Болын шундый бер чуарлык белән бизәлгән, шундый бер яшьлек белән балкыган ки, каршында сәҗдә итми мөмкин түгел...»

Шода авылында булу тәэсире белән М. Фәйзи бик матур шигырьләр язды. Аның «Чишмә янында», «Ибрай яры буенда», «Эх, нинди күңелле!» һәм башка шигырьләре әнә шундыйлардан. Эш сөяр авыл кешеләренең матур итеп бәйрәм итә белүен ул шулай тасвирлый:

**Урамнарда асыл гөлләр үскән бүген,**
**Өсләренә сөенеп куна минем күзләр,**
**Гөлләр алар ил бизәге — җанлы гөлләр,**
**Гөлләр кебек матур егет, матур кызлар.**

**Чишмә яны, яшел чирәм өсләренә**
**Җилбәзәкләр, гөлбизәкләр сибелгәннәр,**
**Гөлдәй янып, алтын кояштай нурланып,**
**Яшь-җилкенчәк киенгәннәр, сөенгәннәр.**

**Ак алъяпкыч матурлыйдыр егет билен,**
**Кәнителле кәләпүштә нурлар яна.**
**Егетләре кызга карап елмайганда**
**Кызларының керфегеннән гөлләр тама.**

Менә бу шигъри чәчәкләр безнең авыл тәэсире белән язылганнар. Әсәрләренең ике томлык җыентыгында «Шода авылы» дигән адрес шактый еш очрый.

Мирхәйдәр Фәйзи безнең авылга җәйге ялын үткәрү, кунак булу өчен генә килми иде. Ул авыл халкы белән аралашып яшәде, яшьләр белән дуслашты, авылның мөгаллиме, коммунист Салих Касыймов белән танышты, мәктәп тормышы белән кызыксынды.

Кайвакыт безнең ишегалдына авыл яшьләре җыела иде. Шунда Мирхәйдәр абый яңа пьесаларын кычкырып укый, тыңлаучыларның фикерләрен сорый. Гомумән, ул бөтен әсәрләренең кульязмаларын үзе белән алып килә иде. Шулай итеп, безнең авыл кешеләре авторның әле матбугатка чыкмаган әсәрләре белән алдан ук таныша алдылар.

Әдәбият тарихы өчен моңарчы ачыкланып бетмәгән Шода авылы белән бәйле кайбер фикерләр белән дә уртаклашасы килә. Беренчесе, «Галиябану» әсәре турын-

да. Автор аңлатмасында: «Вакыйга Оренбург ягы авылларының берсендә бара»,— дигән сүзләр бар. Бу — бәхәссез, әдәбият тарихчылары тарафыннан расланган хәл. Әмма бу мәсьәләнең икенче ягы да бар: М. Фәйзинең 1916 елгы көндәлекләрендә, Малмыж пристаненнан Шода авылына барган чагын хикәяләгәндә, бу якларның табигать матурлыгына бик нык сокланып яза һәм: «Монда күргәннәр «Сәгъдәтбану» («Галиябану»ның әүвәлге варианты) исемле сәхнә әсәре язу уен тудырды»,— дип куя. Ләкин бередә бернинди дә каршылык юк. «Галиябану» драмасындагы фаҗигале вакыйгалар чыннан да Оренбург якларында булган. Драмадагы тормыш детальләре, табигать күренешләре, су буйлары, яшьләр уеннары исә, чыннан да, авторның Шода якларында күргән тәэсирләре белән язылган.

«Сәрвиназ» хикәясе ничек язылган? дигән сорауга да җавап бирүе кыен түгел. Бу хикәя безнең Шода җирлегендә, авылдашларыбыз турында авторның үз кичерешләре нәтиҗәсендә язылган.

Ул чакта кечкенә малай гына булсам да, мин бу вакыйганы яхшы хәтерлим. Хикәядә исемнәре күрсәтелмәгән кешеләр: «ул», «кыз» — Шода авылының реаль кешеләре. Ибраһим дигән егет, Гыйлембану исемле кыз һәм... автор үзе, ягъни, Мирхәйдәр Фәйзи.

Хикәяне искә төшереп үтик. Ике дус егет бер-беренә сөйгән кызларын күрсәтергә вәгъдә бирәләр. Һәм яшьләрнең кичке уеннары вакытында таныштыру була: «Менә ул!». Ләкин, гаҗәпкә каршы, икесенең дә күз атып йөргәне бер үк кыз булып чыга.

Тормышта эш болай була: Мирхәйдәр абый безнең күршедә генә яшәүче Гыйлембану исемле бик матур кызны яратып йөрде. Яратып һәм... сызланып, чөнки Гыйлембануның авылда үз егете Ибраһим бар. Күптән танышканнар, бик пар килгәннәр. Билгеле, кунак язучы аларның араларына керә алмады, өметсез мәхәббәт белән сызланып йөрүдән башка чарасы юк иде аның. Бу хакта ул көндәлекләрендә бик ачынып яза: «Гыйлембану Шодадагы көннәремнең таҗы булды. Аның белән каракаршы килеп бер сөйләшү мең рәхәттән рәхәтрәк тоела иде... Гыйлембану исемә төшкәндә сөенеп, Ибрай исемә төшкәндә көенеп китәм... Ибрай — ямьле егет, күргәч тә яраткан идем. Әмма Гыйлембану белән йөргәнен белгәч... Киту белән йомшарган күңел бу юлы Ибрайны дошман күрмәде. Ямьле егет бит, Гыйлембану белән пар килгәннәр бит, дип уйладым...»

Мирхәйдәр Фәйзинең безнең якларда булуын, ул барында үткәргән күңелле көннәр, кешеләрнең бу сөйкемле кунакка карата чиксез ихтирамы, самими дуслык мөнәсәбәтләре әле дә онытылмый. Авылны бик тә ярата иде М. Фәйзи, күбрәк авылда яшәде. Язган әсәрләренең барысы да диярлек авыл тормышыннан, авыл кешеләрен чагылдыра. Шода авылында исә әле дә Мирхәйдәр Фәйзине хәтерләүчеләр шактый, аның альбомнарга язган җылы шигъри сүзләрен әле дә кадерләп саклыйлар.

# ФЛЕРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА



Флера Гыйззәтуллина — әдәби җәмәгатьчелеккә таныш исем. Аның шигырьләре «Казан утлары» журналында һәм башка вакытлы матбугатта күренә килә. Татарстан китап нәшриятында ике-өч җыентыгы басылып чыкты. Дөнья күргән әсәрләренә карашлар уңай булды.

Тумышы, биографиясе белән ул — балачагы, яшьлек еллары сугыш һәм аннан соңгы авыр чорга туры килгән шагыйрьләр төркеменнән. Вакыйгаларга кытлык юк — хәл ителәргә омтылган каршылыклар, чынга ашарга торган хыяллар, үзләре өчен көрәш таләп иткән бәхетләр — барысы да күңелдә җыйналган. Шагыйрьнең гражданлык, гуманистик нигезе дә шунда.


Ф. Гыйззәтуллина шигырьдә дә җиңелгә исәп тота алмады. Уй-тойгылары формасын мең газаплар һәм эзләнүләр аша гына таба килде. Иң хәерлесе — таба алды. Акрынрак, озаграк булса да, һәм таба килә.

Аның иң уңышлы шигырьләрендә сурәтләнгән картиналар матурлык белән мәҗбүрият конфликты буларак гыйбрәтле. Кырыс һәм рәхимсез дөреслек. Купшы буяусыз, уйлап чыгаруларсыз. Тойгы һәм сурәт дөреслеге.

Флераның иҗади табышлары башлыча аның үзе үзләштергән эшләре, профессиясе белән аерылгысыз бәйләнгән. Шигырьләрен укыгач, үз һөнәрен дөньяның тоткасы иткән хезмәт кешесе, аның кечкенә тоелган олы эшләре, кичерешләре күңелгә килә. Эш төсмерләве аның дөньяга карашында, мәхәббәтендә, кешеләргә мөнәсәбәтендә — төрле рәвешләрдә. Ул үзенең шигырьләрен, чигү үрнәге шикелле, дөнья төрлелегеннән җыя, әнә очыннан, әнә күзеннән үткәрә. Шигырьләре белән үзен, үз яшәеш формасын раслый.

ӘХСӘН БАЯНОВ

# РИЗВАН ХӘМИД



Соңгы елларда драматургиягә килүче яшьләр арасында Ризван Хәмид үзенең беренче әсәре белән үк әдәби һәм театр җәмәгатьчелеген җәлеп итте. Сүз аның «Синең урыныңа кайттым» драмасы турында бара. Яңа ситуацияләр, проблемалар, көчле характерлар алып килгән бу пьеса, Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелеп, тамашачылар тарафыннан да җылы кабул ителде. Шунысы куанычлы: бу пьеса авторның очраклы уңышы булмаган икән. Ризванның соңгы елларда иҗат ителгән: «Иске йорт кешеләре», «Кайтыр идем...», «Айсберг», «Китәм инде», «Каен җиле» пьесалары драматургия һәм театр законнарын бик яхшы белеп, профессиональ осталык белән язылганнар. Берничә пьесасы, рус теленә тәрҗемә ителеп, төрле өлкә театрларында куелды. Шулай ук авторның балалар сәхнәсе өчен дә эшләвен уңай яктан билгеләп үтәсе килә.

Югары педагогик белеме һәм эрудициясе булган яшь драматургның перспективасы зур. Ул иҗатында актив, җәмәгать эшләренә теләп катнаша. Киләчәктә ул безнең драматургиябезне тагын да көчлерәк, югары идея-художество таләпләренә җавап биргән әсәрләр белән баетыр дип уйлыйм.

ИЛДАР ЮЗЕЕВ.

# ФӘХРИ ӘСГАТЬНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Аның иҗади мирасы күләм ягыннан зур түгел. Кыска-кыска гына хикәяләр, нәсерләр. Якты хисләр белән сугарылган, сыйнфый көрәш ялкыны белән өретелгән бу әсәрләр җыр кебек кыска һәм дәртле. «Без чәчәкләрдән сүзләр, ә сүзләрдән чәчәкләр ясыйбыз», — дип яза Әсгать. Үзе үлгәч басылган җыентыгы да бик хаклы рәвештә «Сүзләрдән чәчәкләр» дип аталган. Гази Кашшаф сүзләре белән әйткәндә, ул реалист язучы һәм әдәби телебезне юлга салучыларның берсе буларак, һичшиксез тәкъдир ителергә хаклы.

Әсгать Йосыф улы Фәхретдинов 1901 елның 13 октябрендә хәзерге Әлки районы Алпар авылында туган. Уникe яшеннән Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган. Революциядән соң Чистай педтехникумында һәм авыл хуҗалыгы техникумында белем алган. 1921 елда Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга кергән.

1923 елда ул комсомолга керә, җәмәгать эшләренә чума, Казан дәүләт университеты каршындагы әдәбият түгәрәген оештыручыларның берсе була. Кави Нәҗми, Гадел Кутуйларның яшьлек дусты булган Фәхри Әсгать шул чорда ук Язучылар союзы оештыру турында да хыялланып йөри.

Ф. Әсгатьнең күпчелек әсәрләре вакыйгалар үзәгендә катнашкан «мин» исеменнән язылган. «Мин» — тәрәзәсен яңа тормыш җилләре ачкан, революция казанышларын яклап көрәшкә ташланырга әзер торучы яшь егет. Ул ил-халык тормышындагы матур үзгәрешләрне күреп куана, киләчәккә зур ышанычы һәм өмет белән карый. Язучы үзенә таныш вакыйгалар, кичерешләргә таяна, кеше күңеленең нечкә үзгәрешләрен тасвирларга омтыла. «Батырлар» исемле кечкенә хикәядә, мәсәлән, аның күзәтүчәнлеге, сюжет кору осталыгы, халыкчан, образлы телгә ия булуы күренә. Гражданнар сугышы һәм НЭП чоры күренешләре, шул елларда авылдагы кискен көрәш, Кызыл Армиядә сәяси аңы үскән, сыйнфый зирәклеккә ирешеп кайткан егетләрнең кулакларга каршы чыгуы характерлы детальләр аша күз алдына бастырыла.

Язучының күңелендә кайнаган хисләр аның нәсерләрендә ачык гәүдәләнеш таба. Ул табигатьтәге гармонияне тормыштан эзли, һәр күренешнең мәгънәсен, фәлсәфи көчен күрергә омтыла. «Таш кала» исемле нәсерендә Ф. Әсгать ерак авылдан күтәренке рух, сүнмәс дәрт белән, югары белемгә һәм иҗат эшенә ашкынып килгән яшь егетнең кичерешләрен тасвирлый. «Тәнемдә көч, күкрәгемдә иман, бөек гамәлләргә, ленинизм күпере аркылы коммунизмга атлыгу, тереклеккә һәм якты йолдызларга омтылу сизәм»,— ди ул. «Таш кала» үзенең теле белән дә, фикеренең ачыклыгы белән дә, яңа тормыш төзү өчен омтылуны образлы итеп сурәтләве белән дә 20 нче еллар башында язылган уңышлы әсәрләр рәтеннән саналырга хаклы».— Язучының 1977 елда кабат басылып чыккан нәсерләр һәм хикәяләр җыентыгына кереш сүзендә Гази Кашшаф әлеге парчага әнә шундый бәя бирә.

1926 елның 25 сентябрендә егерме биш яше дә тулмаган Фәхри Әсгать туберкулез чиреннән вафат була.

Үзе исән чагында язучының «Тормыш кочагында» исемле кечкенә бер җыентыгы гына басылып чыга. Ләкин аның иҗаты бүгенге көндә дә үзенең сәнгатьчә көчен югалтмый, югары зәвыклы замандашларыбызның кызыксынуын уятырлык дәрәҗәдә сурәтле теле, үткен фикере белән аерылып тора.

# ГӨЛСЕМ БОЛГАРСКАЯНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Танылган татар артисткасы Гөлсем Болгарская — берничә буын язучылар һәм артистларның замандашы. Ул күренекле артистлар Г. Кариев, М. Мутин, З. Солтанов, К. Шамил, Х. Әбҗәлилов, Ф. Халитов, Г. Шамуков һәм Ш. Биктимеров белән сәхнәдә уйный.

Гөлсем Болгарская театр сәхнәсенә егерме яшьтә аяк баса, җитмешнең аръягына чыккач кына китә. Ул башкарган рольләрнең исәбе-саны юктыр. Болгарская театрга бернинди махсус әзерлексез килә, ә аннан исә сәхнә остасы булып китә. Актерлык сәнгате әлифбасын ул беренче татар режиссеры һәм педагог Габдулла Кариевтан өйрәнә. Гөлсемнең партнерлары, «Сәйяр» труппасы артистлары, аңа сәхнәдә үзен табигый, иркен тотарга, үз иҗат йөзен табарга ярдәм итәләр. Ә берничә елдан яшь артистка гомуми кызыксыну уята башлый. Аның башкару осталыгы Мулланур Вахитовны да сокландыра. А. Островскийның «Яшенле яңгыр» драмасы буенча куелган спектакльдәге бенефисыннан соң Вахитов болай дип яза: «Аның интерпретациясендә Екатерина тирән фикерле һәм хискә бай булуы белән аерылып торды... Талантлы артистка үзенең җитди рольләр уйнарга хакы булуын исбатлады, ялган пафоссыз, бернинди шау-шусыз тамашачыга Островский героинясының шигъри, ирек сөючә җанын ачты. Кем белә бит, бәлкем, Болгарская да, әгәр күңел түрендә Островский героинясы белән туганлаштыручы чишмәләр кайнап тормаса, Екатеринаның иң яшерен кичерешләрен тапшыра алмаган булыр иде» (Мулланур Вахитов. Сайланма әсәрләр. 34 бит. Казан, 1967).

Актриса совет театры сәхнәсендә зур иҗади җиңүләр юлы үтте. Болгарская чыннан милли драматургия актрисасы булса да, рус һәм чит ил классикасы үрнәкләрендә дә уңыш арты уңыш казана. Утызынчы елларда ул А. Островскийның «Яшенле яңгыр»ы белән кабат очраша, һәм бу юлы инде каты бәгырьле, деспот хатын Кабаниханы уйный. М. Горькийның «Дошманнар» пьесасы буенча куелган спектакльдә ул башкарган Полина образы да бик көчле килеп чыга. Кабаниха белән Полина бер үк социаль сыйныф вәкилләре булсалар да, алар арасында ифрат зур аерма бар. Кабаниха — сәүдәгәр хатыны, череп таркалучы иске тормыш вәкиле, Полина — капиталистик формациянең типик җимеше. Бер-берсеннән үзгә ике эпоха вәкилләренең сыйнфый уртаклыгы һәм социаль аермасын актриса грим һәм костюм аша гына биреп калмый. Алар дөньяга карашлары, эчке культуралары һәм тирә-юньдәге кешеләргә мөнәсәбәтләре белән дә аерылалар. Әгәр Кабаниха үзенең тар дөньясында яшәсә, бары үз өе эчендәге кешеләрне генә куркытып тотса, ажгырып торган Полина властен һәм кодратен үз заводы эшчеләрен буйсындыруга гына түгел, бөтен тирә-якка җәелдерергә омтыла. Г. Болгарская, геройларының характерын ачыклап, бу аерманы искә ала һәм драматургның фикеренә тугры булырга тырыша.

Татар артисткасына Көнбатыш Европа драматургиясеннән бары бер генә роль уйнарга насыйп була. Ләкин бу роль үзе унга тора. Сүз 20 нче елларда В. Шекспирның «Гамлет» трагедиясе буенча эшләнгән спектакльдә артистка тарафыннан иҗат ителгән Гертруда образы турында бара. Гертруда белән Гамлет күренеше үткен һәм динамикалы. Улы әнисен әтисенә хыянәт итүдә гаепли. Бу диалог киеренке, югары ноталарда бара, Гамлет (әлеге рольне атаклы трагик артист Мохтар Мутин уйный) гаепли, җавап таләп итә... Ә Гертруда — Болгарская акланмый, ул үзе башкаларны гаепли, үзе һөҗүм итә. Шуның аркасында күренеш зур эчке киеренкелеккә һәм динамикага ирешә.

Г. Камалның Гөлсем Болгарская уйнамаган бер генә пьесасы да юк. Ул Г. Камал пьесаларындагы барлык хатын-кыз рольләрендә диярлек уйнап чыга: «Бәхетсез егет»тә — Гайни, «Беренче театр»да — Гафифә, «Банкрот»та — Гөлҗиһан һ. б. Алар барысы да төрле-төрле, бер-берсенә охшамаган, шул ук вакытта бер уртак сыйфатка да ия. Бу сыйфат — кыерсытылганлык, эчке көчсезлек һәм өметсезлек. Татар драматург-

лары пьесалары буенча Болгарская тудырган башка образлар да хәтергә кила. Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясендәге Галимә ролен ул сизелеп торган ирония белән тасвирлы итеп башкара. Артистка ниндидер канәгатьсез, мыжык карчыкның үткен, гротеск дәрәҗәсенә җитә язган образын тудыра. Беренче карашка бик диндар кыяфәтле, күркәм холыклы хаҗи җефете булып күренсә дә, Галимәнең холкы пәри өермәсе белән бер. Аның бетмәс-төкәнмәс шикчел кинаяләре, аяктан яздырырлык гаепләр тагып торуы Юныс хаҗины (бу рольне атаклы артист Зәйни Солтанов соклангыч итеп уйный) хатынының уяулыгын киметү өчен һәр юлы яңа хәйләләр корырга мәҗбүр итә. Артистлар үз рольләрен гаҗәп бер колорит белән, истә калырлык итеп башкаралар. Алар чын мәгънәсендә персонажлар тормышы белән яшиләр, үткән чор кешеләрен замандашлары өчен аңлаешлы итәләр. Үзләре уйнаган образлар аша артистлар тамашачыны искелеккә кабат кайту юк һәм булмаска да тиешлегенә тагын бер кат ышандыралар.

Г. Болгарская иҗат иткән икенче образ — сәүдәгәр хатыны Ханзифа, сорыкортлар доньясындагы бөтен явызлык һәм мәкернең гәүдәләнеше булып хәтердә кала. Т. Гыйззәтнең «Шомлы көннәре»е буенча эшләнгән спектакльдә артистка Ханзифаның характерын чын кырыслык, каты күңел һәм килешмәүчәнлек белән ача. Ул, әйтерсең лә, бернинди гүзәллеге, игелеклелеге, кешегә хас сыйфатлары калмаган өчен аңа хурлык тамгасы суга.

Ләкин Г. Болгарская үз героиняларын ярата һәм аларны тамашачыдан да яраттыра белә иде. Менә йомшак табигатьле һәм киң күңелле, кешеләргә изге эш эшләүдән тәм таба торган яучы карчык Бәдига. Шундый рольләрдә уйнаганда, артистканың доньяга карашы, иҗатының халыкчанлыгы ачыграк чагыла.

Г. Болгарская йөзләрчә роль уйный һәм һәр юлы тамашачысына үз героиняларының эчке доньясы турында тулы сөйләргә тырыша. Ул кешеләрне үзе тудырган образларның чын булуына ышандыра. Шуңа күрә тамашачылар Г. Болгарская иҗат иткән образларга бер кайчан да битараф калмадылар: я аларны кызгандылар, я куралмадылар.

Сәхнәбез осталарыннан берсенең — ТАССРның халык артисткасы Гөлсем Муса кызы Болгарскаяның иҗат позициясе менә шундый иде.

**Халит КУМЫСНИКОВ.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАР — АВЫЛ ХЕЗМӘТЧӘННӘРЕНӘ

Киеренке авыл хуҗалыгы эшләре барганда игенчеләр, терлекчеләр алдында язучыларның һәм сәнгать осталарының чыгышлар ясавы күркәм бер гадәткә әверелде.

Татарстан Язучылар союзының ачык партия җыелышында сүз нәкъ менә урып-җыю көннәрендә әдипләребезнең колхоз-совхозларга чыгуы турында барды. Республикабыз каләм осталары, сүзләрендә торып, быелгы урак өстендә республикабызның күп кенә районнарында төрле очрашулар үткәрделәр, хәзерге авыл турында материал җыеп, газета һәм журналларда күп санлы мәкаләләр һәм очерклар бастырып чыгардылар.

Бу күркәм эштә күп язучылар катнаштылар, шул исәптән Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, Ф. Миңнуллин — Арчада, М. Садри, Х. Халиков — Кукмарада, Ф. Шәфигуллин, Ә. Гадел — Мамадышта, К. Тимбикова, Ф. Гыйззәтуллина — Октябрь районында, Ф. Миңнуллин, М. Вәлиев — Әгерҗедә, Р. Хәмид — Чирмешәндә, Р. Миңнуллин, Ф. Гыйззәтуллина — Кама Тамагында, Ә. Гаффар — Буада, Ш. Маннапов — Баулы районнарында булып кайттылар.

Әдипләребезне җир-су язмышы, республикабызның кече елгалары, урманнары, табигатьне саклау мәсьәләләре — кыскасы, бүгенге авыл тормышы кызыксындыра.

Җәйге кыр эшләре вакытында республикабыз композиторлары да авылларда булып кайттылар. Мамадыш районына ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе Мирсәет Яруллин җитәкчелегендәге иҗат группасы чыкты. Аларның чыгышларын «8 Март», «Красный партизан», «Спартак» колхозлары, «Пятилетка», «Берсут» совхозларының кыр станнарында, ындыр табакларында, болынлыкларда тыңладылар. Алар шулай ук Кама леспромхозында, «Сельхозтехника»ның район берләшмәсендә, «Берсут» ял йортында очрашуларда катнаштылар. М. Яруллинның Композиторлар союзының эшчәнлеге турында сөйләвен, К. Хәйретдинова белән М. Галиевнең җырлавын яратып тыңладылар.

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казанда Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты белән бәйле урыннар күп. Шуларның берсе — Бауман урамындагы 7 нче йорт. 1923 елда биредә Муса Җәлил «Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасы редакциясендә эшләгән.

Хәзер бу бинага герой-шагыйрь истәлегенә мемориаль такта куелды. Тантаналы митингны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты.

Татарстан Журналистлар союзы идарәсе председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Х. Хамматов, шагыйрь Мөхәммәт Садри, ветеран-журналист Фазыл Мөбарәкшин, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин герой-шагыйрь турында сөйләделәр, истәлекләр белән уртаклаштылар.

Мемориаль тактага (авторлары — скульпторлар Г. А. Зябликов һәм А. К. Бәширов) рус һәм татар телләрендә «Бу бинада 1923 елда «Татарстан» газетасы редакциясендә Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлил эшләде» дип язылган, шагыйрьнең барельефы төшерелгән.

## Ф. КӘРИМНЕҢ ТУГАН ҖИРЕНДӘ

Башкортстанның Бишбүләк районы Аит авылында шагыйрьгә багышланган зур бәйрәм булды. Башкортстан Язучылар союзы оештырган бу бәйрәмгә Уфадан шагыйрьләр Рафаэль Сафин, Фәйзи Гомәров, Казаннан өлкән язучы Әмирхан Еники, шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев, Фатих Кәримнең кызы Ләлә Кәримова килгән иде.

Кунаклар башта шагыйрь музеенда булдылар, авыл белән таныштылар. Кичен авылның культура йортында тантаналы кичә булды. Кичәне КПССның Бишбүләк райкомы секретаре Ж. М. Хәйретдинов ачты. Шагыйрьне якыннан белгән күренекле язучы Әмирхан Еники һәм Илдар Юзеев, Рафаэль Сафин, Ләлә Кәримова, Фәйзи Гомәровларнең чыгышларын халык йотылып тыңлады.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ЯШЬ АВТОРЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ БҮЛЕГЕНДӘ

Казан дәүләт педагогия институты студенты Зиннур Хөснетдиновның ике повесте буенча индивидуаль семинар үткәрелде. Семинар җитәкчеләре Л. Ихсанова һәм С. Маннапов яшь авторга файдалы киңәшләр бирделәр, әсәрләрне кабат эшкәрткәч, матбугатка тәкъдим итеү мөмкинлеген әйттеләр.

Шулай ук бүлектә яшь автор Язилә Аб-

дулкадырова пьесалары тикшерелде. Семинарны язучылар А. Гыйләҗев һәм И. Юзеев алып барды.

Үзбәкстанда яшәүче автор Сафуан Муллагалиев шигырьләрен тикшерү булды. Аны тикшерүдә шагыйрьләр И. Юзеев, Р. Гәрәй, Р. Низамиев, Х. Әюпов катнаштылар. Сайлап алынган шигырьләр республика матбугатына тәкъдим итәрлек дип табылды.

Язучылар союзы каршындагы тәрҗемәчеләр секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда тәрҗемәче А. Бадюгина иҗаты тикшерелде. Ул күренекле язучы Ә. Еники хикәяләрен рус теленә тәрҗемә иткән.

Хикәяләрне тикшерүдә К. Миңлебаев, Э. Вагапов, Э. Нигъмәтуллин, М. Зарецкий, С. Шәмси, В. Бәширов, Р. Кожевникова катнаштылар.

Чыгышларда тәрҗемәләрнең югары сыйфатлы булуы, Ә. Еники иҗатына хас үзенчәлекләрнең саклануы билгеләп үтелде, тәрҗемәләрнең сыйфатын тагын да күтәрү җәһәтеннән А. Бадюгинага файдалы киңәшләр бирелде.

Чаллы шәһәрендә Әлмәт татар дәүләт драма театрының гастрольләре булды. Гастрольләр вакытында бирегә язучылар Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Р. Хәмид, Ф. Садриев килде. Алар яңа спектакльләр карадылар, театрның репертуары белән таныштылар. Театр коллективы белән берлектә бүгенге көн татар драма түгәрәге турында зур сөйләшү булды.

Соңыннан шушы ук язучылар Минзәләгә бардылар. Анда Минзәлә татар дәүләт драма театры коллективы белән очраштылар, бирдә сүз хәзерге драматургия алдында торган бурычлар, аның перспективалары һәм проблемалары хакында барды.

## ӘДӘБИ КИЧӘ

«Крутушка» санаториесендә күренекле язучы, Габдулла Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты Фатих Хөсни белән очрашу кичәсе үткәрелде. Язучы бүгенге татар совет әдәбиятының торышы, аның үсеш перспективалары, үзенең тормыш һәм иҗат юлы, киләчәккә планнары, партиянең XXVI съезды, СССР язучыларының VII съезды карарлары яктылыгында әдипләр алдында торган бурычлар турында сөйләде, әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә караган күп төрле сорауларга җавап бирде. Ф. Хөснинең ял вакытында иҗат иткән яңа хикәясе әдәбият сөючеләргә бик ошады. Алар әдипкә тирән рәхмәтләрен җиткерделәр, яңа иҗат уңышлары, сәламәтлек теләделәр. Бу хакта безгә педагогия фәннәре кандидаты Фәнис Исламов хәбәр итте.

## БАТЫРЛЫК ЭЗЕННӘН

1980 елның 23 июлендә Азнакай районының Октябрь-Булак авылы егете Альберт Шәйхетдинов хезмәт вазифаларын үтәгәндә һәлак булган иде.

Шагыйрь Нур Әхмәдиев батыр якташы һәм аның иптәшләре турында материал туплау максаты белән А. Шәйхетдинов хезмәт иткән частька барды. Ул офицерлар, матрослар алдында чыгыш ясады. Татарстанга һәм әдәбиятчылар эшчәнлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирде, үзенең шигырьләрен укыды.

БАССРның Салават районындагы «Янгантау» санаториесендә ял итүчеләр белән персональ очрашу булды. Очрашуда башкорт шагыйре Р. Сафин, М. Басыров, шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев катнаштылар. Алар үзләренең шигырьләрен укыдылар, хәзерге әдәбият турында сөйләделәр һәм ял итүчеләрнең күп сорауларына җавап бирделәр.

Мәхмүт Хөсәен — татар әдәбиятын актив пропагандалаучыларның берсе. Әдәбият сөючеләр һәм тамашачылар белән очрашуларда ул классикларыбызның, күренекле әдипләрнең һәм яшь авторларның иҗаты турында мавыктыргыч итеп сөйли, олы һәм яшь каләмдәшләренең шигъри үрнәкләре белән таныштыра.

Шагыйрь туган илебез буйлап күп йөри, чыгышлар ясый. Үткән ел ул мари шагыйре Гани Гадиатов белән бергә Мари республикасының Морки районында колхозчылар һәм мәктәп укучылары белән очрашты. Хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү буенча актив хезмәте өчен КПССның Морки район комитеты Мәхмүт Хөсәенне Почет грамотасы белән бүләкләде.

Үзбәк язучылары Самаретдин Сиражетдинов һәм Иркен Азаматов белән бергә М. Хөсәен Сәмәрканд каласының «Щетка» фабрикасында, Юлдаш Ахунбаев исемендәге Пионерлар сараенда һәм төзүчеләр институтында чыгыш ясады. Шулай ук татар үзешчәннәренең Сәмәркандта оешкан «Умырзая» исемле вокаль-инструменталь ансамбле членнары белән иҗади очрашу уздырды. Үзбәкстан Язучылар союзы М. Хөсәенне «Нәүрүз» исемле традицион яз бәйрәмендә катнашырга чакырды. Ул үзбәк халкының күренекле шагыйрьләре Котдус Мөхәммәди, Ильяс Мөслим, Сайяр, Гөлчирә Нуруллаева, Аман Мохтар һәм Кадыйр Каюмов белән Янаюл районының XXI партсъезд исемендәге колхозында, Ташкент медицина институтында, 128 нче ГПТУда үткәрелгән шигърь бәйрәмнәрендә катнашты. Ташкентның Белемнәр Йортында Мәхмүт Хөсәеннең иҗат кичәсе татар телендә үткәрелде.

Җамбул шәһәрендә уздырылган шигырь бәйрәмендә М. Хөсәен герой-шагыйрь Муса Җәлил иҗаты турында сөйләде, каһарман шагыйрьгә багышланган әсәрләр укыды. Үзенең туган якларында — Казагыстан далаларында кунак булганда М. Хөсәен казакъ акыны Бәхетгәрәй Исхаков һәм рус язучысы Василий Антонов белән Күкчәтау өлкәсенең илебезгә миллион потлап икмәк биргән Арык-Балык төбәгендә игенче җир батырлары белән очрашты. Колхоз һәм

совхоз эшчәннәре интернациональ рухта узган бу чыгышларны яратып тыңладылар, чирәм җир каһарманнарының фидакарь хезмәтен олылаган әдипләргә рәхмәт белдерделәр.

Язучы Мәгъсум Насыйбуллин һәм журналист Сәмигулла Хәйретдинов республикабызның Кукмара районында булып кайттылар. Алар КПССның XXVI съезды уңае беләп. Байлангар авылы Культура йортында һәм урта мәктәптә уздырылган әдәби кичәләрдә катнаштылар, колхозчылар һәм укучылар алдында чыгыш ясадылар, «Маяк» колхозы белән таныштылар.

Икенче көнне Кукмарада чыга торган «Хезмәт даны» газетасы редакциясендә, аның каршындагы әдәби берләшмәдә һәм музейда булдылар.

М. Насыйбуллин, моннан тыш, Казандагы 9 нчы урта мәктәп укучылары, вертолет берләшмәсе эшчеләре, Васильево санаториесендә ял итүчеләр белән дә очрашты, аларга лекцияләр укыды.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Кызу урак өстендә язучылар Разил Вәлиев, Эдуард Касыймов, Нәҗип Мадъяров, Газиз Кашапов Алабуга районы хезмәтчәннәре белән очраштылар, механизаторлар, печән җыючылар, сыер савучыларга бүгенге татар әдәбияты, үз әсәрләренең язылу тарихы, тормыш белән әдәбият арасындагы бердәмлек хакында сөйләделәр, шигырьләр укыдылар.

«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе члены Рахмай Хисмәтуллин, Рифкать Имаев, Раил Рахман Түбән Кама районы совхозларында шундый ук әдәби очрашулар үткәрделәр.

Моннан биш ел элек фаҗигага очрап, егерме яшендә урын өстенә яткан КХТИ студенты Михаил Гоголевның хикәяләре күпләргә таныш инде. Аның әсәрләре район матбугатында да, республика газеталарында да дөнья күрде.

Авыр хәлдә булуына да карамастан, М. Гоголев соңгы елларда берничә повесть, дистәләгән хикәя иҗат итте. Яшь язучының туган авылы Ижевкада (Алабуга районы) үткәрелгән семинар М. Гоголев иҗатына багышланган иде. Язучылар Эдуард Касыймов һәм Разил Вәлиев әлеге әсәрләргә җентекле анализ ясадылар, авторга киләчәк иҗаты өчен киңәшләр бирделәр. Яшь язучыга филологик белемен күтәрү кирәклеге әйтелде, иң яхшы әсәрләре матбугатка тәкъдим итү өчен сайлап алынды.

Семинарда КПССның Алабуга шәһәр комитеты секретаре Д. Г. Галләмова катнашты.

Инде өч ел рәттән Грузиядә Маяковский көннәре үткәрелеп килә. Маяковский ватанына быел төрле республикалардан 39 шагыйрь килгән иде. Алар Тбилиси, Кутаиси шәһәрләрендә әдәбият сөючеләр белән очраштылар. Грузиянең тарихи урыннары белән таныштылар.

таныштылар.

Евгений Евтушенко җитәкчелегендә узган быелгы Маяковский көннәрендә Татарстаннан шагыйрь Разил Вәлиев катнашты. Ул, төрле милләт шагыйрьләре белән бергә, бүгенге совет поэзиясе проблемаларына багышланган семинарда чыгыш ясады, Кутаиси автомобиль заводында, Маяковский һәйкәленә нигез салуга багышланган митингта һәм шагыйрьнең туган авылы Багдадида үз шигырьләрен укыды.

Р. Вәлиевнең чыгыш һәм шигырьләре Грузия газеталарында басылып чыкты.

Чаллы язучыларының эшчеләр тулай торакларында чыгыш ясаулары, әдәби кичәләр үткәрүләре инде күптән күркәм традициягә әйләнде. Июнь-июль айларында КамАЗ тулай торакларында узган шундый кичәләрдә Разил Вәлиев, Эдуард Касыймов, Газиз Кашапов, М. Сафин, Л. Можегов, А. Симонова, В. Паршин, В. Мартынов, Ю. Малков, А. Попов, Н. Цыганцев, Ю. Волостнов, А. Сычев, Р. Асылбаева катнаштылар.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Язучылар оешмасы җыелышында «Татнефть» берләшмәсенең генеральный директоры урынбасары Үзбәк Сатгаровның иҗат отчеты куелды һәм аны СССР Язучылар Союзы членлыгына тәкъдим итү мәсьәләсе каралды. Аның иҗаты турында Р. Төхфәтуллин, Э. Мөэминова, С. Кальметов, Вл. Мальцев, Г. Афзал, Ю. Әминов, Туфан Миңнуллин, Ә. Маликов һ. б. чыгыш сөйләде.

Ү. Саттаров әдәбиятта актив эшли, аның кечкенә күләмле йөздән артык хикәясе «Казан утлары» журналы битләрендә дөнья күрде. «Чаян» журналында да еш катнаша, дип билгеләп үттеләр чыгыш ясаучылар. «Алма биргәч ни дияргә?» исемле китабын укучы яратып кабул итте. Язучы хәзерге вакытта фәнни-популяр темага күләмле әсәр өстендә эшли.

Җыелыш бертавыштан Үзбәк Саттаровны СССР Язучылар Союзына член итеп тәкъдим итәргә дигән карар кабул итте.

Әлмәт татар дәүләт драма театры яшь драматург Фоат Садриевның өченче әсәрен — «Кондырлы кодачасы» исемле ике бүлектән торган трагикомедиясен сәхнәләштерде. Әсәр мораль темага, бүгенге көннең актуаль мәсьәләләренә багышланган. Спектакльдән соң фикер алышулар булды. Театр артистлары һәм язучылар Туфан Миңнуллин, Әдип Маликов, Үзбәк Саттаров спектакльнең уңышлы икәнен билгеләп, аны тагын да камилләштерү буенча киңәшләрен бирделәр.

## ИҖАТ ОТЧЕТЫ АЙЛЫГЫ

Июль аенда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татар дәүләт драма һәм комедия театры үзенең иҗат отчеты айлыгын үткәрде. Айлык Га-

риф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча куелган спектакль белән башланып китте.

Иҗат отчеты айлыгын ачу тантанасында Татарстан АССР культура министры урынбасары Ренат Харисов тамашачыларга һәм артистларга котлау сүзе белән мөрәҗәгать итте. Театрның баш режиссеры, ТАССРның атказанган культура эшлеклесе Равил Тумашев коллективның башкарган эшләре һәм иҗат планнары турында сөйләде.

Казанлылар һәм башкалабыз кунаклары театр артистлары башкаруында Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясе, Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев һ. б. ларның пьесалары буенча куелган спектакльләрне кызыксыну белән карадылар.

Иҗади отчет айлыгында театр коллективы соңгы елларда сәхнәгә куелган һәм яхшы дип табылган 12 спектакль күрсәтте. Жанрлары ягыннан төрле-төрле булган бу әсәрләр эшчеләр һәм колхозчыларыбызның, совет интеллигенциясенең тормышы турында сөйли. Заманыбыз кешесенең характерлы сыйфатлары, бүгенге көн проблемалары, коммунистик тәрбия мәсьәләләре, шәхес һәм җәмгыять, шәхес һәм коллектив мөнәсәбәтләре спектакльләрдә ачык чагылыш тапты.

## ГАСТРОЛЬЛӘР ҖӘЕ

Июль аенда Казан тамашачылары беренче тапкыр ике иҗади коллектив — Калининград өлкә драма театры һәм Караганда музыкаль драма театры спектакльләрен карадылар. Калининградлылар үзләренең гастрольләрен В. И. Качалов исемендәге театр бинасында А. Толстой пьесасы буенча РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе режиссер Э. Вайнштейн куйган «Патша Федор Иоаннович» спектакле белән башлап җибәрделәр. Караганда музыкаль драма театры Казанга И. Штраус, И. Кальман, Ф. Легар, О. Штраусның опереттaларын һәм совет композиторларының танылган әсәрләрен алып килде. Спектакльләр шәһәребез тамашачыларында җылы тәэсир калдырды.

## БҮТӘН ТЕЛЛӘРДӘ

Мәскәүнең «Художественная литература» нәшриятында шагыйрь Зәки Нуриның «Күңел яктысы» («Одаренность») дип аталган яңа шигырь җыентыгы басылып чыкты.

«Зәки Нури фронтовик татар шагыйрьләре арасында зерым урын алып тора»,— дип яза китапка кереш сүзендә Михаил Львов һәм үзенчәлекле татар шагыйренең иҗатын әдәбият сөючеләр яратып кабул итәр, дигән ышаныч белдерә.

Самат Шакирның «Үлемсезлек» исемле документаль повесте Башкортстан китап нәшриятында басылып чыкты. Әсәрдә фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән шагыйрь, полк командиры, полковник Хәйретдин Мөҗәйнең тормыш юлы хикәяләнә. Укучыларны шагыйрьнең иҗаты белән таныштыру максатында китапта Хәйретдин Мөҗәйнең берничә шигыре дә урнаштырылган.

## КАЗАН КУНАКЛАРЫ

Хәрби-патриотик темага иҗат итүче совет һәм поляк язучыларының Волгоград шәһәрендә уздырылган «Коралдаш туганлык — рухи туганлык» дигән симпозиумына бару юлында бер төркем әдипләр Казанда булдылар.

Польша халык республикасы сейммы депутаты, хәрби язучыларның Бөтенпольша советы җитәкчесе Война Жукровский һәм СССР Язучылар союзының хәрби-художество әдәбияты буенча комиссия председателе урынбасары Юрий Тарский иптәшләр җитәкчелегендәге делегациялэр членнары республикабыз язучылары белән очраштылар, Татарстан башкаласының истәлекле урыннарын карадылар.

Бу очрашуларда КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов һ. б. иптәшләр катнашты.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Минзәлә татар дәүләт драма театры директоры **Анатолий Степанович Богатыревка**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1981 ел, 5 август Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты һәм матбугатындагы хезмәтләре өчен шагыйрь **Рәшит Гәрәйгә**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткалары **Рахилә Хәйдәровна Мифтахова** һәм **Лариса Георгиевна Башкирова**, РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә, «РСФСРның атказанган артисткасы» дигән мактаулы исемгә лаек булдылар.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләрен искә алып, композитор **Бату Гатауллович Мулюковка**, РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, ТАССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә, Әлмәт татар дәүләт драма театры артисты **Зәкәрия Галимович Галимовка**, Казанның В. И. Качалов исемендәге рус Зур драма театры артисты **Евгений Николаевич Кара-Гяурга** «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

# ЯКТЫ КӨН

ФАСИЛ ӘХМӘТОВ музыкасы
ГАРИФ АХУНОВ шигырь




Якты көн,
Илһам бир миңа,
Көн буена житәрлек:
Уйларымны, хисләремне
Халыкныкы итәрлек!

Якты көн,
Сабыр бир миңа,
Ай буена житәрлек:
Шатлыгыма шашылмаслык,
Кайгымны юк итәрлек!

Якты көн,
Акыл бир миңа,
Көн буена житәрлек:
Айны узып, елны узып,
Гасырларга китәрлек!

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!**

Күргәнегезчә, бу санда зур күләмле ике проза әсәре басыла башлады. Журналның киләсе айда чыгачак 11 нче санында исә аларның ахыры биреләчәк. Болардан тыш Л. Хәйдәрованың шактый зур күләмле «Кырым хикәясе» булачак.

Шигъри әсәрләрдән Ф. Сафинның, Р. Гатауллинның, Г. Моратов һәм Р. Зәйдуллинның яңа шигырьләре басылачак.

Билгеле ки, журнал саннан-санга совет халкының унберенче бишьеллыкта башкарган героик хезмәтенә, шул өлкәдә дан алган батырларны тасвирлауга зур урын биреп килә. Алдагы айда бу темага багышланган ике язма тәкъдим ителәчәк: язучы С. Шакирның «Ил һәм халык рәхмәте», М. Әмирханов белән Р. Кильматовның «Яңа күпер» исемле очерклары.

11 нче санның әдәби тәнкыйть бүлегенә М. Вәлиевнең «Шагыйрь уты» исемле хезмәте урнаштырыла. Ул шагыйрь С. Хәкимнең декабрьдә билгеләнәчәк юбилеен каршылау йөзеннән бирелә. Н. Юзиевның «Уйлы туйра» исемле мәкаләсе шагыйрь Р. Харисның иҗат портретына штрихлар төсендә язылган.

Ноябрь аенда иҗаты барлык төрки әдәбиятлар үсешендә гомум әһәмияткә ия булган шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың тууына 150 ел тулу көне киң рәвештә билгеләнәчәк. М. Госмановның һәм Д. Гарифуллинның мәкаләләре шул датага багышланган.

11 нче санда «Китап күзәтү», «Кечкенә рецензияләр», «Безнең календарь», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» кебек даими рубрикаларга да шактый кызыклы материаллар тупланган.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210